# Казан утлары

3.1997





Галимжан ИБРАҺИМОВ
(1887—1938)

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИЖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**3**

**(893)**

**1997**

КАЗАН


## *Бу санда*


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Р. НИЗАМИ. Син әйттең... *Шигырь* ........ 3
З. ХӘКИМ. Гөнаһ. *Роман* ........ 4
Р. ФӘЙЗУЛЛИН. «Кыска поэмалар» циклыннан ........ 46
К. МИҢЛЕБАЕВ. Бакый. *Роман* ........ 52
Ф. МӨСЛИМОВА. Хатирәләр сүтелә... *Шигырьләр* ........ 95
Л. САБИРОВА. Көнләшү. *Хикәя* ........ 100

ОСТАХАНӘ

И. ЮЗИ. Хуш киләсез, кыр кызлары. ........ 103
ИЛГӨЛЕМ, ГӨЛНУР, Э. ҖӘЛИЛОВА, С. ЗАКИРОВА, Н. БАШУРИНА, Г. ЗАКИРОВА шигырьләре ........ 104

ПУБЛИЦИСТИКА

Ә. БОРҺАНОВ. Туган якның җиле татлы ........ 112

ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН

Ф. ХӨСНИ. Йөзек кашы. *Повесть* ........ 124

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Проза турында сөйләшү ........ 151

НУРМӨХӘММӘТ ХИСАМОВКА 60 ЯШЬ

Н. ХИСАМОВ. XIV йөз шигъриятендә кеше идеалы ........ 157

МӘГАРИФ

Татарстанның баш мөгаллиме (*Татарстан мәгариф министры В. Г. ГАЙФУЛЛИН белән әңгәмә*) ........ 172

КҮРЕНЕКЛЕ ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

М. ӘХМӘТҖАНОВ. Гасырлар капкасын ачканда ........ 180
Котлыйбыз! ........ 188

ӘЗ-МӘЗ МӘЗӘК

Т. НӘҖМИЕВ мәзәкләре ........ 189

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 191

*Баш мөхәррир*

**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**
**Нәҗип Бакиров**
**Хәлим Гайнуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Нажар Нәҗми**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Булат Солтанбәков**
**Камил Сәгадәт**
*(җаваплы сәркатип)*
**Ренат Харис**
**Розалина Шаһиева**
**Харрас Әюпов**

Безнен адрес: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 43-56-12,
бухгалтерия — 43-56-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар,
тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

# В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: начало романа З. ХАКИМА «Грех», продолжение романа К. МИННЕБАЕВА «Баки», рассказ Л. САБИРОВОЙ «Ревность»; стихи Р. ФАЙЗУЛЛИНА, Ф. МУСЛИМОВОЙ.
«Творчество молодых»: стихи ИЛЬГЮЛЕМ, ГУЛЬНУР, Э. ЗАЛИЛОВОЙ, С. ЗАКИРОВОЙ, Н. БАШУРИНОЙ, Г. ЗАКИРОВОЙ.
«Публицистика»: статья А. БУРГАНОВА «Нежный ветер родного края».
«Из сокровищницы татарских рассказов»: повесть Ф. ХУСНИ «Перстень».
«Литературная критика»: разговор о современной прозе.
«К 60-летию Н. Хисамова»: статья Н. ХИСАМОВА «Идеал человека в поэзии XIV века».
«Просвещение»: беседа с министром просвещения Татарстана В. Г. Гайфуллиным.
«Выдающиеся личности»: статья М. АХМЕТЗЯНОВА посвящена к 60-летию ученого Р. Фахрутдинова.
Забавные истории Т. НАЗМИЕВА.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «В предгорьях Урала» — фоторепродукция из картины Б. Урманче; известная писательница Набира Гиматдинова.

● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.

● Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Тәүфикъ Әйди.**
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.

Производствога бирелде 31.01.97 ел. Басарга кул куелды 28.02.97 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 12 384. Заказ Н-34.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1997 ел.

# ШИГЪРИЯТ

## Рашат Низами

### Син әйттең...

«Кояшым!» — дип син эндәштең миңа...
Үз-үземнән торам оялып.
Дөнья чаклы шундый олы сүзне
Ничек уйлап тапты хыялың?

Син барында — ничек инде мине
Кояш белән мөмкин тиңләргә?
Ай шикелле салкын планета мин,
Серле язмыш минем иңнәрдә.

Үз-үземнән сорау алам бүген,
Һәм орышам мәҗнүн-егетне,—
Ничек итеп ычкындырдым икән
Сүз әйтүдә беренчелекне?

Эзләп табып синең күзләреңне
Миллионлы шушы шәһәрдә,
«Кояшым!» — дип, иң беренче булып,
Мин тиешле идем дәшәргә!

Шулай балкый алыр идеммени —
Син нурыңны сирпеп тормасаң.
Бары синең, синең нурланыштан
Мин яктырам, мине моң баса.

«Кояшым!» — дип мине газаплама,
Мин Ай булып барыбер калырмын.
Чиләк-көянтәле Зөһрә итеп
Үз яныма тартып алырмын.

Мең йолдызлы Галәм сукмагыннан
Барасы да безгә барасы...
Нинди якын
һәм нинди дә ерак
Кояш белән Айның арасы!

# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



## Зөлфәт Хәким

# ГӨНАҺ

РОМАН

### Беренче кисәк

### 1

Фәиз, караватын шыгырдатып, торып утырды һәм, дөм караңгы тышта нәрсә булса да абайларга ниятләп, тәрәзәдән карады. Төннең караңгылыгын җиңәрлек түгел, ә битарафлыгы исә кичеп чыккысыз иде. Нинди караңгылык бу?! Ничек күтәрә икән хәят мондый зольмәтне?! Чиге дә юк, азагы да...

Йокы аралаш хатыны ыңгырашып куйды:

— Ник йокламыйсың?

— Йоклап булмый.

Нәркизә чандыр гәүдәсен авырлык белән калкытты һәм алар, тәрәзәдән тышка карап, селкенми дә шактый вакыт утырдылар.

Хатын түзмәде:

— Фәиз, әйдә, бер генә тапкыр булса да ачыктан-ачык сөйләшик әле.

Ире дәшмәде. Аның өрәк сыман берсүзсез утыруына ачуы килеп, Нәркизә үзе дә сизмәстән тавышын күтәрде:

— Инде өч ел бергә яшибез... Мин белә-белгәннән бирле шушындый бит син... Нишләп мондый син? Нәрсә «ашый» сине?

Фәиз кинәт эчке сискәнү тойды. Уйлары газаплы булуга карамастан, хәсрәтләнеп утырганда комачауласалар шулай ук бик читен икән. Күрәсең, ул инде күңел газабыннан башка яши алмыйдыр. Хәсрәтләнү кирәк аңа. Подсознаниенең кайсыдыр бер ерак почмагында газапны саклый торган каршы тору көчләре хөкем сөрә. Караңгы уйларының чыганагы булган күптәнге хәсрәтне аның беркемгә дә «бирәсе» килми, ул аныкы, фәкать аныкы, ул аны курчак кебек назлый, ярата, уйный. Шул хәсрәт белән бергә-бер калып кичергән халәт вөҗүденең кайсыдыр өлешенә

---

Зөлфәт ХӘКИМ (1960) — *прозаик, шагыйрь, драматург, эстрада җырларының автор-башкаручысы. Казанда яши.*

ләззәт бирә, җан сызлап, түзүләрнең ахыр чигенә якынлашкан сурәттә дә караңгы халәтне күңелдә иркәләп тибрәтү ихтыяҗы бетми.

Нәркизә, җавап ишетү нияте белән, янәшә утыручы шәүләгә текәлде.

— Син нәрсә инде...— дип мыгырдады Фәиз, хатынының битен караңгыда күрергә тырышып.

Фәизгә хатынының битен күрү гаять әһәмиятле: Нәркизәнең шулай төн уртасында бәйләнә башлавы караңгыда аның битен күреп булмавы белән икеләтә катлаулы һәм куркыныч иде. Кеше белән сөйләшкәндә әңгәмәдәшеңнең күзләрен, бит җепселләренең кыймылдавын, чыраеның үзгәрүен күзәтеп, сөйләшүне әллә ничекләр боргалап, алдап, «адаштырып» була. Сөйләшкәндә, кешенең йөзен аермачык күргәндә, кирәк чакта үзеңне яклау-саклау вазифасын үти торган психологик «кабык» белән чорнау мөмкин. Күңел төпкелендәге теге «курчакны» бирмәскә дә бик җайлы. Әчеңдәгеен сакларга караңгыда гаять авыр. Күрергә иде Нәркизәнең күзләрен, күреп ул аны, гадәттәгечә, теләсә ни сөйләшеп, бутап, алҗытып үзен бер үк сораулар белән бимазалаттырмас иде. Ә бәлки әле бөтән аптыратмас. Әллә кочаклап бераз иркәләргәме үзен... Бәлки наз кирәк булганга гына төпчеләдер... Газаплы уйлардан арына башлауга җанында тагын ниндидер көчләр калыкты һәм кан тамырлары тартылып, бугаз тирәсендә авырту тоелды, пульс тагын ешайды, авыз корыды — өянәге бигүк ерак йөрми иде, ахрысы.

Юк, Нәркизә әле һаман җавап көтә, инде күптән тынгы бирмәгән бер сорауны аңлату, чишелеш кирәк иде аңа.

— Ниндидер бетмәс кайгың бар синең,— диде ул ачынып.

Фәиз тагын тышка карады. Шул төнсез караңгылыкка төшеп китәсе килде аның. Бу тынчу өйдән, шикләнеп һәм төпченеп утыручы, шыр сөякле хатыныннан кинәт качасы килде. Шушы дөм караңгы чиксезлекнең берәр тарафына гаип буласы иде. Ләкин йөгереп тә, очып та китәрлек түгел — хәсрәт йөге авыр, аның белән ерак китеп булмый. Үзеңнән китеп булмый. Үз-үзеңнән качу мөмкин түгел.

Нәркизә соравын кабатларга җөрьәт итте:

— Нинди кайгың бар соң синең? Ник әйтмисең?

— Юк сүз сөйләмәсәнә! — Хатынының мондый әңгәмә корырга маташуыннан Фәиз тәмам пошаманга калды.— Йокла.

Җан сызлавына куәт өстәп, Нәркизә ямьсез итеп елап җибәрде:

— Кыяфәтеңә кара... Ябыгып, каралып беттең бит инде. Бала юклыктан гына түгел бу... Ниндидер авыррак хәсрәтең бар синең...

— Йокла, йокла,— дип әйтүдән башкасын булдыра алмады Фәиз.

Нәркизә, йоклау түгел, хәтта елавыннан да туктарга уйламады.

— Фәиз, ник сөйләшмисең? — диде ул сулкылдап.— Ниләр уйлыйсың, нигә кинәт-кинәт сәерләнеп китәсең?

— Шундый кеше инде мин,— дип ыңгырашты Фәиз.— Йокла.

Юкка-барга кызмый, сабырлыгын бик сирәк очракларда җуя торган хатын, көтмәгәндә, үзенә хас булмаган җан биздергеч юантык тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Йокламыйм! — Үзенең тавышына үзе дә хәйран калып бермәл тынып торды.— Нәрсә борчый, әйт! Кешеләрдән дә яхшы түгел, әллә ниләр уйлыйлардыр инде.

«Кеше ни уйлый?», «Кеше ни әйтер?» кебек сораулар безне һәрвакыт куркытып, бимазалап тора. Башкалардан хөкем көткән кебек, кеше үзе турында ни уйлауларын белергә тырышып яши. Әйләнә-тирәдәгеләр аны теге яки бу адымнары өчен әрлиләрдер шикелле тоела, болай карап торуга туры күренгән юлдан барса да, кемгәдер нәрсәдер ошамагандыр, кайдадыр кемдер битәрлидер кебек. Нәрсәдән бу? Үзеңнең пакь түгеллегеңне аңлауданмы? Гөнаһлы икәнеңне белүдәнме? Яман эш кылган кеше башкаларның үзе турында ни уйлауларын һәм дә күңелләреннән аны хөкем итүләрен сизә — бу халәт авыр җәзага тиң, һәм берәдә гайре табигый күренеш юк та шикелле. Җинаять кылмаган, «дөрес» яшәүче

кешене аның турында башкаларның нәрсә уйлавы ник борчый соң? Гадел кеше дә аның теге яки бу эшен, адымын, теләкләрен күршеләр, танышлар, дуслар һ. б. ничек кабул итәрләр дип борчыла. Кешенең хөкем итүенә битараф булалмый беркем дә. Үзеңдә гөнаһ сизүдән түгелме икән бу?.. Үзеңнең хаклыгыңа шикләнү — чисталыгыңда икеләнү түгелмени?! Икеләнү, шөбһәләнү, кешеләрнең бәяләвенә зур ригая һәм әһәмият бирү — болар барысы да һәркемгә үзен белә-белгәннән бирле хас. Димәк, үзен гөнаһлы тоюга кеше нарасыйлыктан ук, тумыштан ук дучар ителгән.

Кеше фикере куркыта! Кеше хөкеме, сүз белән әйтелмәсә дә, коточкыч! Әмма ләкин кемдер синең хакта хөкемле уйлар белән йөри икән — бу исә фәкать синең кичерешләреңнең проекциясе генә. Аның фикерләве турында син уйламасаң, аның хөкемләве юкка чыга. Үзеңне гөнаһлы сизеп, кеше хөкемен тану — үзеңне хөкем итү. Ничек кенә булмасын, үзең турында башкалардан ишетәсе, үзең хакында башка берәүнең күзләреннән укып беләсе килә. Бу күренешнең үзеңне хөкем итеп җәзалауның бер алымы икәнлеге турында, никтер, уйламыйсың, чөнки ни дисәң дә... Кеше барыбер синең турыда уйлый, бәяли, йә мактый, йә киресенчә әрли һәм кайвакыт каргый. Бу күренешнең табигате кызыксындырмый, аң өчен анык булган төшенчәләр генә хәрәкәт итә: гөнаһ тою, аңа тәңгәл бәя эзләү һәм нәтиҗә буларак — җанда кайгы асрау.

«Кеше әллә ни уйлый», дип... Бернишләп булмый, уйлыйлардыр инде...

Фәиз хатынын кочаклап яткырды:

— Булды, булды. Йә, тынычлан.

Ирнең ягымлылыгы хатын-кызга ничек тәэсир итәргә тиеш булса — Нәркизәгә нәкъ шулай тәэсир итте. Иренә елышып, беркавым сулкылдап ятканнан соң ул, иркәләнеп:

— Мине дә яратмыйсың син! — дип әйтеп куйды.

— Йокла, йокла.

Хатынының көйсезләнүе түгел, уйларыннан арынып торырга мәҗбүр булу Фәизнең эчен пошырды. Янәшәсендә болай да ярсыган күңелне җилтерәтеп утыручы кеше булуы чыгырдан чыгарды.

— Яратмыйсың син мине, — дип кабатлады Нәркизә балалар кебек киреләнеп.

Шулчак Фәиз түземлеген тәмам җуйды.

— Җиттеме сиңа! — дип җикерде ул һәм, сикереп торып, өй буйлап арлы-бирле йөренә башлады.

Нәркизә юрган астына качып елавын дәвам итте, ләкин бәгырьне тырный торган тавышны юрган гына каплап томаларлык түгел иде — Фәиз сүгенә-сүгенә ишегалдына чыгып китте.

Айсыз-йолдызсыз төн уртасында тәмәке уты бердәнбер яктылык кебек тоелды. Ул нигез буендагы бүрәнәне капшап утырды.

Янгыр килә, ахрысы. Дөнья томаланган. Күңелдә дә давыл бит... Ничәмә еллар бу кайгымны берүзем күтәреп йөрим. Инде ачарга вакыттыр бит. Тукта, нигә әле мин аны якты дөньяга чыгарып селкергә тиеш? Алай сөйләрлек сер булгач, нишләп моңарчы дәшми йөрдем? «Аны» күпме гомерләр җанымда асрау ник кирәк булган алайса?.. Юк, юк, элегрәк сөйләп булмый иде... Ә хәзер буламы?.. Күңелгә бәлки җиңеллек килер иде... Болай яшәве бик куркыныч бит. Бәлки сөйләгәч, алай ук куркытмас. Борчуларымны үз күңелемдә генә биклəп асрауның авырлыгын инде беләм, ә уртаклашкач ничек буласын белмим ләбаса. Шулай булгач... Бәлки җиңеллек килер... Кайгыны уртаклашсаң җиңелрәк, диләр бугай. Нәркизә дә нык төпченә башлады. Туктале, Нәркизәгә ачылырга ярыймы соң?.. Ә кемгә сөйлисең тагы?! Кемем бар соң минем? Нәркизә белән дә уртаклашмагач инде... Ничек кабул итәр икән ул аны? Ни әйтер икән? Менә бит! Тагын «ни әйтер икән...», тагын кеше уе, кеше фикере куркыта...

Кеше хөкеме куркыта шул! Тукта әле, кеше хөкеменә лаек түгелмени соң мин?! Үземә тиешле җәзаны кайчандыр алырга тиештермен ләбаса. Алай дисәң, үз-үземне «ашап» кайчаннан бирле җан газабы кичерүем җитмәгәнмени?! Бәлки шул җәза житкәндер һәм аны туктатыр өчен кайгыны уртаклашу мәслихәттер. Бу теләк бит инде бүген генә тумады, ул теләк тикмәгә генә барлыкка килмәгән ләбаса. Ә бәлки хәсрәтемне сөйләргә ашкынуым катырак җәза алу ниятеннәндер?.. Моңа кадәр булган халәтем таныш, мин инде киләчәктә дә бу хәлдә яши алмаячакмын, нииндидер үзгәреш зарур. Сөйлим бүген, ачылам. Ни әйтер икән?.. Хәер, ни әйтсен инде. Шулай да, ничек башларга соң бу кара хикәяне, аны сөйләп бетерү мөмкинме соң, ул хикәя мәңгелеккә сузылмасмы???

Дымлы җил кинәт биткә килеп бәрелде. Һаванын бөркүлеген юк итәргә теләгәндәй, давыллы яңгыр килә, коеп явып китсә — җиңеләю булачак. Сулышны кысып торган тынчулыкны, һаваларны шартлатып ярып, давыллатып-бөтереп, таркатып кына була. Бу — бердәнбер чара. Табигатьнең бер бушанып, җиңеләеп китүе бу.

Фәизнең күңеле дә бушану сорады. Күңеленең ерак бер почмагында үзе төзеп куйган тынчу зинданның ишекләрен шар ачып, аның һәр аулак култыгына, һәр ярыгына давыл тутырып уйнатып, яшәү өчен шифалы һәм сихәтле бер сулыш алу кирәк иде.

Фәиз катгый карарга килде, әмма әле шул ук вакытта бу ниятенә нииндидер көч каршы тора, гүя теге ямьсез кара «курчакны» югалтудан Фәизнең кайсыдыр «өлеше» хайваннарча курка иде. Ләкин аяклар инде өйгә атлады, йөрәк бугаз тирәсенә менеп дөпелди башлады. Хәзер нәрсәдер булырга тиеш иде. Күктә дә, Фәизнең җанында да. Ул өйгә кергәндә тышта инде ишелеп яңгыр коя башлаган иде.

Ул утны кабызып өстәл янына утырды.

— Нәркизә, тор!

Юешләнеп беткән битен җыерып, күзләрен утка чекерәйтеп, хатын аптырап калды.

— Ник?

— Сөйләр сүзем бар.

— Әйдә, ят инде,— диде Нәркизә нииндидер куркыныч якынлашуын сизеп. Ә үзе барыбер торып өстәл янына килде һәм хәтеренең чатырына кереп барган, үткәннәргә сәяхәтен башларга батырчылык иткән иренең каршысына килеп утырды.

— Чынлап та, сиңа сөйләр сүзем бар,— диде Фәиз һәм авыр, тирән итеп сулап куйды.

Гүя сөйлисе хикәясен ерып чыгасына шикләнә иде.

## 2

Фәиз белән Зәбирне балалар йортына бер үк көнне китерделәр.

Фәизнең әтисе гаиләсен ташлап юкка чыккан иде. Бер ел узгач әнисе сукыр эчәгесенә операция ясатканда үлеп китте. Шулай итеп, ике яшьлек малай карт әбисе кулында калды. Малайның ун яше тулганда, әби яткан урыныннан тормас була һәм күп тә үтми дөнья куя. Фәизне ятимнәр йортына алып китәләр, чөнки якын тирәдә туган-тумачалары табылмый.

Зәбирнең язмышы тагын да ачырак һәм фаҗигалерәк башлана. Әтисе, холыксыз эчкече, хатынын кыйнап үтерә һәм ундүрт елга ирегеннән мәхрүм ителә. Үзләренең шәһәрендә туган-тумачалары булса да, Зәбирне асрамага алырга берсе дә батырчылык итми. Әтисеннән куркалар — төрмәдән чыккач аның алдында малай өчен җавап бирү җиңел булмас, нигә минем улым болай түгел, ник тегеләй түгел дип теңкәгә тиюеннән шүрлиләр. Кыскасы, Зәбир дә ун яшендә детдом баласы була.

Икесе дә 1960 елны бер үк шәһәрдә туганнар, ятимнәр. Ягъни шук, тиктормас бу ике малайның уртаклыклары, охшашлыклары шактый иде. Алар беренче көннән үк бер-берсенә ныкияләштеләр. Алга таба тәрбиячеләр дә, башка балалар да аларның туганнарча татулыкларына сокланып туймадылар.

Караватлары янәшә, икесенә бер тумбочка булды. Алар бер класста, бер партада утырып укыдылар. Тапкан ризыкны, кулга төшкән малны һәрвакыт урталай бүлделәр. Бала-чага арасындагы котылгысыз ызгышсугышларда, берсен-берсе яклап, кыерсытучыларга каршы җаннарын фида кылырдай булып еш кына сугышырга туры килә иде.

Тәкъдирнең рәхимсезлегенә рәнҗеп ямансулаган вакытларда ике ятим бер-берсенә тугры булырга һәм ташлашмаска ничәмә тапкыр антлар бирделәр.

Еллар үтә торды. Вакыт ул бәхетсезне дә, бәхетлене дә санга сукмый. Аның өчен язмыш та, хәтта кеше үзе дә юк. Шушы ике ятим, дәүләтнең бер салкын-кысан бинасында, ахири дуслар булып үстеләр. Балалык, үзенекен итеп, киләчәктә якты хәят барлыгына инандырды, яшь йөрәкләр, офыкларга карап, түземсезлек белән киләчәкне көтте, күңелләр алдагы шау чәчәккә баткан гөлбакчаны күрергә зур өметләр баглап җилкенделәр, ашыктылар, ярсыдылар.

Гомер уза бирде. Тик менә Фәиз генә дустыннан бераз «калышты» — гәүдәгә дә, тазалыкка да, төскә-биткә дә. Зәбир кап-кара кашлы, коңгырт күзле, куе бөдрә чәчле егеткә әйләнгәндә, Фәиз чандыр буйлы, дустыннан бер башка тәбәнәгрәк, саргылт чәчле, кысык күзле яшүсмер булып кала бирде. Зәбир детдомда, мәктәптә, компанияләрдә, танцыларда — һәркайда абруйлы һәм игътибар үзәгендә булды. Иң нык көнләштерә торганы шул иде — кызлар гел Зәбиргә гашыйк булдылар. Дөрес, Фәиздә моңлану, хискә бирелү, китап ярату, матур итеп җырлау кебек сыйфатлар бар һәм мәктәптә дә ул Зәбиргә караганда яхшырак укый иде. Әмма, кызганычка каршы, үсмер чакта яхшы уку һәм хиссият колы булу егетлек саналмый. Ул вакытта абруйлыкны башка төрле сыйфатлар билгели һәм хәл итә.

Оста, көчле, чибәр дусты белән сокланып, аның белән горурланса да, шул ук вакытта Фәизнең күңелендә көнләшү, ачу килү, кайвакыт хәтта нәфрәтләнү (бигрәк тә кызлар мәсьәләсендә) кебек каршылыклы хисләр дә юк түгел иде. Ләкин җанны бимазалаучы ул хисләр ничек барлыкка килсәләр, шулай ук тиз арада юкка да чыга торган булдылар.

Гомерләренең әле алда булуы, яшьлек, дуслык һәм детдомнарда гына туа торган туганлык — болар барысы да көнләшүләрдән, кимсенүләрдән һәм башка ваклыклардан һәрвакыт көчлерәк, өстенрәк булып чыга иде.

Инсаннар арасындагы тигезсезлекнең һәм гаделсезлекнең мәгънәсенә элек-электән төшенергә тырышканнар, әмма аның сәбәбен әле беркемнең дә тапканы юк. Җан ияләре арасында тигезлеккә ирешүгә хәтта дин дә ярдәм итә алмады, философларның чәчләре агарып бетте, ләкин барыбер кемдер көчле, кемдер көчсез булып кала бирде. Шагыйрьләр, рәссамнар, матурлыкка мәдхияләр язып гүзәллеккә табындылар, әмма барыбер кемдер матур, ә кемдер ямьсез булып калды. Табиблар күселәрнең баш миенә операция ясарга өйрәнделәр, тик менә һаман да кемдер сәламәт, кемдер гарип булып туа торды.

Үзен башкалардан ким-хур итеп тою күпләргә хас. Бу — үзен көчсез, булдыксыз итеп сизү галәмәте. Андый кеше курка. Аның бу халәтен кимчелекләр комплексы дип атыйлар, бу халәттән неврозлар һәм психик авырулар ерак йөрми.

Нәрсә соң бу?

Үзеңне кимсетеп хис итү дә үзеңне гөнаһлы тоюдан микән әллә?..

Әгәр синдә җитешмәгән сыйфатлар бар икән, бу гөнаһлы булудан түгелмени?! Гөнаһлы булганга табигать тарафыннан кимсетелә түгелме кеше? Әгәр ул тумыштан ямьсез яки гарип икән — ата-ана, әби-баба

гөнаһларыннан түгел микән? Ямьсез кеше булмый, дияргә тырышалар, әмма ләкин барыбер матур кешеләрне яраталар, чибәрләргә йөрәкләре белән якынаерга омтыла һәммәсе дә. Матур әйбергә кулын суза кеше, гүзәллеккә тартыла барысы да. Кеше тәскә-биткә ямьсез икән, монысы да тикмәгә түгелдер, бу да кемнеңдер ниндидер гөнаһы өчендер...

Нигә, ни өчен менә бу кешегә чибәрлек бирелмәгән? Ә тегеңә бирелгән? Бу кеше ни өчен тегеннән аерылып тора? Нишләп тегене яраталар, нишләп бу — игътибарга туймый? Ким-хур булу — гөнаһлы булудан һәм әле шунысы һич кенә дә билгеле түгел — кешегә җибәрелгән җәза шул гынамы, әллә гомер агышында аны яңа сынаулар, кыйналулар, фаҗигаләр көтәме? Тагын нинди җәзалар көтә кешене?

## 3

Әле моңарчы балалар йортындагы тормышын Фәизнең беркайчан беркемгә сөйләгәне юк иде. Ятимлекнең ни икәнен аңлаганга, иренең ачы язмышын актарып җан җәрәхәтенә кагылмас өчен, Нәркизәнең беренче булып детдом турында сүз башлаганы булмады.

Сөйләүдән туктап, Фәиз бик озак бер ноктага текәлеп утырды. Хатыны да ашыктырырга җөрьәт итмәде.

— Чәй куй әле,— диде Фәиз беркавым утыргач.— Аннары дәвам итәрмен.

...Караңгы, юеш булса да, тышта һава барыбер рәхәтрәк иде. Кыска вакыт эчендә дулап алган давыллы яңгыр инде күптән еракта җәнҗаллана иде. Бүрәнәгә урнашып, ул тагын уйга батты.

Бер тапкыр, шәһәр паркына танцыга баргач, шунда буталып йөрүче исерек малайлар Фәизгә бәйләнгәннәр иде — юаш кешегә эләгә инде яшь вакытта. Дустын яклап, Зәбир бик каты сугышты. Шунда Фәиз аның җитезлегенә һәм җегәрлегенә тагын бер кат таң калды.

Ә бер тапкыр... Алар икесе дә бер үк кызга гашыйк булдылар. Кыз, әлбәттә, Зәбирне сайлады. Нык рәнҗеде Фәиз, нык көнләште. Хәтта башында коточкыч уйлар да уйнаклады. Әмма дустын үпкәләткәнгә үкенеп һәм аны югалтудан куркып, Зәбир кызны икенче көнне үк ташлады.

Төрле чаклар булды. Детдом балалары арасындагы мөнәсәбәтләр шактый кырыс һәм кайвакыт рәхимсез дә була иде. Тәрбиячеләр күз-колак булып житалмыйлар, өстәвенә, малай-шалай арасында үзләре уйлап чыгарган блатной кануннар бар иде. Шуңа күрә анда көчле аркадаш бик кирәк һәм Фәиз өчен Зәбир шикелле ышанычлы җан дусты барлыгы зур бәхет иде. Әйе, төрле вакытлар булды. Ике дусның үзара чәкәләшкән чаклары да булмый калмады. Әмма ләкин Зәбир, көчлерәк булганга, дустына бигүк каты сукмый — моны Фәиз үзе дә сизә иде.

Ләкин ни генә булмасын, алар арасындагы ирләрчә туганлыкны бернәрсә һәм беркем җимерерлек түгел иде. Үпкәләшүләр, сугышулар минуты белән онытылып, юкка чыгып, алар янә бергә вә тагын дуслар булалар иде. Ятимлек, уртак фаҗигагә әйләнеп, күңелләрендә сөйләп аңлатмаслык сагышка әверелеп яшәде. Тәкъдирнең рәхимсезлегендә беркемне гаепләмәсәләр дә, дөресрәге, кемне (яки нәрсәне) гаепләргә белмәсәләр дә, барыбер дөньяга ниндидер үпкәләре бар иде. Кешелек хәятен тәгаен үз итеп бетермәү, тирә-яктагы тормыш-көнкүрешне чит-ят күрү, аларны бер-берсенә тагын да ныграк якынайтты, бер-беренең моң-зарларын, күңел халәтләрен аныграк аңларга мөмкинлек бирде...

— Чәй кайнады инде.

Фәиз сискәнеп китте. Нәркизә тагын аны уйларыннан арындырды. Фәизнең кабат җен ачулары кабарды, хатынына карата күңелендә яңадан нәфрәт уянды. Соңгы вакытта еш кына хатынын күралмый башлавы да

бимазалады аны, ләкин шул ук вакытта ул аңа чиксез рәхмәтле һәм бурычлы иде. Хатыныннан тәмам туйган чакларда ул үзен ялгыз итеп күз алдына китереп карый, ләкин Нәркизәдән башка харап булачагын акылы белән аңлап, эчендәге ямьсез хисләрен куарга тырыша.

Инде күптән сүнгән тәмәкесен ташлап таптады, тагын бер тапкыр төнге һаваны тирән итеп сулады да өйгә кереп китте.

Чәйне бер йотып куйгач, ул хатынына сынаулы караш ташлады.

— Бер ярты чыгар инде. Чәй генә хәл кертмәс.

Нәркизәнең кыяфәтенә тагын еламсырау йөгерде.

— Эчмә инде, Фәиз! Аннары тагын чирлисең.

— Юк, юк, ярты стакан гына кабам да...

Нәркизә, борын астыннан мыгырдап, кече бүлмәгә чыкты, шүрлектән бер шешә аракы алды. Стаканга яртылаш итеп салгач, олы якка алып чыгып ире алдына куйды. Фәиз үзе генә аңлый торган бер өмет белән стаканга төбәлде. Эчмичә генә, шул стаканга карап утыру гына да аның хәлен күпмедер дәрәҗәдә җиңеләйтер иде, ахрысы. Нәркизә өчен аның тагын аракы эчәргә маташуы аерым бер кайгы булса да, моңарчы ишетелмәгән, ләкин ишетелергә тиешле серле бер вакыйгага якынлашу теләге өстенлек алды. Зур табышмак чишелер шикелле һәм гаиләдәге хәяттә, шәхси тормышта озакка сузылган бәхетсезлеккә чик куелыр сыман иде. Гүя уртак тормыш караңгылыгында бер генә сәбәп бар иде — Фәиз күңелендәге нинди дер каты төеннең һаман чишелмәве.

Фәиз аракыны ике тапкыр голт итүдә эчеп бетерде, аннары газаплы кыяфәт белән чыраен сытып ипи капты. Эчкәннән соң битенең җыерылуы, күзләрен йомып, тиз генә ипи кабуы хәмернең ачылыгыннан түгел, бары тик гадәт буенча, аракыны беренче тапкыр капкалаган чаклардан калган бер гореф кебек кенә кыланыла иде. Хәзер инде ул аракы ачысына тәмам күнеккән, ярты стакан аракыны күзләрен шар ачып, эһ тә итмичә эчәргә сәләтле. Аннары шунысы да бар: хатын карап утырганда, бигрәк тә эчкән өчен битәрләгәндә чырайга бераз газап төсе чыгару мәслихәт. Аракы эчүнең татлы әйбер ашау түгеллеген хатынга тагын бер кат күрсәтү һәм үзеңне аз гына булса да акларга тырышудан бу. Имеш, аракы эчү дә алай бигүк җиңел түгел.

Хәмер күкрәкне җиңелчә генә өтеп алгач, Фәиз хатынына бик озак карап торды. Гүя күз карашы белән бу «начар» гына хатынының ышанычлымы-юкмы икәнлеген сынады, үзенә карата аның хәзерге мөнәсәбәтен һәм хикәяне сөйләгәннән соң булачак мөгамәләне күрергә, төшенергә, аңларга тырышты. Юк, Нәркизә никтер ят иде аңа, хәер, ул үзе хатынына ят иде. Хатынын чит-ят иткәнгә күрә, хатыны да аны ят итәдер кебек тоела иде. Ләкин моны Фәиз акылы белән аңламады. Кеше психологиясендә үзеңнең кайбер сыйфатларыңны, уй-кичерешләреңне башкаларга проекцияләп, аларда үзеңнең сыйфатларыңны күрергә тырышу һәм күрү таныш күренеш.

Фәиз, үзе дә сизмәстән, күзләрен челт-челт йомып утыручы хатынына:

— Нәрсә? — диде.

Иренең бу мәгънәсез соравыннан бераз каушаса да, аракы тәэсиреннән аның битләре алсуланып китеп, күзләренә яшәү төсе кайтуын күргәч, Нәркизә, тынычланып, көтеп утыруында булды.

— Син мине күралмыйсыңдыр? — диде Фәиз, көтмәгәндә.

— Әй, теләсә ни сөйләшеп утырма инде. Нишләп мин үз иремне күралмаска тиеш ди?!

Фәиз авызын кыйшайтып көлемсерәде.

— Болай гына әйтәм инде.

— Болай да, тегеләй дә әйтмә андый сүзне, — диде Нәркизә кырыс булырга тырышып.

— Ярар, әйтмәм.

Нәркизә түзмәде:

— Йә, сөйлисеңме?
— Ашыктырма.

## 4

Мәктәпне тәмамлагач, аларны эшкә бер заводка, бер үк цехка урнаштырдылар. Слесарьлар бригадасында тимер-томыр игәүләп, егетләр коммунизм төзүгә өлеш кертә башладылар. Бригада мастеры — гомер буе план өчен «янган» карт коммунист — детдом «җимешләрен» бик күңелсез кабул итте һәм аларны баштан ук өнәмәде. Акчалы эшләрне, төшемле заказларны, гадәттәгечә, өлкәнрәк яшьтәге оста эшчеләргә бирде, ә Фәиз белән Зәбир вак-төяк йомыш башкарып каңгырап йөрделәр. Өстәвенә, егетләр шук һәм тәртип бозарга да күп сорамыйлар иде. Алар тарафыннан чак кына уңга-сулга тайпылу күренсә, цех коллективы, совет халкына хас булган күмәк хөкемләү белән, ике ятимне: шпана, уголовник балалары, уйнаштан туган нәрсәләр дип битәрләде, бу ике маңкадан цех котылырга тиеш дигән таләп куйды. Югыйсә, егетләрнең шуклыгы — балалыкның фәкать актык мәртәбә чагылып калырга омтылу галәмәте генә иде. Аннары, яңа тормышка аяк басып, әле детдомнан соң башка төрле мохиткә ияләнеп җитә алмау да үзенекен итте. Асылы белән табигатькә каршы булган советларның казармалы тормышына аларның аң астында протест сулкылдады. Егетләрнең шуклыгы, кайчак тәртип бозулары — күпмедер дәрәҗәдә психологик саклану чарасы иде. Әгәр кеше яңа мохиткә җайлаша алмый икән, аның үз-үзен тотышы регрессиягә дучар була, ягъни ул үзен йә бала-чага шикелле тота, яисә тәртипсезләнә.

Фәиз белән Зәбирне акларлык нәрсәләр күп, мәсәлән, аларның хезмәт хакы шулкадәр аз, хәтта тулай торак буфетында туенырга да җитми. Детдомнан соң ирек булыр сыман иде, ләкин аңа ансат кына ирешә торган түгел икән. Киресенчә, инде ияләшеп беткән детдом, андагы кәбестә шулпасы, кайнар ботка сагындыра да башлады. Ә биредә? Акча юк, кием начар... Тамак туйдырыр өчен дә, күңел ачар өчен дә, матур киенергә дә, кызлар белән иркенләп йөрергә дә акча кирәк.

Урлаштыра башладылар. Соры чынбарлыктан, тынчу бертөрлелектән котылыр өчен аракы эчтеләр, шау-шулы компанияләрдә кәеф-сафа кордылар. Эштә инде, әлбәттә, прогуллар башланды. Әмма заводтан куабыз дип куркытырга тырышсалар да, кем әйтмешли, егетләргә «ике дөнья — бер морҗа» иде. Детдом балаларын эштән куып чыгару завод җитәкчеләре өчен дә алай бигүк җиңел түгел, чөнки завод ятимнәрне, имештер, тәрбияләргә, кеше итәргә тиеш. Фәиз белән Зәбиргә исә барыбер иде — тәрбияилиләрме-юкмы, куаларммы-калдыраларммы...

— Тиздән армиягә алачаклар,— диде Зәбир беркөнне тулай торакның шыр ялангач бүлмәсендә нишләргә белми аптырап утырган чакта.

— Әйе, киләсе көздә ычкынырбыз инде,— диде Фәиз авыр сулап.

— Бергә туры килсәк ярар иде дә бит...

— Военкоматта үтенеп сорарбыз — бер частька җибәрсеннәр.

— Военкоматта синнән сорап тормаячаклар. Хәтерлисеңдер бит, теге вакытта, комиссия үтеп йөргәндә... военкомат офицерлары бөтенебезне, артыбызга тибә-тибә, акырып, сүгенеп бүлмәдән-бүлмәгә куып йөрттеләр. Кайда, кем белән хезмәт итәсең килә дип, алар синнән-миннән сорар дисеңме?

— Сине морфлотка, йә десантка алырлар,— диде Фәиз көрсенеп.— Синең тазалык та, кыяфәт тә бар. Ә мин, мескен, берәр стройбатта бетон болгатырмын инде.

Зәбир дустын тынычландырырга ашыкты:

— Алай-болай сине стройбатка ала калсалар, мин дә стройбатка барачакмын.

— Үзең әйтәсең бит, военкоматта сөйләшеп тә тормаячаклар дип.
— Шулай шул. Бәлки икебезне дә армиягә алмаслар әле...
— Алала-ар.
— Карале, Фәиз, син бит бик башлы. Мәктәптә дә гел бишлегә укыдың.
— Шуннан?
— Ник берәр институтка кереп карамыйсың?
— Ә син?
— Ха, мин бит икелегә-өчлегә укыдым, мине институтка якын да китермәячәкләр.
— Шулай булгач? Нишләп мин синнән аерылып институтка китим ди. Аннары, әллә кереп була әле анда, әллә юк. Анда бит блат кирәк. Мине кем кайгыртсын анда?
— Ул армия куркыта әле мине. Анда «стариклар» яшьләрне бик кыерсыталар, ди. Коточкыч, ди, андагы хәлләр.
— Син җегәрле, аларга бирешмәссең. Менә миңа авыррак булачак.
— Берәр ничек котылырга иде ул армиядән.
— Минем дә солдат буласым бик килеп тормый.
— Берәр дару эчик мәллә?
— Җүләр! Кит моннан.
— Җүләр дигәннән... Әллә җүләргә сабышыйкмы?
Ике дус рәхәтләнеп көлештеләр.
— Ха-ха-ха, күзләрне акайтып, авыздан күбек агызырга өйрәнәбез дә...
— Юк, барып чыкмас.
— Чыкса да барыбер алачаклар, чөнки безнең армиягә андый җүләрләр дә кирәктер.
— Армиядән без синең белән котыла алмабыз инде.
— Чит илгә ычкынырга иде,— диде Зәбир, кинәт җитдиләнеп.
Фәизнең татлы елмаюдан авызы җәелде:
— Бик ычкынырга иде дә бит... Акча күп кирәк аның өчен. Хәер, акча күп булса да, кем чыгара соң әле сине чит илгә?!
— Анысы, акча булса, мөмкинлекләр бар ул. Мәсәлән, акча юнәтсәң, берәр портта моряклар белән сөйләшеп-килешеп мичкә эченә кереп качасың да... йә капчык эченә. Кораб чит ил портында тукталгач чыгасың.
— Тел белмәгәч, чит илдә нишләмәк кирәк?
— Син бигрәк... Чит илгә эләгеп булса, ачтан үлмәс идем әле.
Чит илләр, ерак сәфәрләр, озак сәяхәтләр турында алар инде күптән хыяллана иде. Коммунизм төзү белән мәшгуль булган илдә үзләренә урын һәм ямь табалмый аптырап йөргән ике яшүсмер егет өчен Көнбатыш (дошманнар тарафы итеп тасвирланганга һәм капитализм коточкыч строй дип көн-төн тукыганга, ахрысы) үзенә гаҗәеп зур көч белән тарта иде. Көнбатыштан яңгыраган дәртле, ритмлы музыка, аннан кайткан джинсылар һәм яшьләр өчен затлы саналган башка күп төрле әйберләр, никтер, илдәге идеологиягә караганда көчлерәк тәэсир итә иде. Пионерияле, комсомоллы, КПССлы, социалистик йөкләмәле, бишьеллык планлы һәм әле офыкта да күренмәгән «якты киләчәкле» тынчу тормыштан котылу чарасын табалмасалар да, күңелләрдә барыбер азатлыкка омтылыш бар иде. Ирекккә омтылган эчке ихтыяр соры тормыштан өскәрәк күтәрелергә вакытлыча мөмкинлекләр тудырды. Бу халәт рух дәрәҗәсендә генә булса да, аның нәтиҗәсендә эчке куәт дәрт һәм дәрман биреп торды.
Егетләрдә армиядән генә котылу түгел, гомумән, бигүк матур башланмаган гомернең киләчәген ничек тә яктылыкка илтә торган агымга бору ихтыяҗы зур иде. Тәкъдир язган фаҗигале хикәятнең бичара персонажы булудан котылу теләге икесендә дә яшәде.

Котылу сүзе төрки халыкларда чистарыну, гөнаһлардан арыну мәгънәсендә дә киң кулланыла. Бу очракта да, егетләр нинди дә гөнаһтан котылу юлын эзләделәр микән әллә? Дөньяга үзләре белән килгән гөнаһтанмы? Унҗиде ел буена эшләнгән яманлыклардан мы? Әллә алда кылынасы гөнаһлардан котылырга омтылыш бармы? Китү (кайвакыт хәтта — качу) ихтыяҗы һәркемгә диярлек хас. Бу — кешенен үзеннән-үзе качу теләге ләбасә. Ә нигә качмакчы була ул үзеннән? Димәк, яратмый ул үзен, үзеннән курка. Чөнки үзен гаепле сизә, гөнаһы бар аның. Алай гына да түгел, интуиция дип аталган эчке сиземләү киләчәктә кылынасы фаҗигаләрне, буласы гөнаһларны да сизә — ана колак сала белергә генә кирәк. Шуңа күрә кеше тынгысызлана, шуңа күрә кая да булса качмакчы була, шул сәбәпле аның тәкъдир алып барган сукмактан котыласы килә. Әмма подсознаниедәге «котылам», «чистарам» дигән, акыл белән тәгаен аңлап бетерелмәгән хис еш кына фаҗигаләрне тагын да ныграк катлауландыра. Чөнки котылуның ысуллары, юллары бихисап күп. Кеше шуны аңлап җиткерә алмый: яман эшләр кылуга сәләтле «мин»нән котылам дип, аның яңа һәм тагын да әшәкерәк җинаятьләр башкаруы ихтимал. Акыл белән аңланып бетмәгән күңелдәге каршылыклардан качу ниятеннән кеше кайвакыт соңыннан мәңге ерып чыгалмаслык эшләр кыла.

Зәбир белән Фәиз нәрсәдән котылырга омтылганнарын да, күңел төпкелендәге бу куәтле ихтыяҗның асылын һәм чыганагын да аңларлык түгелләр иде — яшьләре буенча да, тормыш тәҗрибәсе буенча да. Бу теләк, бу омтылыш аларның үсмер акылларында армиядән, күңелсез тормыш-көнкүрештән котылу ихтыяҗы буларак кына гади формада калыкты һәм тынгы бирмәде. Һәм дә аларга иң әүвәле фәкать акча кирәк иде. Акча кирәк иде аларга, акча!

## 5

Фәиз тагын ике тапкыр хатынын стаканга аракы салып керергә мәҗбүр итте. Инде өченче мәртәбә кушкач, Нәркизә шешәне алып керде һәм өстәлгә шапылдатып куйды:

— Мә инде, тыгын! Үзең чирлисең аннары.

Һәм шундук, дорфа әйттем бугай дип, иренә ягымлы итеп караган булды. Фәиз исә аның сүзләрен колагына да элмәде, шешәдән аракы салып эчте дә башын аска иеп дәшми утырды. Шул газаплы тынлыкны ярып мич артында чикерткә сайрый башлады. Фәиз чикерткәгә җавап итеп ишетелер-ишетелмәс мыгырдап сүгенеп куйды.

— Сөйлә инде,— диде Нәркизә.

Фәиз башын күтәрде дә, бөтенләй таныш түгел кешегә юлыккандай, аптырашлы кыяфәт белән хатынына бакты. Нәркизә иренең кыяфәтеннән пошаманга калды — күзләре эчкә баткан һәм нурсыз, бите саргаеп тартылып калган.

«Тагын чирли,— дип куйды Нәркизә,— тагын өянәге башланырга тора. Тәмам акылыннан язмаса ярар инде. Элегрәк, аракы эчкәч, кызарыбрак, сәламәтләнеп, дәртләнебрәк китә торган иде... Ә хәзер хәлне яхшыртам дип эчә дә, кыяфәтеннән төсе кача үзенең».

Фәиз аның ниләр уйлаганын белә, шуңа күрә хатынына көлгән сыман итеп авызын кыйшайтып карады. Елмаю түгел иде бу, киресенчә, уйларыңны беләм дигән явыз шатлык иде.

— Сөйлә инде,— дип кабатлады Нәркизә, хикәяне тыңлау теләгеннән бигрәк иренең ямьсез күзләреннән котылыр өчен.

— Нәрсә сөйлим?— диде Фәиз каушап калган хатыныннан төссез күзләрен алмыйча.

— Нәрсә дип... Ни турында сөйли башлаган идең соң?

— Ни турында?

— Каян белим мин,— диде Нәркизә һәм урыныннан кузгалды.

— Утыр урыныңа.
— Фәиз, арыгансың син. Ят, йокла. Иртәгә сөйләп бетерерсен.
— Утыр! — дип җикерде Фәиз.— Үзең бит «сөйлә» дидең. Тыңла.
Нәркизә берсүзсез буйсынды. Фәизнең җикерүе яңалык мыни аңа, эш иренең ярсуында да түгел, Нәркизә аның чирләвеннән, гасаб өянәгеннән шүрләде — ул төннәр буе утырырга риза, авырып бимазаланмасын гына.
— Тыңлыйм, Фәиз, тыңлыйм,— диде ул янә урынына утыргач.— Арыганга охшагансың. Шуңа күрә генә әйткән идем.
Фәиз тагын да ямьсезрәк итеп карады:
— Шикләнә башладым әле мин синнән.
— Әй, минем кай җиремнән шикләнәсең инде!
— Бик шикле күренәсең әле син нишләптер!..
— Ярар инде, Фәиз, аракы эчкән саен әллә ничек аркылы-торкылы сөйләшә башлыйсың.
— Чөнки мәҗбүр итәсең. Карале, Нәркизә, ә син миннән шикләнәсеңме?
Хатын әңгәмәнең андый юнәлеш алуына сөенеп елмайды:
— Әй, Фәиз, нишләп мин синнән шикләнергә тиеш соң?!
Дөресен әйткәндә, иренең сәерлегеннән шикләнү генә түгел, соңгы вакытта ул хәтта котсыз кала башлады. Фәиз үзенең сәерлеген үзе дә аңлап бетерми иде шикелле — шунысы бигрәк куркыныч. Бер үк төрле сораулар белән Фәизнең теңкәсенә тиеп бетте инде ул, әмма җавап алмады. Һәм менә, ниһаять, хәзер җавап булыр шикелле.
— Шикләнерлек берни кылганың юк ла синең,— дигән булды сәер һәм авыр холыклы ир белән яшәп хәйләкәрлеккә дә шактый остарган хатын.
Фәиз өстәлгә китереп сукты:
— Ихлас сөйләшмисең! Мин кылганны белсәң син! — Ул никтер якягына карап куйды. Нәркизә калтырый башлады. Чикерткә сайравын дәвам итте. Фәиз шул почмакка карап сүгенеп куйды. Аннары тагын шаулап ява башлаган яңгыр тавышына колак салды.— Шикләнерлек эшләрем байтак минем.
Нәркизә түзмәде, тавышын күтәреп таләп итте:
— Сузма инде, алайса! Сөйлә тизрәк. Нигә җәфалыйсың үзеңне дә, мине дә. Сөйлә, җиңелрәк булып китәр.
— Сөйлим, сөйлим, ашыктырма,— диде Фәиз һәм бераз хәлсезләнеп башын салындырды.
— Читен мәллә? Ятып тормыйсыңмы?
— Юк, юк, хәзер, бер генә минут түз.
Фәиз сөйләвен дәвам итәр алдыннан хәл җыеп утырды. Нәркизәнең дә тавышын күтәрүе бу хикәянең бүген сөйләнеп бетәсенә икесен дә ышандырды.
Әмма ләкин сөйләве авыр, һай авыр. Бу — чирнең каршы торуы. Психиканың кайсыдыр почмагы эчке серне ачып салуга каршы тора, күңелдәге кара «курчакны» бирәсе килми, кайгысын уртаклашса чир таралып бетәр шикелле тоела аңа. Шуңа авыр Фәизгә күп еллар асрап йөргән чирне актарып утыруы. Шуңа күрә авырып йөрүгә караганда сөйләве җиңелрәк түгел. Ул кайгы инде күптән бәгырьгә тамыр җәйгән, аны йолкысаң шарлап кан агар төсле. Шулай да аны йолкып ырргарга кирәк, чөнки вакыт җитте бугай инде, юкса гасаб кылларының шартлап өзелүе бар. Тышка чыгарга тиешле күпме уй, күпме хис тыелып, аң астына этеп төшерелгән, алар бит җыелып яталар, алар кайчан да булса чыгарга тиешләр, юкса алар кешене бетерәләр.
Фәиз куркудан бөрешеп калган хатынына текәлде.
— Курыкма, хатын,— диде ул аптырагач.— Мин курыккан да муеннан җиткән.
— Курыкмыйм мин, нишләп куркыйм,— дигән булды Нәркизә.
— Син мине ташламассың микән?
— Җүләр. Нишләп ташларга тиеш ди соң мин сине.
— Ышанмыйм мин сиңа.

— Әй, ышанмасаң ышанмассың инде.
— Гафу ит, Нәркизә. Сөйләшүемнең дә рәте юк.
— Ашыйсың киләме?
— Юк. Тыңлап кына утыр.
— Тыңлыйм, тыңлыйм.

## 6

Шәһәр буйлап сукбайланып йөргән чакларда алар һәрвакыт берничә кибеттән торган «Спорткульттовары» исемле сәүдә йортына керәләр иде. Кибетләрнең иң ямьлесе һәм кызыктырганы «Культтовары» дигәне, чөнки анда ювелир әйберләр сатыла торган бүлек бар. Андагы алтын балдаклар, чылбырлар, алкалар, савытлар, кашыклар әллә кайлардан күз явын алып торалар. Кая барырга белмичә арлы-бирле сугылып йөргән чакта аяклар, никтер, үзләре шушы кибеткә атлый иде.

...Алар инде әллә ничәнче мәртәбә мөкиббән китеп алтын-көмеш тезелгән витринага йотлыгып карап тордылар.

— Менә кайда бит ул акча! — дип пышылдады Зәбир һәм сатучылар ишетмәде микән дип башын күтәрде.

Сатучылар — урта яшьләрдәге ике юан хатын почмакта кара-каршы утырып гәп куерталар. Әңгәмәләре бик кызык иде, ахрысы — торып-торып икесе дә буыла-буыла көләләр.

— Монда байлык житәрлек, — дип куйды Фәиз.

Зәбир дустының җиңеннән тартты:

— Әйдә!

Алар урамга чыктылар да, алдан сөйләшеп куйгандай, кызу-кызу атладылар. Гүя икесенә дә бер үк уй килде — никтер икесе дә нык дулкынландылар. Бара-бара берсүзсез бер-берсенә карап куйдылар.

— Күрдеңме сул якта такталар өемен? — диде Зәбир.

— Күрдем.

Кибетнең бер ягында ювелир әйберләр, ә ишекнең сул ягындагы өлешендә уенчыклар сатыла торган бүлек иде. Тик ул вакытта уенчыклар бүлегендә ремонт бара, шул сәбәпле кибетнең сул өлеше стенага сөяләп куелган крагислар, такталар, фанерлар, ниндидер мичкәләр, баскычлар һәм чүп-чар белән тулган иде.

Алар урам буйлап тиз-тиз атладылар. Ниндидер уртак карар алып барды шикелле. Зәбир инде катгый карарга килде, ә Фәиз исә инстинктив рәвештә дустының ихтыярына буйсынып шундый ук уйлар кичерде, әмма капма-каршылыклы хисләр белән иярел кенә барды.

— Стенага сөялгән крагислар артында качып калып була, — диде Зәбир, һаман кызу атлап.

— Күрерләр бит, — диде Фәиз сулышы кабып.

— Күрмәслек итеп качарга кирәк.

— Каравылчысы бардыр ул кибетнең.

— Каравылчысы булмый калмас. Ә бәлки юктыр каравылчысы. Анда бит сигнализация бар. Шулай да иң элек каравылчысы бармы-юкмы икәнне белешергә кирәк.

— Ничек белергә икән? Болай кереп сорасак, шикләнәчәкләр.

— Юк, болай кереп турыдан-туры сорау ярамый. Берәр ничек хәйләләп белергә кирәк.

...Икенче көнне Зәбир, сәүдә йортының арткы ишегеннән кереп, «Директор. Габдрахманов Ильяс Хәмитович» дип язылган ишекне шакыды. Җавап ишетелмәде. Зәбир ишекне ачып бөдрә чәчле башын тыкты:

— Исәнмесез!

— Исәнмесез, — диде директор укып утырган кәгазьләреннән башын күтәрмичә генә.

Зәбир кабинетка керде:

— Сезгә каравылчы кирәк түгелме?

Директор, 45—50 яшьләрдәге симез вә түгәрәк агай, өстәл артында мәңге кузгалмаслык позада утыра иде. Ул болай да кысык күзләрен чекерәйтеп ут чәчеп торган егетне бик озак сәерсенеп күзәтте. Зәбир исә бераз каушап калды һәм директор аның ниятен аңлагандыр дип курыкты.

— Нәрсә кирәк?— диде директор, ниһаять, әллә юри, әллә чынлап та аңламыйча.

— Сезгә каравылчы кирәк түгелме?

— Ник кызыксындыра сине бу мәсьәлә?

Зәбир курка башлады.

— Мин эш эзлим,— диде ул юаш тавыш белән.

— Безгә каравылчы кирәк түгел, безгә грузчиклар кирәк. Әйдә грузчик булып урнаш.

— Каравылчыгыз бармыни?— дип сораганын Зәбир үзе дә сизми калды.

— Юк. Бездә каравылчылар бөтенләй юк. Һәм кирәк тә түгел. Грузчик булып кер, рәхим ит.

— Мин уйлармын. Гафу итегез... Сау булыгыз.

— Хуш,— диде директор тыңкыш тавыш белән.

Зәбир атылып тышка чыкты һәм Сәүдә йортыннан еракkарак китәргә ашыкты. Фәиз вак-вак атлап аның артыннан иярде.

— Әйдә читкәрәк,— диде Зәбир әле һаман нык дулкынланып.— Каравылчы юк икән монда.— Ул дустының иңеннән кагып куйды.— Тәк, туган, әзерләнә башларга кирәк!

Фәизне курку әсир итте:

— Кирәкмәс мәллә?

— Нәрсә кирәкмәс?

— Мондый эшкә... тотынырга.

Зәбир дустын иңеннән кочып атлады:

— Болай хәерче булып йөреп тә әйбәт түгел бит. Эшләп барыбер байыйсыбыз юк.

— Акчалы эш эзләп карыйк.

Зәбир кыза башлады:

— Акчалы эш, акчалы эш. Кайда бар соң ул синең белән минем өчен акчалы эш?! Заводта эшлибез бит менә. Эшләп кем баеган анда?.. Гомер буе ат шикелле эшләгәннәре дә бай түгел әле. Син аларның кигән киемнәрен кара да, чырайлары нинди — игътибар ит. Аннары... онытма, тиздән армиягә алып китәчәкләр. Ычкынырга кирәк бу илдән. Син бит күрәсең һәм сизәсең — без синең белән монда беркемгә дә кирәк түгел.

— Кирәк түгел.

— Шулай булгач?

— Ә тотылсак?

— Тотылмаска кирәк!

Зәбир сөйли дә, ышандыра да белә иде. Фәиз аның каршында һәрвакыт бераз гипнозланып кала шикелле иде. Икеле-микеле бәхәсләрдән соң, тегесен дә, монысын да уйлагач, Фәиз үзенең кыюсызлыгы белән саруларны тәмам кайнаткач, барыбер баю теләге өстенлек алды. Акчаның ни галәмәт көчкә ия икәнлеген кем белми, кем аңламый! Чит илләрдә балда-майда йөзеп нужасыз гомер кичерү турындагы хыяллар йөрәкне җилкендереп, яшь башларга болай да тулаем җитеп бетмәгән акылны оетты, исертте. Асылда бит чит ил тормышында түгел, гомумән, тормыштан ләззәт алу мохтаҗлыгы иде бу. Эчтә ниндидер чиста, таза көчләр каядыр читкә, гөнаһтан ераккарак тарта иде. Әмма гөнаһлардан ерак булыр өчен нинди көчләр башка төрле гөнаһларга этәрә икән соң?

**Урлауга** үзләренчә нык әзерләнделәр. Кибеттә ремонт тәмамланганчы житешергә кирәк иде, шуңа күрә бик ашыктылар.

Алтынны урлагач, бу шәһәрдән китү мәслихәт, шул сәбәпле иң беренче нәүбәттә заводтан увольняться итәргә кирәк дип таптылар. Әмма унсигез яше тулмаганнарга, бигрәк тә детдомнан килгәннәргә, эштән китәргә рөхсәтне ВЛКСМның район комитетында гына бирәләр иде.

Гаризаларын тотып егетләр райкомга киттеләр. Балигъ булмаган үсмерләр белән эш итү комиссиясе бүлмәсендә сап-сары чәчле, зәп-зәңгәр күзле бер яшь кыз прәннек белән чәй эчеп утыра иде.

Егетләр гозерне әйткәч, кыз:

— Ә кая барасыз соң сез? — дип кызыксынды.

— Казанда минем туганнарым бар, шунда китәбез,— дип ялганлады Зәбир.

— Казанда сездән башка да шпана житәрлек,— диде кыз ачусыз гына һәм эштән чыгарга рөхсәт биреп кул куйды, күрше бүлмәдән алып кереп пичәт сукты, шуннан соң егетләргә хәерле юл теләде. Егетләр, кимендә ун тапкыр рәхмәт әйтеп, кош тоткандай чыгып йөгерделәр.

Заводта обходной лист белән эшне төгәлләгәч, аларга хәтта житмешәр сум расчет акчасы да түләделәр. Шул ук көнне, акчаларын бергә кушып, «М-107» мотоциклы сатып алдылар. Аны куеп торыр урын табалмый интектеләр. Аптырагач, тулай торакның вахтасына кертеп куйдылар. Вахтер карчык чыр-чыр-чыр кычкыра башлагач, аның кытыршы һәм җыерчыклы учына бөгәрләнеп беткән бер сум тыктылар, шуннан соң әби, мотоцикл мәңге шунда торса да, каршы килмәслек булды.

Заводтан киткәнгә күрә аларны тулай торак бүлмәсеннән мәхрүм иткәннәр иде инде. Шулай да, бик ялваргач, комендант хатын аларга үзләренең бүлмәсендә коры караватларда ике төн йокларга рөхсәт бирде.

Шыр ялангач бүлмәдә, тимер караватларның ямьсез тавыш белән шыгырдауларында, кашагасыз тәрәзәдә — барысында шом һәм кисәтү чагылды. Фәизгә шушы төнге бүлмә инде төрмә камерасы сыман тоелды. Зәбир исә, нык һәм какшамас хәлдә, булачак операциянең детальләрен башында барлап ятты.

Инде карар кылдылар бугай. Тик... Фәиз өчен артка чигенү, кире уйлау Зәбиргә хыянәт итүгә тиң иде. Карар кылдым дип әйтү карар кылу түгел бит әле ул. Әле эчтә «юк» белән «әйе» арасында коточкыч сугыш бара. Үзең өчен әйтү әле карар кылу түгел ул. Карар кылу — эшне эшләгән мизгел. Шул эшкә әзерләнү, шул урынга бару, хәтта инде адым ясау — әле карар кылуга якынаю гына. Карарга кадәр бихисап күп мизгелләр бар. Аларның һәммәсендә кешенең туктап калуы ихтимал. Бары тик бер мизгел эчендә, йөзләгән, меңләгән вариантлар арасыннан сайлап алып, вөждан нишләргә кирәклеген әйтә. Әзерләнү дәверендә исә аң астында вөждан карары әле шулай ук әзерләнә генә. Карар «әйе» ягынамы, әллә «юк» тарафына авышамы — анысын кеше җинаятьне эшләгән мизгелгә кадәр төгәл белеп, аңлап бетерми. Вөҗүднең, психиканың меңләгән фикерләрен уртак тамырга китереп карар кылуы, кешенең көнкүреш тормышта көн күрүче «өстәге» аңына, җирдәге акылына бик аз дәрәҗәдә бәйледер.

Дусты белән килешеп бу тәвәккәл адымны ясарга ризалашса да, Фәиз барыбер кемнәндер, нәрсәдәндер булачак җинаятьне булдырмауны өмет итте. Меңләгән сәбәпләр арасыннан берәр якты сәбәп табылыр һәм иртәгә эшләнәсе эш бәлки гамәлгә ашмас дигән тынычландыра торган уй да бар иде аңарда. Шул ук вакытта, «бәлки тотылмабыз» дигән уй-хыял, кайнар кочагына алып, болай да болганган башны кайнатты.

— Курыкма, Фәиз,— диде Зәбир, дустының капма-каршылы уйлар әсире булып ятуын сизеп.

— Ничек курыкмыйсың инде! Син үзең курыкмыйсыңмы әллә?
— Куркам мин дә. Тик... курыкмаска кирәк.
— Әллә үзең керәсеңме кибеткә?
— Мин үзем керер идем дә... Мотоцикл йөртә белмисең бит. Аннары... син тәбәнәгрәк буйлы, ябык — такталар артына качырга сиңа җайлырак булыр. Син пыяла диварны ватып чыгуга, мин мотоцикл белән килеп житәрмен. Каушама гына.

Фәиз авыр сулап куйды:

— Ярар.

— Менә мотоцикл гына номерсыз инде. Сине көтеп торганда ГАИ-мазар килеп бәйләнмәсә ярар иде. Номер алырга әле житешмәдем диярмен инде. Мотоциклның номерсыз булуы икенче яктан әйбәтрәк.

Фәиз аның сүзләрен ишетмәде дә. Хәер, Зәбир үзенә-үзе сөйләде бугай, планнарны кат-кат барлап ятты ул.

— Харап булабыз без синең белән,— дип куйды Фәиз, дустының дәшми ятуыннан файдаланып.

Зәбир ачуланып җикерде:

— Харап булабыз дип үзеңне-үзең куркытып ятсаң, әлбәттә, харап булачаксың!

— Кибет басу җиңел булса, бөтен кеше кибет басып кына баер иде.

— Чүбек чәйнәп ятма әле! Авыр булмыйча... Кем сиңа китереп бирер соң байлыкны? — Дусты бөтенләй баш тартыр дип шүрләп Зәбир шундук тагын аны үгетләргә тотынды һәм инде, гадәттәгечә, Фәиз күнеп ахири дустының ихтыярына буйсынды.

— Акча да кирәк шул,— диде Фәиз беркавым тып-тын яткач.

Ул инде үзен-үзе тынычландырырга һәм күпмедер дәрәҗәдә хәтта акланыр өчен шулай диде.

— Куркуыңны җиңәргә кирәк. Күңелем сизә, бөтенесе тәртиптә булачак.

— Алтын-көмеш урлаучылар моңарчы гел тотылып килделәр бит,— диде Фәиз янә куян психологиясенең колына әверелеп.

— Ә без тотылмаячакбыз! — дип кырт кисте Зәбир.

Дусты йокыга киткәч, Фәиз торып тәрәзә янына килде. Шәһәр йоклый, берән-сәрән утлар гына ерактагы өмет сыман җемелдиләр. Аның, никтер, бәләкәй генә җылы йортта кайнар аш ашап, кулга тотып йөри торган кечкенә транзисторлы радиоалгыч тыңлап утырасы килде. Җыйнак кына якты бүлмәдә, үзе хуҗа булып, күңеленә яткан урында эшләп яшисе килде аның. Шушы тар гына бүлмәдә, аптыраганнан җинаятькә адым ясарга торган җан дустына да урын табып, аңа да кайнар аштан өлеш чыгарыр иде ул. Шул вакытта Фәизгә дә кызлар игътибар итәрләр иде. Бәлки иртәгә язмыш хәл ителер — кайнар аш та, кызлар да булыр? Куркыта, һай ничекләр куркыта шул. Ә бит байыйсы да килә. Бәлки тотылмабыз, дигән хыял күңелнең бердәнбер таянычы булып калды.

## 8

Икенче көнне, сәүдә йорты ябылырга ярты сәгать чамасы калгач, Фәиз «Культтовары» кибетенә якынлашты. Ювелир бүлегендә унбишләп кеше һәм алар барысы да витринага иелеп алтын-көмеш әйберләрне күзәтәләр, ә сатучылар исә күренмиләр — каядыр шунда почмакта утыралар иде булса кирәк. Фәиз инде бу вакытта үзенә буйсынмады, аны ниндидер көч ишеккә таба этәрде, ишектән керү белән ул сул бүлеккә, ремонт бара торган якка тайпылды һәм стенага сөялгән крагислар арасына шылды. Такталар артында обойлар өеме дә бар икән — гәүдәсе кечкенә булганлыктан ике арада җайлы гына гаип булды. Аның бөтен гәүдәсе, жаны-тәне бер йөрәк тибеше белән сулкылдады. Һәм инде, әлбәттә, башында: «Күрмәделәр микән?» — дигән бердәнбер

уй чынлады. Бу мизгелдә шушы сорауга җавап алыр өчен мөгаен җанын тәслим кылырга да ризалашыр иде. Бу халәттә алтын да, хәтта гомер үзе дә бәясен югалта. Бу мәлдә нәрсә кыйммәт — әйтүе кыен. Бу нинди дер нейтраль мизгел, ахрысы, кеше, җанварга әйләнеп, моңарчы булган кыйммәтләрне, яшәү мәгънәсен югалткан мәл. Хәтта кеше гомеренең дә бу вакытта кадере калмый. Алайса, нидән курка соң бу минутларда? Нәрсә аның котын ала? Булачак җәза алдан куркыта түгелме? Шулай булгач, ГӨНАҺ түгелме соң ул? Бит гаепле икәнеңне сизү куркыта. Гөнаһлы булу куркыта лабаса.

Гөнаһ!

Вөҗдан хәбәр бирә: җавап бирәсе бар. Нишләп монда килгәндә дәшмәде соң ул? Дәште, дәште. Ләкин ник бу сызыкка кадәр килеп җителде соң? Вөҗдан сыный мәллә? Әле соң түгел бит. Сатучылар, судлар, прокурорлар, төрмәләр куркытадыр шикелле... Бу бик гади, примитив аңлату. Юу-у-ук, гөнаһ куркыта, гөнаһ. Хөкем итәчәкләре куркыта икән — гөнаһлы булудан куркуның трансформациясе бу. Кеше хөкеме гөнаһың булган сурәттә генә җәза була.

Гомумән, гөнаһлы кеше генә курка түгелме? Куркуның табигате төрле булып саналса да, аның асылында бары тик гөнаһ ятадыр. Гөнаһсыз булса, кеше курыкмас иде. Имеш, курку — саклану хисе, куркыныч килгәндә туа. Курку хисе кешенең игътибарын куркынычның чыганагына каршы юнәлтеп, аннан котылырга ярдәм итә. Әмма курку — үзеңнән-үзең курку түгелмени?! Кеше холкының, дөресрәге, үзеңнең холкыңны алдан әйтеп-күреп булмауның нәтиҗәсе түгелме соң бу?! Үзеңә үзең хуҗа булалмыйча яман эшкә адым ясау һәм шул ук вакытта курку колы булу — үзеңнән курку лабаса! Ә үзеңнән куркуның сәбәбе исә үзеңә ышанмаудан — үз-үзеңә чит-ят булу һәм, әлбәттә, җаныңда яман көчләрнең барлыгын тоюдан килә. Боларның барысы да гөнаһлы булудан түгелмени? Гөнаһ — үз ихтыярыңа каршы бару түгел микән? Тирәнрәк уйлап баксаң, шулай да шикелле. Әмма ләкин кеше ирекле. Ул бит үз ихтыярына каршы барырга да ирекле. Һәм инде, ниһаять, җәзага дучар ителергә дә хакы бар. Әмма моның мәгънәсе нәрсәдә?!.

Җинаять кылмаганда да курка бит кеше. Әгәр, курку — кешене саклый торган инстинкт икән, бу очракта гөнаһны аклап була. Әгәр кешегә дөньяда куркыныч яный икән, ул үз-үзен саклау ниятеннән каршы торырга мәҗбүр, шулай итеп, ул кайвакыт гөнаһ кылмый булдыра алмый. Бу аклауның чиге юк. Кайда туктатырга бу аклауны? Мәсәлән, яшәргә шартлар булмаса, кешегә кешечә яшәргә мөмкин түгел икән, ул гөнаһ кылачак. Кешене гөнаһлы булырга кемнеңдер гөнаһлылыгы этәрә түгел микән? Шул ук вакытта, кешегә кешечә яшәргә мөмкинлек булмау — аның үзенең гөнаһлы булуы нәтиҗәсе түгел микән? Ә сабый балалар? Алар ни өчен кеше гөнаһын күтәреп йөриләр дөнья буйлап?

Күргәннәрдер... Фәизнең башында, никтер, шул уй урын алды. Күргәннәрдер, күргәннәрдер... Ни гаҗәп: күреп калуларын теләгән шикелле, шул сүз берөзлексез эчтә кабатланды. Үзе хайвани дәрәҗәдә котсыз калса да, күңелдә ниндидер көч һаман да әле җинаятькә каршы тора иде, ахрысы. Шул көч күреп калуларын теләгәндер, шуңа күрә чигәләрдә кан сулкылдавы белән бергә, тавыш-тынсыз гына колакларны тондырып, шул сүз кабатланды. Күргәннәрдер, күргәннәрдер, күргәннәрдер...

Юк, күрмәделәр. Фәизгә исә әкренләп барыбер була башлады — күрсәләр ни дә, күрмәсәләр ни. Әмма бу битарафлык куркуны җиңмәде. Тизрәк бу эшнең бетүен теләде ул, тизрәк котылырга иде аннан, ахыры ничек бетүгә карамастан...

Юк, күрмәделәр. Күргән булсалар, инде күптән йолкып чыгарырлар иде. Ә бәлки милиция чакырганнардыр, милиция килгәнче ятсын дип уйлыйлардыр. Шулчакны Фәиз милиция килүен теләп куйды — күңелендә җинаятькә каршы сугыш бара иде.

Чынлап та, аны беркем күрми калды. Такталар белән обойлар арасында ятучы чандыр малайның начар гына тәнендәге җанында ни галәмәт кайнауларның, давылларның барлыгын беркем ишетмәде, белмәде. Шул малайның вөҗүдендә шушы мизгелләрдә инсаният дөньясына хас булган барлык хисләр купты, бер ятимнең үзәгендә кан, күз яше, хәсрәт, шатлык, явызлык, изгелек — барысы бергә буталып, җиһаннарны урталай ярырлык булды. Әмма ләкин шушы күпьеллык давылның иясе итеп ходай бер ятимне сайлаган иде.

Күрмәделәр...

Зәбир бу вакытта кибеттән өч йөз метр чамасы читтәрәк, газон куаклары ышыгында мотоциклы белән әзер торды.

Буяу, тузан исеннән Фәизнең сулышы кысылды. Ул үзен шушы ярыкка мәңгегә кереп яткан кебек хис итте. Терсәк бик нык авыртты, чөнки таянып ятарга туры килде. Ниһаять, икенче кулындагы рюкзакны көчхәл белән терсәге астына кыстырды. Торымнан-торымга качып яткан урыныннан чыгарга теләге барлыкка килсә дә, үзендә чыкмаслык көч тапты. Бирелергә, чигенергә өндәүче көчләр җиңалмады.

«Кибетне бикләгәндә такта артын тикшерсәләр...» Ләкин беренче адым ясалган иде инде. Хәзер монда кереп яткач, артка чигенү мөмкин түгел. Аның иң куркынычы, иң авыры шушында кереп яту иде ләбаса. Артка чигенү мөмкин түгел дип, соң да түгел әле, әлбәттә. Ята торгач, көтмәгәндә, ул үзендәге куркак уйларны җиңә башлады. Туктале, әле бит җинаять эшләнмәгән. Әле алда ни көткәнен әйтеп булмый. Әле бернинди коточкыч нәрсә эшләмәде бит ул. Үзендә бераз тынычлану сизгәч, ул кибеттәге тавышларга колак сала башлады, ә мона кадәр бернинди тавыш ишетер халәттә түгел иде.

Ниһаять, кибетне сигнализациягә куйдылар.

Биш минут чамасы быдыр-быдыр сөйләшкән тавышлар ишетелеп торды. Ишекне бикләделәр. Тавышлар тонык булып кына тыштан ишетелде һәм бераздан тынлык урнашты.

Кибетне бикләделәр. Киттеләр.

Әмма кибет тынып калгач та, ул әле бик озак аңышмыйча ятты — сатучылар кайтып киттеләрме, юкмы? Тынлыкка колак салып ятканда кинәт бер уй чыңлап үтте: алтын-көмешләр шунда, витринада калды микән соң? Аларны яшереп яисә берәр җиргә бикләп куймадылар микән? Беренчедән, бу уй яман тәэсир итсә, икенче яктан күңелгә хуш түгел дип әйтеп булмас иде. Чөнки җинаятьне туктату ихтималы әле һаман күңелнең бер почмагы өчен шифа һәм сихәт вәгъдә итеп торды. Ләкин шулай да, бу эшнең шактый катлаулы өлеше тәмамланып, инде кибеттә берүзе калу — зур нәрсәгә ирешү һәм кечкенә бер җиңү иде. Баю теләге тагын нык өстенлек алды.

Чыгарга куркып бик озак ятса да, максатка ирешү нияте гаять көчле иде: алтын берүк витринада гына булсын инде.

Ул башын такталар артыннан чыгарды. Кибетнең урам як дивары тоташ пыяладан гына корылганлыктан урам уч төбендәге кебек — анда инде караңгы төшкән, кибет исә дөм караңгы һәм тып-тын иде.

Фәиз үзендә тынычлану сизде, гасаби киеренкелек кимеде. Качып яткан җиреннән калыккач ул үзен барыбер ирекгә итеп хисләде. Кабаланмыйча гына кесәсеннән юка күн перчаткаларын алып киде, шуннан соң тагын кибет эчендәге тынлыкка колак салып торды.

Зәбир урынында микән? Каушамас микән? Хәер, Зәбир каушый торган зат түгел.

Алтынны рюкзакка тутыргач, пыяланы ватып тышка чыгасы бар. Сигнализация кабыначак. Ләкин пыяланы ватмыйча чыгып булмый, бу — бердәнбер чара. Кабынса кабына инде. Шул вакытта Зәбир мотоцикл белән килеп җитә дә, алар бу шәһәрдән чыгып чабарга тиеш. Ә мотоцикл кабынмаса? Кабыныр, нишләп кабынмасын... Яңа мотоцикл бит ул. Ничек булса да, ул инде монда... кибеттә, эчтә. Моннан барыбер чыгарга кирәк.

Йә алтын белән, йә алтынсыз. Юк! Монда кергәч инде алтынсыз чыгу мәсхәрә. Булды, җибәрмәскә кирәк. Уңышлы үтәр дип ышанырга кирәк. Алтынсыз чыксаң да, сигнализация эшләячәк. Югыйсә, Зәбирне алдап та булыр иде — алтын-көмеш витринада түгел дип. Ә бәлки чынлап та витринада юктыр?! Ә нигә алдарга? Бер кергәч, нишләп алтынсыз чыгарга? Бу уйлар яшен тизлегендә баш эчен айкадылар.

Ул ювелир әйберләр бүлегенә атлады. Дулкынлану тагын көчәя башлады. Икеләнүләр юкка чыкты, тагын баю теләге өстенлек алды, витринада зиннәтле әйберләрнең булуын җаны белән теләде ул.

Кинәт гәүдәне ток суккандай булды — кибетнең служебный бүлмәләр урнашкан коридорында кемдер йөри иде. Фәиз, аяк очларына гына басып, яңадан такталар янына килде дә тиз генә качып яткан урынына кереп китте. Яшеренде.

Ләкин кибет эчендә тагын кемдер бар бит! Бетте! Ник тотындык бу җинаятькә! Эләктем микәнни?..

Кибет эчендә түшәм, стеналар буйлап фонарь уты йөгереп уйнаклады. Бер ир кеше, борын төбендә ниндидер көй шыңшып, кибет эчендә йөри иде.

Каравылчы!

Каравылчы бар икән ләбаса! Их, җүләрләр!

Шул директорга ышанып соң инде! Кибеттә каравылчы булмый димәни... Харап булдым, харап булдым. Әллә чыгып бирелергәме?

Тавыш куптармый гына каравылчы белән килешеп, котылыргамы?..

Юк, каравылчы тавыш куптармый калмас.

Агайның тавышы якынайды, фонарь яктысы ул качып яткан крагислар өстендә чагылды. Фәиз, тын да алырга куркып, катып утырды. Бу минутларда инде ул акылына түгел, фәкать инстинктка гына буйсына иде. Ул интуициясенең колына әверелде. Аның кулы, үзеннән-үзе, идәндәге чүп-чарны капшады. Нинди дер каты әйбер эләкте — кирпечме, ташмы...

Агай фонарен сүндерде, җырлаудан да туктады. Шырпы сызды, тәмәке кабызды. Шундук тәмәке исе борынга бәрелде. Диварлар буйлап янә фонарь уты йөгерә башлады. Фәиз качып яткан арадан башын чыгарды. Каравылчы аны инде күргәндер шикелле иде. Иреннәрендә тоз тәме тоелды. Нинди дә булса адым ясарга кирәк бит. Агай аңа арты белән торган мәлдә ул качып утырган куышыннан атылып чыкты һәм кулындагы таш белән бар көченә агайга орды. Дөм караңгы булганлыктан, башына туры китерә алмады, муенынамы, иңенәме эләкте, ахрысы. Агай башта борылды бугай, аннары гына кычкырып җибәрде. Фәиз тагын сукты — таш каравылчының маңгаена шыкылдап бәрелде.

Авыр гәүдә обойлар өстенә гөрселдәп ауды.

Вакыйганың бу өлешен Фәиз аермачык хәтерли. Нинди көчләр этәрде аны монда? Хәер, җавап бар шикелле — курку аңа тәвәккәллек бирде, курку. Гөнаһлы буласын сизеп курыккан кеше нишләп шул халәтендә җинаять эшли ала соң?.. Менә бу сорауга кем җавап бирер икән?.. Мондый кискен мәлдә кеше ничек булса да исән калырга тырыша, чөнки аның аңы астында әле алда яшәү бар дигән өмет ята. Әле киләчәктә юармын кара тапларымны, алдагы гомеремдә чистарынырмын дигән өмет тә үзен сиздерәдер. Хәлиткеч мизгелдә «ничек тә булса исән калып, киләчәктә үзгәрермен» дигән ышану да бардыр инде кеше психикасында.

Ул, никтер, агайны торгызырга маташты. Аннары, нинди максат белән монда керүен исенә төшереп, нинди хәлдә калуын аңлап, идәннән рюкзагын эзләп тапты. Тораташ каткан бер нерв җепселенә әверелеп, ул алтынлы витринага таба юнәлде. Урам баганаларыннан төшкән утлардан ул тараф яктырак иде. Аның бер кулында рюкзак, икенчесендә каравылчыны еккан таш иде. Витринаның пыяласы тартып ачыла торган булса да, ул таш белән орды. Икенче витринаның да пыяласы чәлпәрәмә килде. Хәтта шул мәлдә дә алтын-көмеш шундамы, юкмы икәнен ул белмәде. Кулы белән капшап карагач кына аңлады — алтын-көмеш йөзекләр, кашыклар, чылбырлар шунда иде.

Алтын-көмеш белән бергә рюкзакка пыяла кисәкләре дә тулды. Моңарчы һич сизелмәгән, аңарга хас булмаган тәвәккәллек вакыйганың киеренкелегеннән туды, төгәлрәк әйткәндә, бу мизгелләрдә аны хайвани курку курыкмас иткән иде.

Кулга эләккән затлы әйберләр белән рюкзак яртылаш тулгач, ул пыяла диварны кайданрак ватыйм икән дип карап торды. Ташны инде тотып аткан иде, ә аяк белән калын пыяланы тибеп ватасына икеләнде. Яңадан крагислар янына барырга туры килде. Шунда ул каравылчының ыңгырашуын ишетте. Кабаланып рюкзакны җилкәсенә асты да, чүп-чар өстеннән бер таш кисәге табып, каравылчыга таба бер адым атлады һәм... туктады. Юк! Ташны бар көченә пыяла диварга ыргытты. Пыяла, коточкыч тавыш белән дөньяны яңгыратып, коелып төште. Ләкин ул ике катлы булып чыкты. Аны-моны уйлап тормыйча, ул икенче катына китереп типте, тик пыяла ватылмады.

Шулчак ул нык каушады. Тагын пыялага тибәргә үзендә көч тапмады. Каравылчы менә-менә торыр шикелле иде. Ә бәлки торгандыр да инде. Ташны эзләп карады, табалмады. Үзәкләр куырылды, чарасызлык аяккулларны богаулап ташлады.

Шул вакытта урамда яктылык уйнап алды, мотоцикл тавышы ишетелде. Мотоциклның якынаюы, дөресрәге, Зәбирнең, җан дустының янәшә булуы аны «уятты», каяндыр тагын дәрман өстәлде. Фәиз бар көченә, бөтен гәүдәсе белән пыяла диварга ташланды һәм җан өшеткеч зеңгелдәүгә ияреп, тышка килеп төште.

Мотоцикл килеп туктагач, Зәбирнең:

— Тизрәк! — дип кычкырганы ишетелде.

Бу вакытта кибет эчендә каравылчыдан башка тагын бер кеше бар иде. Ул үрмәләп мичкәләр арасыннан чыкты һәм нишләргә белмичә аптырап калды: кайдадыр караңгылык эчендә ятучы каравылчыны эзләп табаргамы, ватык тәрәзәдән чыгып качаргамы, әллә мичкәләр артына кире кереп посаргамы?

Номерсыз мотоцикл ярты рюкзак байлык белән төнге шәһәр буйлап чапты. Провинциаль шәһәрнең тынлыгы бу очракта миллионлы каланың шау-шуына караганда куркынычрак һәм яманрак иде. Берән-сәрән кешеләр, машиналар күренгәләде, ГАИ, милиция-мазар очрамады.

Инде шәһәрдән чыгып урманга таба чапканда да арттан куучылар күренмәде.

Зәбир башын артка борып мотоцикл тавышын уздырып кычкырды:

— Булдымы?

Фәиз нәрсә булдымы икәнне аңларлык түгел иде. Сорауны анык аңларлык халәттә булмаса да, булды дип җавап бирергә кирәклеген төшенде.

— Булды, — диде ул.

Зәбир ишетмәде:

— Булдымы дим?

Фәиз кинәт акырып җибәрде:

— Булды!

Урман ерак түгел иде инде.

## 9

Нәркизә үз колакларына үзе ышанмый утырды. Әкият дисәң әкияткә, хикәя буларак чынга охшамаган иде иренең сөйләгәне.

Фәиз тәмәке кабызды — мондый хикәяне сөйләгәндә тышка чыгып тартмас бит инде. Бушап калган яшькелт шешәгә текәлеп, ул кәкрәйгән тәмәкесен тирән итеп кат-кат суырды.

Шушы кечкенә буйлы, тар җилкәле, көчсез кеше каравылчыны бәреп кибет баса алды микәнни — Нәркизә ирен җентекләп күзәтте. Булыр

да. Әнә бит ул нинди куркыныч. Күзләре генә ни тора. Әле теге вакытта, яшьрәк чакта көчлерәк тә булгандыр. Әле өч ел элек кенә дә, өйләнешкәндә, ул хәйран житез һәм бүгенге кебек үк хәлсез түгел иде. Гәрчә шул вакытта ук вакыты-вакыты белән әллә нишләп китсә дә. Детдом баласы бит, сәерлеген дә табигый сыманрак итеп кабул итәргә тырышты Нәркизә, тырышты һәм шулай кабул итте дә.

Нәркизә хикәянең дәвамын дәгъваларга куркып утырды. Фәиз, дәвам итимме дигәндәй, беркавым хатынына текәлеп карап торды; аның нурсызланган күзләреннән Нәркизәнең бөрешкән үзәге тагын да ныграк куырылды. Аракы гына сорамасын, дип уйлап куйды бичара хатын.

Һәм, үч иткәндәй, әйтерсең лә уйларын укыган, Фәиз таләпчән итеп:

— Бир тагын бер ярты! — диде.

— Бүтән юк! — дип өзде Нәркизә.— Менә бу эчеп бетергәнең соңгысы иде. Монысын да телевизорны рәтләргә килүче мастерга дип саклап тота идем.

Ни гажәп: Фәиз көйсезләнмәде, аракы да дауламады. Күрәсең, сөйләү бераз бушандыргандыр һәм азмы-күпме тынычландыргандыр.

Ул авыр, тирән итеп сулап куйды:

— Менә шулай, карчык.

— Да-а-а-а,— дип сузган булды Нәркизә, ни әйтергә белмәгәч. Хәер, аңа берни әйтергә дә кирәк түгел иде.

— Ә син мине сәер дисең.

— Кем сине сәер ди?

— Син мине гел сәер дисең.

— Минме?!

— Син! Әйдә, башыңны жүләргә салып утырма инде, яме! Син бит инде ничә ел буе мине сәер дип йөдәтәсең.

Нәркизә югалып калды, әмма үзен гаепсез сизү аңа бөтенләй үк каушамаска мөмкинлек бирде. Ул тавышын шактый күтәреп әйтеп тә салды:

— Әйтсә ни! Әйтмичә... Үз иремә, өч ел бергә яшәгән кешегә әйтүдән ни булган?..

— Сәерме мин?

— Сәер! — дип кырт кисте Нәркизә ышанычлы итеп.

Фәизнең башы хәлсезләнеп салынып төште:

— Шулайдыр шул. Ачуланма инде, карчык. Сөйлим хәзер барысын да... Сөйлим... һәм син барысын да аңларсың — ни өчен мин шундый. Син аңларга тиеш, чөнки син акыллы хатын.

— Бигүк акыллы булмасам да, бөтенләй үк жүләр түгелдер,— дип жавап бирде Нәркизә, баягы мескен халәтеннән өскәрәк күтәрелә алуына эчтән куанып.

— Үпкәләмисеңме миңа?

— Юк инде, Фәиз, юк.

Өйдә тагын тынлык урнашты. Иренең йомшарыбрак китүеннән файдаланып, Нәркизә сорарга булды:

— Ә алтынны нишләттегез соң?

Һәм сорап ялгыш эшләде. Фәизгә бу сорау бик начар тәэсир итте, ул беркавым жавапсыз утырганнан соң кычкырып жибәрде:

— Вәт син аны, ә! Тизрәк алтын турында кызыксына. Каравылчы исән калдымы дип кызыксынмый, тинтәк! Тизрәк алтын турында сорый.— Ул инде ярсып кычкыра башлады.— Төрмәгә утыртмадылармы дип кызыксынмый! Алтынны нишләттегез ди...

Нәркизә, әлбәттә, сорауны ник биргәненә үкенде. Иренә рәнжеде, чөнки болай сүгенеп кычкырырлык берни дә булмады лабаса. Каршы кычкырырга да исәбе юк түгел иде, әмма шулай да вакыйганың дәвамын йә ахырын ишетәсе килде. Күптән көткән әңгәмәне бүген ничек булса да ерып чыгу мәслихәт. Ярсысын, кычкырсын, ләкин эчендәген ачып салсын.

— Ул кадәре кызма, Фәиз. Әллә нинди тинтәк сораулар бирсәм дә, мин бит сиңа дошман түгел инде.
Фәиз кинәт тынычланды, ник ярсып алганына үзе дә гаҗәпләнеп куйды, ахрысы.
— Гафу ит,— диде ул, башын салындырып.
— Гафу да үтенмә. Акырып утырышлы булгач, синең гафу үтенүеңнән ни файда.
— Бик авыр бит.
— Миңа да җиңел түгел... Менә бит, кызмыйча гына нервыланмыйча да сөйләшеп була. Сөйлә, бернинди сорау бирмим, валлаһигазим.
— Нәрсәдә тукталдым әле мин?
— Мотоцикл белән чаптыгыз...
Фәиз тагын хәтеренә чумып телсез калды.
Нәркизә сөйлә дип әйтергә батырчылык итмәде, шуңа күрә:
— Ашыйсың килмиме?— дигән булды.
Фәиз дәшмәде.
— Тамагың ачмадымы?
— Юк, юк,— диде Фәиз аңына килеп.— Тыңла.
Өзелгән хикәя ялганды һәм сагаеп, бөрешеп калган йортка шом иңдереп Фәиз дәвам итте.

## 10

Урманга җитәрәк юл начарланды, мотоцикл берничә тапкыр чак кына аумый калды. Битләргә салкынча дымлы саф һава бәрелде — урман каршыда иде. Кинәт бер сикертмәдә бик каты дыңгырдатты, мотоцикл, беркавым гөжләп ятканнан соң, пырхылдап сүнде.
Тынлык урнашты.
Егетләр, әле бер-берсенең исәнме-юкмы икәнен белмичә, тып-тын дөньяга колак салып яттылар.
Кайдадыр еракта этләр өрде. Күкне чуарлаган йолдызлар җылылык бирмиләр, киресенчә, салкын һәм кырыс шаһитлар сыман аска карыйлар иде. Әллә йолдызлар да алтын микән?..
Егетләр дәшәргә куркып яттылар. Бер-берсенең исәнме-юкмы икәнен сорарга җөрьәт итмәделәр, чөнки бу мәлдә алар бер-берсенә бик кирәк иде. Бу караңгылыкның авырлыгын ялгыз кеше күтәрерлекмени?! Коточкыч салкын күк астында берьялгызың бу мизгелләрдә нишләмәк кирәк?
Ниһаять, караңгыда Зәбирнең тавышы ишетелде:
— Син исәнме?
Аның бу соравы «Син йокламыйсыңмы?» кебек килеп чыкты. Әйтерсең лә алар тулай торак бүлмәсендә яталар.
Фәизнең иң элек ыңгырашуы, аннары гына:
— Исә-ә-ә-ә-н,— дип сузганы ишетелде.
Зәбир, калкып, башта шәһәр ягына карап торды — арттан куучымазар күренмәде, ишетелмәде. Шуннан соң ул аһ-ваһ килеп мотоциклны калкытты, мотоцикл астыннан уфылдап Фәиз үрмәләп чыкты.
— Сынган җирләрең юкмы?— диде Зәбир.
— Әллә тагы... Юк бугай.
— Рюкзак сындәме?
Рюкзак турында ишеткәч Фәиз тагын куырылып китте, аның бу вакыйгадан котыласы, онытыласы, рюкзак белән бәйле сәгать-минутларның һәм эчендәге байлыкның да шушы ямьсез, салкын йолдызлы галәмдә юк булуын теләде.
— Рюкзак синдәме?— дип кабатлады Зәбир.
— Миндә.— Фәиз шәһәр ягына карап куйды.— Әйдә тизрәк урманга.

Зәбир, кабаланып, мотоциклны торгызды. Маташып карадылар, ләкин мотоцикл кабынмады. Этеп тә кабыза алмагач, нишләргә белми аптырап тордылар.

— Мотоцикл сөйрәп йөреп булмый инде,— диде Зәбир, аны яңадан аударып.

— Кызганыч,— диде Фәиз. Ул кинәт хәлсезләнеп китте.— Хәлем начар минем.

— Түз, түз, анда урманда һава да әйбәт... Әйдә, бик ашыкмабыз... әкрен генә.

— Куа чыкмадылар микән безне?

— Белмим. Әйдә, ашыгырга кирәк.— Ул тагын еракта тоныкына элҗе-мөлҗе килгән шәһәр утларына карап торды.— Бир рюкзакны, үзем күтәрим.

— Мә.— Фәиз капчыкны бирде.— Хәйран авыр ул.

— Авыр булмыйча... Алтын бит ул!

Кызганыч булса да, мотоциклны ташлап калдырырга уйладылар. Эзәрлекләүчеләр күренмәде, шулай да тизрәк урман эчендә гаип булу мәслихәт иде.

Илле адым чамасы үткәч, Фәиз җиргә утырды:

— Хәлем юк минем...

Зәбир, кабаланып, дустын калкытырга тотынды:

— Тор, тор, әйдә! Урманда хәл алырсың.— Ул аның муенын капшады.— Карале, син канга батмансың икән бит. Тир генә түгел бу.

Моны ишеткәч, Фәиз тагын да ныграк хәлсезләнеп китте.

— Пыялага киселгәнмендер,— диде ул ыңгырашып. Шулай да, дустының кулына ябышып торып басарга ул үзендә көч тапты.

— Нык киселгәнгә охшамаган,— дигән булды Зәбир, дустын тынычландырыр өчен.

Караңгыда Фәизнең яралары күренмәде, ә шырпы сызсаң, утны әллә каян ук абайлаулары ихтимал иде.

— Әйдә, урманда карарбыз, чүпрәк белән бәйләрбез,— диде Зәбир һәм, аны култыклап, урманга таба сөйрәде.

Озакламый мәһабәт гәүдәсе белән каршыда урман калыкты.

Үзе дә сизмәстән Зәбир тагын бер сорап куйды:

— Син исәнме?

— Һи, бу кадәре алтынны калдырып үлеп китәргә җүләр түгел лә.

Фәизнең шаяруыннан икесенә дә җиңелрәк булып китте.

Катнаш агачлы урманда һава иркен, рәхәт иде. Әмма егетләр урман сулышында назланып торырлык халәттә түгел иделәр. Караңгыда агачлар арасыннан бару авыр булса да, алар тизрәк эчкәрәк кереп китәргә тырыштылар. Еш абынып егыла башлагач хәл алырга туктадылар. Авыр сулап бер сүз катмый озак утырдылар.

— Бөтен милиция аякка баскандыр инде,— диде Зәбир сулышы бераз тигезләнгәч.

— Мотоциклны күрерләр инде.

— Их!..— Зәбир яман итеп сүгенде.— Ялгышлык эшләдек. Җүләрләр без. Кем инде мотоциклны шунда калдыра... Урманга кадәр аны ничек булса да сөйрәп алып килергә иде.

— Әйе шул. Мотоциклны күргәч безнең кай тирәдә икәнебезне чамалаячаклар. Әллә кире барыйкмы?

— Кая?

— Мотоциклны алып килергә.

— Тилермә. Хәзер инде, киресенчә, ераграк китү ягын карарга кирәк.

— Бераз утырыйк әле.

— Юк, Фәиз, тор, ашыгырга кирәк.— Ул аңа торырга булышты.— Түз инде, эчкәрәк кергәч ял итәрбез.

Туктарга куркып бик озак бардылар. Фәиз акрын атлады, шул сәбәпле бигүк ерак китә алмадылар шикелле. Ләкин инде бераздан этләр өргән

тавыш та, хэтта җил искәне дә ишетелмәс булды. Тора-бара куаклар башланды. Куаклар арасыннан атлау тәмам кыенлашкач, ниһаять, туктап төн уздырырга әзерләнделәр.

Дөм караңгы урман кочагында янында дустың барлыгы гына тәндә җанны саклыйдыр. Юкса бу билгесезлек акылдан яздырачак. Куркудан шашу мөмкин икән ул, ике җанның янәшә булуы гына вөҗүдкә шифа биреп, өметне саклады. Монда бөтен нәрсә уртак — язмыш та, урман да, капчыктагы хәзинә дә һәм инде, ниһаять, гөнаһы да. Ә менә аларны көткән җәза уртак булырмы, юкмы, бу минутларда ул хакта ничектер уйламаска тырыштылар. Тотылмаска өмет бар иде. Гөнаһ кылу юлының күпме өлеше үтелгәндер — анысы да мәгълүм түгел иде әлегә. Фәиз кибеттән исән-имин чыгуына куанса да, ул барыбер капма-каршылы хисләр әсире булып калды. Бу матавыкның тизрәк ахырын күрәсе килде аның. Зәбир исә инде татлы хыяллар белән мәшгуль иде. Фәиз дә аңа карап, канатланып куйды. Әмма алдагы билгесезлек кичеп чыккысыз чатыр сыман иде.

Шырпы сызып Фәизнең яраларын карадылар. Тәннең киселгән урыннарын шактый булса да, яралар тирән һәм куркыныч түгел иде.

— Пүчтәк! — дип юатты дустын Зәбир, — сыдырылгансың гына бераз.

Ул күлмәген шатырдатып ертты да Фәизнең кан күбрәк саркыган урыннарын бәйләп куйды. Аның шәрә тәне өстендә юка курткасы гына калды.

Фәиз дер-дер калтырап утырды.

— Учак ягыйкмы әллә? — диде Зәбир. — Өстеңдә свитер булса да бик нык туңасың бугай.

— Минем калтырану нервыдан ул. Учак ягу турында уйлама да. Ут яктысын әллә кайдан ук күрәчәкләр.

Бер-берсенә елышып утыргач Фәизнең дерелдәве кимеде.

Рәхәтләнеп тәмәке тарттылар. Аннары, шырпы яндырып, бик озак итеп капчыктагы алтын-көмешне караштырдылар. Ләкин сөенергә иртәрәк иде — дөм-караңгы урман уртасында, иртәгесе көн ни китерәсен белмәгәндә алтын әле хәзинә түгел. Алтын, гомумән, хәзинә түгел икәне дә билгеле, әмма унсигез яшьлек ике бала өчен байлык иде бу.

Ике дус августның җиләс куенында усак яфраклары сыман калтырап яттылар. Урман тып-тын. Ара-тирә генә ниндидер кошларның, җәнлекләрнең аваз салып куйганнары ишетелгәләде.

— Хәлең ничек? — дип пышылдады Зәбир.

— Ничек булсын инде хәл? Синеке шикелледер инде. Киселгән урыннар әчетә.

— Бетә ул, бетә.

— Бүреләр юк микән монда?

— Белмим. Юктыр. Мондый урманнарда бүреләр булмый.

— Син тынычландыра беләсең.

— Тизрәк таң атсын иде.

— Карале, Зәбир, каравылчы килеп чыкты бит анда.

— Кайда?! — дип гаҗәпләнде Зәбир.

— Кибеттә! Аның каравылчысы бар икән бит. Мин аның башына ордым... таш белән. Үлмәде микән?

«Үлмәде микән» дигәнне Зәбирнең ишетәсе килмәде, шуңа күрә сөйләшүне башкачарак юнәлештә җибәрергә ниятләп карады:

— Бәрәч, каравылчы каян килеп чыксын икән анда?.. Каравылчы булмагандыр ул.

— Ә кем булды икән соң ул?

Зәбир һаман ҮЛЕМнең булмавын теләде, булган суәттә дә, дусты таш белән орган кешенең каравылчы түгел, берәр начар кеше булуын күңеленең бер почмагы белән теләде:

— Каравылчы булмагандыр ул, берәр карак-мазар булгандыр. Алтын урларга керүче, безнең кебек.

Фәизнең ачуы килә башлады:

— Син белмәгән килеш әллә нәрсәләр уйлап чыгарып ятма инде. Каравылчы иде. Ул бит анда фонарь яктыртып җырлый-җырлый йөрде.

— Нык суктыңмы соң?

— Әллә тагы. Куркудан хәтерләмим дә.

— Кычкырмадымы?

— Кычкырды бугай.

— Егылдымы?

Фәиз түзмәде, кычкырды:

— Егылды, егылды! Ник төпченәсең!

— Тс-с-с-с. Тилерденме әллә. Ник кычкырасың?

— Тилердем,— дип пышылдады Фәиз тешләрен кысып.

— Кызма, Фәиз, нык бул, хәзер безгә кызарга ярамый.

Фәиз, ни гаҗәптер, шундук тынычланды.

— Мин кибеттән чыгып киткәндә ул ыңгырашып калды.

— Чынлап ишеттеңме?

— Ишеттем, ыңгырашты.

Зәбир шатланып дустына төртеп алды:

— Димәк, исән! Исән ул, исән.

— Исән булсын берүк.

Беркавым шомлы тынлыкка колак салып яттылар.

— Бай без хәзер,— диде Зәбир ясалма тантана белән, үзен түгел, күбрәк дустын шатландырырга теләп.

— Тотачаклар безне,— дип җавап бирде Фәиз. Аның тавышы битараф иде, гүя вакыйганың ничек тәмамлануы аны һич кенә дә кызыксындырмый иде.

— Куертма! — диде Зәбир.— Тотылабыз дип ятсаң тотылачакбыз да... Тотылмау турында уйларга кирәк.

Фәизнең бирешәсе килмәде:

— Син ул чәйнәшәсең. Кибеткә керүче син түгел. Каравылчыны үтерүче дә син түгел... Синең өстә бигүк күп нәрсә асылынып тормый, шуңа күрә җилле сөйләшәсең. Ә мин менә кеше үтердем.

— Үлмәгән ул,— диде Зәбир тыныч кына.

— Каян беләсең?

— Ыңгырашып яткан бит.

— Ярдәм итәргә тиеш идек без аңа. Скорый чакыртырга иде.

— Бигрәк кызык кеше булып чыктың син. Скорыйлар чакыртып йөрисе булгач, кибет басудан ни мәгънә соң? Мин синең хәлеңне аңлыйм. Йокларга кирәк сиңа. Безнең хәзинәбез бар, аңлыйсыңмы? Кибеттә булган хәлләр бетте-китте, артта калды. Тынычлан, Фәиз.

Фәиз дәшмәде.

Коточкыч киеренкелектән соң саф һавада, салкын булса да, алар балаларга хас тирән йокыга талдылар.

## 11

Алар беренче кошлар сайрый башлагач ук уяндылар. Торып утыргач, танырга ниятләгәндәй, җентекләп бер-берсенә карап тордылар. Чыннан да, бу мизгелләрдә бер-берсен танырга тырышу ихтыяҗы бар иде, ниндидер бер сызыкны, психологик киртәне чыгып билгесез тарафка юл тотуларын күңел белән сизенделәр һәм шул сәбәпле бер-берсендә тышкы зур үзгәреш абайларга тырыштылар. Нәрсәләр булды, кибет басу гына түгел — зуррак, авыррак эш кылынды, мең кибетләрне басарлык мөмкинлекләр ачылды психикада. Әмма алай җиңел генә булмый, мөмкинлекләр булса да, эчтә барыбер сугыш бара, үзен

гаепле сизүче нинди дер бер «орган» тынгы бирми. Вөждан дип атыйсы килмәсә дә, аны вөждан дип атарга туры килер инде. Вөждан кичә ирек бирде дә, бүген әнә бимазалана. Зәбирдә алтын-көмешкә сусаган «мин» өстенлек алды, ә Фәизнең күңелендәге исә һич кенә дә аңларлык түгел иде.

Асылда, бу инде икесенең дә гөнаһ өчен җәза башы иде. Хөкем инде башланды, хәтта нык һәм какшамас Зәбирне дә тәкъдир куе урман чатырына кертеп адаштырды.

Ә алайса, нинди гөнаһлары өчен гөнаһ юлына баса соң кеше? Бу өзелмәс бәҗраны кай җиреннән өзеп булыр икән?

Алар бер-берсенә зур дикъкать белән карап тордылар. Ни гаҗәп, алар бер-берсен таныдылар. Алай гына да түгел, алар хәтта кайгылы да түгел иде бугай.

Фәизнең муенында, кулларында пыяла кискән сызыклар, оеп кипкән кан таплары бар, ә Зәбирнең бите бераз сыдырылган гына иде. Бер-берсенең кыяфәтендә алай кот очарлык үзгәрешләр тапмагач, эзәрлекләүчеләр күренмәгәч һәм инде рюкзак янәшәдә яткач, егетләрнең кинәт күңелләре күтәрелеп китте. Кичәге вакыйга хәзер төш сыман гына тоелса да, аның өндә булганлыгын рюкзак эчендәге алтын гына «кычкырып» ялтырап «әйтеп» тора иде.

Зәбир капчыкны ачып карап торды:

— Ничә сумлык икән бу?

Фәиз капчыкка күз салды:

— Күп монда.

Бер-берсенә карап алдылар. Икесенә дә күңелле булып китте: байлык алар кулында ләбаса. Яңа көн туды. Әлегә тотылмадылар. Сак булсалар, кем тотсын аларны.

— Каушама гына син,— диде Зәбир, дустын иңеннән кагып.— Барысы да тәртиптә булачак, менә күрерсең.

Фәиз елмайды, аның елмаюы Зәбиргә кирәк иде, ул инде дустының тәмам шәлберәюеннән бик курыккан иде.

— Молодец! — диде ул һәм Фәизне ирләрчә каты итеп тагын иңеннән какты.— Йоклап булдымы соң?

— Йокладым. Туңып уянгаладым, әлбәттә.

— Мин үле кеше кебек йоклаганмын.

Егетләр сискәнеп киттеләр — якында гына мотор тавышы ишетелде. Алар тавышны аңларга тырышып сагаеп тыңлап тордылар. Гөрселдәү кайдадыр якын-тирәдә ишетелде, трактор тавышына да, вертолет гөрләвенә дә охшаган иде.

Аучыдан өркегән куркак җанварлар шикелле алар җан-фәрманга, абына-сөртенә, урман эченнән йөгерделәр.

Тын алырга туктагач тыңлап тордылар — гөрселдәү ишетелмәде. Тирә-якта мең төрле урман авазлары хөкем сөрде. Кай тарафка, нинди юнәлештә юл тотуларын аңламыйча алар, сирәк-мирәк очраган кура җиләге, шомырт белән тамак ялгап бардылар да бардылар.

— Вертолет булды микән әллә? — диде Фәиз хәл алырга туктагач.

— Юктыр, тавышы якын ишетелде бит, вертолет булса күренми калмас иде.

— Мотоцикл андый чатырда йөри алмый инде.

— Урман хуҗалыгында эшләүче тракторлар булгандыр.

— Безне эзәрлекләүчеләр түгел микән?

— Безне трактор белән кем куып йөрсен инде.

— Синең өчен танк чакыртырлармыни?

Зәбир моны шаяру итеп кабул итте, Фәизнең исә шаярырга хәле дә, исәбе дә юк иде.

Адашып йөри торгач, инде көн кичкә авышты.

Ниһаять, агачлар сирәгәйде.

Тагын ярты чакрым чамасы абына-сөртенә үткәннән соң алар урман авызына килеп чыктылар. Каршыда аллы-гөлле болын җәйрәп ята иде, ә теге ягында — бер чакрым тирәсе ераклыкта — авыл күренде. Сөенергәме, көенергәме — белмәделәр. Алар шәһәрдән бик еракка китә алмаганнар иде — урманда адашып, урап йөргәннәр. Авылдан шәһәргә ун-унике чакрым ара бар. Алар инде алтмыш-җитмеш чакрым юл үттек дип уйлаганнар иде.

— Зәбир, бу бит Каенсар авылы. Бер тапкыр детдомнан монда машина белән бәрәңгегә килгән идек.

— Әйе шул.

— Нишлибез?

— Бераз хәл җыйыйк та, мин авылга барып килермен.

— Чын әйтәсеңме?

Фәиз ялгызы калырга курыкты, берүзе уй-хисләренең колы булып калырга йөрәге җитмәс кебек иде.

— Ник? Кыяфәтем ничегрәк минем?

— Начар. Өстәвенә пычрак та әле.

— Авыл башында буа бар, битне шунда юармын.

— Әллә йөрмисеңме?

— Ничек инде, «йөрмисеңме»? Ачтан үләсең киләмени? Бер капчык алтын-көмеш кашыклар белән урманда ачтан үлү — бик ямьсез күренеш, кешедән яхшы түгел.

Ул тигез, матур тешләрен күрсәтеп елмайды.

Фәиз дә никтер аңа ияреп елмайды, күрәсең, дустына ышану, аның авылдан ризык алып киләсенә шикләнмәү билгесе иде бу.

— Куртканы бөтен төймәләренә төймәлә,— диде Фәиз.— Эчтә күлмәгең юклыгы күренмәсен.

Ун минутлап ял итеп утырдылар.

Зәбир урыныннан кузгалды.

— Урманнан чыкма. Киттем мин.

Фәиз аны җиңеннән тотып туктатты:

— Ашыкма әле. Ә авылда ишеткән булсалар?..

— Нәрсәне?

— Нәрсәне, нәрсәне. Башыңны җүләргә салма инде. Кибет басканны ишеткән булсалар? Шәһәр ерак түгел бит моннан. Андый хәбәр тиз тарала ул.

Зәбир уйланып торды. Аннары:

— Ишетелсә ни,— диде.— Алтын урлаучының мин икәнен алар белми бит. Әле тотылсам да, кибеттә минем бармагымның отпечаткалары юк бит.

— Аның каравы мотоциклда бар отпечаткаларың.

— Анысы шулай...

— Йөрмә, Зәбир!

— Ашыйсы килә бит.

— Килә шул.

— Менә нәрсә. Әгәр дә мин бер сәгатьтән әйләнеп килмим икән, димәк, мине эләктергәннәр дигән сүз. Дөресрәге, тоткарлаганнар дип аңла. Һәм яңадан урман эченә кач — бу тирәдән еракрак кит.

— Юк, синнән башка мин беркая да бармыйм,— дип кырт кисте Фәиз.

— Бала-чага булма әле! Мин сине сатмам, алай-болай тоткарласалар, качу ягын кара. Киттем мин. Барырга кирәк.

— Сак бул.

Зәбир рюкзактан бер балдак сайлап алды.

— Акча юк бит,— диде ул, Фәизнең аптырашка калуын күреп.— Авылда ашамлыклар кибете бар.

Фәиз котсыз калды:

— Тилермә! Бу балдак белән эләгәсең син.

Зәбир дустына көлеп карады:

— Бигрәк инде син... Бер дә алтын кибетен басучыга охшамагансың. Мин аны на всякий случай алам. Болай гына ризык юнәтә алмасам, берәрсенә сатармын.

— Кырыйдагы өйгә кер дә ипи белән сөт кенә сора инде.

— Иң элек шул өйгә керәм, әлбәттә. Урманда машинабыз ватылды дип алдармын.

Фәиз елмаерга тырышты:

— Син хәйләле беләсең.

— Ярый, киттем мин.

— Сак бул.

Ап-ачык болын буйлап атлаучы дустын күзәтеп ятканда Фәизнең сикереп торып аның артыннан йөгерәсе килде — дусты шулкадәр ялгыз һәм ярдәмсез шикелле тоелды. Эләкмәсә генә ярар иде. Зәбирне тотмасыннар өчен Фәиз шушы таушалып беткән рюкзакны алтыны-ние белән кемгә булса да бирергә риза иде. Зәбир ерагайганнан-ерагая барды. Җибәрәсе калмаган дип уйлады Фәиз. Әмма дустының кыю атлап баруына игътибар иткәч, исән-имин әйләнеп урманга кайтуына ышанасы килде.

## 12

Буа янындагы өй бикле иде. Зәбир урам буйлап атлады. Икенче йорт иске һәм күпне күргәнгә охшаган — черегән, чалышайган иде. Гүя дөнья авырлыгын күтәреп торып арыган да хәле беткән һәм инде аның, ниһаять, газиз җиргә ятасы килә. Менә-менә аварга торган шундый ук кыек капка янындагы утыргычта, җәйнең соңгы нурларыннан аз булса да яшәү көче өстәп, бөрешеп беткән бәләкәй генә карчык утыра иде. Аңа сиксән яшьләр булгандыр, бәлки күбрәктер дә, аның бөтен төскыяфәтен бербөтен итеп алып күзәткәндә, ул августта алмагачтан өзелеп төшеп җирдә бөрешеп яткан алманы хәтерләтә иде.

Зәбир саклык белән генә карчык янына килде:

— Нихәл, әби!

Әби аны күрәме-юкмы — анысын аңларлык түгел, томан пәрдәсе белән капланган күзләр карыйлар да, карамыйлар да шикелле иде. Аның сул кулы берөзлексез калтырап тора, уң кулы никтер күлмәк итәген йомарлап тоткан иде.

— Ни дисең, улым? — диде әби калтыравыклы тавыш белән.

— Исәнме, дим!

Карчыкның җавабы искитәрлек гаҗәп булды:

— Аллага шөкер әле, улым. Кул-аяклар гына сызлап тора менә.

Көзге яфрак сыман дерелдәп утыручы, килеш-килбәтендә яшәү төсе югалган карчыкта әле яшәү өмете бар иде.

Зәбир озакка сузмады:

— Әби, ашарга бирәр нәрсә кирәк иде.

— Ипи белән шикәр генә инде, улым, — диде әби тонык тавышын дерелдәтеп. — Пешкән әйбер юк.

— Сөтең бармы?

— Юу-у-у-к, каян булсын. Сыер асрарлык түгел бит инде мин.

Шулчак Зәбир кибетнең шушы урамда, өч-дүрт йорт аркылы гына икәнен исенә төшерде.

— Әби, кибетегез ачыкмы?

— Нәрсә ачыкмы?

— Кибет.

— Сәгать ничә соң әле?

— Әллә тагы.

Ул, әби белән әңгәмәне шундук өзеп, кызу-кызу кибеткә таба атлады.

Сатучы, егерме биш — утыз яшьләрдәге түгәрәк битле, кысык күзле хатын, Зәбиргә зур кызыксыну белән карап торды. Сатучы чибәр, әмма чыраеның туклыгы гына аның табигатьтән бирелгән гүзәллегенә каршы «көрәшеп» тора шикелле иде. Егет аңа беренче күрүдән үк охшаса да, тавышын усалрак итәргә тырышып, сатучыларга хас кырыслык белән әйтеп куйды:

— Бикләргә җыенам кибетне. Нәрсә аласың?

Кибет кечкенә булса да, алыр әйбер җитәрлек, кәнфит-прәннектер, берничә төрле җимеш, хәлвә, консервалар, тәмәке, төрле банкалар — ризык шактый күп иде. Зәбир сынаулы караш белән сатучыны күзәтте.

— Машинабыз ватылды,— диде ул, ниһаять.

— Шуннан.

— Машинабыз урманда. Тамак ачты.

Хатын аның каушавын күреп елмайды:

— Соң, ал бирәр нәрсә. Менә, хәлвә бар, прәннек, печенье. Ипи бар.

Аның елмаюы Зәбиргә бераз кыюлык бирде һәм ул:

— Акчам юк минем,— диде.

Кибетче кысык күзләрен бермәлгә генә акайтып алды:

— Ха, мин бит бушлай бирмим.

Һәм андый җөмлә килеп чыкканнан көлемсерәп куйды.

Монда озак торырга ярамый. Кибеттә кешеләр булмаганлыктан файдаланып, Зәбир тәвәккәлләде.

— Минем алтын йөзегем бар.

— Кая, күрсәт.

Зәбир чалбар кесәсеннән йөзекне чыгарып сатучыга бирде.

— Алтмыш сумга бирәм.

Сатучы йөзекне әйләндергәләп карады.

— 583 нче проба...— диде ул әле йөзеккә, әле Зәбиргә карап.

Зәбиргә бу минутлар чиксез озакка сузылган кебек тоелды. Тирләп чыкты, йөрәк еш-еш типте. Нәрсәсен алай озаклап карый инде?!. Алтын бит инде, алтын!..

— Алтмыш сум кыйммәт була,— диде кибетче хатын һәм кысык күзләрен тагын да мутландырыбрак чекрәйтте.

— Илле?

— Илле дә күп. Егермегә алам.

Сатулашып торырга вакыт булмаса да, Зәбир:

— Егерме биш ит инде,— диде.

— Ярар, егерме бишкә алам,— диде хатын һәм йөзекне имән бармагына киеп тә куйды.

Шуннан соң прәннек үлчи башлады.

— «Ювелирныйны» басканнар,— диде сатучы хатын үлчәүнең саннарына текәлеп. Бу хәбәрне ул фәлән апаның сыеры бозаулаган дигән сыманрак кына гадәти һәм пүчтәк бер вакыйга итебрәк әйтеп ташлады.

Зәбирнең йөрәгә жу итте.

— Нинди ювелирныйны?— дигән булды ул, үзе дә сизмәстән.

— Шәһәрдә... Бик күп алтын-көмеш әйбер урлаганнар.

Зәбир чак кына кибеттән чыгып йөгермәде. Шулай да ул үзендә көч тапты:

— Бу йөзек урланган түгел.

— Урман эчендә калдымыни машинагыз?

— Әйе, ватылдык.

Сатучы буш кәгазь коробкага ике шешә аракы, дүрт ипи, сигез консервы, хәлвә, прәннек, ун пачка «Прима» сигареты, ике кап шырпы тутырды һәм егерме биш сумнан өч сум сиксән дүрт тиен сдача да бирде.

— Зур рәхмәт сезгә!

Зәбир, коробканы кочаклап, ишек янына барып җиткәч, сатучы:

— Тагын алтын әйберләрең бармы?— дип сорады.

Зәбир шып туктады, борылып сатучыга текәлеп карап торды:

— Юк. Ә нигә?..
— Болай гына. Сатып алыр идем.
— Юк, юк. Бүтән юк.

Шулвакыт кибет янына мотоцикл килеп туктады. Зәбир ишекне ачты. Бусагада аңа алагаем гәүдәле милиционер очрады. Зәбир тышка чыгып җитешә алмады, кибет эчендә калды, милиционер эчкә узды. Зәбир котсыз калды һәм үзе дә сизмәстән, никтер:

— Исәнмесез!— диде.

Милиционер дәшмәде, аңа дикъкать белән бер карады да сатучыга таба атлады. Зәбир исә урамга атылып чыгуын сизми дә калды. Чыккач ул кайсы якка барырга кирәклеген онытып исәрләнеп торды. Аяклары, үзләреннән-үзләре теге карчык йортына таба атладылар. «Эләктем!»— дигән уй чигәләрне каезлады. Йөгерергә кирәк, ләкин аяклар никтер тыңламас булды. Чөнки баш эчендә: «Йөгерсәм шикләнәчәкләр»,— дигән уй да сулкылдады, ахры, шуңадыр йөгерелмәде. Шулай да, адымнарын кызулатты һәм әбинең йортына килеп тә җитте. Капка төбендә утыручы карчык кына коткарыр шикелле иде. Гомере буе Аллага табынып, намаз укып яшәгән әби иң ышанычлы, иң таянычлы кешедер сыман иде. Шул бөрешеп, шәлберәеп беткән әби генә аңа начарлык кылмас кебек тоелды. Ни әйтергә белмәгәч, ул:

— Әби, лапасыңа качыйм әле,— диде һәм, әбинең ризалыгын көтмичә, чалышайган капкадан ишегалдына кереп шылды.

Лапастан башка качыр урын да юк иде, ул шыгырдап торган кадим баскыч буйлап түбәгә менеп китте. Лапас түбәсендә печән юк иде, черек такталардан тузан куптарып ул түбәнең урам ягына мүкәләде. Такта ярыгыннан урамны күзәтә башлагач, мотоциклы тавышы ишетелде. Мотоцикл ыжгырып килде дә әби турына җиткәч туктады.

— Әби, моннан берәр кеше узмадымы?— диде милиционер.

Карчык дәшмәде. Милиционер сүгенеп мотоциклын сүндерде дә кычкырды:

— Моннан бер егет узмадымы? Кулында коробкасы да бар иде.

Зәбир үлле-мәллә хәлдә түбәдә барысын да ишетеп ятты. Бетте баш!

— Юк, узмады,— диде әби.

Зәбир үз колакларына ышанмады, шулай да әле бөтенләй харап булмадым бугай дигән өмет бугазына ябышкан куркуны ычкындырды шикелле.

Милиционер, карчыкка таба бөкрәя төшеп, кычкырды:

— Кибеттән чыккан егет турында сорыйм мин. Кайсы якка китте ул, күрмәдеңме?

«Хәзер әби аңына килер дә аның ишегалдына кереп китүен исенә төшереп әйтер бирер...»— дип Зәбир тагын котсыз калды. Әмма әбинең җавабы мең алтынга торырлык булып чыкты.

— Ә-ә-ә-ә-ә, ул бит теге урам буйлап китте,— диде әби, калага таба алып китә торган юл ягына ишарәләп.

Милиционер мотоциклын кабыза алмый интекте. Ниһаять, мотоциклга җан керде һәм ул җәһәт кенә менеп атланды да әби күрсәткән тарафка очты.

Әби алдады. Гөнаһ-фәлән диеп тормаска нәрсә этәргәндер. Бәлки саташкандыр. Мөгаен НКВДдан михнәт күргәне булгандыр. Бәлки гомер буе Аллаһы тәгалә белән сөхбәт кылып кайда гөнаһ, кайда гөнаһ түгел икәнне дин туфрагына тамыр җәйгән җаны белән тоядыр. Бәлки, гомер буе кыйблага карап, унҗиде яшьлек баланың тәкъдирен, бүгенгесен вә киләчәген укый алу сәләтенә ия булгандыр...

Мотоцикл тавышы еракта эреп юк булгач та әле Зәбир лапас түбәсеннән төшәргә куркып ятты. Нишләргә? Милиционер сизенде микәнни? Шушында качып утырыргамы? Сатучы хатын йөзек турында әйткәндер. Урманга йөгерсәм, милиционер кире борылып бу якка килер, күрер. Ә Фәиз бер сәгать кенә көтәчәк... Тагын ярты сәгать чамасы вакыт калды. Нишләргә? Фәиз китсә, ничек табарбыз бер-беребезне? Ни булса — шул!

Урамга чыкты. Әбигә карап торды, аннан берәр сүз ишетәсе килде, ләкин карчык дәшмәде.

— Рәхмәт, әби! Мин сиңа әле киләчәкмен. Мин сиңа яңа йорт салырлык акча бирәчәкмен. Рәхмәт!

Карчык ишетмәде, ахрысы. Аның кыяфәтенә «бар, тизрәк урман юлына төш», дигән теләк кенә язылган иде. Зәбир әбигә өч сум акча тоттырды да тартмасын култык астына кыстырып урманга таба йөгерде.

Әби, сикәлтәле юлдан җан-фәрманга чабучы ятимнең исән-иминлеген ходайдан сорап, аның кылган яман эшләрен ярлыкауны үтенеп, дога кылып калды.

Юлның калку урынына җиткәч, Зәбир борылып карады — эзәрлекләүче-мазар күренмәде.

## 13

Сатучы хатын кибеттә бикләнеп елап утырганда, милиционерның мотоциклы авылны чыгып кала юлында туктады. Юлда, якынтирәдә беркем күренмәде. Тирә-якны күзәткәндә авылның икенче ягындагы калкулыкта берәүнең йөгергәне күренде. Йөгерүче урманга юл тота иде. Мотоцикл үкереп авыл эченнән шул тарафка чапты. Карчык әле һаман өй турында изрәп утыра иде, милиционер үтеп барышлый яман итеп сүгенде һәм йодрык күрсәтте. Әби юлдан купкан тузан эчендә калды һәм иреннәрен чак кына кыймылдатып мәңгелек догасын дәвам итте.

Зәбирнең колагы мотоцикл тавышын тиз эләктерде. Мотоцикл үргә менгәндә ул ярты юлны гына узган иде, шулай итеп, әле урманга тагын ярты чакрымлап юл бар. Йөгерүдән туктап, әкренрәк атлады, чөнки әгәр куа килүче икән — барыбер качып котылырлык түгел, әгәр дә теге милиционер түгел икән — бигрәк тә чабудан мәгънә юк. Бәлки утыртып барырлар урманга кадәр. Ул артка борылып карарга куркып барды. Күңелдә бары бер теләк кенә яшәде — милиционер булмаса ярар иде. Мотоцикл тавышы якында ишетелгәч, түзмәде, борылып карады. Бетте! Эләкте!

Зәбир юл кырыена чыкты, мотоцикл чыелдап туктады. Милиционерның кыяфәте яман иде. Зәбир алдашу вариантларын башында кайнатты, дөресрәге алар үзләре кайнадылар, аның ихтыярыннан башка.

Милиционер мотоциклыннан төшкәнче үк акырды:

— Тукта, шакал!

Аның табак битле киң чырае киеренкелектән ап-ак булган иде, ул Зәбиргә таба атлады. Зәбирне бер тапкыр да кулга алганнары юк иде әле, шуңа күрә ул нишләргә белми аптырап торды.

— Кая барасың?— диде милиционер яман усал итеп.

— Урманга,— диде Зәбир юаш булып кыланып.

Асылда исә бу мизгелдә ул юаш түгел иде. Милиционерның шакал дип акыруы аңарда шундук нәфрәт уятты. Әмма сабыр булып карарга кирәк. Алга таба ничек булыр. Фәиз күргәндер, урман эченә качкандыр.

— Нинди машинагыз ватылды?— Милиционер, Зәбир кебек үк, ешеш сулады, әйтерсең лә, ул да җәяү йөгергән.

Зәбир машина ватылды дип ялганлауның файдасызлыгын аңлады:

— Ялганладым, бернинди машина да юк.

— Тә-ә-ә-к, кая барасың соң син хәзер?

Зәбир коробкасын кочаклап арткарак чигенде, чөнки милиционер шулкадәр ярсыды, хәтта сулышы биткә бәрелеп торды.

— Урманга. Хәзер анда иптәш малайлар, кызлар мотоцикллар белән килергә тиешләр. Бер дустымның туган көнен үткәрергә җыенабыз.

— Алдыйсың! Ну-ка күземә кара!

Карарга курыкса да, Зәбир аның күзләренә карады. Егетнең күзләреннән өлкән лейтенант ни укыгандыр — анысы мәгълүм түгел, никтер ул кинәт йомшарыбрак китте:

— Алдыйсың, брат, тагын алдыйсың. Утыр әле.

Ул үзе иң беренче булып юл кырыендагы чирәмгә утырды. Зәбир коробканы җайлап куйды да милиционер белән янәшә чүгәләде. Көн инде сүрелеп килсә дә, икесе дә шабыр тиргә баткан иде. Милиционер фуражкасы белән битен җилләтте. Зәбирнең башына әллә нинди уйлар килде: торып йөгерергәме әллә. Милиционерга көче җитмәс шул, бәреп мотоциклын алып китсәң шәп булыр иде.

— Алдамыйм,— диде Зәбир, өлкән лейтенантның бер сүз дәшми күзәтеп утыруыннан шүрләп.

— Алдыйсың, алдыйсың. Битең нишләп сыдырылган?

Зәбир кулы белән битен сыпырды:

— Котырган идек дуслар белән.

— Котырган идек. Кайдан син?

— Казаннан,— дип ычкындырды Зәбир үзе дә сизмәстән.

— Монда нишләп йөрисең?

Зәбир Каенсардан ерак түгел Тарлау исемле авыл барлыгын ишетеп белә иде. Теленә шул исем килде:

— Тарлауга кунакка килдем. Менә, туган көн үткәрмәкче булабыз.

— Рәмзиягә син йөзек бирдеңме?

Зәбирне гүя салкын су белән коендырдылар.

— Мин,— диде ул.

Милиционер шак-шок итеп бер-бер артлы сораулар яудырды:

— Күптән беләсеңме син аны?

— Күптән.

— Күптән очрашасызмы аның белән?

— Мин аның кибетенә генә керәм, шунда гына күрәм.

— Ә нигә миннән качтың?

— Качмый. Миңа бит унсигез юк әле. Миңа аракы, тәмәке не положено...

Милиционер Зәбирне җентекләп күзәтә бирде:

— Әйт дөресен. Рәмзия белән синең арада нәрсә бар?

Зәбир аптырап карап торды — өлкән лейтенантның кыяфәте коточкыч иде.

— Бернәрсә дә юк,— диде Зәбир, милиционер усал булса да, үзендә бераз тынычлану сизеп.— Мин курыктым аракы алганым өчен сез ачуланырсыз дип.

— Син, давай, тәүфикълы песи булып кыланма, бер дә юаш кешегә охшамагансың! Рәмзиягә тиктомалга ничек инде син йөзек бүләк итәсең?!. Аңлашылмый.

— Безнең акчабыз юк. Минем дә, дусларымның да. Бер кызыбыз әнисенең балдагын алып килде, шул балдакка менә аракы, закуска алдык.

Милиционер күзләрен чекрәйтеп карап торды:

— Алдыйсың,— дип кабатлады ул һаман.— Ярар, көтик әле дусларыңны.

— Алар тиз генә килмиләр әле,— дигән булды Зәбир. Ул тагын кинәт дулкынлана башлады. «Бу милиционер мине җибәрмәстер инде...»— дип уйлады ул.

— Тарлауда кемнәрең бар?

— Әниемнең сеңлесе.

— Исеме ничек?

— Галия,— дип ташлады Зәбир.

Өлкән лейтенант кашларын җыерып уйлап торганнан соң көлемсерәп куйды:

— Ул авылда Галия исемле хатын юк бугай бит.

— Бар, нишләп булмасын,— дип мыгырдады Зәбир.

Милиционер торып басты, як-ягына каранды, Зәбир дә кузгалды.

— Нишләтергә икән сине?

— Нишләтергә дип... Мин бит берни эшләмәдем. Аракыны мәгез, алыгыз...

— Рәмзия белән күптән очрашасызмы?— диде кинәт милиционер һәм аның чырае тагын аксылланды.

Зәбир ат хәтле гәүдәле милиционердан шул арада бик нык туйды, тәмам җаны бизде. Эчке сиземләү белән аның халәтен аңлады һәм ялганлауның иң дорфасын сайлады.

— Әйе, әйе, күптән очрашабыз Рәмзия белән!— дип акырды ул бөтен булынга.

— Акырма, ник акырасың,— диде милиционер тыныч кына.— Исемең ничек синең?

— Зәбир минем исемем. Рәмзиягә йөзек мин бүләк иттем, чөнки яратам мин аны,— диде Зәбир тавышын бераз акрынайтып. Ул инде эшнең нәрсәдә икәнен аңлап алган иде. Хәзер оста итеп уйнарга гына кирәк.

Милиционерда киеренкелек башкарак юнәлеш алды.

— Ник аны башта ук шулай димәдең?

Зәбир калтырана башлады, дөрес ялганладым микән, дип аңларга тырышып торды.

— Аңлашылды,— диде милиционер һәм мотоциклын кабызды.— Ул монда урманга килергә тиеш идеме?

— Әйе,— диде Зәбир инде тәмам интуициягә генә буйсынып.

— Рәмзия белән күңел ачып ятмакчы идегезме?

— Әйе.

Мотоцикл авылга таба очты. Зәбир баскан урынында катып калды. Ул әле һаман ышанып бетмәде — иреклеме ул?.. Мотоцикл ерагаеп кечерәя барды, ул тартманы алды да, һушына килеп, урманга йөгерде.

## 14

Сабитов Камил Юныс улы условниклар яши торган спецкомендатурада хезмәт итә иде. Дежур вахтаның смена башлыгы буларак, бер тәүлек вахтада торгач, ике тәүлек ял тиеш аңа. Ул көнне өлкән лейтенант эштә иде, үзе урынына ярдәмче сержантны калдырып, Каенсарга китте. Анда аның сөяркәсе Рәмзия кибеттә сатучы булып эшли. Көнче кеше буларак, сөеклесе янына ул көн саен барып йөри, хәтта дежур көннәрне дә очрашырга җай таба.

Рәмзия ирдә чакта ук очрашалар иде инде алар. Ире салырга ярата иде, аннан котылырга яхшы сәбәп иде бу — Камил ярдәмендә ирен ЛТПга озаттылар. Рәмзия белән өлкән лейтенантның мәхәббәте шактый көчле. Көнләшү бик авыр хис булса да, аның романтикасы да юк түгел иде. Ирен ЛТПга озатмаска да була иде, тик Камил шулай кирәк дип тапты — мәхәббәткә комачаулый имеш.

Иренең төрмәгә озатылуын Рәмзия барыбер авыр кичерде. Бу кадәр каты бәрелмәскә иде, дип уйлады ул. Мәхәббәт дип инде... «Гаебем зур Фәритем каршында, зур гөнаһ бу»,— дип үз-үзенә генә түгел, сөяркәсенә дә күп тапкырлар кабатлады ул. Аерылышырга иде дә инде, шуның белән вәссәлам!

Тик... Монда тагын бер җитди сәбәп бар шул. Шәһәр горпромторгында эшләгәндә Рәмзиянең растратасы чыкты, шул вакытта аны Камил үзенең ОБХССтагы дуслары белән коткарып калды. Камилгә дә бурычы зур шул аның, ул булмаса, беткән иде баш. Шуңа күрә Камил ничек тели — шулай булып чыкты, ире бер елга озатылды.

Камилнең көнләшүе җанны тынгысызласа да, аның белән Рәмзиягә рәхәт иде. Ул инде, көнләштермәс өчен, авыл ирләренә хәтта елмаерга да курка иде әүвәле. Ләкин тора-бара Рәмзия аны көнләштереп интектерүдән күпмедер дәрәҗәдә ләззәт татый башлады. Рәмзиянең күзләре

ачылды — бу милиционер аны чынлап та үлеп ярата, шуңа күрә көнләшә икән, көнләшсен! Элегрәк ул аның көнләшүен үз йөрәгенә дә якын кабул итә торган булса, вакыт үткән саен торгаш хатын көнләшү көнләшүченең шәхси проблемасы икәнлеген хәйләкәр акылы белән аңлый башлады. Ә өлкән лейтенант исә, гел Рәмзияне уйлап, аның белән саташып, кибетенә берәр чибәр егет кереп сөяркәсен тартып алыр дигән уйлар белән бимазаланды. Ул хәтта Рәмзия фатир кергән хуҗа хатын Әкълимә апага да күз-колак булырга кушты. Аның инде кайвакыт тыгыз тәнле түгәрәк бу сатучыны ташларга исәбе дә булгалады, әмма җиңел генә ясала торган адым түгел иде бу.

Әйтерсең лә, Рәмзиянең ире каргаган да милициянең өлкән лейтенантын тыныч тормыштан мәхрүм итеп, аңа хатынын тапшырып киткән. Көнләшү — мәгънәсез хис. Әгәр хатын-кыз сиңа хыянәт итә икән, бу очракта көнләшүдән мәгънә юк, чөнки көнләшеп кенә бернәрсәне үзгәртеп булмый. Әгәр дә хатын-кыз хыянәт итми икән, бу очракта көнләшү шулай ук мәгънәсез. Ике очракта да көнләшү мәгънәсезлек. Бик күп акыл ияләре тарафыннан болай дип әйтелгән: хатын-кыздан көнләшү һәм гомумән көнләшү — кеше күңеленең иң хәшәрәт почмагы. Көнләшүгә дучар ителү — җәза, моны көнче кеше бик яхшы белә. Гөнаһ өчен бирелә көнләшү дә. Кеше үзен көчсез, булдыксыз итеп хис иткәндә көнчегә әверелә, үзен шәхес буларак импотент итеп сизгән саен аңарда көнләшү хисе арта бара һәм ул, ниһаять, садистка әверелә башлый. Әмма бу халәт көнләшү объектына кайгы китерсә дә, иң беренче чиратта ул көнченең үзенә — зур фаҗига. Мондый җәза нинди дер гөнаһ өчен буладыр. Көнләшү үзе гөнаһ түгелме? Бер гөнаһ икенчесен тудыра. Тагын божра тоташа!

Көнләшүнең табигатен өлкән лейтенант Сабитов белми, аңламый, бу коточкыч хисне җиңәрлек көч аның таза гәүдәсендә һәм кокардалы фуражка эчендәге башында да юк. Хатыны белән аерылгач, ул үзеннән үзе шикләнеп йөрде. Аны гаепләүче булмаса да, ул үзен никтер булдыксыз дип санады. Менә Рәмзия белән танышты. Очраша башладылар һәм ничектер бер-берсенә хуш килделәр шикелле. Әмма Рәмзия белән дә аерылышу ихтималы алдан ук кытыклый башлады. Беренче хатыныннан аерылганнан соң барлыкка килгән икеле-микеле уйлар йөдәтте.

Һәм менә — көнче кешегә туры килеп тора бит ул — кибеткә кергәндә чибәр яшь егет Рәмзия яныннан чыгып килә. Таныш түгел, ләкин исәнләште. Исәнмесез, ди. Мыскыл итә, хайван! Рәмзия янына килгән. Элек монда күренгәне юк иде бу егетнең. Нахал, исәнләшә бит әле ул.

Егет артыннан ишек ябылгач, Камилнең ярсуы бәреп чыкты:

— Кем бу?!

Рәмзия сискәнеп китте, чөнки милиционерның акыруы каты чыкты.

— Ник кычкырасың! — диде Рәмзия, сөяркәсенең яман кыяфәтеннән куркып.

— Кем иде ул?

— Бу егетме?

— Әйе.

— Кайдан белим. Сатып алучы. Продукты алырга кергән.

— Алдыйсың.

— Нишлисең си-и-и-ин? Камил, акылыңа кил инде.

— Нишләп сез икегез генә идегез кибеттә?! — дип ярсып кычкырды Камил.

— Башка кеше булмаганга! — дип кычкырды Рәмзия аптырагач. — Мин гаепләмени аның берүзе кибеткә кергәненә?!

Соңгы вакытта Рәмзиянең мондый допрослардан саруы нык кайный иде. Әкренләп кузгала башлаган нәфрәт вулканы чәчрәргә генә тора. Туйдырды бу көнләшүләре, тәмам гарык булды ул. Кинәт бу милиционерны күралмый башлады. Мондый минутларда ул үзенең рәнҗетелгән, мыскыл ителгән ирен исенә төшерә һәм күңелендә ничек тә булса бу

милиционердан үч алу теләге туа. Менә бит хәзер дә акылыннан язар дәрәҗәгә житеп көнләшә, әйтерсең лә, Рәмзия анык ы, башка беркемнеке дә түгел.

Рәмзия күзләрен чекрәйтеп карап торды да кинәт үзе дә сизмәстән әйтеп ташлады:

— Чукын инде! Дөресен әйтәм — минем яныма килде ул егет. Гашыйк булган миңа. Син дә бит миңа гашыйк булгач, иремне төрмәгә утырттың, мине үзеңә тартып алдың.

— Дәшмә, сука! — дип кычкырды Камил. Йөгереп барып ишекне эчтән бикләде. — Чынлап әйтәсеңме?

Рәмзия дә кычкыра башлады:

— Миңа гашыйк булуын әйтте. Менә, йөзек бүләк итте.

Камил, өнсез калып, тораташ булып катты.

— Сезнең арагызда берәр нәрсә булдымы инде?

— Әлегә юк, — диде Рәмзия, шундый удар ясый алуына куанып һәм бер үк вакытта шөлләп.

Шундук Камилгә болай дип әйткәненә үкенеп тә куйды. Чөнки, ни дисәң дә, ничек кенә булмасын, Камил аны растратадан коткарды. Аннары... мәхәббәт хисләре дә сүрелеп бетмәгән бит әле.

Шуннан соң инде Камил мотоциклына атланып ары-бире чапты һәм Зәбирне куып житеп сөйләште.

Кире кибеткә килгәндә аның кыяфәте чарасызлыктан саргаеп калган иде. Рәмзия елап шешенеп беткән битен яшерергә тырышты.

Камил кереп ишек катында басып калды.

— Ишекне биклә, — диде Рәмзия сулкылдап.

Камил ишекне бикләде һәм прилавкага утырып сөяркәсенә карап катты.

— Нәрсә? — диде Рәмзия, ник алдашканына үкенеп.

Камил дәшмәде.

— Гафу ит мине, — диде Рәмзия, аның иңенә таянып. — Ялганладым мин. Ачуым килде дә... Ул егет минем янга килмәгән иде. Машиналары ватылган урманда. Акчасы булмагач, менә бу йөзекне калдырды. Егерме биш сумга сатты.

Камил кинәт һушына килде, хатынның кулын алып атты:

— Нәрсә тагын алдашасың инде! Мин бит ул егетне куып тоттым, сөйләштем.

— Шуннан?

— Мин Рәмзия белән күптән очрашам диде. Йөзекне бүләк иттем диде.

Рәмзия ни әйтергә белми аптырап торды һәм чарасызлыктан елмаясы итте:

— Боларын инде үзең уйлап чыгардың.

— Бар, ул сине урманда көтә! Нишләп ашыкмыйсың?!

Рәмзия ышанмыйча карап торды:

— Шаярасыңмы, әллә инде көнләшүдән тилерәсеңме?

— Сез бит урманда очрашырга тиеш икәнсез. Ул көтә сине аракы, закускалар белән.

— Ярар, теләсә ни сөйләшеп утырма инде. — Рәмзия халатын салып кофтасын киде. — Әйдә, биклим кибетне.

Камил хатынның тынычлыгына гаҗәпләнде. Кинәт ул акырып жибәрде:

— Сука! Хыянәтче! — һәм Рәмзиянең яңагына сугып жибәрде. Рәмзия чак кына егылмый калды:

— Нишләвең бу, Камил? Милиционер башың белән... Минем бер гаебем дә юк бит... Ник көнләшәсең инде... Минем бит синнән башка беркем белән булганым юк, очрашканым юк, теләгем дә юк.

Рәмзия прилавка артына посты, Камил икенче якта кыжрап торды.

— Ул бит миңа бөтенесен сөйләде.

— Нәрсә сөйләде?— Рәмзия аңларга тырышып кашларын җыерды.— Ул молокосос нәрсә сөйли ала минем турыда?!

— Синең белән очрашам, диде. Яратам, ди, сине.

Рәмзия акыллырак, дөресрәге, аек акыллырак иде. Ул эшнең нәрсәдә икәнлегенә тиз төшенде. Һәм тыныч кына әйтте:

— Син миңа бүтән сукма. Милиционер дип тормам. Синең миңа сугарга хакың юк. Ә хәзер мине тыңла. Тынычлан. Тыңла. Минем андый бала-чага белән чуалганым юк. Аннары, синең белән гел очрашып торабыз, синнән башка беркемем юк — моны яхшы беләсең. Шул чукынган көнләшүең аркасында гына тилерәсең. Син аны куып җиткәч, Рәмзия янына килгән идеңме, дип төпченә башлагансыңдыр. Син бит гел шулай. Мине берәр ир белән күрсәң, барып сораштыра башлыйсың. Ул егет аңлаган синең көнче икәнеңне. Һәм синнән котылыр өчен минем янга килдем дип ялганлаган. Ә син, тиле, шуңа ышанып, монда чапкансың.

Камил тынычлана башлады:

— Ә нишләп менә нәкъ алай дип алдаган соң ул? Нишләп башкача алдамаган ул?!

— Башлы егет ул, димәк. Тагын ничек дип алдасын? Син кибеткә килеп кергәч, котсыз калды бит ул, хәтерлисеңдер. Син аны кулга алырга килгәнсең, дип уйлады бит ул.

— Ә нишләп курыкты соң ул? Ник мин аны кулга алырга тиеш?

— Син һаман бернәрсә дә аңламадыңмыни?

— Юк.

— Ювелирный кибетен басучыларның берсе шул бит, бу йөзек кайдан килгән дип беләсең?

Камил көнләшү өянәгеннән арына алмаса да, Рәмзиянең сүзләреннән милициягә хас сагаю белән катып калды. Чыннан да... нишләп Рәмзиянең сөяркәсе булсын инде ул шалапай...

— Син аның кибет басучы икәнен кайчан аңладың соң?

— Минме? Кибеткә килеп керүгә үк шикләндем мин аннан. Ә инде йөзек тәкъдим иткәч, тәмам ышандым. Кыяфәтеннән үк күренеп тора иде бит. Син генә ул көнләшүдән тәмам исергәнсең. Милиционер!

Камил нишләргә белмәде. Хәзер ул егетне куа чыкса барыбер тота алмаячак. Отделга хәбәр бирсә, нишләп дежурство вакытында Каенсарга барып чыктың дип сорарлар. Аннары, ниһаять, ул аның эше түгел. Кибет басучылар белән шөгыльләнүчеләр болай да муеннан җитәрлек.

— Рәмзия, чыннан да, кибет басучыга охшаган иде бит ул.

— Шулай булмый.

— Нишләп соң син башта мине алдадың, гашыйк булып йөрүче егет дип?

— Сиңа ачуым килде. Көнчелегең белән җелегемне корыткасың бит инде.

— Ник миңа кибет басучыдыр бу дип шундук әйтмәдең?

— Беренчедән, йөзек миңа егерме биш сумга гына төште. Ул егетне кулга алсаң, мин бит йөзектән мәхрүм була идем. Икенчедән, кызгандым мин ул егетне.

— Нишләргә?

— Бернишләргә түгел. Тынычлан. Аларны барыбер тотырлар инде. Бу йөзекне миннән тартып алырлармы икән?

— Белмим. Карале, Рәмзия, аны куа чыксам, урманда тоталмам инде. Тотсам, анда шул кадәре алтын...

— Ә тотмасаң? Син аларны урманда тоталмыйсың. Эзләп йөрергә вакытың да юк, сине инде спецкомендатурада югалтканнардыр.

Камил бөтенләй югалып калды. Үзен мескен хәлдә хис итүе, борын төбеннән шул егетне ычкындыру, Рәмзиядән көнләшүе, спецкомендатурадан вахтаны ташлап монда йөрүе — бөтенесе бергә җыелып, бер зур гаеп хисе булып җанны ашады. Ә асылда исә бу башка бер зур гөнаһның күптөрле чагылышлары иде.

Ул сәгатенә карады. Бер шешә аракыны алып кулында әйләндергәләп торды. Алар икесенә шул бер ярты аракыны эчтеләр. Склад вазифасын үти торган бүлмәдә аларның иске матрацлары бар иде, аны көнбагыш мае саклана торган мичкәләр артына җәеп салдылар.

— Ишек бикле микән соң?

— Бикле, бикле.

Өлкән лейтенант сөяркәсен кайнар итеп үбә башлады, тегесе кинәт мәлҗерәеп аның колына авырелде.

Алар ыңгырашып мәхәббәт белән шөгыльләнеп ятканда Зәбир урманда иде инде.

Ялгыз карчык капка төбеннән һаман китмәде. Әллә аның догасы коткардымы Зәбирне өлкән лейтенант Сабитовтан? Зәбир алдашмаса һәм милиционер ялгышмаса, бәлки гөнаһның кайсына булса да нокта куелыр иде? Ә бәлки, киресенчә, яңа фаҗигаләр, яңа гөнаһларның башы булыр иде бу.

Кибет эчендә ыңгырашу туктады.

— Гафу ит мине,— диде милиционер.

— Арыдым мин,— дип җавап бирде Рәмзия.

— Миннәнме?

— Арыдым, туйдым, гомумән дөньясыннан.

— Алай димә инде.

— Барыбер бәхетле булмаячакмын мин.

— Ник алай дисең?

— Шулай менә... Кешене бәхетсез итеп, бәхетле булу мөмкин түгел. Менә без синең белән ни бер-беребезне тәмам ташлый алмыйбыз, ни бәхетле булалмыйбыз. Иремнең каргышы төшмәс дип уйлыйсың мәллә?

— Ул сиңа кешеләрчә яшәргә ирек бирмәс иде.

— Нәрсә, бүгенге тормышым кешеләрчәме әллә?

Гөнаһ үзе яңа гөнаһлар тудыру сәләтенә ия — моны капка төбендә тәсбих тартып утыручы әби белә, ләкин ник алай икәнен аңлата алмый. Гомер йөген озак еллар сөйрәгән карчык гөнаһтан качу өчен гөнаһ кылу мисалларын да меңәрләп китерә алыр, әмма нидән бу һәм дә мәгънәсе нәрсәдә — әйтә алмас. Бер бөҗра эчендә кайный торган бу хәят, бербөтен зур гөнаһ буларак, кайгының да, бәхетнең дә чыганагы түгел микән?.. Бәлки шуңа күрәдер, урман ягына да күз салып, кибет янындагы мотоциклга да игътибар итеп, әби, һәммәбезне ярлыкауны сорап кат-кат дога кыладыр. Һәркемнең үз гөнаһы барлыгын әби яшь-яшь аңлаган, бу хакыйкатькә ул ишетеп түгел, гомер итеп ирешкән. Һәркемнең үз гөнаһы бар, гөнаһлар кайвакыт очраша, алмашынып, яңа гөнаһ булып, кемнеңдер җанына асылына. Бәлки бөҗраны өзәр өчен, гөнаһлар үрчемәсен дисәң, үз гөнаһыңны үзеңдә генә саклап, аңа чыгарга юл бирмәү кирәктер. Ә үз гөнаһың үзеңнеке генә була аламы соң?.. Аның башы кайда, кайчан башланган — кем белгән! Үзеңдә генә калдырган сурәттә яман гөнаһ үзеңне җәзалап үтермәсме? Нигә кирәк бу? Гөнаһлы булудан теләсә кем җәзага ирешми. Гөнаһны һәр кеше үзенчә кичерә. Шуңа күрә берәүдә бикләнеп калса, икенче берәүдән шул ук гөнаһ чыгарга мөмкин. Бер үк гөнаһ та тигез бирелми бит әле. Юк, аның ниндидер бер җинаять өчен гөнаһы шул бер үктер инде, фәкать аны кичерү, җанда асрау авырлыгы һәм дәрәҗәсе тигез түгел, үзгә.

Инсаният дөньясының чистарынасына ышанычын югалтканга микән — карчык көннәр буе пыш-пыш дога укый. Бәлки, киресенчә, әле өмет булганга Алладан ярлыкау сорыйдыр. Аның гомер кояшы инде баеп килә. Мәңгелектән мәңгелеккә китеп баручы бу олы җанлы карчык сиксән ел яшәп, бу хәяткә нинди мөнәсәбәт белән китә — әйтеп булмас. Моны ул хәтта үзе дә белми. Шуңа карамастан, аның вөҗданы гөнаһ җәзасыннан инсаннарны коткаруны тели. Аның вөҗданы өчен җинаятьче дә, шул җинаятьчене эзәрлекләүче дә бертигез. Чөнки ул белә: чистарыну гөнаһлы белән гөнаһлының көрәшеннән башлана алмый. Алай гына да

түгел, аларның икесе дә гаепле, шул ук вакытта гаепсез дә. Һәркем хаклы һәм гаепсез бу дөньяда.

Ә бәлки һәркем гаепсез һәм хаклы булганга күрә, һәммәсе гаепле һәм гөнаһлыдыр?..

Җир шарындагы хәят дәвам итте. Шул коточкыч кайнауның уртасында ялгыз карчык, һәммәбезгә мәрхәмәт вә иганәт сорап, Күк белән сөхбәт кылып утыра иде.

## 15

Зәбир артына борылып карады — милиция мотоциклы авыл янындагы калкулыкта иде инде. Ул бераз хәл алырга туктады. Урман якын инде. Фәиз качкандыр, дип уйлады ул. Милиционерны күргәч җан-фәрманга урман эченә йөгергәндер.

Авыл ягына тагын бер борылып карады да (мотоцикл инде күренмәде) йөгерде.

Урман авызына җиткәч туктады. Хәзер инде кай тарафка баруны чамаларга кирәк иде. Фәизне табу мөмкин булырмы, юкмы? Шунысы куркыныч, ул үзе генә харап булачак — каушап, югалып калачак, алай-болай тотылса, барысын да сөйләп бирүе ихтимал. Урман эченнән берничә адым атлагач, ул кычкырып дәшеп карады. Ләкин авызын ачуы гына булды, куаклар арасыннан берәүнең тавышы ишетелде:

— Зәбир!

Бу — Фәиз иде.

Алар күп еллар күрешми торганнан соң очрашкандай, шатырдатып кочаклаштылар.

— Фәиз! Мин сине инде качкандыр дигән идем.

— Син нәрсә, ялгызым кая барыйм мин. Нәрсә булды? Нинди милиционер иде ул? Мин күзәтеп яттым.

— Әйдә тизрәк, киттек, бара-бара сөйләрмен.

Алар урман эченә ашыктылар. Зәбир барысын да бәйнә-бәйнә сөйләде.

— Мин инде харап булдык, тотылдык дип уйлаган идем, — диде Фәиз ял итәргә туктагач.

— Мин үзем дә шулай дип уйлаган идем. Ә ул көнче күбәләк, сөяркәсе өчен борчылып йөрүче мент булып чыкты.

Шулай да бу милиционерның очравы нык куркытты. Алар урман эченәрәк керергә ашыктылар. Бу тирәдән ераккарак китү мәслихәт иде.

Хәйран ерак ара үткәннән соң усаклык уртасындагы кечкенә бер аланда тамак ялгарга утырдылар. Авызыннан гына бер шешә аракыны эчеп бетерделәр һәм бик тиз исерделәр. Булган ризык белән тамак ялгап, тәмләп тәмәке тарткач, кинәт кәефләр күтәрелеп китте. Ләкин бик нык арылган иде. Кояшның баеп килүе күңел шатлыгын шундук сүрелдерде. Агач ботакларыннан ашык-пошык шалаш ясадылар, шалаш кечкенә булып чыкты, аның каруы җылырак булыр диделәр. Шалашка кереп яткач сүз дәшмәделәр һәм каты йокыга талдылар.

Таң беленгәндә алар инде аякта иде. Беркавым сикергәләп, кул-аякларны болгап алгач, җан кергәндәй булды, әмма алан салкын, дымлы булганлыктан туңдырып калтыратты. Ныгытып җылыныр өчен икенче шешәне дә бушаттылар. Аракы шундук башка китте, җылытты, дәрт һәм дәрман бирде. Ашап та куйгач, шул кадәре рәхәт булып китте ки, хәтта шушы халәттә мәңгегә урманнарда калырлар иде, ахрысы.

— Яшибез, туган! — диде Зәбир, дустының иңен шап-шоп кагып.

— Мин теге милиционердан гына шикләнәм, — диде Фәиз.

— Юу-у-у-к, ул үзенең сөяркәсе белән мәшгуль, җинаятьчеләр белән кызыксына торган ментка охшамаган ул.

— Эләкмәсәк ярар иде.

— Йә, йә, тагын коелып төшәргә маташасыңмы. Эләкмәбез.
Аракы шаукымы Фәизгә дә кыюлык өстәмәде түгел. Ул рюкзакны ачып карап торгач:
— Карале, безнеке бит бу! — дип куйды.
— Шулай шул. Безгә хәзер тизрәк бөтенләй еракка, портлы шәһәргә ычкынырга кирәк. Шуның өчен башта Казанга барырга тиешбез, аннан поезд белән китәрбез.
— Вокзалларны тикшерәләрдер инде. Ювелирныйны баскач бөтен милиция аяктадыр.
— Белмим. Беребез башта разведкага барып килер — ничек анда вокзалда хәлләр. Сак булырга кирәк. Каушамаска кирәк — иң мөһиме шул.
— Чыннан да, каушамаска кирәк главное, — дип куйды Фәиз дә. — Алай бөтен җирне милиция алган булса, без бит алтынны урманда берәр җирдә күмеп куя алабыз.
— Молодец, Фәиз, синең дә башың эшли башлады, — диде Зәбир һәм дустының батыраюына куанып шаркылдап көлеп куйды. — Алай-болай алтын белән китү мөмкин булмаса, алтынны бит еллар үткәч тә казып алып була.
— Армиягә алып китәчәкләр бит.
— Әй, чукынсын ла армиясе! Бүтән чара булмаса, барып хезмәт итеп кайтырбыз. Алтынны гына әйбәтләп яшереп калдырырга кирәк.
Бу идея Фәизгә бөтенләй үк ошый башлады:
— Зәбир! Карале, чынлап та, без болай рисковать итеп йөрмик, алтынны ышанычлы урынга яшереп куйыйк. Бу урманнан якты дөньяга чыгып бераз яшик, аннары күз күрер — нишләтергә бу алтынны, ничек аңардан файдаланырга. Без бит инде ни көтүен белмибез. Бәлки һәрбер кешене туктатып тентиләрдер, кая булдың фәлән көнне дип сорыйлардыр. Аннары бу милиционер да шикләнми калмас, ул да отделга хәбәр биргәндер инде.
— Ничек булса да, безгә хәзер Казанга барып чыгу зарур. Алтынны Казан янындагы урманда яшерербез, чөнки теләсә кайсы җайлы моментта алтынны казып алып, поездга утырып китәчәкбез.
Зәбир тагын да зәһәрләнебрәк китте. Күзләреннән очкыннар чәчри диярсең. Ниһаять, ташып чыгарга торган энергиясен тыялмады — сикереп торып бии башлады. Фәиз дустына карап сокланып утырды. «Биргән бит ходай гәүдәне дә, чибәрлекне дә, осталыкны да».
— Зәбир, син акчасыз, алтынсыз да бәхетле булыр идең.
Зәбир биюдән туктады һәм, еш-еш сулап, дусты белән янәшә утырды.
— Ник алай дисең?
— Ник дип... Чибәр, житез, көчле. Кызлар гел сиңа гашыйк булалар. Хәтта әнә теге милиционер да синнән шул хәтле көнләшкән бит.
— Шуннан нәрсә? — диде Зәбир, көчкә сулыш алып.
— Бернәрсә дә түгел. Нишләп мин синең шикелле түгел икән?
Фәизнең үзен ким-хур итеп тоюы Зәбиргә дә бик авыр тәэсир ясый иде. Андый вакытларда ул һәрвакыт дустының кәефен күтәрердәй сүзләр таба, гомумән, төшенкелеккә бирелмәс өчен чара юллый иде.
— Моңайма, моңайма, — диде ул, ахири дустының иңенә авыр кулын куеп. — Аның каруы, син матур җырлыйсың. Зиһенле. Китаплар күп укыйсың, күп беләсең...
— Ярар, ярар, юатма, — диде Фәиз елмаеп. Төчерәк булса да, дусты әйткән сүзләр бик кирәкле, җылы сүзләр иде.
— Сөенергә кирәк — алтыныбыз күп! Тамак тук!
— Алтын... Аның яртысы көмеш бит.
— Барыбер күп.
— Бигрәк кызык. Менә шуның кадәре алтын булса иде дип күпме хыялланып йөрдек ләбаса. Менә, пожалуйста, алтыныбыз бар!

— Син, туган, төшенкелеккә генә бирелмә. Җебемә! Бөтен нәрсә тәртиптә булачак.

— Димәк, Казанга таба юл тотачакбыз?

— Әйе. Әгәр мөмкин булса, бәлки Казаннан туп-туры Мәскәүгә китәрбез. Мәскәүдән йә Мурманскига, йә Владивостокка.— Ул як-ягына карап бөтерелде.— Тәк... Кояш бу яктан чыкты... Димәк, Казан әнә теге яктарак булырга тиеш.

Фәиз тагын уйга батты:

— Белергә иде, безне эзлиләр микән инде?

— Әлбәттә кибет басучыларны эзлиләрдер,— диде Зәбир ачуланып.— Әмма ләкин безне эзлиләрдерме, башка кешеләрнеме, анысы мәгълүм түгел. Тагын җеби башладыңмы? Җебемә!

Фәиз дустына карап елмайды:

— Ярый син бар әле!

Сөйләшмичә генә тәмәке тарттылар. Шуннан соң кузгалдылар да Казанга таба киттеләр.

Катыш урман куерганнан-куера барды.

## 16

Ешлыкны аралау тәмам кыенлашкач, сулгарак каерылырга булдылар. Бу авыр сәфәрнең азагы булмастыр кебек тоелды. Инде әллә ничә тапкыр ял итәргә туктадылар. Инде күп мәртәбә җан тирләре бәреп чыкты. Ләкин атларга, барырга кирәк иде. Кая булса да барырга. Туктап калу ярамый. Һәм туктап калу хәзер инде мөмкин дә түгел. Курку, билгесезлек һәм кылган җинаять өчен гаеп хисе авыр йөк булып күңелләргә асылынды. Әмма икенче яктан, шулай ук хәйран авыр йөк булып капчыктагы алтын-көмеш тагылган иде. Шул сәбәпле күңелдә якынча тигезлек тә әлегә бар сыман иде.

Тамак ялгагач, иртән эчкән аракының шаукымы тәмам беткәч, айнып китү куркуны бермә-бер арттырды.

Урман куелыгыннан алҗып тагын бераз сулгарак юл тоттылар. Бәхеткә, урман отыры сирәгәйде.

— Якын-тирәдә су бар, ахрысы,— диде Зәбир туктап.

— Шулай бугай шул. Су исе килә. Сизәсеңме, черки дә күбәйде.

— Әйе. Елга микән, күл микән. Әйдә, атлыйк, якында булырга тиеш ул.

Беркавым баргач, мүк һәм торф исе белән куерган дымлы җылымса һава битләргә бәркелде.

— Сазлык бу!— диде Фәиз, чыраен газаплы итеп сытып.

— Тәк, уңга борылырга туры килер.

— Уңга микән? Сулга түгелме?

Зәбир як-ягына карап уйланып торды, аннары башын күтәреп кояшны чамаларга тырышты.

— Юк, уңга,— диде ул, катгый итеп.

Сазлык аша чыгарга җөрьәт итмичә, килгән юнәлештән уңга каерылып, алар сазлык яныннан каты җиргә басып бардылар.

Тынчу, шомлы сазлык кырыеннан бару бик озакка сузылды. Тагын ял итәргә туктадылар.

— Бу сазлыкның бетәсе юк, бугай,— диде Фәиз һәм лап итеп җиргә ауды.— Карале, әбизәтелне сазлыкның теге ягына чыгара кирәкме безгә?

Зәбир, аһ-ваһ килеп, янәшә утырды:

— Әйе. Казан шул якта.

Кинәт Фәиз көтелмәгән тәкъдим ясады:

— Алайса, әйдә сазлык аша чыгып карыйк. Зәбирнең күңелендә сазлыкны ерып чыгу теләге булса да, «Фәиз сазлыкка керергә батырчылык итмәс» дигән уй аны бу тәкъдимнән тыеп килде. Ә хәзер, менәтерә, Фәиз үзе шулай киңәш итә. Зәбир, дусты шаяртмый микән дип, карап торды.

— Чын әйтәсеңме син?— диде ул аптырап.
— Ник, чын әйтәм.
— Синме бу?!— диде Зәбир, елмаеп.— Мин сиңа бу тәкъдимне күптән ясамакчы идем, ләкин син каршы килерсең дип тыелып килдем.
Фәиз авызын кыйшайтып елмайгандай итте дә башын читкә борды:
— Кибет басып чыккан Фәиз сазлыкка керергә курка дип уйлыйсыңмы әллә син? Тик менә аны кичеп чыгарга хәл җитәр микән?
— Җитәр, җитәр!— диде Зәбир кабаланып.— Әйдә, бу сазлык бик киң түгел бугай.
— Әйдә,— диде Фәиз, кузгалып.— Без инде болай да сазлыкка кереп баттык бугай.
Аның соңгы сүзләре Зәбиргә көтмәгәндә авыр тәэсир ясады. Ул туктап дустына карап торды:
— Алай димә, Фәиз. Чыгачакбыз без бу сазлыктан да, башка сазлыктан да.
— Әйдә, таяклар әзерлик,— диде Фәиз ишетелер-ишетелмәс итеп.
— Таяк түгел, күсәк кирәк монда.
Алар берәр юан һәм озын таяк белән коралландылар.
— Тиз-тиз атларга кирәк булыр,— диде Фәиз суга керергә чирканып карап торганда. Әйтерсең лә, аның сазлыклар аша йөргәне бар.
Зәбир сазлык өстенә күз салды. Илле метр ераклыкта инде томан иде, бәлки томан артында сазлык тәмамланадыр да. Яшелләнеп беткән су өстеннән зур-зур түмгәкләр, куаклар, кәкре таяклар чыгып торгач, сазлыкның шомлылыгы бераз кими шикелле иде.
Зәбир тирән итеп сулап куйды:
— Күрәсеңме, нинди зур түмгәкләр бар, димәк чыгабыз без бу сазлыкны. Киттек!
Таякларына таянып, алар суны ерырга керештеләр. Сазлыкка керүгә үк су тезгә җитте, түмгәкләр дә күзгә күренеп сирәгәя башлады. Иң котны алганы — су эчендә аяк астының тирбәлеп торуы иде. Баскан җир ныграк тирбәлгән саен кызурак атларга тырыштылар. Сазлыкның чигекырые күренмәде. Абынып егыла-егыла киемнәре лыч булды, бара торгач, хәтта билдән тиң үк чумгаладылар.
— Әйдә, кире борылабыз,— диде Фәиз егылган җиреннән мүкәләп торгач.
Зәбир да каршы килмәде. Ләкин алар килгән якта да томан иде инде. Бата-чума барырга туры килгәнлектән, алар кире борылабыз дип ялгыш юнәлештә китеп бардылар.
— Адаштык!— диде Зәбир ачынып һәм бер олы түмгәккә килеп утырды.
Фәиз, әлсерәп, аның кырыена ауды.
— Керәсе калмаган сазлыкка.
Алар лыч булып пычранып беткәннәр, рюкзак та юешләнеп бермәбер авырайган иде.
Тирә-якта гел сазлык кына, өстә җәйрәп яткан яшькелт су астында упкын бардыр сыман иде.
— Без моннан килмәдек бугай бит,— диде Фәиз куркудан дерелдәгән тавыш белән.
— Адаштык,— дип җавап бирде Зәбир.
Тагын кузгалдылар. Кинәт Фәиз билдән тиң лайлага төшеп китте. Зәбирнең көчле куллары аңа шундук тиз генә чыгарга ярдәм итте.
— Дөрес барабызмы?— дип шыңшыды Фәиз.
— Дөрес бугай. Әнә теге куаклар артында бетә бугай сазлык.— Ул йөз адым чамасы ераклыктагы куакларга ишарәләде.
Фәиз күзләрен чекрәйтеп карап торды, ләкин берни аңлый алмады. Абына-сөртенә, чокырларга бата-чума, болганчык суда тончыгып алар шактый бардылар. Теге куаклар якынлашты һәм тагын даерактарак томан аша зәңгәрсу булып урман күренде шикелле.

Кинәт Зәбир чапылдап чокырга төшеп китте һәм бата да башлады. Фәиз алдарак иде, кире борылып дустына таба ашыкты.

— Лайла монда! Тирән!— дип кычкырды Зәбир.— Кермә!

Фәиз туктап калды. Шул арада Зәбирнең гәүдәсе лайлалы су өстеннән билдән тиң генә чыгып калды.

— Мә рюкзакны!— дип кычкырды ул ямьсез тавыш белән.

Фәиз якындагы түмгәккә ятып кулын сузды, Зәбирнең калтыранган кулыннан манма су булган рюкзакны эләктереп алды. Икенче кулын Зәбиргә сузды, әмма куллар кушылмады. Ул, сикереп торды да як-ягына каранды — куәсәк яки таяк-мазар күренмәде, ә үзенең колгасын ул инде күптән югалткан иде. Шулчакны ул дусты бата башлаган чокыр янында куак барлыгына игътибар итте.

— Куакка тотын!

Зәбирнең кулы куакка җитмәде. Ул инде түшеннән баткан иде.

— Бир кулыңны!— дип кычкырды Фәиз һәм тагын түмгәккә ятып сузылып карады.

Зәбирнең куллары лайлалы су өстеннән калыккан иде, ләкин ул берсен дә Фәизгә сузалмады. Гәүдәсе киерелеп, аның куллары, Аллага ялваргандагы сыман итеп, бите алдында торараш булып каткан иде. Ул күзләрен акайтып авызын ачты... нидер әйтмәкче булды... әйталмады. Кулларын өскәрәк күтәрде, бер кулы Фәизгә таба сузылды кебек. Фәиз кулын тагын сузды. Ныграк сузарга да була түгелме?.. Әйе, ул эчке сиземләү белән сизде — кулны ныграк сузып була, тик... нәрсәдер комачаулый шикелле... Сузарга кирәк кулны... Ныграк сузылса, Зәбирнең кулын эләктереп була... Куркыта мәллә... Нәрсә бу?! Кулын сузган килеш ул, дустының хайвани курку белән үкерүеннән котсыз калып, түмгәккә ятты. Ныграк сузып була түгелме кулны?! Нишләп куллар кушылмый соң? Бу сиземләү яшен тизлегендә, мизгел булып, аңны ярып үтте. Кул Зәбирнекенә таба сузылса да куллар кушылыр алдыннан гына үзеннән-үзе артка тартылган шикелле була... Үзеннән үзе түгел, ниндидер көч куллар кушылуына каршы, ахрысы. Кулны ныграк сузып та була шикелле, шул ук вакытта мөмкин дә түгел бугай. Бу мизгел Фәизгә гомере буе тынгылык бирмәячәк.

Зәбир инде муеннан кереп баткан иде. Лайла өстеннән аның чем-кара бөдрә чәче, акайган күзләре һәм җанварларча үкерүе генә калкып калды. Ул берничә тапкыр тончыгып алды. Йөткерә-йөткерә, пошкырып ул тагын акырды. Соңгы чиктә инде ул яшәүгә, бу дөньяга тешләре белән ябышырга әзер иде бугай.

Фәиз тагын кулын сузып карады. Бәлки чәченнән эләктерергәдер. Юк, кул җитми. Юк, коткарып булмый...

Коточкыч төш шикелле күренеш иде бу. Фәиз нишләргә белмәде, бу вакыйганы ул булганынча аңларлык халәттә түгел иде инде. «А-а-а-ы-ы-ы» дигән кыргый авазны тамак төбеннән ертып чыгарып, ул абынасөртенә сазлык буйлап мүкәләде. Әллә нинди тирән чокырларга төшеп чумды. Торып тагын йөгерде. Һәм кинәт зур, коры түмгәккә абынып егылды.

Шактый вакыт һушсыз ятты. Тәмам аңын җуярга әле яңа гына кичергән вакыйганың коточкычлыгы ирек бирмәгәндер — күзләрен ачты. Рюкзак үзе белән иде. Коры җир ерак булмаган икән югыйсә. Томан аркасында гына күренмәгән. Башын калкытты. Менә бит ул алар качып йөргән урман. Шушы яктан килделәр бит алар.

Аңы кинәт тәмам ачылып китте. Ул сикереп торды да яңадан батачума дусты батып яткан тарафка ашыкты. Башы эшләмәсә дә, аяк астын абайламыйча барыр юлына игътибар бирмәсә дә, ни гаҗәп, инстинктив рәвештәдер, күрәсең, ул тиз арада инде кабат **шул урында** басып тора иде. Катып калган гәүдәсе, манма су булса да, җебеп бетәрлек түгел иде. Зиңкүләнгән башын эшләтеп аңны туплыйсы килде. Менә **ул урын**. Менә теге түмгәк. Әнә теге ярдәмсез куаклар. Менә ул... **сазлы чокыр**. Анда

инде күбек кенә йөзеп йөри. Аннан Зәбир калкып чыгар сыман. Юк, ул бит инде беркайчан да аннан чыкмаячак. Мондый упкыннан исән чыгып була димени?

Фәиз җан ачысы белән дөньяны ярып, кычкырып җибәрде.

— А-а-а-а!

Бу аваз миһербансыз сазлык өстендә бик озак яңгырап торды, аннары аны урман эләктереп алды. Бу җан өшеткеч кычкыруны бөтен кешеләр, бөтен дөнья ишетер кебек иде.

Бу ачы аваз мәңге яңгырар, ахрысы.

Ул янә сикереп торып йөгерде. Кая үрмәләгәнен хәтерләмәсә дә, хәтернең бер почмагында рюкзак пәйда булды.

Бик озак бөтерелеп йөрде, әмма рюкзакны, хәтта аны ташлап калдырган урынны да табалмады. Ары-бире сугылып, башсыз калып бәргәләнсә дә, нинди коточкыч, мәңге төзәтеп булмаслык вакыйгага юлыкканын һәм үзенең чынбарлыктагы халәтен анык кына аңларлык түгел иде ул. Адашкан җанвар сыман сазлык кырыен айкаганнан соң, аяк астында тагын коры каты җирне тойгач, ниһаять, гөрселдәп ауды.

Йокыга охшаган һушсызлану аны оныттырды, дөнья, беркавым чайкалганнан соң, юкка чыккандай булды. Шундый хәлдә күпме яткандыр — билгесез.

Күзләрен ачты. Өстә күк кисәге, артта урман, алда сазлык иде. Ул шундук чынбарлыкны аңы белән тоя башлады. Зәбир дә юк, рюкзак та юк! Ләкин моңа ышанасы килмәде. Рюкзагы чукынып, кадалып китсен, бетсен, юкка чыксын, янсын, шартласын! Зәбир кирәк! Җан дусты, ахири дусты Зәбир кайда?! Барысы да исенә төште — Зәбир юк! Чөнки ул батты!

— Зәбир!!!

Урман бу исемне кат-кат кабатлады. Ул сазлыкка таба ташланды, әмма суга керергә инде үзендә көч тапмады.

— Зәби-и-и-и-р!!! — дип үкерде ул.

Ләкин Зәбир юк иде, аның исеме генә Җир белән Күк арасында бик озак яңгырап торды.

*Дәвамы бар.*





# Равил Фәйзуллин

## «КЫСКА ПОЭМАЛАР» ЦИКЛЫННАН

### Җилләр сагышында — интер уй

*Сугыш салган күкәй...*
Ги де Мопассан

I

Арчалардан чыгып, бераз киткәч,
зират кала олы юл буйлап.
Нимес зираты ул... Аңлаганнар
үтә булыр төрле уй уйлап.

Кайберәүләр нәфрәтләнеп уза:
сезгә монда бер уч җир әрәм!
Жәлләүчеләр була: нинди генә
язмышларга тармый Җирдә адәм!

Казансуга килеп баш салганнар
Рейннарда үскән ир-атлар.
Әсир төшкән алар — заманында
безгә каршы чыккан солдатлар.

Әтиләребезгә атучылар
булганнардыр араларында.
Китерүче бардыр ятимлекне
шушы якның балаларына.

...Арчаларда нимес әсирләрен
хәтерлиләр әле хәзер дә.
Йөргән алар монда сак астында
таш чыгарып, утын әзерләп...

Яшәгәннәр алар шул заманның
кырыс кануннары буенча.
Үлүчесе булган... Хәер, ул вакытта
гадәти хәл һәр өй борынча.

Илләр бераз тынгач, исәннәрен
җибәргәннәр туган иленә.
Ә байтагы мәңгелеккә калган
Казан арты — Арча җирендә.

Бәлкем, кемнәрнеңдер үскәннәрдер
Алманнарда онык-торыны.
Адәм баласына мәгълүм түгел
соңгы туктар чикнең урыны.

Каберләре калган безнең җирдә
ят утрау булып яланда.
Тупыллары җилдә шомлы шаулый
авыр хәтер булып заманга.

II

Арчалардан Әтнәләргә таба —
юлың төшсә Олы Мәңгәргә,
зиратына кереп баш иеп чык,
гыйбрәт өчен, вакыт жәлләмә.

Бер кырыйда гына — ерак түгел
ярымайлы чардуганнардан —
каберләр бар. Яссы ташларына
ят исемнәр язып куйганнар.

Вакыйга шул: сугыш вакытында
вагон-вагон нарасыйларны —
латыш балаларын китергәннәр,
үткәнче дип афәт сынавы.

Авыл апалары ятимнәргә
күрсәтсә дә, хәлчә бар дикъкать,
аларны да чапкан аямыйча
Әҗәл дигән ачы хакыйкать.

Ханнар дәфенләнгән бу якларда
ята Янис, Дайна, Гунарлар...
Зыкы суыкларда җилләргә дә
бәсле киртә уртак — кунарга...

...Кайсына — биш, ә кайсына — алты,
сирәкләре — мәктәп яшендә...
Шушы туфрак сабыйларның күпме
хыял-өметләрен яшергән!

Үлән белән каплап, тирән йоткан
мәңгелеккә, кайтмаслык итеп.
Фани дөнья яшәеше шундый:
кайгы — бөтен, шатлыклар — китек...

Ерак латыш җирләрендә кайчак
бәйгеләрдә көчләр ким булса,
гарәбәләр бераз тоныграк,
чәчәкләрдә төсләр ким булса,
ятим хуторларның тәрәзеннән
хуҗа күләгәсе үтмәсә,
Күмәк җыр бәйрәме сафларында
берәр кирәк аваз җитмәсә —
алар шушы кабер эчләрендә,
шушы туфракта һәммәсе.
Халыкның бер көче, кайтмас төсе,
югалтылган моңы, шәүләсе...

## III

Менә шулай: ике каберстан
Казан арты туфрагында.
Берсен латыш халкы белә булыр,
үзенекен — нимес ягы да...

Чит-ят җирдәге һәр ятим кабер —
Һәр халыкка үзгә бер яра.
Миңа калса, кайчак ул каберләр
сөйләшәдер кебек үзара.

.................................................................

Нәни әрвахлармы оран сала:
— Ник без монда? Сезме гаепле?
Нимес каберләре дәшми сыман,
«юк» диеп тә, яки «җә» дип тә.

— Әйлән-бәйлән уены түгел икән
Газраилнең үлем уены...
Исән чакта «Җир! Җир!!» дидегез сез,
тар түгелме кабер куены?

Янә эндәшмиләр...
«Ни диясең,
ни әйтәсең нарасыйларга?
Үзебезнең монда калуларны
акылыбыз җитми аңларга...»

— Кемнәр җиңде, әй, сез хөкемдарлар,
без катнашкан безсез сугышта?

«Мәгънәсезлек җиңде!» Җилләр әйтә:
барсы өчен тоташ сулыштан.

— Киләләрме Сезне яд итәргә?
— Булгалады уллар, оныклар...
— Сезнекеләр?
— Каян булсын! Без бит
сабый килеш ятим сыныклар.
Ә ...хәтердә
килеп киттеләр шул бер елны

карт кешеләр. Ә без танымадык.
«Яшьтәш идек», диләр, елыйлар.

* * *

Әй, укучым! Болар шигъри фараз,
мин чарасыз гади бер бәндә.
Яшәү-Үлем кемне уйландырмас
фани дөнья кичеп килгәндә.

Ә кем белә, шушы әрвахларның
җан-рухлары инде күктәдер?
Галәм киңлегендә йолдыз булып
кайлардандыр җавап көтәдер?

Казан артындагы ике зират.
Ә андыйлар җирдә бихисап.
Саный китсәң, Әлмисактан бирле
кәгаземә булыр бик кысан.

Һаман арта бара... Үзе гыйбрәт
чичән халкындагы яралар!
«Бүленмәслек «бәхет» диеп анда
сабый балаларны чалалар!..

Искә ал син татар фаҗигасен,
баск, балкар, месхет, көрдләрнең,
карачайлар, калмык, уйгырларның...
тагын дистәләгән күпләрнең...

...Сабыйларның җаны юкка чыкмас —
тупланадыр алар көч булып.
Кешелекне мордар сурәтендә
үзен һәлак итәр Үч булып.

Бәлки, көтәләрдер яңа көчләр —
шәһит киткәннәрнең рух-җанын?

Күкләр белә: Җирдә кылынганның
бернне дә югалмаганын...
Көтмәгәндә Илаһ нәгъpә орса —
сынау тотар Җирнең Үзаңы!

---

**P.S.:** Җанның җаннан аерылуы
туу булыр — Яшәү яшене!
Нинди язмыш кичерсә дә кеше,
үз Җирендә булсын җәсәде.

Арча аша Кырлай юлларында
бөреләнгән уйлы хисләр бу.
Милләттәшем, Туган җиребездә
бердәм булып яшик! Исән бул!

*1996. Хургада (Мисыр).*

## Җир турында ертык җыр

*Җир кемнеке булса,*
*Җил — шуныкы...*

Кырылышып җир бүләләр,
сутыйлап та, илләп тә.
Сугышып та, димләп тә...

Җир бүләләр! Җир бүләләр!
Кемнәр көчле — шул ала.
Гомер бакый һаман Сине
Бүлгәлиләр, Җир-Ана.
Юккамыни әйләнгәнсең
иманнан иманага...
Сәясәт Җир сөрмәсә дә,
сөргәндәй булып бара.
Вәзгыятькә, декретларсыз,
бүгенге көннән кара.

Берсе әйтә: «Мин — фермер!», ди,
Икенчесе: «Мин — варис!
Тарихта гел сәрмаяле
Җиргә хуҗа булган ич!».

Өченчесе: «Безгә кулай
күмәк хуҗалык кына.
Эш майтара ала бездә
көтүдәй халык кына!»

Бәхәс бара: Җир кемнеке?
Минеке дә минеке!
Чынлап эшкәртергә булса —
Хуҗа Насретдиннеке...
Йә эшче көч житеп бетми,
йә булмаса — техника...

Берәүләр шаулап йөргәндә,
берәүләр алып куя.
Алып куя да кишәрлек
(кесәгә салып куя),
зур сарай салып куя.
Коймасына чәнечкеле
чыбыклар сарып куя.

...Монсы бездә.
Ә, гомумән,
Һәр кыйтгада — Фәләстыйн!
Меридианнар, параллельләр...
Кем түбән дә, кем өстен?
Океан төпләренә төшеп,
Бүлмәкчеләр Җир өстен.

Һаман кыйммәтләнә бара
Кояш төшкән һәр карыш.
Ике аяклы адәм саны
дистә миллиардка барыш.

Уйласаң, басып йөрибез
кемнәрнеңдер күзенә!
Тере матдә меңәр гасыр
сибелгән Җир йөзенә.

Җирдән күтәрелгән җаннар
кая китсен?
— Җиренә!
Кавемнәре яткан туфрак
әверелә Иленә.

Болынлыкмы, ком-сахрамы,
тау-ташлыкмы, басумы?—
ни булса да, хакыйкать бер:
Җир — Ватанның асылы.

Халык тарих яза шунда,
яза җырын, дастанын...
Туган җирдән дә кадерле
бер нәрсәсе юк аның!

...И газиз Җир! И изге Җир!
Бездә ник чын хуҗа юк?!.
Төп варисның — хокукы юк,
килмешәкнең — нужа юк.

Елап яткан җирләр күпме
Рәсәй киңлекләрендә!
Импер күз һаман төбәлгән
чит ил җимлекләренә.

Җиребезне сырып алган
баскын канлы дүңдәләк.
Аның ашказаны тулса,
бар дөньясы — түгәрәк!

Һаман җитми Планетаның
алтынчы өлеше дә...
Кайчан бу илне гөлбакча
ясарга керешерләр?

Ни уйлыйдыр безнең хакта
«тәлинкә»дә төшкәннәр?
Киләчәктә ни буласын
юк һичкемнең чишкәне...

Әй, Җир-Ана! Кемне генә
җанлы, тәнле итмәдең!
Юмарт бирдең Ямангa да,
Изгегә дә икмәгең.

Галактика киңлегендә
кемнәрнеңдер Күге Син!
Барыбызныкы булсаң да,
беркемнеке түгел Син!

Әй, газиз Җир!
Гамәли әйләнешеңдә
ярылмый түзче инде!
...Бу ялваруны, ишетсә,
бер Аллаһ үзе инде...

*1996. Казан*

**Кыям Миңлебаев**

# БАКЫЙ

РОМАН

## V баб

### «Сара ханым улы Илдар белән»

*«Бераүне дә матурларга кирәкми.*
*Матурлыкны аның үзеннән табарга кирәк!»*
Бакый Урманче.
*1987 ел, 28 май.*

Мәскәүдә төпләнергә ниятләгәч, Габделбакый итәк-җиңен җыеб-рак йөрергә карар кыла. Һәрхәлдә, сәясәткә якын бармаска тырыша. Хәер, сәнгать диңгезенә чумсаң, аннан алай тиз генә чыгармын, кайчан да булса мәшәкатьтән арынырмын, димә инде. Әле монда бизисе була берәр бинаның бүлмәләрен, әле тегендә. Өстәвенә иҗат дигән нәрсә дә бар бит әле: денем өчен түгел, көнем өчен дип, интерьер белән генә, бүлмә бизәп кенә яшәү һич мөмкин түгел. Аның белән, сәнгатькәр буларак, вакланасың-бетәсең, коргаксыйсың-кибәсең. Менә ни сәбәпле, Ходайның һәр бирмеш көнендә карандаш белән генә булса да берәр этюд ясап ташлау зарур. Ә инде илһам килгән көннәрдә кыл-каләм тибрәтсәң дә, һич зыян итми...

Рәссамның акварель белән генә түгел, майлы буяу белән дә шактый әсәрләре әнә шул рәвешле языла.

Сирәк кенә булса да, әллә нигә бер дигәндәй, таныш-белешләренә кунакка да баргалый рәссам. Аның да җаны бар ич! Тик инде Габделбакый берәр мәҗлескә эләксә, чәйләр эчеп, гөбәдиясе-фәләне белән сыйланып кына калмый, саф ана телендә искиткеч матур сөйләве белән барчасын да авызына карата, әңгәмәне үзенә кирәкле юнәлешкә борып җибәрә — дилбегәне үз кулына алып та өлгерә. Күпне күргән, зур укымышлы, әйбәт хәтерле, матур тавышлы сәнгатькәр шулай итеп чын-чынлап зыялы буларак танылып өлгерә. Кызык-матур сөйли белү үзе бер дәрәҗә булса, тамагын кыргалап, баритон тавышы белән борынгы көйләрне җырлаган чагында аның талантына сокланып биһуш булмаган кеше калмыйдыр.

— Мәскәүдә бит мине рәссам буларак белмиләр иде, Мәскәүдә мине җырчы буларак беләләр иде,— дип ярты гасырдан соң искә төшерүе, мөгаен, юкка түгелдер.

---

Дәвамы. Башы журналыбызның февраль санында.

Әнә шундый мәҗлесләрнең берсендә «Кара урман»ны сузып кына җырлап җибәргәч, көтмәгәндә-уйламаганда кара чәчле, зифа буйлы, елгыр гына бер туташ урыныннан кубып, фортепиано янына барып утыра да җырга кушылып уйнап та җибәрә. Кунаклар «аһ!» итә, җыр беткәч, ихлас күңелдән кул чабалар.

— Афәрин, Габделбакый! Булдырдың, Сара ханым!— дигән мактау сүзләре ишетелә.

Инструмент яныннан торып баскан яшь ханымга сәнгатькәр баш иеп рәхмәтен белдерә, үзе шул арада аның бигрәк мөлаем елмаюын күреп, чибәрлегенә хәйран кала.

— Сара ханым, безнең халыкта бит, хәерчегә ачык чырай күрсәтсәң — ямаулык сорый, дигән бик гыйбрәтле бер мәкаль бар. Белер-белмәс җырлаганда без фәкыйрегезгә ярдәм кулы сузгач, ихтимал, баштан ук сүз куешып, берәр җыр башкарырбыз? Бу юлы инде, Сара ханым, сезнең уйнавыгызга ияреп, көйгә һичбер төрле хилафлык кылмаска тырышачакмын, вәгъдә — иман!

«Өй түбәсе дранча» дигән борынгы озын көйне дә мәҗлестәгеләр онытылып тыңлый.

Кунаклар таралышыр вакыт якынлаша, әмма сәнгатькәрнең күңеленә бигрәкләр хуш килгән музыкант ханымны болай ансат кына югалтасы килми, аның белән чак кына гәпләшмәкче була, үзенә тагын бер елмайганын күрергә өметләнә.

Тик менә Сара ханымны мәҗлестәгеләрнең барысы да белә һәм ярата икән, алай тиз җибәрәселәре килми бугай әле. Көтми хәлең юк. Вә асбир, Габделбакый, сабырлыгыңны җуйма. Хатын-кызның даны, аеруча яманаты бик тиз чыгучан икәнен беләсең бит... Шуңа ул кеше алдында музыкант ханымга сүз кушмый, урамда көтәргә ниятли.

Озаклап көтсә көтә рәссам, ничек итсә итә рәссам, тик инде Сара ханым белән рәхәтләнеп сөйләшә-сөйләшә, өенә чаклы озатып куя. Сүзләре дә, серләре дә килешә бу икәүнең. Ә инде янә күрешергә вәгъдәләшкән кичне сәнгатькәр бер кочак чәчәк күтәреп өенә килә һәм... шул ук кичне куна кала.

Сабыйларны йокларга яткыргач та әле, бик озаклап гөрләшеп утыралар. Сөйләшә-аңлаша торгач, икесенең дә әдәбиятка, музыкага һәм рәсем сәнгатенә карашлары тәңгәл икәне беленә, гомумән, серләре килешә. Азып-тузып йөрмәгән карт егеткә ике сабый мыш-мыш килеп йоклап яткан, иң түргә җыйнак кына кызгылт рояль кунаклаган, ярыйсы ук иркен бүлмә җәннәт булып күренә.

Биек түшәмле, зиннәтле өйнең бер квартирында өч бүлмә булып, өчесендә өч гаилә яшәп ята, кухня-мазар өчесенә уртак иде. Сара ханымның кухня белән ике арада бер чыгып та бер кереп, мәшәкатьләнеп йөрүләре дә егет күңеленә хуш килде. Ә инде чибәркәйнең сылулыгы, мөлаемлеге, уймактай авызы белән генә түгел, зур кара күзләре белән дә балкып елмаюы тәмам биһуш итте, бөтенләй сихерләп үк ташлады. Сылу хатын исә ир-ат затын бигрәкләр дә нык сагынган-тансыклаганзарыккан булып чыкты. Егетнең баһадир гәүдәсенә, түм-түгәрәк мәһабәт йөзкәенә сокланып, әледән-әле мәхәббәтле, елмаюлы карашын ташлый, аның илаһи көчен үзенең билләрендә, иңнәрендә тоярга хыяллана, аратирә ымсынып каравын абайлап алып, зур кара күзләрен озын керфекләре эченә яшергәли — зарыгуы җиткән иде ир-ат назын, күкрәкләре тәмам тулышып әрни, һич кенә дә тынгы белми иде.

«Һай, шушы көрәктәй зур, саллы кулларын ичмасам бер салса икән иңнәремә! Һай, ныгытып бер кысса икән нечкә билләремнән! Һай, җан бирергә насыйп булса икән шушы мәһабәт вә көчле, олпатлы вә гайрәтле егетнең кочагында!.. Юк шул, юк, аның әле кыюлыгы җитми. Димәк, азынмаган, минем шикелле үк, мулла нәселеннән, затлы төптән чыккан, әдәпле вә инсафлы шул егете... Әнә, мескенкәй, төн урталарына чаклы тәүфыйклы гына утырды-утырды да урыныннан ук кузгалды... Нидер әйтте түгелме соң? Әйе-әйе, башын иеп, әдәпле генә сөйли шикелле...»

Кунагының чәйләр өчен рәхмәтләр укыганын да, кайтыр вакыт җиткәнлекне искәртүен дә, янә бүтән әдәпле сүзләрен дә аңламады хуҗа ханым, аны-моны аңларлыктан узган иде — күкрәкләре сулык-сулык килеп әрни иде, ике ирене дымланып тулышкан иде. Ә инде тәүфыйклы вә инсафлы кунагы аның нәфис кулларын ике учына алып, иреннәренә, күзләренә тидергәч, Сара ханым тыелып кала алмады, ул инде әдәп саклаудан бертөрле мәгънә чыкмасын аңлады, куе чәчле, килешле генә башын артка ташлап, сихерле кара күзләре белән елмайды да:

— Алай бик ерактан үпмә мине, якынрак кил, газизем,— диде.

Әлеге сүз егеткә тәвәккәллек өстәде, һәм ул үзе чибәр, үзе мөлаем, үзе япь-яшь хатынның бит алмасына,— йа Хода, күпме кызыгып карап торган иде! — кыюсыз гына иреннәрен тидерде. Һәм шунда ук музыкаль тавышның дерелдәп киткәнен:

— Һәмишә ерак әле... Кил инде якынрак...— дигән ялварулы пышылдавын ишетте.

Егетнең зәңгәр күзләре гүя татлы сүздән сихерләнде, үзлегеннән йомылды, иреннәрен ниндидер дымлы нәрсә көйдереп алды.

Хуҗа ханым затлы иде, нәфис иде, чибәр иде, сылу иде, яшь иде, дәртле иде — егеткәең тәмам исерде. Дымлы иреннәрдән аерылгач, ныгытып бер кочаклады. Чибәркәй ишетелер-ишетелмәс кенә иттереп ыңгырашып алды, кара озын толымлы башын пәһлеванның киң күкрәгенә салып, тыныч кына, әллә кайчан хәл ителгән нәрсә кебек:

— Бүген кайтып йөрмәссең инде, бик соң бит...— дип фәрман кылды.

Габделбакый аны ике иңеннән алып, кабат суырып үпте, бер сүз дәшмәде, бөтен әгъзаларында сәләт вә дәрт, кодрәт вә көч артканны тоеп, чибәркәйне җитез генә күтәреп алды, күзен, борынын, иренен шашынып үбә-үбә, ишеккә каршы почмактагы авыр агач караватка илтеп салды. Хуҗа ханым аны муеныннан назлап кочаклады, аңа отыры ныграк сыену ягын карады, баһадиры утны сүндергән арада караватның хәтфә япмасын дивар буена шудырды, киң вә озын түшәген рәтләде, әмма чишенергә өлгермәде — егете очып килеп җитте, дерелдәвек юан бармаклары белән сәдәфләрен ипсез-җайсыз ычкындырып, затлыга кия торган яшел ефәк күлмәген салдырды. Хатынның:

— Үзем салам...— дигәненә, ай-ваена карамыйча, анадан тума чишендереп ташлады.

Шуннан соң баһадир авыз эченнән генә:

— И Ходаем, мәдәт бир! — дип куйды да күз ачып күз йомган арада үзенең өстендәге киемен сыдырып атты — эләккәне урындык башына асылынып калды, эләкмәгәне идәнгә шуып төште.

Сара ханым, бу чаклы да әрнүле вә газаплы булыр, бөтен бәгырьләрем актарылыр, димәгән иде, татлы вә ләззәтле әрнүгә түзә алмыйча, егетнең ике иңенә чытырдап ябышты, дымлы иреннәреннән ыңгырашу авазлары сытылып чыкты. Түр караватта изрәп йоклап яткан сабыйларын бөтенләй онытып, яшь вә дәртле хатын аһылдады, уһылдады, ыңгырашты, иркәләнде, үрсәләнде, үзе ана булуны хәтереннән үк чыгаргандай, гыйффәтле чагыдай, әнкәсен исенә төшерде, аңардан ярдәм сорады, Аллага ялварды... Әмма үзе пәһлеванга отыры ныграк сыланырга, үзенә тирәнгәрәк сеңдерергә тырышты, җирләр-күкләр өстенә ишелеп төшкәндәй, сикеренде, чарпаланды, тәнендәге бер генә күзәнәге дә тынгы белмәде.

Бу төндә Сара ханымның күзенә йокы эленмәде. Бу төндә чибәркәй ничәмә-ничә ел буена тансыклап яшәгән, ә дөресрәге,— моңарчы әле гомерендә дә күрмәгән бәхеткә кинәнде, назны алды, шушы яшькәчә пыскып яткан дәрте-хисе дөрләп киткәнне тоеп, хәйран калды. Бу төндә асыл зат үзенә лаек ярын тапты, ниһаять, морадына ирešте.

Сара ханым Пензадагы мәшһүр Шәрәфи ишан кызы була. Кече яшьтән укуга һәвәслек күрсәтеп, әтисенең китапларын берәм-берәм алып, зур кызыксыну белән укып чыга. Ничәмә-ничә китап арасында

үзенең шигъри аһәне белән «Йосыф китабы» аның күңелен җәлеп итә. Шунысы кызык, бераз үсә төшкәч, элек яратып укыган китапларының укалары коела — кызыгы калмый. Сабый чакта бигрәк беркатлы булганмын икән, дип фикер йөртә. Фәкать ике генә китапка мәхәббәте сүрелми туташның. Ул китапларның берсе — Истамбулдан ишан үзе алып кайткан зур форматлы, шома калын кәгазьгә басылган һәм үгез тиресе белән тышланган Коръән булса, икенчесе — шулай ук матурлап, чәчәкләп-бизәп эшләнгән «Кыйссаи йосыф» китабы.

Өйне җыештыручы асрау аларга кагылмый да, өстәлне чүпрәк белән сөртеп чыга, әлеге китапларга исә тәһарәт алмыйча, кулын юмыйча, кагылырга да җөрьәт итми. Хәер, остабикә үзе дә әллә нигә бер генә, хәзрәт янына дәрәҗәлерәк берәр шәхес йомышы-фәләне төшеп килгән чакларда гына, изге китапларны алып, түрдәге калын пыялалы, зур китап шкафына куя торган иде. Андый чакны кыз бала чит кешенең күзенә күренеп йөрми, тик инде кунак киткәннән соң, чыгып, ул китапларны яңадан имән өстәл өстенә алып куя, берсен шундук, фал китабы ачкан шикелле, теләсә кайсы җиреннән ачып, укырга ябыша торган иде.

Хәзрәт үзе, моны күреп, елмая гына. Бибисарага һичбер каты сүз әйтмәс, кызының укымышлы булып үсүенә сөенер генә. Өстәвенә әле яраткан кызының үзалдына «Йосыф көе»н көйләп йөргәне, чигү чигеп утырганда исә мөнәҗәт әйткәне колагына чалынып, укуга һәвәслек өстенә кыз баланың музыкага да күңеле ята түгелме, дип уйга калган чаклары да булмады түгел. Гәрчә үзе ишан булса да, замананың кая барганын, Рәсәйнең яңарышка йөз тотканын шәйли һәм фәкать кадимчелекне генә яклап, җәдитчелеккә дә каршы бармый, моның файдасы юклыгын аңлый. Үзенең балаларына исә дин гыйлеме бирү белән генә чикләнми, дөньяви шөгыльгә өйрәтү ягын да кайгырта.

Ишле гаилә булгач, оланнарның берәрсе өйрәнә алмасмы дип, өенә рояль кайтарттыра. Чынлыкта исә, яраткан кызының музыка белән мавыгып китүенә өметләнә. Чынлап та шулай килеп чыга шул. Сара туташ музыка өлкәсендә гаҗәеп дәрәҗәдә сәләтле икәнен исбатлый һәм әлеге кызгылт рояльгә бик тиз ияләшеп китә, биш-ун ел буена дәресләр ала, аннары инде, НЭП дәверендә, башкалага барып, консерваториягә укырга керә. Аны уңышлы гына тәмамлап, пианист квалификациясе алып чыга. Шундук эше дә табыла — Сара туташ Мәскәүдә төпләнеп кала.

Сараның беренче ире татар халкының гореф-гадәтләрен өйрәнеп йөрүче, матбугатта аз-маз исеме күренгәли башлаган, җыйнаграк кына гәүдәле, җор телле, тынгы белмәс бер җан була. Бергә тора башлауларына бер ел тулар-тулмас аларның балалары туа. Янә дә ике-өч елдан Сара ханым тагын бәбили.

Мәҗаралар яратучы, җор телле кешенең кайда ниләр сөйләгәнен кем белеп-чүпләп бетергән дә аның сүзенә кем игътибар иткән? Әмма табыла аның өстеннән әләк язып ятучы бәндәләр, һәм шуның аркасында аны ябып та куялар...

Сара ханымның үтә дә газаплы-мәшәкатьле көннәре, айлары, еллары шунда башлана. Сабый балаларын тәрбияләү, аякка бастыру намена аңа, музыка мәктәбендә укытудан тыш, әле тагын өендә дә бөкрәеп утырган килеш балаларга дәрес бирергә туры килә, өстәвенә әдәби-музыкаль кичәләргә катнашып акча табарга, очын очка ялгарга тырыша.

Иреннән бертөрле дә хат-хәбәр килми, ичмаса күңел өчен генә булса да төрмәдән чыгучы берәрсе аркылы да исәнлеген белдерми. Алай гынамы соң?! Таныш-белешләре арасында иренең үлгән хәбәре тарала. Яман хәбәр көне-сәгате белән Сара ханымга да килеп ишетелә...

Дус-ишләре аның кайгысын уртаклашалар, бу ике баланы ялгыз башың ничекләр генә кеше итәрсең икән инде, дип аһ оралар; кайсыбере хәтта әле, ата кулы юклыгын сизеп, оланнарың йөгәннән ычкынып адәм рисвае булмагае, берәрсен йортка кертмисеңме, дип күңеленә коткы салалар, кемнәр беләндер кавыштырмакчы булып маташалар.

Сара ханым аларга ак та дими, кара да дими. Нәрсә әйтсен? Бер димләдегез бит инде, җитәр, дисенме? Әллә югыйсә, тынгы белмәс бер җан, маҗарага хирес бер мәхлүк белән кавыштырганда ләббәйкә дип, ризалашып торганыма шөкранә кылыгыз, дисенме? Консерваторияне әле генә бетергән, яңа үз көнен үзе күрүгә дучар ителгән туташ түгел инде, күзе шактый ачылган, дөнья алып баруның ачысын-төчесен татыган, яхшыны яманнан аерырга өйрәнеп өлгергән инде. Берәүнең дә кубызына биергә җыенмый. Шулай да ахирәтләренә дорфа бәрелмәскә тырышып:

— Шул сабыйларымны аякка бастырмый торып, яңа ярлар эзләмәскә әле исәбем,— дип котыла. Әмма шулай да Сара аларның хаклы икәнен, шулай да башка чара калмаганын аңлый, кардәшләренә дә, ахирәтләренә дә авыз ачып авыр сүз әйтми.

Әнә шундый чарасызлык заманында Габделбакый пәйда була. Монысы инде берәүгә дә охшамаган: теге ире кебек чирләшкә гәүдәле түгел, мәһабәт буй-сын, үзе олпатлы, үзе баритон тавышлы (Сара ханым тенорларны бик үк өнәп бетерми иде; әллә нечкә тавышларын ишетеп саруы кайный, әллә инде үзләрен бик үк ирләрчә тотмауларын күреп җирәнә иде), үзе сәнгать әһеле. Җитмәсә ялгыз, торыр урыны да юклыбарлы гына шикелле. Сара ханым уйга кала. Уйланырлык иде анысы, уйланырлык... Холкын-фигылен әйбәтрәк өйрәнеп бетерсәң, ышанычлырак булыр иде дә бит булуын... Кулай холыклысын каян табасың ул ярның? Юк бит алар, ю-у-ук! Монысын да берәр яшьрәге, койрыксызрагы сугып алса, калырсың аннары авызың ачып...

Моңарчы азып-тузып йөрмәгән, күңеленә хуш килердәй асыл затны очратмаган, башлы-күзле булу ягын кайгыртырга вакыты булмаган сәнгатькәр илаһи бер гүзәллек иясенә — шомырттай кара озын толымлы, зифа буй-сынлы, искиткеч матур, мөлаем чырайлы, кара кашлы пианисткага бер күрүдән үк гашыйк була. Шундый да сылу ханымның күңеленә үтеп кергәч, назлыбикәнең куенкае җылысын татыгач, тәвәккәлли карт егет, озын-озак уйлап тормый — гомерен Сара ханым белән бәйли. Аларның кавышуына, ихтимал, икесенең дә сәнгать әһеле булуы, бере икенчесенең хезмәтенә вә иҗатына хөрмәт белән каравы да сәбәпче булгандыр, бик ихтимал.

Язылышканнан соң берәр ай вакыт узгач, төн карасы үзенең бәллүр пәрдәсен нәрсәләргә япкач, көндезге мәшәкатьләрдән арынып, җылы түшәгенә иплән кенә яткач, газиз иренең ни дәрәҗәдә гайрәтле вә дәртле икәнлеген яту белән татыгач, Сара ханым тынычланып-тынып калды. Әмма холкын шул арада өйрәнеп өлгергән яшь ире аның, наздан эреп китү белән бергә, нәрсәдәндер шикләнеп-шөбһәләнеп ятуын, ниндидер бер ят авазга колак салуын-сагаюын абайлап алды.

— Сарам, сине нәрсәдер борчый бугай. Эшеңдә берәр төрле күңелсезлек-мазар юктыр бит? — дип йомшак кына сүз кушты.

— Эшемдә, Аллага шөкер, иминлек, әйтмәгәнем булсын,— дип, сылу хатын олы гәүдәле иренең куенына тәмам сеңә язды, төн карасында да күзен яшерергә тырышты.— Мине уйга калдырган нәрсә, Бакый, карынымнан ишетелгән яңа аваз булды...

Шулай диде дә хатын үзенең түшәгендә, көчле вә гайрәтле, олпатлы вә дәртле яшь ире куенында тынып калды. Гәрчә, карынымдагы тавышка гына колак саламын, дип үзен үзе ышандырырга тырышкандай тоелса да, чынында исә мәгърур холыклы яшь иренең ни әйтерен, үзе җаны-тәне белән гашыйк булган мәһабәт пәһлеванының карарын тын да алмыйча көтә иде. Яшь ир ничек әйтсә, шулай булыр. Гәрчә аның сабыйларын алдына алып сөйсә дә, үзенең аяк-кулын бәйләрме-юкмы? Ана һәрчак туасы яңа баланы тансыклап каршы алса да, һич гаҗәп түгел, чөнки ул үзенең йөрәк парәсен иркәләп-тәрбияләп карынында чакта ук үстерә. Ә менә әлегә хәтле өйләнмичә кырык яшькә җитеп килүче, типсә тимер өзәрлек ир-егет ул баланы тансыклый алырмы, шундый изге адымны ясарга башы җитәрме?

Ләкин бер дә менә Сара уйлаганча килеп чыкмады, бер дә аның шик-шөбһәсе акланмады. Яшь ир куенына сеңәрдәй булып сарылып яткан сылуны аеруча бер саклык белән кочаклап алды да, берданбер хәсрәтен әйткәндәй:

— Сарам, газизем, инде син авырга калгач, назларга да ярамастыр инде моннан ары? Синең иркә-назыңны татымыйча мин ничекләр яшәрмен икән инде? — дип сөйләнде.

— Һи тилем-тилем... Ул бит әле янә дә җиде-сигез айдан гына дөньяга киләчәк. Әле без рәхәтләнеп сөешә, назда коеныша алабыз. Минем үземә дә синең назлавың бик-бик рәхәт. Бу чаклы дәртле булырсың дип һич башыма китермәгән идем. Һәркөн синең дәртеңне татулары, һай, рәхәт, җаным-бәгърем. Бөтенләй эреплар китәм инде менә, эрепләр китәм. Ничә ел буена ир-атка якын да бармагач, мин инде бөтенләй коргаксыган-үлгән-беткән идем. Син, пәһлеваным, миңа җан өрдең, дәрт бирдең...

Хатыннар, гомумән, ир-атның изгелегенә рәхмәтлерәк булучан, фидакярлеккә җавап итеп күңелләрен дә, куеннарын да киңрәк ачарга ярату-чан. Бу юлы да нәкъ әнә шулай булды: хатын агач инструменттан да көй чыгарырга сәләтле озын вә сизгер бармакларын ир-егетнең йөзеннән йөретте, үпте, аңа ныграк сыенды — ял итәргә дә ирек бирмәстән, дәртен кузгатырга кереште. Ире, гүя шуны гына көтеп яткандай, дерт итеп кузгалды-җанланды, сөеклесенең кабат иләсләнеп-дәртләнеп китүенә сөенеп бетә алмады, көрәктәй учын бил тирәсендә биетте, иңнәреннән кысып кочаклады. Хатын исә үбүен белде, нәфис озын бармаклары белән сөеклесенең муен тирәләрен назлап сыйпаштырды, йомрыланып торган көчле иңбашларын, беләк мускулларын капшады, кысып карады, аннары ике учын бердәй түбәнгәрәк шудырды, ир-егетнең, гранит чокырга сәләтле газизенең таштай ныклы-егәрле икәнлегенә янә дә тәмам инангач, сулуы капкан сыман еш-еш сулап, дымлы иреннәрен киң итеп ачкан хәлдә, түшәгенә чалкан төште, сөеклесен үзенә тартты...

Шушы аңлашу-сөешүдән соң гаиләдә хәлләр тагын да әйбәтләнеб рәк китте. Яшь ир үзенең назлыбикәсенә аеруча игътибарлы булырга тырышты: әллә кайларга барып, затлы ризыклар алып кайткалады, әфлисунын, лимонын ташыды.

Сара ханым тыйнаклык йөзеннән:

— Кирәкмәс иде инде, картым, — дигән булды.

Моңа каршы ирнең сүзе сүз иде:

— Син авыз да ачма, Сарам. Сиңа хәзер ике кешелек ашарга кирәк. Нәниебез рәхәтләнеп үссен... карыныңда чагында ук. Мохтаҗлык күрмәсен балаларның берсе дә.

Бу айларда Габделбакый гомерендә дә күрсәтмәгән зирәклек арты зирәклек, уңганлык арты уңганлык уйлап чыгарды. Яшь атаның йөзеннән елмаю китмәде, баритон тавышы туктый белмәде, олы учына бәпбәләкәй малаен алып сөйде, аны күкләргә чөяргә, аның белән бергә егетнең сөекле әнкәсен дә үчтеки иттерергә әзер иде.

Бала бүләге сыйфатында ул хатынына искиткеч зиннәтле матур муенса алып кайтып бирде. Хәер, аның белән генә чикләнмәде, өй эчендә, хуҗалыкта кирәге булырдай әллә күпме затлы нәрсә ташыды. Әллә ниләр сөйләп Сараның кәефен күтәрде, көлдерде.

Ә бер көнне, эштән кайткач, Габделбакый елмаеп-балкып:

— Элекләре бит, Сарам, дөньяның бар мәгънәсен эштә күрә идем. Менә ни сәбәпле бөтен сәләтемне сәнгатькә, рәсем ясауга, картина язуга багышладым, шуннан тәм таба торган идем. Хәйран-тамаша инде, газизем: синең белән кавышканнан бирле яшәүнең мәгънәсе фәкать синең елмаюыңа бәйләдер сыман тоела башлады. Сиңа, ихтимал, ышануы да авыррактыр, әмма ләкин минем үземнең иманым камил: син минем тормышымнан күп нәрсәне бәреп чыгардың. Моны бер дә

менә арттырып әйтүем түгел. Инде янә бер әкият димәсәң әкият: улыбыз туганнан бирле сәнгатьнең яме китте дә барды. Нәниебез гүя иң-иң гүзәл сәнгать әсәре буларак дөньяга килде,— дип сөйләнде.

Иртәгесен эшкә китәр алдыннан чәйләп утырганда:

— Сарам, без синең белән икебез дә сәнгать әһеле була торып, улыбызны математик итмәбездер инде. Яшьтән үк үзенә музыка дәресләре бирерсең, Аллаһы боерган булса. Әллә бәлкем, аңардан татарның Моцарты яисә Паганиние чыгар. Мәшәкате-михнәте синә төшә икән үзе төшүен...— дип сайрарга тотынды, аннары башын кашып алды.— Хәер, мин дә читтән генә күзәтеп тормамын, берәр елдан кулына карандаш тоттырырмын, рәсем ясарга өйрәтермен, Аллаһы боерган булса. Малайлар халкы сурәт ясарга, сызыклар сызарга яман һәвәс була бит ул. Моның шулай икәнен мин үземнән беләм... Һәрхәлдә, Тициан дәрәҗәсенә күтәрергә үземнең кодрәтем җитмәсә дә, Урманче хәтле генә сәнгатькәр итеп тәрбияләргә көчемне-куәтемне һич кызганмам.

Шулай дип әйтте дә рәссам, тагын хыялларга бирелеп, уйга калды.

«Тукта, Сарамның мадонна чагын киндергә төшерим әле!» — дигән теләк рәссамның күңеленә һич көтмәгәндә килде.

Ләкин ничек итеп, нинди сюжетка яисә калыпка яраклаштырып язарга? Борынгыда рәссамнарның хәле әйбәт булган: җаннары теләгән чибәркәйне Мәрьям ана кыяфәтенә китереп, итәгенә бала утыртып,— анысы аның Гайса-Христос, Алла буласы малай, имештер... Ходаем, үзең ярлыка, әйттем исә кайттым! — гүзәллек алиһәсе иттереп язганнар да ташлаганнар.

Күпме халык аннары шул әсәрләрне сурәт-икона урынына күреп табынган, күзен ала алмаган. Ислам динендә сурәт ясау юк шул. Ходай тәгаләнең дә, пәйгамбәрләребезнең дә кыяфәтләре безгә мәгълүм түгел, һәм аларның сурәтләрен кәгазьгә яисә киндергә төшерү олуг гөнаһ санала. Ә бит католикларда аларның сурәтләрен язу белән генә дә чикләнмәгәннәр, бәлки әле балавыз ише берәр нәрсәдән укмаштырып адәми сыннарын да ясаганнар...

Әмма шулай да, абзыкай, ул сыннар-сурәтләр сәнгать әсәрләре буларак тамашачының игътибарын җәлеп иткәннәр. Ал син Рафаэльнең «Сикстин мадоннасы» дигән мәшһүр картинасын. Леонардо да Винчиның «Литта мадоннасы» дигән кечкенә генә әсәрен. Аларның гүзәллегенә, камиллегенә дөньяда сокланмаган кеше юк. Әгәр берсе Дрезден галереясен бизәсә, икенчесе Эрмитажны бизи. Рафаэльнең бит сюжетлы график әсәрләрендә дә сабыен күтәргән хатын, мадонна еш очрый. Мәхәббәте булган, күрәсең... Ә синең иҗатыңда ник бер бала-чага күренсен икән! Әйе, моңарчы бала образы иҗат иткәнең булмады шул. Хәзер инде үзеңнең улың бар, әнкәсе белән шул үз әсәреңне син, абзыкай, һичшиксез, мәңгеләштерергә тиешсең. Тик мулла малае башың белән хатыныңны да улыңны икона иттереп язмассың инде! Икенче бер нәрсә уйлап табарга туры килер. Башка чара юк...

Картинаның композициясе бөтенләй уйламаган җирдән табылды. Дөресрәге, бу хакта уйланып йөрсә дә, башында җыен вак-төяк дөнья мәшәкате айкала да чайкала иде. Шул чагында хатынының бала өстенә иелгәне күзенә чалынды. Бу чаклы да самими булса да булыр икән! Сабыена бөтен җаны-тәне белән бирелгән бит ул, аны, шул сабыен дөньядагы барлык афәт-михнәттән сакларга, кешенең өстенә ябырылырдай җил-давылны, кар-яңгырны, ачлык-ялангачлыкны, кайгы-хәсрәтләрне — һәммәсен дә үз өстенә алырга әзер ләбаса! Табигать әнә шул сокланып туймаслык олуг фидакярлекне бары тик ана дигән затка гына биргән, күрәсең. Син, абзыкай, артык баш ватып азапланма, катлаулы-ясалма сюжетлар корып башыңны катырма, чын рәссам икәнсең, тот та сөекләреңне әнә шул килеш — искиткеч табигый бер халәтендә мәңгеләштер! Гади рәссам буларак кына язма картинаңны, гашыйк дивана бер дәрвиш буларак яз! Ихтимал, син гашыйк дивана түгелсеңдер? Ихтимал,

син дәрвиш түгелсеңдер? Ныклабрак уйлап кара, абзыкай, мәхәббәтеннең, гыйшкыңның көчен-кодрәтен түшәктә күрсәткән кебек үк, дәртләнеп-үҗәтләнеп, елый-елый, шаулый-шаулый, ыңгыраша-ыңгыраша, профессиональ художник буларак,— син бит инде рәссамнар оешмасы әгъзасы,— киндердә күрсәтә алырсың микән, юк микән? Хәлеңнән килерме, юкмы? Шуны булдыра алсаң, җир йөзендә үзең өчен иң-иң газиз шушы ике җан иясен киндергә иңдерә алсаң, аннары инде яшәвеңнең үкенече калмый... Ашыгасы юк. Гомумән, ашык-пошык башкара торган эш түгел бу. Хатын үзебезнеке, беркая китми, сабый да Ходай биргән байлыгын тырпайтып ята бирә — алар беркая китми. Уйлабрак эш итү мәгъкуль булырдыр. Алтынсу төсләрдә, җылы гаммада алу хәерлерәктер...

Әйе, Башкортстанга командировкага барып, анда үз күзең белән күргән, шаулап торган колхоз ындырын акварель белән натурадан язу түгел бу сиңа. Дөрес анысы, анда да хәрәкәтне күрсәтү өчен, эш процессын тамашачы кабул итсен өчен, ярыйсы ук чиләнергә, көч куярга туры килде килүен... Тик инде үз өеңдә, үз өнеңдә көчне тагын да күбрәк сарыф итү зарур. Хиссият бар нәрсәдән өстен чыгарга тиеш, өстен!

Киндерне биеклеге метрдан бер чирек кимрәк, иңе метрга якын итеп үз кулы белән ясаган подрамникка һәйбәтләп тарттырды. Аннары аны мул итеп грунтлады, ягъни җилемле ак буяу салып тигезләде-ныгытты. Шуннан соң инде, ак кәгазьгә карап өнсез-тынсыз калган шагыйрь сыман, әзер киндергә текәлде дә: «Нәрсәне ничегрәк һәм кайсы тарафкарак урнаштырыйм икән?» — дип уйланырга тотынды.

Сара ханым натурачы сыйфатында затлырак киенергә — үзе яраткан озын итәкле яшел ефәк күлмәген яисә инде күгелҗем-зәңгәр бәрхет күлмәген кияргә бик теләсә дә, ире белән сүз көрәштереп тормады, гадирәк киенергә ризалык бирде.

— Бакыем, синең теләгеңә каршы бара алмамдыр, ахры... Бу очракта бигрәк тә: син беренче скрипканы уйныйсың,— дип, мөлаем генә елмайды да кыска җиңле, сарыга буй-буй кызыл төшкән, әрсезгә тоткан күлмәген киде.

Әллә кайчаннан бирле буяулары белән мәш килгән рәссам түгәрәк битен балкытып:

— Бик дөрес итәсең, карчыгым. Син бит безнең өйдә мәшһүр музыкант, мадонна гына да түгел! Әгәренки мин картина язарга алынып та музыкантның нәфис кулларын күрсәтә алмасам, атым корысын, аннары инде рәссам буларак кыйммәтем базар көнне Буа базарында да бер генә тиен,— дигән булды, теләнә салынды.

Сара ханым да сүзгә аптырап торучылардан түгел иде:

— Комплиментыгызга рәхмәт, әфәндем. Аурупа тәрбиясе алган джентльмен икәнегез ерактан ук күренә,— дигән булды.

Рәссам гөлдерәп:

— Һи, нишләп әле син миңа алай ерактан гына карарга тиеш? Якынрак киләбез аны,— диде, урындыгыннан кубып, хатыны янына килде, көчле куллары белән кысып кочаклап алды.

Әмма хатын бирешмәде, киенү-төзәтенү-ясанудан туктамады:

— Сабыр ит инде, Бакыем. Назыңны киндергә сакла, дәртең сүрелә-нитә күрмәсен,— диде дә үзе шунда ук, тупасрак кагылмадым микән, дип шикләнә калды һәм: — Мин бит беркая китмим, мин теләгән чагыңда синеке,— дип өстәде, мөлаем генә елмаеп куйды.

— Рас әйтәсең: әгәр дәртең булмаса, пычагым да яза алмыйсың. Бездә анысы дәрт дигәнең, Ходайның биргәненә мең шөкер, син каракаш гүзәлкәемә дә, киндергә дә житәрдер. Әмма ләкин кечтеки генә сере бар аның: сине иркәләмәсәм, төсләрне бик үк шәйләп бетермим... Ә инде үзеңне һәйбәтләп назлаганнан соң күзем төсләрне аеруча анык күрә, кулым буягычны ышанычлырак, гайрәтлерәк йөртә, һәр күзәнәгемдә илһам нуры кабына.

Сара ханым искиткеч мөлаем итеп елмайды да:

— Кая, берәр шифасын табыйк, бәлкем, ачылып китәр,— дип, күзләреннән үбеп алды.

Габделбакыйның шуңа да күнеле булды:

— Ярый, тырышып карыйк соң,— диде. Мәгәр үзе сәнгатькәр буларак бәйләнүдән һич туктамады: —Өстең-башың дигәндәй, кыяфәтеңйөзең дигәндәй — күркәм хәзер, сүз дә юк. Әмма, Сарам, ни сәбәпледер чәч толымнарыңны яшереп өлгергәнсең, шунысы начар. Мин яратканны белмисең, ахры?

Сара ханым, гаепле кешедәй, башын иеп кенә елмайгандай итте:

— Бакыем, толымнарыма гашыйк икәнеңне дә беләмен, тик алар көннән-көн сыеклана, чәчем әллә нигә бик нык коела башлады. Шулай гына калыйм инде, газизем, ачуланма,— диде.

Рәссам аның баш чүмече турысына ыспай гына төйнәп куйган, җемҗем килгән чем-кара чәченә профессиональ күз ташлады да:

— Ярар анысы, зарар юк,— диде, сүзне озынга сузмады.

Һай бу мәхәббәт, илаһи кодрәткә-көчкә ия самими хис! Ул булмаса, дөньяның нинди генә яме-кызыгы калыр иде икән... Менә яза рәссам, онытылып-дәртләнеп кыл-каләмен тибрәтә — үзенә һәр күзәнәге яхшы таныш сөекле йөзкәен профильдә алып маташа... Менә маңгае, матур гына борыны, уймактай авызы, гап-гади ияге, музыкаль ноталарны бутамаска өйрәнгән, меңнәрчә көйне, моңны, аһәңне ишеткән бер шикелле ыспай гына колагы... Чак кына куерак алынды бугай сөеклесенең йөзкәе... Хәер, кипкәч, ни килеп чыгасын бер Ходай үзе белә. Һәрхәлдә, тән төсеннән бераз кызгылтрак, куерак килеп чыгуы бик ихтимал. Вангог әле яшел йөзем бакчасын да кып-кызыл иттереп язып калдырган. Сәнгать диләр аңа. Яманларлык, тел-теш тидерерлек булса, Пушкин исемен йөрткән Изомузейга алмаслар иде аны... Шулай да кулларын нәкъ әлеге төстә язып ташлавың хәерле булырдыр...

Төенгә төйнәлгән чәч толымына ризасызлык белдереп кырын карап алды да тәгаенләп язып тормады, башка вакыт язарга калдырды. Аның каруы Сарасының нәфис бармакларын кабат-кабат, кайта-кайта, һич тә иренмичә язды. Хатынының силуэтын тоташы белән язып чыккач, аның муен-җилкә тирәләрен килешле иттереп чыгарды, аннары үзенә бик тә нык таныш, күпме яратып сыйпаган-назлаган, әле кием үтәли дә күреп торган аркаларын, билләрен нәкъ менә түшәктәге тырышлык белән язды, сул беләге астыннан тулы күкрәгеннен беленерлек иттерде. Ә менә сабые өстенә иелгәнлектән, янбашларын, да, бот тирәләрен дә артык бизәп тормады — иелгән силуэтка тәңгәл килердәй генә иттерде. Анысы тамашачыга тәтеми аның янбашлары, анысын үзебез рәтләрбез. Һич тә кимен куймабыз, диебрәк, көнчелек галәмәте калкыды бугай, әллә инде бераз тыйнаклык күрсәтүе шул булды... Әллә бәлкем, игътибар үзәгенә сөеклесенең мадонна булуын алганлыктан, йөзенең генә түгел, бөтен гәүдәсенең нәнигә омтылуын күрсәтергә тырышканга шулай тыйнаграк килеп чыккандыр...

Аның каруы аларның газиз балалары табигатьнең искиткеч баллы-татлы бер җимеше дип әйтерлек дәрәҗәдә мул итеп сурәтләнде. Сабый зур караватта, әниләре түшәгендә җәйрәп ята. Әнкәсен күргәч, нидер әйтергә дә бит исәбе, тик менә сөйләү сәнгатен үзләштереп җитмәгән, әлегә телен чыгарып, «гый-гый» дип әнкәсенә генә аңлаешлы сүзләр әйтү белән чикләнергә мәҗбүр. Хәзер менә үзенең нәни куллары белән кочып алыр иде әнкәсенең матур муенын, тик менә торып булмый шул әле, бармакларны тырпайтып, нәни кулларны сузудан, аякларны кыймылдатудан артык берни эшләр әмәл юк. Әйе, хәрәкәттә бәрәкәт, дип борынгы бабайлар белми әйтмәгәннәрдер. Әйе, шулай кыймылдый торгач, акрынлап кына йөреп тә китәр әле сабыегыз, нәни куллары белән икегезне берьюлы кочып алыр, колакларыгызга иң-иң назлы сүзләрен пышылдар, әкренләп укырга-язарга, әнкәсенең һөнәре — музыкага, әт-

кәсенең һөнәре дип — рәсем ясарга өйрәнер. Их, тизрәк йөреп китеп булсачы!..

— Инде үлсәм дә үкенәсе түгелмен!

Чынлап та рәссам һәркем сокланырлык гүзәл әсәр иҗат итү бәхетенә ирешә. Ананың йөзе-кулы тән төсеннән чак кына куерак бирелгән; сабыйның алсурак гәүдәсе яшькелт буяулы «ак» мендәр өстендә бигрәк инде ачык күренә; тырпайган нәни генә чәнти бармагы аеруча табигыйлек өсти; биредә һичбер төрле «салкын» буяуга урын юк; ә инде сабые өстенә иелгән Сара ханымның коңгырт-сары күлмәге картинаны мөлаем вә җанлы итә, күңел җылысына төрендерә.

Әнә шулай сөенеп-сөешеп яшәгәндә, көннәрдән бер көнне пәйда була... Сараның беренче ире, олырак балаларының атасы. Киткәннән бирле бер кәлимә сүз язып җибәрә белмәгән, исән-имин яшәвен сиздермәгән элгәрегә иренең — кечрәгрәк кенә җыйнак гәүдәле, почык борынлы, тамчысыз-ябышкак колаклы, елтыр күзле бәндәнең житез-җилле йөрүен, каударланып атлавын күрү белән, Сара ханымның күңеленә көйсез-фальш нота килә: берәү бигрәкләр масаеп, кылтыйланып, инструментны газаплый, тик үзе фальштан, ясалма-ялган ноталардан һич арына гына алмый...

Хатынының бәләкәй караватта йоклап яткан сабыйны кай арада алдына алып, хәвефтән сакларга теләгәндәй, күкрәгенә кысып утыруына әлләни исе китмәде шикелле тегенең. Елгыр-житез бәндә: «Белмәссең, берәрсенә барып сыенгандыр, печән ашатып булмый ич аның жанына да, тәненә дә, музыкант булмагае чурт булсын, ир-ат кирәк хатыннарга, ир-ат!» — диебрәк фикер йөртте бугай. Менә ул күзен йомгалап алды, уфтанып куйды, арык кына кулын селтәде. Тик инде җәмгатенең үзенә күтәрелеп тә карамыйча, аңа битараф көенчә, сабые белән тәтелдәргә тотынуын күргәч, күңеленә зәмһәрир суыклары йөгерде, өметләре тәмам өзелде.

Беравык сүзсез-өнсез утырганнан соң ул, ятып калганчы атып кал, дип кенә, елтыр күзләрен челт-челт йомгалап, хәлсез-дәрмансыз тавыш белән сүз кушарга җөрьәт итте:

— Бибисара, минем сүзгә колак салсаң иде... Күпме еллар элек син бит миңа кыз көенчә килгән идең, матур гына яшәп тә алдык шикелле... Инде мине хөкем итеп утыртканнан соң аралар ераклашты... Мин һич тә сине гаепләмим, Бибисара, атта да булды гаеп, тәртәдә дә...

Хатынның башын күтәреп үзе сөйләгәнгә колак салуын күреп, аның гаҗәеп чибәр йөзендәге хәсрәтне-сагышны яздырмакчы булып хыялланып:

— Ике балабыз янына сыяр синең нәниең дә... Җилдән бала таптың, дигәнне миннән ишетмәссең... Әйдә, Бибисара, никах яңартыйк та гөрләтеп яши башлыйк бергә-бергә...— дип ялварды.

Әмма Сарасы әлеге сүзләрдән нишләптер егылып төшмәде:

— Юк инде, сүзеңне әрәм итеп сөйләмә дә. Үзеңнең хат-хәбәрең булмагач, гүр иясе, дигәннәренә ышандым. Сиңа тугрылык саклый алмадым. Инде бер каралган икәнмен, шул хәлемдә калдыруың хәерле булыр, бигайбә,— диде.

Ирнең бирешергә исәбе юк иде:

— Үлгәнче син миннән гаепләү сүзе ишетмәссең, Бибисара, менә антлар итеп әйтәмен... Җилдән бала таптың, дип гомеремдә битәрләмәм!..— дип тә карады.

Әмма хатын исә тагын да ныграк булып чыкты:

— Үзең монда чакны ят ирләргә күз атып, кеше белән йөреп сине адәм рисвасы калдырмадым. Ходайга мең шөкер. Сабыем җилдән тумады, аның әткәсе белән кавыштык, языштык. Ул бигрәк инде бала җанлы, синекеләрне дә үләп ярата... Балаларны моңарчы да

синең ярдәмеңнән башка тәрбияләдем, анысын үзең миннән яхшырак беләсең... Инде киләчәктә дә, шәт иншалла, өчесенә тиң карап, үстерә алырмын.

Шулай диде дә башын артка ташлап, куе каш астындагы кара күзләре белән төбәп карады. Йа раббым, үзең сакла! Аның йөрәге жуу итеп китте: яшьлеген алган, әмма гомер эчендә бер яшәүгә теләк-дәрт уята алмаган, кыз баланың тирәнгә яшеренгән табигый хисләрен кузгата белмәгән, хиссият диңгезенә чумдырмаган, үзе елгыр, үзе мәхәббәтсез, мез-мез килүче шушы бәндәгә ирем дип, киләчәктә пыскып яшәр өчен генә пәһлеван гәүдәле, күркәм күләч йөзле, куе-көр тавышлы, мәхәббәтле, көрәктәй зур һәм назлы куллары белән бер кочып алса дөньяны онытттыра алырдай, күтәреп үзеңне түшәкләргә салып, сәгатьләр буе иркәләүче, әле күкләргә күтәрүче, әле җирләргә төшерүче, җәннәттәге бәхетләрне бирүче газизеннән ваз кичсенмени инде, ә? Җирләрне-күкләрне күкрәтеп, ыңгыраша-ыңгыраша, Аллага ялвара-ялвара, шул ятудан тормаска да риза булып, үләргә дә, җанын фида кылып шәһит китәргә дә әзер көе дәртләнеп сөешүләрдән бөтенләй мәхрүм ителер микәнни инде, ә?

Кайчандыр хатыны булган бу чибәркәй шуннан соң да ниләр сайрагандыр — анысын елгыр абзый тыңлап тормады, ишетмәде, йөрәге ярылудан сагайды бугай, капылт кына урыныннан купты да атлыййөгерә ишеккә юнәлде. Ул яшен суккандагыдай миңгерәүләнгән, елтыр күзләре акаеп калган иде. Әле кайчан гына гыйффәтле көенчә үзенә бирелгән, һәр сүзенә колак салып, авызына гына карап торган, хәзер әнә икенче берәүне яр иткән һәм аңардан бала билгән, шул баланы калкан рәвешендә күкрәгенә кысып кочаклаган килеш, мәгърурланып үзенең карарын чыгарган асыл затның сыгылып төшүен дә, искиткеч матур кара күзләреннән ачы яшьләр агызуын да, әлбәттә, күрә алмады...

Ватан сугышы башлангач, Сара ханым, картны сугышка алалар икән дә янә бала-чага белән ялгыз башым төялеп калам икән, дип хафаланган иде. Тик алай булып чыкмады. Военкоматка чакырмадылар 44 яшь тутырган Урманчены, милициягә дәштереп алдылар. Анда каһәрләнгән чырайлы, акай бәбәкле бер майор сөйләште аның белән:

— Фәлән елны фәлән статья буенча биш елга хөкем ителгән Урманче Б. И. синме инде ул? — дип сорады.

Киеренкелекне бераз йомшарту нияте белән рәссам:

— Срогымны текмә-тек тутырып кайттым мин, — дип әйтеп карады.

Ләкин теге акай күзнең үз туксаны туксан иде:

— Тутырып кайткансыңмы, качып кайткансыңмы — анысы безгә караңгы. Без шуны гына беләбез: немец фашистлары ил өстенә ябырылып килгәндә, Советлар Союзы башкаласы Мәскәүдә ышанычсыз элементларны яшәтә алмыйбыз. Егерме дүрт сәгать эчендә Мәскәүдән чыгып китәргә тиешсең! — диде.

Тораташтай катып калган, ни әйтергә аптыраган рәссамга:

— Менә шунда кул куегыз да китегез. Сезнең ишеләр белән гәп сатарга минем вакытым юк, — дип тә өстәде.

Өйгә кайтып сөйләгәч, Сара бөтенләй телсез калды. Бераз аңын җыйганнан соң иренә:

— Син бит Художниклар оешмасында торасың, шуны әйтер идең ичмасам... — дип карады.

Шундый кыен чакны да Габделбакый хатынына кара чырай күрсәтмәде, гайрәтен-ачуын йота белде.

— Их, Сарам-Сарам... Аңа бит синең нинди һөнәр иясе икәнең дә, кайсы оешмада торуың да кирәкми. Аның, гомумән, кешедә эше юк. Кулында өр-яңа указ, шуннан чыгып кына эш итә...

— Без кая барырга тиеш ди инде бу бала-чага белән?

— Мәсьәлә дә нәкъ әнә шунда шул, Сара, шунда... Кая барырбыз — шуны икәүләшеп бергә хәл итик. Әле бит Мәскәүдән киттем дә котылдым, дип кенә эш бетми, әле бит иртәгә дә яшисе бар, бу сабыйларны тәрбия кылып үстерәсе, ныгытып аякка бастырасы, адәм рәтле кеше итәсе бар. Аларның хакы — безнең өстә.

— Рәхмәт жылы сүзеңә, Бакыем. Шундый авыр чакны да сабыйларны уйлаган өчен Ходайның рәхмәте яусын үзеңә!

— Соң алар синең бәгыреңнән өзелеп төшкән алмалар бит! Алардан да, синең үзеңнән дә якынрак, газизрәк беркем юк мина бу дөньяда.

Сараның хәйран уңган хатын булуына рәссам тагын бер кат инанды: ул аркылыны буйга алмыйча теленә салынган арада хатыны кайлардандыр өч-дүрт чемодан тартып чыгарды, аларның тузанын сөрткәләп, берсенә балаларның киемнәрен урнаштыра башлады. Моны күреп, гаилә башы да исен-акылын жыя төште:

— Без болай итик, Сара. Мин хәзер үзебезнең Рәссамнар оешмасына барыйм, тегендә-монда сугылып, аласы акчаны юнәтим дә билетка чабыйм.

— Кая хәтле дип алырга инде исәбең ул билетларны?

— Сара дим, әйдә Сәмәркандка Мөхсинәләргә китик үзең белән! Тормыш алып барыр өчен безгә шуннан да муафикъ урын булмастыр сыман...

Хатын исә эш арасында гына:

— Казаныңа тартмыйммы соң күңелең? — дип, иренә күз салды.

— Анда бер дә күңел тартмый шул. Өстәвенә рөхсәт тә итмәсләр. Хәер, Казан ул гомер буена ачка интегә, сугыш заманында һич тә без анда тернәкләнә алмабыздыр. Ә менә Сәмәрканд — вакытында бөтен Шәрыкның мәркәзе булган кала. Аксак Тимер дә, аның оныгы Олугбәк тә ил-көн өчен аны кулай күргәннәр, фани дөньядагы ожмах иткәннәр.

— Шулай дисеңме? Ярый алайса, Бакыем, син кая дисән, шунда китәрбез, тәвәккәллик соң, Аллага тапшырып...

Кичке якта рәссам, үзенең ай буена куйган хезмәте өчен кесә тутырып акча алып, Сәмәркандка билетлар булмагач, билетны Алматы поездына жайлап-юнәтеп, өйгә кайтып кергәндә, хатыны әйбер-караны жыештырып бетергән, ашарга-эчәргә хәстәрләп, балаларның тамакларын туйдырган, урыннарын жәйгән дә үзе рояль янына утырган, нотасыз-нисез генә Шопенның ноктюрннарын уйнап күңелен юата иде. Әмма куллары үзенеке түгел диярсең, һич кенә тынлата алмый иде. Ирe кайтып керүгә, дымлы күзләрен күтәреп аңа карады, берни сорашмады: кыяфәтеннән юлы уңганны аңлады, аянычлы тавыш белән үзе сүз башлады:

— Бакы-ы-ый дим! Без бит инструментны Сәмәркандка хәтле алып бара алмабыздыр...

Шулай гына диде дә, күз яшен тыя алмыйча, әрнеп-сулкылдап елап та жибәрде, утырган жирендә сыгылып төште.

Ире аны тизрәк юату ягын карады, елмайган булды, көлгән булды:

— Һи, Сара-Сара... Баш сау булсын, яңасын алырбыз аның анда, моннан да ныграк ялтырый торганын! Менә үземә күп итеп акча биреп жибәрделәр. Аллаһы боерган булса, Мөхсинәләргә генә барып житик тә үзеңә пианино сатып алырбыз. Монысы утырсын шунда үзебез кайтканны көтеп. Ашарга сорамый бит ул...

Ышана иде Сарасы Габделбакыйның вәгъдәсен үтәвенә дә, тоткан жиреннән өзмичә калдырмавына да, ышана иде. Шуңа борчулары акрынлап кимеде, күңеле урынына утырды. Ул, рояль янынан торып, иренең тамагын кайгырта башлады. Рәссам үзе чүп өстенә чүмәлә өймәскә тырышты, яңа хәбәрне әйтергә бик үк ашыкмады. Аннары инде, жае килгәнне чамалап кына кай тарафларга кайчан китәселәрен төшендереп бирү ягын карады:

— Сарам, без, әлбәттә, Мөхсинәләргә исән-имин барып житәрбез. Анысына минем зәррә кадәр дә шигем юк. Мәгәр бүгеннән әле

Ташкентка да, Сәмәркандка да билет булмады. Бигайбә, Сарам, үзең белән кайтып киңәшләшмичә генә, тәвәккәлләп Алматы поездына билетлар алып кайттым.

Хатын ул арада ярыйсы ук тынычланып өлгергән иде инде, бер дә күтәрелеп бәрелмәде.

— Үзең гаилә башы, үзең беләсеңдер, син кая кушсаң, шунда барырбыз,— дию белән бетерде.

Әмма язмыш дигән нәрсә аларның теләк-ниятләре белән исәпләшеп тормады, мәсьәләне үзенчә хәл итте дә куйды. Алматыга исән-имин генә барып җиткәч, Сәмәркандка алар тиз генә чыгып китә алмадылар. Дөресрәге, Алматыдагы көнкүреш шартлары күңелләренә хуш килеп, шунда төпләнеп калдылар.

Вөгъдә иткән инструментны караганга кадәр эш мәсьәләсен кайгыртасы бар иде әле. Күпме генә эзләмәсеннәр, Сара ханымга кулай хезмәт һич кенә дә табылмады. Сугышка киткән укытучылар урынына математика, физика укытырга тәкъдим итеп карадылар да соң, үз һөнәрен әйбәт белгән һәм яраткан музыкант андый алдашу-яраклашу юлына басмады. Аның фикеренчә, теләсә кем балаларны музыкага өйрәтә алмаган кебек, математика фәненнән дә мәктәптә дәрес бирә алмаячак, андый укытучы, хезмәт хакы алып ятса да, укучыларны шыр надан калдырачак иде.

Балалар яңа урынны бик ошаттылар. Кай арада танышып та дуслашып өлгерделәр — көн буена урамда чабарга әзер иделәр. Әмма аларга да бирәр шөгыль кирәк булырдыр, болай трай тибеп кенә йөрсәләр, алардан юньле кеше чыкмаячак иде. Олырагын казакъ мәктәбенә бирделәр, әмма аның мәркәздән алып килгән дәреслекләре эшкә ярамады, яңаларын мең бәла белән табыштырдылар. Аның дәресләрен ата кеше күзәтеп-өйрәтеп торырга алынды. Ана телен әйбәт белгән бала үзе дә тугандаш телнең үзенчәлекләрен бик тиз шәйләп алды, укуында тернәкләнеп китте. Кечеләрен исә өйдә генә тәрбияләргә ниятләделәр — ана кеше аларның икесенә бер скрипка тоттырды. Сабыйларның күңеленә бу хәл бигрәк тә инде хуш килде, бер-берсе белән ярыша-ярыша инструментны дөрес тотарга, сызгычны шомарак йөртеп, әүвәл шыгырдаган, чыйнаган тавышлар чыгарырга, тора-бара көйгә охшашлы авазлар табарга тырыштылар.

Өйне җыештырып, ирен һәм балаларын ашатып-эчертеп, тәрбия күрсәтүгә бөтен көне үтеп китсә дә, утырып ял итәргә, ичмасам, бер минут вакыты калмаса да, акча эшли алмаганга Сара ханым кайгыра-борчыла, җанына тынгылык таба алмый иде. Үз-үзен битәрләү-әрнү аркасында тәмам корыды-кипте.

Күпне күргән, моннан хәтәррәк хәлләрдә дә яшәп караган Габделбакый гына борешмәде. Яңа мал-гонорар тапкалаганчы бар булганын туздырмыйчарак тоту ягын карады, шуңа күрә әйбер-караның арада бер кирәгенә акча тотса да, базарга хатынын җибәрмәде, үзе йөрде. Яшелчәҗимешнең кайчан арзанрак булганын бик тиз шәйләп өлгерде, малны кысыбрак тотарга өйрәнде. Хатын-кызның олау бушатканын күрсә, һич кенә дә алар яныннан дәшми-тынмый узып китә алмады, ярдәм кулы сузды. Мәһабәт чырайлы, таза гәүдәле ир-атның көченә, саллы хәрәкәтләренә хатын-кыз сокланып, үз итеп карады, аңа зур-зур кавынын-мазарын бирең җибәрде яисә дөгесен-фәләнен җүнрәк бәядән сатты. Биш кешелек гаиләсен ачка интектермәсә дә, ир кеше ничек тә ике кулына бер эш табу ягын кайгыртты.

Рәссамнар оешмасына барып, учетка керде, худфондларыннан эш алырга тырышты. Гәрчә үз кешеләре бик аз калган булса да, зур мал төшерерлек олы заказлар күренми иде.

— Булса, әкәжан, хәбәр итәрбез,— дип өметләндерделәр.— Үзең дә калада гына ятма, якын-тирәләрне йөреп әйлән, колхозга тегесен-монысын язасы да сызасы булмыйча тормас,— дип киңәш тә бирделәр.

Шулай бер китүендә рәссам атна-ун көн буена күренмәде, аның каруы, клуб белән колхоз идарәсен бизәп бетергәч, бер олау азык-төлек төяп кайтты. Сара ханымның сөенүе бер хәл инде, бала-чага отыры нык сөенде. Аларны ата кеше йоклап яткан җирләреннән уяттырды, карышып маташкан хатынына исә:

— Дәшмә син, Сарам, балаларны бик тә сагындым, тәтелдәгәннәрен ишетәсем килә, бергә-бергә чәйләрбез... Тамаклары туйгач, йоклавы да рәхәтрәк булыр үзләренә,— диде.

— Бәләкәен генә уятыйммы?

— Юк, Сарам, син аларның өчесен дә уят. Өчесе бердәй сагынылган.

Бала-чага белән мәйханә килеп, Ходайның һәр бирмеш көнендә ир белән хатын бер-беренең кәефен күреп, назлашып та сөешеп, тату гына яши торгач, ике-өч ел гомер үтеп тә китте. Сара ханым Мәскәү белән ара-тирә хат алыша иде, мәркәздәге музыка мәктәпләренең хәлен белеп торды. Аның өчен иң әһәмиятлесе шул: кайтып кергәннең икенче көнендә үк үзенең яраткан әшенә урнашачак, рәхәтләнеп, җиң сызганып эшли башлаячак. Төрле концертлар да булгалый икән, таныш-белеш җырчылар анда да чакырачаклар... Мәскәү Мәскәү инде ул, авыл булмас...

Иренә сүз кушкач, ир-ат уйга калды.

— Тагын берәр ел сабыр итмибезме, Сарам?— дип әйтеп карады.

Әмма, сыер дуласа — аттан уза, дигән мәкаль өстен чыкты, хатын үз сүзеннән кайтмады:

— Сиңа рәхәт, Бакый, син язасың да сызасың, һич югы минем яисә балаларның рәсемен ясыйсың. Мин нәрсә генә эшлим соң? Кухаркага әйләндем ләбаса. Музыкант түгел мин хәзер. Инструмент күрмәгәнемә күпме булды, тагын берәр елдан профессиональ музыкант булудан да туктаячакмын. Аннары үзең үк битәрләрсең әле менә...

Ир кеше ничек тә аны юатырга тырышты, көрәктәй дәү учы белән иңеннән, аркасыннан сыйпады, тагын да түбәнгәрәк шудырды, сөяргә-назларга исәбе барын сиздерде. Әмма хатын иркәләнүдән узган иде инде:

— Бакы-ы-ыем дим, кайтыйк өйгә, кайтыйк Мәскәүгә-ә-ә!— дип ачынып сөйләнде дә, иренең күкрәгенә капланып, сулкылдап елап җибәрде.

Габделбакый нинди авырлыкларга да түзә, күтәрә, тик менә хатынының елавына түзә алмый иде, йөрәкләре парә-парә телгәләнде.

— Һи, алай ук сынатма инде, Сарам... Анда кайтуга әллә мин каршыдыр димсең? Юк, мин үзем дә яраса менә хәзер очып китәр идем, икебез янәшә канат җилпер идек... Ярамыйдыр бит әле, сугыш бетмәгән...— дип, назлап сыйпады, яшьле күзләреннән үбеп дымны киптерде.

Сараның да җаны тынычланды, ул да кабат уйга калды.

— Без болай итик, Сарам. Бала-чага белән төялешми торыйк, мин бер башым гына кайтыйм да рөхсәт алыйм. Аннары инде гөрләтеп кайтып төшәрбез Мәскәүләргә, насыйп булса!

Тик менә гөрләтеп кайтып төшәргә насыйп булмады — якадан умырып тоткан иде Мәскәүләр, җибәрергә һич уйламады. Милициядә утыручы лейтенантның контузиясе бетеп җитмәгән иде әле, сөйләгәндә бигрәк тә сулъяк яңагы тартыша торды.

— Фашист илбасарларын үз өннәрендә әлегә тар-мар итеп бетергәнебез юк, сиңа да башкалага кайтырга указ чыкканы юк,— диде, тел яшереп тормады.

Юньле сүз ишетмәячәген чамалаган сәнгатькәрнең алдан ук уйлап-әзерләп куйган «контрдоводлары» бар иде, шуларны тезәргә кереште:

— Башкаланың үзенә үк булмаса, ихтимал, якын-тирәгә кайтып, шунда яшәргә рөхсәт бирерсез?— дип карады.

— Фашист илбасарлары Мәскәүгә якын ук килделәр бит. Алар анда агентларын калдырмагандыр дисеңме? Империализм агентлары белән элемтәгә керергә, контакт урнаштырырга җыенасыңмыни?!— дип сорауга сорау белән җавап кайтарды түрә.

Мондый гаеп ташлаудан миңгерәүләнеп китәрлек иде. Шулай да сәнгатькәр зиһенен җыйды-туплады, тагын бер талпынып карады:

— Алайса, ихтимал, Казанга-фәләнгә күченеп урнашырга ярыйдыр? Минем хатыным — укытучы, музыка мәктәбе укытучысы, аңа бит эшләргә кирәк,— диде, үзенчә инде бик тә ышандырырлык дәлил китерде.

Әмма теге бәндәгә сәнгатькәрнең дәлилләре кирәкми, ул аларга, гомумән, мохтаҗ түгел, аның үз туксаны туксан иде:

— Казан дип авыз да ачма, ул безнең дары мичкәбез. Сине анда яшәтә алмыйбыз. Ә инде хатыныңа килгәндә, указ аңа кагылмый, указ синең ишеләр өчен махсус чыгарылган.

— Алайса аңа башкалага кайтып яшәргә дә рөхсәт?

— Мин бит әле генә әйттем, указ синең шикелле ышанычсыз кешеләр өчен чыгарылган, дидем. Хатының кайтса кайтсын, без аңа тоткарлык ясарга җыенмыйбыз.

— Үземә кайчан рөхсәт бирерсез икән инде?

— Фашист илбасарларын үз өннәрендә тар-мар итеп бетергәч, күз күрер анда, карарбыз,— диде лейтенант, яңагы тартышканны сиздермәскә тырышып, урыныннан сикереп торды, аудиенциянең тәмам икәнен белдереп, нindидер кәгазьгә кул куйдырды да: — Ура мыегыңа, Мәскәүдән бүген үк китәсең! — дип ныклап искәртте.

Мәгәр әле сугышлар беткәннән соң да, «тамгалы» булган Габделбакый Мәскәүгә яисә Казанга кайтып яшәргә-иҗат итәргә һичбер төрле рөхсәт-фәрман ала алмады. Җәмәгатен бала-чагалары белән бергә Мәскәүгә кайтарып урнаштырса да, әллә ничә айга бер, хәтта елга бер өендә күренде исә, күрше карты шундук барып чага да, милицияләр, үч иткәндәй, төн уртасында килеп, Сара ханымның ачыргаланып елавына-сыктавына илтифат итмичә, рәссамны яткан җиреннән кубарып, яраткан хатынын нәүмиз калдырып, ачлыкка интеккән дәрвишнең кулына килеп кергән ризыгын авызыннан тартып алгандай, тансык ризыгыннан мәхрүм иткәндәй, җилтерәтеп алып китәләр дә поездына утыртып җибәрәләр иде...

Килер вакыт, алтмышы тулганда Урманчены Татарстанга иң олы түрәләр үзләре ялынып чакырырлар, авиация заводы салдырган бер генә катлы таш өйнең яртысын бүлеп, остаханә итеп бирерләр, ә инде яшәү өчен биек түшәмле, иркен генә, өч бүлмәле фатир табарлар. Габделбакый шунда тизрәк Мәскәүгә йөгерер. Исәбе — тиз арада-тиз көндә хатынын алып кайту, гаиләле булып имин генә яшәү, тапкан малын кайтарып бирү, дөнья көтүне хуҗабикәгә тапшыру, үзе исә, җиң сызганып, уемәвәләү эшенә ябышу, заяга узган елларның каруын кайтару, барлык хыялларын тормышка ашыру булыр.

Әмма нинди генә дәлилләр китермәсен, нинди генә вәгъдәләр бирмәсен — гомер иткән хатыны моңа ризалык бирмәячәк. Сара ханымның дәлилләре шулай ук саллы, төпле һәм ышандырырлык булыр:

— Бакый, зинһар, күңелеңә авыр алма. Синең ул ач Казаныңа барырга һич кенә дә күңелем тартмый. Гомер буе Мәскәүдә яшәп, мин инде бик нык тамыр җәйгәнмен, кругом танышлар, пенсиягә чыксам да, әледәнәле йомыш белән мөрәҗәгать итәләр. Әледән-әле өемә килеп, хәл белешәләр. Тимә инде син миңа, Бакыем. Шушында балалар, оныклар янында картаюдан да яхшысы булмастыр. Аннары шунысы бар бит әле, картым...

— Йә, анысы нинди теләк, нинди таләп? Һәммәсен үтимен, берсенә дә каршылыгым юк, Сарам!

— Хатыннар нигәдер иртәрәк картая икән, Бакыем. Мин шуны белми йөргәнмен, бүген төнлә аңладым да — йөрәкләремә кан сауды. Уйлыймуйлыйм да... Бара алмыйм икән мин синең ул Казаныңа. Барудан һичбер төрле файда юк.

— Файдасы аның син Казанга барып, өйне ямьләндереп җибәргәч булыр, Сарам, иншалла, булмыйча калмас. Дөнья рәхәте изге хатын белән, дип белми әйтмәгәннәрдер безнең бабайлар. Сиңа бит, анда баргач, Сарам, дөнья алып бару өчен, көн итү өчен кирәкле нәрсәләрнең һәммәсен алып кайтачакмын. Өч бүлмәле һәйбәт фатирыбызны үз кулыңа алсаң, ямьләнеп китәр иде безнең дөньялар.

— Һаман аңларга исәбең юк синең, Бакыем. Анда барган тәкъдирдә дә бит миннән беркинди рәт чыкмаячак. Шуны аңладым, дип әйтеп торам лабаса. Бүгенге кебек кымтырыклый торган булсаң, мин сиңа чыдый алмам, барыбер Мәскәвемә качып китәрем. Син әле дәрманлы-әүкатле, хатынсыз тора алмассың, берәр яшь-җилкенчәкне табарсың әле. Ә мин дәрмансыз корткамын. Кызыгы калмады, яме бетте хәзер минем өчен дөньяның...

— Хатын аерырга Идрис хәзрәттән һичбер фәрман булмады, Сарам. Идрис хәзрәт үзе дә бер хатын белән гомер кичерде, миңа да хатын аермаска дип васыять әйтеп калдырды. Инде үземнең мөнәсәбәткә килгәндә, синнән гомеремдә дә аерылырга исәбем юк. Тагын ныклабрак уйлап карарсың әле, Сарам, хәзергә бер-беребезнең хәтерен калдырмыйк.

Джугашвилиның әрсез иярченнәре китергән газаплардан арындык бугай инде, бу дөньяда Сак белән Сок шикелле яшәүдән тәмам гарык булдык инде, ниһаять яңадан кавышабыз, яңа өйдә өр-яңадан гаилә тормышы белән яши башлыйбыз, дип өметләнеп кенә торганда — менә сиңа кирәк булса! Элеккечә газаплы ялгызак тормыш алып баруга дучар ителәсең түгелме соң, абзыкай? Үз көненне үзең күрергә тиеш буласың инде, берәүгә дә кирәгең калмаган дигән сүз инде! Рәссамнар оешмасына да, хәләл җефетеңә дә... Ә соң халыкка?

Монысын бит әле бер-ике әсәр иҗат итеп кенә ачыклау мөмкин түгел. Моның өчен эшлисе дә эшлисе... Бүтән беркинди чарасы калмагач, рухы көчле сәнгатькәр бөтен дөньясын онытып, гаилә фаҗигасен бөтенләй кичермәгән-күрмәгәндәй, үҗәтләнеп үзенең яраткан хезмәтенә күмелә — нәкышь, уем, графика өлкәсендә береннән-бере гүзәл вә камил әсәрләр иҗат итү бәхетенә ирешә.

Әмма фаҗига көннең-көнендә, айның-аенда, елның-елында үзен сиздереп тора. Тиз арада онытылса, ул шул, агай, фаҗига дә булмас иде...[1]

Бүген балкыр төс дип алсам палитрадан,
Иртән — сулган, тоскәргән буяу була.
Аллы-гөлле, рәнкарән[2] буяулардан —
Киндернен үзәренә фуза[3] тула.

## VI баб

### «Алмата елгасы»

*«Осталык олуг баскыч ул.*
*Әгәр дә мәгәр кеше, мин бу*
*баскычтан менә алырмын микән,*
*юк микән, дисә — әлеге баскычтан,*
*һичшиксез, менә алмый ул. Баскыч*
*никадәр биегрәк булса, кеше дә*
*шулкадәр осталыкка ирешә».*

Бакый Урманче,
*1982 ел.*

[1] Б. Урманче шигыре.
[2] Рәнкарән (рян гярән) — төрле-төрле төстәге.
[3] Фуза — каткан буяу кисәкләре, кырынтык.

Мәскәүдә яшәгән чагында Габделбакыйга барлык рәссамнар да туганнар-дуслардыр сыман тоелган иде. Арада бер якын күргән, дус иткәннәре — Казагыстанда яши, һәммәсе дә кунакка чакыра торган иде. Ихтимал, әнә шуңа таянып Алматыда төпләнеп калгандыр да әле. Бик ихтимал.

Әмма гаиләсе-ние белән күченеп килгәч, аның талантлы рәссам булуына сөенүчеләр кимегәннән-кими барды сыман. Һәрхәлдә, худфондтан аңа заказ бирергә атлыгып тормадылар.

Аеруча кызыклы бер генә вакыйганы искә төшерү дә җитәдер. Кешеләр белән җиңел аралашучы Габделбакый үзенең коллегалары белән генә аралашып калмый, мәдәният өлкәсендә хезмәт итүче шәхесләрнең дә күбесе белән танышып-дуслашып ала торган иде. Арада бер якын күргәне Мохтар Әүәзев булды. Үзе галим, үзе әдип, үзе әңгәмә өчен бигрәк кулай зат инде менә. Сөйләшә торгач, шунысы да ачыкланды: алар икесе дә бер үк елны туганнар, 1897 елгылар булып чыкты. Алар танышканда Мохтар үз халкының бөек акыны Абай Кунанбаев турында роман язып ята иде. Әнә шул әсәрен акынның 100 еллыгына бастырып, бөтен дөньяга мәшһүр иттереп аның бөеклеген исбат итәргә ашкынып-теш кайрап тора иде. Зур роман язу өчен әдип хәйран күп эзләнгән, бөтен республиканы урап-айкап чыккан, Абайны белүчеләрне күреп сөйләшкән, шул заманнардагы тормыш-көнкүрешне сораштырып, ачыклап йөргән.

Гәрчә боларны сөйләп кенә бетерерлек булмаса да, Мохтар очрашкан саен, хәл-әхвәл сорашкач та, Абайның холкы-фигылендәге берәр сыйфатны яисә акынга бәйле берәр мәзәк хәлне сөйләмичә калмый иде. Аның басынкы гына тавыш белән мәзәкне дә җитди кыяфәттә, көлмичә-нитмичә генә бәян итүен рәссам һәрвакыт яратып, гыйбрәтле нәрсә буларак тыңлый торган иде. Шулай тыңлый торгач, рәссамның күңелендә бөек шагыйрьнең образы гәүдәләнде дә куйды бит. Уйланып йөрде, йөрде дә сәнгатькәр көннәрдән бер көнне, гадәтенчә балкып-елмаеп:

— Мохтарҗан! Синең шул чаклы да рухланып-канатланып Абайның образын иҗат итүеңә, дустым, сокланып туя алмыйм бит. Мине бигрәк тә синең фантазияң сөендерә...— дип сүз башлаган иде, әмма кордашы аны бик тиз бүлдерде:

— Хаталанасың, достым, анда фантазия юк. Һәммәсе булган хәл. Мин бит аларны җир астыннан казып чыгардым, шуны китапка яздым.

— Мохтарҗан, эш болай тора бит. Мин синең шикелле олуг галим дә, мәшһүр әдип тә түгел. Мин фәкать урта кул рәссам гына. Шулай булгач, әдәбият өлкәсендә сүз куертуны синең үзеңә калдырып торып, фәкать үзем әзме-күпме белгән рәсем сәнгате хакында гына фикер йөртәм. Оста барда телең тый, ди бит безнең халык.

— Бар андый өндәмә сездә, бар. Ләкин бит, эндәшмәгән кешегә тау эндәшми, дигәне дә бар бугай әле?

— Әйе, сүзең хак, дустым, әлбәттә, бар андые да. Инде безнең әңгәмәгә килик. Әгәренки рәссам иҗади фантазиягә бирелеп, үзе һичшиксез әйбәт белгән өлкәдә берәр күркәм образ иҗат итә икән, яисә юньлерәк картина яза икән, тамашачы аны тормыштагы образ яисә күренешнең реаль чагылышы буларак кабул итә. Димәк ки, рәссамның үзендә талант булсын да бай хыял булсын. Шулар булмаганда тамашачы аңа ышанмый.

— Әдәбиятта һәм шулай бит, Бакыйҗан достым. Нәкъ шулай.

— Һе, шулай дисеңме? Димәк ки, иҗади хезмәтнең һәр өлкәсендә буяуларны кызганмыйча, әмма ләкин урынын белеп кенә салсаң, укучы да, тамашачы да сиңа ышана. Тормышчан, ди, тормыштан алып язган, ди. Менә синең романыңдагы вакыйгалар да тулаем тормышчан килеп чыкканга иманым камил, дустым.

— Рәхмәт, рәхмәт, Бакыйҗан, синең сүзләрең бик татлы, йөзем шәрабе төсле.

— Амин, шулай була күрсен инде. Әле менә китабыңа рәсемнәр ясау нияте кузгалды үземдә...
— Бакыйжан, расмы әйткәнең? Ясыйсыңмы китапка рәсем?
— Вәгъдә — иман, дустым.
Әуэзевнең сөйләвенә таянып, игътибарга аеруча лаек эпизодларга рәссам тушь белән рәсемнәр ясап ташлады. Аларны авторга да күрсәтте.
— Афәрин, Бакыйжан! Афәрин, достым! — диде Әуэзев, рәсемнәргә күз салу белән.— Бу нәкъ безнең дала килеп чыккан: үзе иркен, үзе киң, һава күп монда. Пәрәвездәй җиңел килеп чыккан. Казакъның җәйләүгә күченүен нәкъ дөрес гәүдәләндергәнсең, молодец! Олаулар, атлар...— дигәч тә, кинәт, сөяк йоткандай, тукталып калды.
Рәссам, елмаюын яшерергә тырышып:
— Нәрсә, кордаш, әллә бик үк сәнгатьчә булып җитмәгәнме? — дип кызыксынды.
Әуэзев күтәрмәде, кулындагы рәсемне бераз читкәрәк этәреп, янә төпченебрәк күздән кичерде дә:
— Атны матур ясыйсың икән, достым... Хәйран җилле чабалар... Очкан кебек... Менә боларына утырып барасыларым килде. Тик бер нәрсә тыелып калырга мәҗбүр итте, Бакыйжан,— диде.
— Бу арада синең Алматыдан читкә йөргәнең юк бугай, шунадыр ул, дустым Мохтаржан.
— Юк шул, Бакыйжан, белмәдең. Бу рәсемдә син атларның барчасын иноходец иткәнсең гуй! Ягъни, юрга... Андый атны казакъ ияргә өйрәтә, арбага җикми гуй.
— Нәрсәдән чыгып әйтәсең әле син моны? Сөйләп җибәр, без дә белик.
— Менә күр инде: синең рәсемдә атлар бик матур, ләкин атның сул аяклары икесе дә арттa, уңнары икесе дә алда. Гади ат бервакытта да алай йөри алмый, ул кешечә йөри: сул аягының арткысын алга чыгарганда уңының алгысын чыгара, шулай атлый, шулай чаба гуй. Бу, достым, табигатьнең язылмаган законнарыннан саналырга хаклы.
— Һәй, Мохтаржан дустым, күзең үткен икән, барысын да күрәсең. Тик менә икенче бер нәрсә бар бит әле, шуны да тыңла. Табигатьнең ул законы яхшы таныш миңа. Әмма рәссамнардан фәкать Мочалов-Френц кына извозчик атларын шулай ясый. Ул рәссамның шактый картинасы Ленинградтагы Рус музеенда саклана. Тематик яктан да әһәмиятле, сәнгать әсәрләре буларак та — импрессионистлар рухында, ачык буяулар белән язылганнар...
— Франц дидеңме, Ференц дидеңме, анысын белмәсәм дә, импрессионистлар, постимпрессионистларның иҗатыннан мәгълүматлымындыр. Син үзең дә шуларга охшатып ясыйсың гуй!
— Минем охшату болай гына ул, дустым, саф реализм калыбына бикләнеп калмас өчен генә. Ә менә Лев Френц исә — зурдан кубып иярә, аның колач киң. Атларының да бер яктагы аяклары йә бер-берсенә тиеп тора, йә инде бик еракка ташланган: алгысы — алга оча, арткысы — артта кала.
— Нәкъ табигатьтәге кебек икән.
— Менә син, әдип кеше, олуг галим, шулай дисең дә бит диюен, мин белгән иҗат ияләренең берәве дә картинасына алай язмый. Ихтимал, контрзакон бардыр. Һәркайсының ат сурәтендә бер яктагы аяклар алда булса, икенче яктагылары — артта кала. Мин дә менә шул юл белән иҗат итеп киләмен. Хикмәт бит аякларын ни рәвешле бирүдә түгел, хикмәт — ышандырырлык итеп атның сурәтен ясый белүдә, хәрәкәтне күрсәтеп бирүдә! Тегеләй эшләргә нишләптер кулым бармый бит, дустым. Син миңа үпкәләмә бер дә...
Атның аякларын башкача язарга кулы бармаганны рәссам янә дә утыз-утыз биш елдан соң исбатлады. Акварель буяу белән ясалган искиткеч камил вә гүзәл әсәре бар — «Кышкы иртә», шунда да атның сул

аяклары алга атлый, уннары икесе дә... артта калган. Әмма бу хәл һич кенә дә сәнгать әсәренең бөтенлегенә дә, камиллегенә дә зыян китерми, пәрәвездәй җиңел эшләнгән әсәрнең эмоциональ тәэссорат көчен һич тә киметми.

Әдипнең сөйләгәнен рәссам күп тыңлады, зур кызыксыну белән тыңлады, бүлдермәде. Кешедә бит һәрвакыт үз җаен кайгырту сыман бер әйбер, эгоизм булучан. Азракмы ул синдә, күбрәкме — анысы табигатеннән, холкыңнан килә, әмма син аңардан бөтенләй азат түгелсең. Урманченың эгоистлыгы иҗатына бәйләнгән, һәм ул үзе әһәмиятле дип санаган, игътибарын җәлеп иткән берәр яңа теманы акрынлап кына үзләштерергә, үзенеке итәргә тырыша, ул инде аны ычкындырмый иде.

Әнә шулай авторны җае чыккан саен сайратып, образны ачыклый торгач, аның күңеленә казакъларның бөек шагыйре Абай Кунанбаев керде дә утырды бит. Шәхес буларак, характер буларак тынгы бирми башлады. Андый чакны исә портретны язмыйча аңардан котыла алмыйсың. Әнә шул рәвешле бер үк образ ике дус иҗатчының бөтен сәләтен бөтереп кенә алды.

Көннәрдән бер көнне урамда шактый вакыт һава сулап йөргәннән соң рәссам әдипне үзенең остаханәсенә алып керде.

— Синдәге китапханә минем өйдә дә юк ул, остаханәнең фәкыйрьлеген әйтәсе дә түгел,— дигән булды хуҗа, авыр имән ишекнең йозагын ача-ача.

Кунак кыстатып тормады, керә-керешкә үк түргә узды. Ят хөҗрәгә килеп кергәч, як-ягыңа карану табигый нәрсә инде ул, әмма Әүэзов уңга-сулга күз атып кына алды да өчаяк-мольберт алдында тораташтай катып калды.

Хуҗа үзе аңа һич илтифат итмәгәндәй, битараф бер кыяфәт белән киштәдәге картиналарын кузгаткан, урыннарын алмаштырган булып маташты. Кунагы ягына әйләнеп тә карамады. Кунак исә мольберттан күзен ала алмады, соң дәрәҗәдә гаҗәпсенеп, әле якынрак килеп текәлде, әле читкәрәк китеп, башын бора-бора, күзләрен кыса-кыса карап азапланды.

Ниһаять, гаҗәпләнүен әйтмичә кала алмады:

— Бакыйҗан, син безнең Абаебызның портретын ясагансың гуй! — дип әйтә куйды.

— Нәрсә, охшаганмыни?

— Абай инде бу, Абай! Күргәч тә мин аны танып алдым. Ай-һай, шәп килеп чыккан бит, дустым!

— Әле эшләнеп бетмәгән, кайсыбер детальләрен тәгаенлисе бар. Менә синнән киңәш-фәлән сорап, галимнәр теле белән әйтсәк, консультация аласым килгән иде.

— Моңа нинди консультация кирәк булсын ди, Бакыйҗан! Портрет идеально чыккан. Әйбәтрәк рамга куярсың да юбилейда халык алдына чыгарырбыз үзен.

— Нәрсә, эше беткән, дисеңмени? Күзе, борыны, башын тотуы ничегрәк, килешәме, ярармы шулай калдырсам?

— Син, дустым, аңа кагылма инде. Портретта Абай Кунанбаев нәкъ үзе. Һәр казакъ сиңа шулай дияр. Син аны рамга куй да...

— Бер дигән багетларым шуны көтеп ята, рамны ясыйбыз аны, шәп итеп ясыйбыз!

Габделбакый бу темага кабат-кабат әйләнеп кайтачак әле. Казакъ халкының даһи улы Абай Кунанбаев сәнгатькәргә, үз халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай кебек үк, тынгы бирмәячәк әле. Әгәр дә сәнгатькәр үзенең гомерендә беренче шәхси күргәзмәсенә (Алматы, 1958) Абайның 100 еллыгына (1945) язылган портретын, ягъни шагыйрьнең тирмәдәге сурәтен куйган булса, 1982 елгысына — махсус зур итеп, матур итеп яңа портретын яза. Әнә шул иҗат дәрте белән янган дәвердә сәнгатькәрнең:

— Мин йокыга яткан вакытта да уйлап ятам: Абайның бу жирен болайрак, теге урынын тегеләйрәк итәсе, төзәтәсе булыр... Шуннан йоклап китәм. Иртән инде тотынам төзәтергә, шәбәйтергә...— дип әйткәнә, мөгаен, тикмәгә түгелдер, аның чын мәгънәсендә Абайны аңлап, тулаем үзен аның мохитында яшәгәндәй хис итүдәндер...

Казагыстанда ун-унбиш ел яшәү дәверендә Бакый Урманче иң гүзәл нәкышь әсәрләрен иҗат итте. Арада сәнгать эшлекләләренең портретлары игътибарга аеруча лаек. Зиннәтле киемнәр киеп, ханбикәдәй утырган мәһабәт йөзле артистка Шара Җәндәрбәкова портретына кемнәр генә сокланмас икән! Рәссамның бу очракта уңышы нәрсәдә? Халык артисткасын ул табигый шартларда — спектакль барган декорация фонында, милли киемнәр кидереп, илаһи бер позага утырткан да әнә шул үз мохитында мәңгеләштергән. Әлеге сәнгать әсәренең Мәскәү музеена барып эләгүе тикмәгә түгелдер инде.

Ә менә балерина Рагәл Таҗиеваны икенче бер халәттә — биегән чагында, дөресрәге балет спектаклендә башкарган ролендә тасвирлый. Рагәлнең җилпәзә шикелле җәелгән итәгендә генә түгел җинеллек, балеринаның үзендә, бөтен гәүдә тотышында, аяк-кулларында. Картинага карыйсың да, менә-менә очып китәрдер сыман тоела...

Тугандаш халыкның тормышы, киң күңелле булуы, иркен вә иреклә, күпчелеге киң далада, турыдан-туры табигать кочагында яшәве рәссамны тәмам сихерли.

Менә бер заман ачык чырайлы агай белән атларга атланалар да чыгып китәләр болар җәйләүгә. Җәй көне җәйләүдә жаның ни тели, шул бар. Иң күбе, әлбәттә, кымыз белән ит.

Әллә инде ат өстендә килеп арылган иде, әллә кымызларына алдандымы, думбра кылларының моңлы көенә сихерләндеме, ничек булса булды, мәгәр кунак өлкәннәр белән әңгәмә коргач, тирмәдә утыра торгач, эңгер вакытлары җиткәнен сизми дә калды. Хуҗаларның ни сәбәпледер ыгы-зыгы килүеннән файдаланып, далага чыкса, ни күзе белән күрсен — иң алдан чәрелдәвек тавыш белән мәэлдәп, хуҗаларга хәбәр бирен кәҗәләр, саңгырау тавыш белән бәэлдәп сарыклар, аннары инде олысымак чайкала-чайкала, ашыкмыйча гына, саллы адымнар белән сыерлар өерләре белән көтүдән кайтып килә икән!

Әлеге гүзәллеккә хәйран калып, тәмам сихерләнеп, Урманче үзенең сәнгатькәр икәнлеген дә исеннән чыгарып җибәрде. Ул шулай мөкиббән китеп, сокланып карап торган арада картина үзгәреп тә өлгерде, дөресрәге аңа икенче төрлерәк төсмер иңде: күкнең зәңгәрлеге куерганнан-куера барды, офыкның алсулыгы шәмәхә төскә керде, юрта араларында тыз-быз йөрүләр кими төшеп, һәркем үзенең иямәшкән-күнеккән шөгыленә бирелде: кайсылары бияләрне, сыерларны саварга чүгәләде; ир-ат халкы сарыкның муен төбен карап симезрәген сайлап, чаж-чож пычак кайрады; хатыннар исә ит пешерергә учаклар тергезеп җибәрде.

Картина үзгәрде дигәннән, рәссам үзенең кем икәнен исенә төшерде һәм кабалана-кабалана буяуларын, кыл-каләмнәрен хәстәрләде. Әлеге мизгелне ничек кенә булса да картонга тоташы белән төшереп өлгерәсе иде бит гуй!

Күкне дә, офыкны да, хәтта әле тирмәләрне һәм алгы пландагы чирәмне дә хәзер үк язып тору мөмкинчелеге юк, аларны соңыннан иркенләбрәк язып булырдыр, хәзергә төсләрен тәгаенрәк билгеләп, хәтергә әйбәтләп сеңдерүдән һәм гарәп хәрефләре белән язып куюдан да яхшысы булмастыр... Ә менә аерым детальләрне... әйтик, әледән-әле тоныклана-карала барган мал-туарны, алар янында кайнашкан-мәш килгән ир-атны, хатыннарны менә хәзер үк буяу белән язгаламыйча ярамас. Боларын хәтер сандыгына салу һич тә килешә торган эш түгел. Тик менә алгы планга кайсысын чыгару мәгъкульрәк булыр икән?.. Бия савучысынмы, әллә инде гап-гади сыер савып утыручысынмы? Юктыр, алай ярамастыр. Сыер сауганы, абзыкай, синнән башка да ясаучылар күп булды.

Син менә бия савучыларның изге хезмәтен мәңгеләштер, шунда булырсың егет!.. Ләкин бу очракта уңайлы булмас алай итү. Һәрхәлдә, кичке эңгер куерып яткан бер мизгелдә иң алгы планда бия савып утыручыны күрсәтү дөрес үк булмастыр. Композицияне тота алмаячак, надан икәнсең, Бакыйҗан, диярләр.

Юк, абзыкай, син инде мәшһүрлек даулыйсың икән, карасу фонга аннан да караңгырак детальләр тезмә, яктырагын эзлә, тап! Ә-ә-әнә теге учакны тартып китер син иң алга! Бердән, яктылыкны күрсәтү һичшиксез отышлы булса, икенчедән... Икенчедәнме? Иң-иң әһәмиятлесе — хәрәкәтне бирәсең. Тик инде бирә алсаң, масаймый-нитми генә чиләнсәң, хәлеңнән килсә...

Илдән сөрелгәннәр ягада, чит җирләрдә очрашса, яман якын тоелып, дуслашып китүчән була. Габделбакый Алматыда татарның олуг галиме белән дә, мәшһүр композиторы белән дә хәйран нык дуслашып ала. Йа рабби! Бер үк дәвердә, бер үк әдипләр белән, сәнгать әһелләре белән аралашып яшәгән шәхесләрнең истәлекләре сөйләп кенә бетәрлекмени!

Профессор Хәйрулла Мәхмүдов — күпне күргән, һәр кешегә турысын әйтә торган гадәте булганга, шактый кыен ашарга өлгергән иде инде. Әйтик, фән докторы булганнан соң да әле биш-ун ел буена профессор исеме бирмичә интектерәләр. Академиклыкка аның кандидатурасын янә биш-ун елдан соң гына күтәрәләр. Әмма тантаналы рәвешкә кертеп бизәлгән залга килеп керү белән, күңеле бик үк өнәп бетермәгән галимнәрне күреп, гадәтенчә:

— Шушы наданнар минем язмышны хәл итәсемени?! — дип шәрран ярып үзенең бәһасен бирә.

Ахырдан үкенми генә дә бит, ичмасам! Әллә ничә телне искиткеч әйбәт белүе, камил белүе алдында хәтта әле Габделбакый да баш ия. Әмма теге мактау сүзен, гомумән, күтәрә алмый, дөресрәге, ул аңа мохтаҗ түгел.

— Син бит һәркемгә ярарга тырышасың! Нишләп әле син бөтенләй сәләтсез бәндәләргә дә елмаясың, башыңны иясең? — дип сәнгатькәрнең күзен ачырмый.

Турысын әйткән кешегә үпкәләмәссең бит инде. Көлә генә сәнгатькәр:

— Мин бит, дустым, бүген үземнең холкымны үзгәртә алмыйм инде. Табигать шундый ачык авыз итеп яраткан икән, берни эшләтер хәл юк, — дип зур-зур кулларын як-якка җәеп җибәрә.

Әллә икесе дә сәнгать әһеле булганга, әллә серләре килешә төшкәнгә, композитор Латыйф Хәмиди белән ешрак очраша Габделбакый. Остаханәсенә килгән саен, ачык чырай белән каршы ала, түрдәге диванына иплəп кенә утырта да хәл-әхвәл сораша. Кунакның җавабына оста гына иттереп бирәр гыйбрәтле-кызыклы хәлне ялгап җибәрә дә, шул рәвешле әңгәмә башланып та китә.

— Хәзер бер кызык хәл сөйлим үзеңә, дустым. Бу теге комбинатка оформление ясаган заман. Эшне тәмамлап киләм, полный ход бара. Айлар буе чиләнгәнемне һәйбәт кенә бәяләсәләр, шуннан артыгы кирәк тә түгел.

— Шулай озаклап эшләдеңмени син анда? — дип кызыксына кунагы.

— Озаклап, дустым. Ике-өч көндә генә башкарылган эш түгел ул. Ярый, миңа ничек тә комбинатның директорын майларга да җайларга кирәк бит инде. Шул, бер көнне өйләдән соң тоттым мин моны. «Федор Афанасьевич, миндә бер 96 яшьлек карт бар, яман зәһәр карт, сезне шуның белән таныштырасым бик килә», — дим. Тегенең бер дә исәбе юк минем арбага менеп утырырга — тегеләй ди, болай ди. Мең бәла белән күндердем үзен. Үкенмәссез, дигән идем, чыннан да шулай булды. Кердек минем хөҗрәгә — беркем юк. Уңга-сулга карана бу. «96 яшьлек картыгыз кайда соң?» — ди. «Хәзер була», — мин әйтәм. Чемоданнан чыгарам да бер литрлы яшькелт шешәне, салам моңарга тимер круж-

каны тутырып. Үземә стакан да баштин ашкан. Тиз генә әйләндереп капламакчы иде теге — ике күзе шар булды. «Спирт икән бит бу!» — ди. «Әйе,— мәйтәм,— 96 яшьлек зәһәр карт шул үзе инде»,— дим.

— Нәрсә, күңеле булдымы соң?

— Һәй, дустым! Булды гынамы! Атна-ун көннән килә минем янга. Портфельле бер кешене дә иярткән. «Теге 96 яшьлек картны күрәсе иде»,— ди. Минем инде исәп-хисап өзелгән, чабата киенгән. «Һәй, кызганыч шул, җан тәслим кылды бит ул, кичә җидесен уздырдык»,— дим...

Кунагын көлдерү бәхетенә ирешкән хуҗа яңа бер кыйссаны башлап та җибәрә:

— Һәр мәмләкәтнең олуг галиме, фидакяр бер әүлиясе була бит ул, дустым. Әле минем кулыма Венгриянең шундый олы шәхесе Вамбери хатирәләре килеп керде. Ишетеп кенә күптән белә идем инде моннан 100—150 еллар элек шундый галим яшәгәнен. Әмма язмаларын фәкать хәзер генә кулыма төшердем.

— Күңелеңә хуш килердәй нәрсә таптыңмы соң?

— Хәйран тамаша ул китап. Гаять кызыклы зат була Вамбери. Аның шөгыле, тоткан иманы — дәрвишләр шөгыленә, дәрвишләр иманына тәңгәл килә. Һәрхәлдә, мин үзем аның фидакярлеген шуларга тиңлимен.

— Үзең дәрвиш булгач, күңелеңә ошардай кешене дәрвишкә саныйсыңдыр инде,— дип елмайды Хәмиди.

— Әлбәттә, шулай! Сүзебез Вамбери хакында бит әле. Менә шул галим бу якларга килеп чыга. Сәмәрканд белән Бохарага илаһи зур, лаек бәһане бирә: безнең Бохараны Лондон белән Парижга тиңли. Дәрвишләрнең Нәкышбәнд җәмгыятенә нигез салучы Баһаветдин шәйхнең мавзолеен-төрбәсен барып күрә, аңа зыярәт кыла. Шунда үзен изге җирләргә хаҗ кылып йөрүче дәрвиш итеп таныта.

— Болай да үзен дәрвиш дисең түгелме соң? Чынлап та шулайрактыр...

— Хикмәтен аңлап җиткермәдең, Латыйфҗан дустым. Андый изге җирләргә бит фәкать мөселманнарны гына кертәләр. Кяферләрне һич якын китермиләр. Ә моның бик тә инде күрәселәре килә. Менә ни сәбәпле изге ялганга юл ачыла.

— Зыярәт кылырга теләгәч, бер дә гаеп эш түгел инде...

— Дөре-е-ес, бер дә гаеп түгел. Әмма сиңа сөйли башлавымның сере икенче нәрсәдә. Шул Вамберидан укып белдем: Баһаветдин шәйх 7 санын изгегә санаган икән! Һиҗри белән исәпләгәндә 717 елны дөньяга килгән, 7 яше тулганда Коръән-хафиз булган, җитмешне тутырып, дөнья куйган...

Хәмиди башын чайкап куйды:

— Ай-һай, җиде яшендә Коръәнне яттан белгән, дигәненә әлләни ышанасы килми бит. Монысы да изге ялган түгел микән?

— Юк шул, дустым! Була ул андый хикмәтле хәлләр. Әмма сиңа сөйли башлавымның сере анда да түгел: мин үзем дә бит 7 санын изгегә саныйм...

Ул арада туган яклар искә төшеп, моңсу булып китә. Остаханә беравык тынып калгандай була. Сәнгать әһелләре аңлыйлар бер-берсен, яхшы аңлыйлар. Ул темага сүз куертудан да мәгънә юк. Туган якны сагынулары хакында авыз ачып сүз әйтмәсәләр дә, әле генә гәпләшеп алгандай, хуҗа, гадәтенчә, тамак кырып ала да сузып җырлап җибәрә:

Ватанның хары — горбәтнең гөленнән,
Васи афзалдыр загы — болболеннән...

Юкка гына алай дип язмаган шул Утыз Имәни: илне сагынган, дустым, ул да, безнең шикелле...

Габделбакый мольберты янына барды да кыл-каләме белән нәрсәнедер төзәткәндәй иттерде.

— Хәзерге телдә ничегрәк инде ул?
— Хәзерге телдәме?

Ватанның шайтан таягы чит илнең гөленнән,
Каргасы — былбылыннан күп өстенрәк.

Хәмиди уйга калды. Аннары башын күтәреп, елмайды да:
— Язучы аны шигырь итеп язгандыр инде, көйгә үзең генә салгансыңдыр, импровизация генәдер,— дигән нәтиҗә ясады.
Габделбакый рәнҗемәде-нитмәде, көрәктәй кулы белән һаваны ярып:
— Дөре-с-ес, дустым. Ярминкә дип күз буяп маташуым Буа базары гына булып чыкты. Профессиональ композитор алдында шулай җөрьәт итеп җырлаган өчен син, әлбәттә, гафу ит,— диде.
— Юк-юк, синең тавышың бик матур баритон. Минем алда гына түгел, сәхнәгә дә чыгып җырлый аласың.
— Кая инде ул безгә! Шушында остаханәңдә бераз мөгрәп алсаң да, күңелгә рәхәт булып китә.
— Нинди шагыйрь диден әле?
— Габдерәхим Утыз Имәни. Узган гасырларда ук яшәгән ул. Яратам шуның шигъриятен. Менә син дә тыңлап кара әле:

Буем зур, куәтем күп, димә, бән йәш,
Хода хөкемендин узып тартмагыл баш.
Бәнмен ага җиһанга, димә, зинһар,—
Агалардан терек кем калганы бар?

Игътибар иттең микән, Латыйфҗан дустым? Гаҗәеп мәгънәле, гыйбрәтле сүзләр бит, масаймаска биргән акыллы киңәш.
Хәмидинең чибәр йөзе елмаюдан тагын да ныграк матурланды. Ул башын чайкап алды:
— Хәйран калам мин сиңа, ничек шулхәтле әйберне хәтерлисеңдер! Әле бит үз эшең дә бар. Анда да син һич төшеп калганнардан түгел. Рәсемнәрең искиткеч матур. Күз үткендер инде синең, төсне төстән аеру осталыгы бардыр.
Инде сынлы сәнгатьнең киртәсенә керсә әңгәмә, андый чакны Габделбакый дилбегәне бик җайлап ала кулларына:
— Төсне күрә белүдә түгел шул, дустым, хикмәт.
— Ә нәрсәдә соң? Мин моңны ишетәм, син төсләрне күрәсеңдер инде. Шунсыз художник булып булмыйдыр инде.
— Рас әйтәсең. Анысына сүз дә юктыр, дустым. Тик менә ул төс дигән нәрсә үзе бит Кояшка бәйләнгән. Димәк ки, рәссам иң әүвәл Кояшны күрә белергә, аңардан җиргә ингән яктылыкның үзгәрүен, Кояшның агачларга, биналарга, кешеләргә ни рәвешле нурлар бөркүен, һәркайсына ничегрәк тәэсир итүен күрә белергә тиеш. Әле анда да мөнәсәбәтне, ягъни мәсәләнн, Кояшның безне чолгап алган, безнең күз күреме җитешкән әйләнә-тирәбезгә мөнәсәбәтен күрә белү зарур.
Кунагының диванда кыбырсый башлаганын абайлап, хуҗа аны да әңгәмәгә тартырга ниятләде:
— Менә синдә бит инде, урысчалап әйтсәк, абсолютный слух, бар нәрсәне көй итеп, моң итеп ишетәсең...— диде.
Гәрчә мәгърур-тыйнак булса да, үз һөнәренә кагылгач, Хәмиди елмаймыйча булдыра алмады:
— Юк, ялгышасың. Барысын да көй итеп ишетсәм, минем бит башым бола-а-ай булыр иде,— дип, ике кулы белән башы тирәли бер тубал ясады.
— Минем кебек кенә ишетмисеңдер инде, хәйләләмә.
— Әллә нигә бер генә моң булып ишетелә бит ул кешеләр сөйләшкәне, кошлар сайраганы...
Остаханәгә яшь рәссамнар килеп керде. Әңгәмә дә шунда өзелде.

Табигатькә хәйран калып соклана белүче рәссам каланың өстенә ишелеп төшәргә әзерләнгәндәй калкынып торган, еракларга сузылган Алатауның гүзәллегенә тәмам инде мөкиббән китә. Шәһәр читенә чыгып, тау итәгендәге елга-ерынтыны да күзәтә-өйрәнә. Этюдлар да язып кайткалый, тик менә күңеле һич кенә дә риза булмый. Тау тезмәсен бит аны карасу төсләрдә күрсәтмичә хәлең юк, ә ул төсләрнең, ни генә димә, кызыгырлык, яратып карарлык ямь бирә алмаганы һәркемгә мәгълүм. Юк, тауларны син реалистик планда тасвирлама инде, абзыкай. Ә ничек итеп тасвирлыйсы икән соң, алай булгач? Импрессионистларчамы, әллә бөтәнчәрәкме? Клод Моне ничек алган булыр иде дә Вангог нинди буяулар кулланыр иде икән? Юк, алай ук ярап бетмәс. Янә дә ничек? Ренессанска ук барып җитмәссең ич инде. Тукта, тукта! Австралия тауларын язган бер негр рәссам бар түгелме соң? Әйе, бар андый талант иясе. Наматжира аның фамилиясе. Альберт Наматжира. Мишәрчәрәк яңгырый ул фамилия: безнең Буа ягында бит Нигъмәтҗан диясе урынга Нәматҗан диләр. Гомерен рәсем сәнгатенә багышлап, бик тә кыен ашый инде бичара Наматжира, зинданга да ябалар үзен... Гомумән, безнең сәнгать өлкәсендә әнә шундыйрак диваналар-дәрвишләр генә эшли бугай. Миңа нәрсә калган инде? Ичмаса теге юлы, Соловкиларда «утырмада» булып кайтканнан соң, сәясәтенә дә, сәнгатенә дә төкерәселәр калган да бит... Юк шул менә! Типсә тимер өзәрдәй егет, койрыгың бозга катмаган чак, теләсәң нинди һөнәрне үзләштерү җае бар иде дә бит, кендегенә буяу каткач, беркая китеп булмый икән шул...

Әмма бу негр мишәреннән үрнәк алу килешеп битмәстер. Ник дигәндә, гәрчә ул рәссам Австралиядәге табигать күренешләрен, тауларны хәйран үзенчәлекле итеп сурәтләсә дә, колоритны төсләр каршылыгында, контрастлы чагылдырса да, аның киндерләрендә һәр нәрсә тәгаен тасвирланып беткән, тамашачыга уйланырлык урын калмаган. Ихтимал, ярыйдыр ул Макдоннелл тауларын тасвирлаган чагында, тик монда бит Алатау, аның үз сыйфатлары, үз бизәкләре, үзенең гүзәллеге бар. Әнә шул үзенә генә хас булган асылташны табып, шуны тамашачыга илтеп җиткерәсе бар. Алатауның бөтен гүзәллеген уч төбендәге алмаз шикелле күрсеннәр иде. Ләкин шул ук вакытта уйланырлык булсын, аңа урын калдырасы бар...

Кызык инде бу сәнгать дигән дөнья! Һәркем әйләнә-тирәсен үзенчә күрә һәм үзенчә тасвирлап бирә. Николай Рерих, әйтик, төсләрнең чарпалашуын күрсәтүдә һәркемне узып китә, бер чакрымда калдыра. Аның Тибет белән Һималай таулары — менә ичмасам таулар! Ул күкнең сафлыгы һәм тирәнлеге дисеңме, ул тауларның җырлап-чыңлап торган гүзәллеге дисеңме! Каян барысын да күреп бетерәдер, һич баш җитәрлек хәл түгел. Һәркемнең сәләте вә таланты Кояшка булган мөнәсәбәтендә ачыла. Без инде аяз көнгә сөенәбез. Кояшның үзен рәхәтләнеп торып, олы итеп чәпәп куярбыз: тамашачы да күрсен аяз икәнне, шик-шөбһә тотмасын бер дә. Гүя үзара ярышабыз, кайсыбыз зуррак итеп сурәтли ала, дигән кебегрәк килеп чыга кайчагында.

Ә менә Рерих һич тә алай кыланмый. Кояшны ул бер генә деталь рәвешендә күрсәтми, бәлки әле әсәрен тоташы белән Кояшка төрендерә. Николай Константинович ул, мөгаен, үзе күргәннәрне киндергә төшереп тә бетермидер. Син аның буяуны бинһая сыек һәм дә аз салуын, грунтовканы хәйран оста файдалануын гына әйт инде! Бик якын килеп карасаң, киндере үтәдән-үтә күренәдер сыман тоела. Буяуны бөтән беркем алай сыек сала алмый торгандыр. Безнең агай-энә сылый инде аны, кызганып-нитеп тормый, рәхәтләнә, күзе күргәнне кәгазьгә яисә киндергә чәпәп бетерми торып һич туктый белми. Мыскалына хәтле төшермәсә, һич күңеле булмый. Талант иясе Рерих исә Кояшның көчен-кодрәтен гәүдәләндерү өчен кыя ташның бер ягын Кояш нурларына төрендерә — алсумы, кызылмы итә, икенче ягын күе зәңгәр төскә бизи. Анда да әле

тоташ зәңгәрне һич күрмәссең: төсләр бит һәр җирдә бер була алмый, табигать үзе моңа шаһит. Күрүен без аны барыбыз да күрәбез, тик менә... язарга утырсак кына, үч иткәндәй, тамашачыны картинабызга якын җибәрмәскә тырышкандай, нәкъ шуның киресен гамәлгә ашырабыз: күк гөмбәзен тоташы белән зәңгәргә манабыз; сөрелгән җирне лачкылдатып карага буяп чыгабыз; сарының, кызылның да төсмерләрен эзләп баш ватмыйбыз. Гомумән, буяу беткәнче, җиренә җиткәнче бер дә җәлләмичә сылыйбыз да сылыйбыз. Полутоннарны, төсләрнең төрле оттенок-төсмерләрен эзләмибез; хәер, эзләгән тәкъдирдә дә таба алмас идек һәм әле тапкан очракта да аны уңышлы-отышлы итеп куллана алмас идек. Ә бит бар андый нәрсә, бар! Табигатьтәге һәр төснең үзенә генә хас төсмерләре, нәфис үзенчәлекләре бар. Моны фәкать күрә белергә генә кирәк. Николай Рерих әнә күрә дә белә, дөрес итеп гәүдәләндерүгә дә көче-кодрәте җитә. Менә нигә аның әсәрләрендә син буяу-фәлән күрмисең, бәлки тауларны тәгаен күрәсең дә әлеге төсләрнең чыңлавын ишетәсең.

Һай, шуның шикелле оста итеп гәүдәләндерсәң иде шушы Алатауны! Аннары, ихтимал, үлсәм дә үкенмәс идемдер... Үз урынына тауның сурәтен калдыргач, фани дөньядан китү хәрәм булмастыр шикелле... Рерих шул ул, дияр иде безнең як агае, син яткан бишекләрне әллә кайчан пычратып чыккан, дияр иде.

Дөрес анысы, Урманче әле дөньяга гына килгән 1897 елны Рерихның инде рәссам буларак биографиясе башлана: сәнгать академиясен тәмамлаганда язган һәм «Хәбәр илтүче» дип алган хезмәтен... Третьяковкага алалар, үзен рәссам буларак таныйлар. Җитмәсә бит әле берьюлы ике вузда укый — 1898 елда Петербург университетының юридик факультетын тәмамлап чыга. Укуны анысын без үзебез дә булдырабыз, һич кимен куймыйбыз. Тик менә тауларны тасвирлап бирүдә генә сынатабыз, һич кодрәтебез җитми әнә шул мәгърур Алатауны уч төбенә төшереп утыртырга, аннары инде иплəп кенә киндергә күчерергә...

Ул көнне Габделбакый матуррак урын эзләп әллә ничә сәгать буена тау итәгендә йөренде. Ахырдан үзе үк:

— Бүген син, абзыкай, тәмам утырган тавыкка әйләндең шикелле, урын сайлагандай кыланасың. Ярый соң, карап карыйк, нindирәк чеби чыгарырсың икән,— дип көлде.

Көлүен көлде, әмма көн ул арада кичке якка авышып өлгергән иде инде. Ә рәссамның әле һаман этюдникгын җайлап куеп, эшли башлаганы юк. Шулай итеп, иҗат итәрмен, тауны язармын, дип өметләнгән көне казага калыр микәнни? Һәй, абзыкай, син инде, ичмасам, үзеңә дөресен әйтергә өйрәнер идең! Көн бетте, икенде-ахшам вакыты, көнең дә, өметең дә акланмады, казага калды инде, калды...

Урын сайлап ни хәтле еракларга киткәнлеген рәссам кайта-кайта гына аңышты.

— Каһәрем-зәһәрем! Бу тирәләрдә бүреләр йөри бугай бит әле!.. Синең изге ниятеңне сорап тормаслар... Очратсалар, шундук ботарлап ташларлар... Юк, абзыкай, авыз ачып бүре көтеп утыру килешмәс, хәстәренә керә тору мәслихәттер, дип, иелеп, кулга сыярдай бер очлырак кына ташны сайлап алды, этюдникгын аркасына җайлабрак асты да кесәсеннән үткен пәке чыгарып, аны ачты.

Әмма бүрегә-шакалга юлыкмады сәнгатькәр, Ходай саклады үзен. Тик менә аягы нишләптер авырта башлады. Чамасыз кызу кайту ярамагындыр инде. Җитмәсә бит әле тигез җир түгел, тау-таш арасыннан... Тырыша торгач кала турысына якынлашты. Аягының авыртуына чыдый алмыйча, яссырак бер таш өстенә чүгәләде. Аягыннан салып, бераз хәл алырга ниятләде.

Шунда гына рәссам як-ягына күз сала алды. Шәһәр өстендә томан шикелле рәшә йөзә, анда-санда агачлар арасыннан утлар күзгә чалына.

Эңгер инеп килгән бер заман. Тауларның карасу-коңгыртлыгы отыры куера төшкән мизгел.

Һай бу таулар, һай бу гүзәллек! Кичке якта үзенә бер ямь инә икән ләбаса бу Алатауга! Күр инде тигезле-тигезсез киртләчләрдә, чыгынтыларда карасу төсләрнең уйнавын! Хәйран тамаша икән бит! Әнә теге сөзәгрәк җиренә Кояшның соңгы нурлары төшеп, бөтенләй дөрләтеп-балкытып җибәргән. Чү! Димәк ки, Кояш батып өлгермәгән. Бу турыдагы, якындагы тау башларына ничегрәк тәэсир итә-үзгәртә икән? Шуны күрәсе иде.

Габделбакый, башына бер фикер килсә, шуны гамәлгә ашырмый торып һичбер тынгы белми торган зат инде. Күз ачып йомган арада аягына киенде, йөген сыртына салды да таудан читкә йөгерде. Кояшның ичмасам актыккы нурларын күреп калыймчы дип, атлады да йөгерде. Аягы, Алланың рәхмәте яусын, авыртудан туктады, һич үзен сиздермәде. Борылып карый-карый шулай җилле генә бара торгач, шактый читкәрәк китеп өлгерде һәм тау башында айкалып та чайкалып йөргән алсулыкны күрү бәхетенә иреште. Сихерләнгән икәнен сәнгатькәр шактый вакыт узгач, Кояш Алатау сыртыннан аргы якка тәгәрәгәч кенә абайлады. Әйләнә-тирәсендәге нәрсәләр күз алдында карасу пәрдәгә төренде. Шомлы тынлыктан рәссамның колаклары чыңларга тотынды. Әмма күңеле тулы куаныч булганда рәссам куркуның ни икәнен дә исенә төшермәде. Теге хәерсезләргә тап булган тәкъдирдә дә үз хәленең хәтәрлеген, мөгаен, аңлый алмас иде. Алатау хәтле Алатауның сыртында кичке шәфәкъ уйнаганын — изге бер мизгелне күрү бәхете Габделбакыйны баһадирга әйләндерде, олы бәхет бирде. Хәзер инде ул үзендә теләсә нинди яман көчкә дә каршы торырлык куәт вә кодрәт тойды.

Табигать, күрәсең, даһиларча шулай эшләү мөмкинлеге бирәдер: өенә кайту белән, рәссам аз-маз тамак ялгап кына алды да хыялларын иртәгәгә калдырып, тынычлап кына йокларга ятты. Иртән уянып китсә, ару-талуның эзе дә калмаган, аягы да сихәтләнеп киткән.

— Ай-һай, күп йөрелде кичә... Ким дигәндә егерме-утыз чакрым бардыр... Ну, арылган да иде соң...— дип үзалдына сөйләнеп куйды.

Зарядкалар ясап, юынгач-кырынгач, ашагач-эчкәч, олуг әсәр язуның хәстәрен күрә башлады. Подрамникка тарттырып, грунтлап куйган киндерләрә арасыннан аркылысы ярты метр, буе шуннан чак кына артыграк булганын сайлап алды. Буяуларның да әйбәтрәген, башланмаган тюбикларны кулай күрде. Чабатасын алдан ук киенеп куярга ярата иде сәнгатькәр, бу юлы да гадәтеннән һич тайчанмады.

Рәссам кичә үзе билгеләгән урынга барып җиткәндә, Кояш ярыйсы ук югары иде әле. Урынның иплерәген сайларга мөмкинлек бар иде әле. Тауның силуэты кайсы ноктадан әйбәтрәк, «живописныйрак» булып күренер икән дә тау итәген ничегрәк аласы булыр икән, иң алгы планда ниндирәк нәрсәне тасвирлау кулайрак чыгар икән? Ни генә әйтсәң дә, тау үзе ерактан матуррак бит, аны якынайтып маташасы түгел, аннан файда юк.

Дөнья кызык, дөнья бай бит! Кайсы төшкәрәк оя корыйм икән, дип уйланып торганда, рәссамның колагына челтерәп аккан тавыш килеп бәрелмәсенме. Бер көчәя әлеге тавыш, бер югала язып кала. Ни булыр бу? Тукта, чишмә түгелме? Шәһәр эчендә ук бер күперне аркылы чыккан иде, һич игътибар ителмәгән...

Тау ерганагы шушы тирәдә үк булып чыкты. Рәссам якынайган саен ерганакның тавышы отыры гайрәтлерәк яңгырады. Менә бер заман сәнгатькәр алдында зәп-зәңгәр булып, шаулый-шаулый, таш араларыннан юл салып агып ятучы уйлаган чишмә — Алматы ерганагы бөтен гүзәллеге белән җәелде.

— Һи-и-и, абзыкай! Алатауны тасвирлап та, шушында Алматы ерганагыдай җанлы, шау-шулы суның тау араларыннан агып чыкканын, челтер-челтер меңләгән тавышлар гармониясе тудырып агып ятканын күрми калсаң, дивана булыр идең!

Хәзер инде шик-шөбһәләргә урын калмады — сәнгатькәр Алатауның кодрәтен шушы урыннан торып язачак.

— Ярый, абзыкай, тауны яздың да, диик. Ә соң шушы гүзәллекне ни рәвешле гәүдәләндермәк буласың? Ходай бәндәсе, аның бит тау-таш арасыннан агып чыгуын да, аннан да битәр илаһи матур тавышлар чыгарып челтерәп ятуын да киндергә төшерә алмаячаксың!

Бер генә әсәрен язганда да рәссам эшкә тыныч күңел белән тотынмады. Гомерендә дә. Әле дә менә күңеле тулы шик-шөбһә. Йөрәге ярылырга җитешеп жуу итеп тора.

— Ни килеп чыгарын һич белгән юк. Аллага тапшырдык. Ошбу матурлыкны, табигатьтә сирәк очрый торган илаһи бер гүзәллекне үзем яратырлык дәрәҗәдә камил итеп тасвирлау бәхетенә ирешсәм, аннары инде, мөгаен, үлсәм дә үкенмәс идем...

Тау башларына алсулык җәелгәнне көтеп кул кушырып утырмады рәссам. Гомумән, аңа эшсез тору хәрәм булып тоела иде. Ашыкмыйча гына күмер белән тауның силуэтын сызгалады, аннары Алатау белән үзе басып торган ерганак арасына таудыр-таштыр, куактыр-мазардыр сала башлады. Ерганакның эше чамасыз күп булып чыкты. Ничек кенә кызыласа да, рәссам үзенең тирә-юнен язып-сызып өлгерә алмады, кайсы нәрсәнең нинди төстә икәнен карандаш белән билгеләүдән бүтән чарасы калмады — тауның өстенә алсулык тасмасы җәелә башлады. Аларын күмер белән дә, карандаш белән дә сызгалау — табигатьнең үзенә хыянәт итү булыр иде. Ошбу мизгелне, кабатланмас гүзәллекне фәкать төсләр белән, үз төсләрендә гәүдәләндерергә мөмкин иде.

Ихтимал, сәнгатькәрнең гомерендә дә эшне бу чаклы кызу тотканы булмагандыр. Форсатны ычкындырасы түгел, ничек тә әлеге күренешне эләктереп калырга кирәк. Бер генә мизгел дә сине көтми. Көтми дә, кабатланмый да. Тормышта, гомумән, һичбер нәрсә кабатланмый. Мәгънәсе дә шунда, фаҗигасе дә. Иртәгә һәммәкие үзгә төскә ук кермәс кергән, тик инде, төсмере бөтенләй бүтән булыр. Ә миңа нәкъ менә шушы нюансны тотып калу зарур, шуны табигый төсләргә тәңгәл китереп киндергә төшереп өлгерәсе иде. Нәкъ менә шушындый иттереп...

Кичке шәфәкъ тауның сыртыннан аргы якка шуып төшкәч тә әле, рәссамның күз алдыннан алсу гүзәллек һич китмәде, айкалды да чайкалды, барча җиһанны ямьләндереп торды. Алсу төскә бераз контраст табасы булыр, аның үзен киң итеп җәю килешмәс, ахры. Зәңгәрсу да, көрән дә булуы бик ихтимал менә бу өлешенең. Ләкин тоташ бер төскә буяп чыгу ярамастыр, Кояшның хәрәкәтенә нисбәтән тауның төсе төрле җирдә төрлечә булырга тиеш. Һич көтмәгәндә, ала-кола пәрдәне ертып, алсу төс-доминант үзенең хакын даулый. Контраст икән, контраст! Алайса тау итәгендә утырган агачларны, куакларны куертыбрак, бераз карасурак итеп бирү мәгъкуль булырдыр. Анысы шулай ук тоташ карасу буяудан тормас. Ә инде чишмәләр-ерганаклар өлешен, үземә якынрак әйләнә-тирәне теге агач-куакларга контраст ролен уйнарлык итеп, бөтенләй ачык төсләрдә, ихлас якты иттереп бирәсе бар. Һи-и-и, абзыкай, ачык төсләрнең нинди генә юк табигатьтә, аларны шулай ук уйнатып, аралаштырып бирү мөмкинлеге бар бит әле... Ярар, абзыкай, әдәп бел, әдәп дигән нәрсә бар бит әле. Бүгенгә җитеп торыр. Көнең хәйран гына игелекле вә нәтиҗәле үтте. Иртәгә, боерган булса, әзер материал белән көнне башларсың, тау сыртларын, иншалла, язып ташларсың...

Буявы кипкәч, алсу төсләр ничектер шунда тоныкланыбрак калды. Юк, болай гына калдырырга ярамас, бераз көчәйтү фарыздыр. Анысын аның кичке шәфәкъ уйнаганда карарбыз, хәл итәрбез. Ә менә тау башы гайре табигый булып күренмәсен өчен, алсу төсне куерак итеп менә шушында, иң-иң алгы планга салып куярбыз. Хәзер үк, көндез үк салабыз анысын, чөнки аны кичке шәфәкъ безгә алып килмәячәк. Без бит фотография ясамыйбыз, картина язабыз. Табигать күренешләре плюс рәссамның фантазиясе диләр аңа, абзыкай. Шунсыз, бер яктан, фәкыйрь чыкса,

икенче яктан, беркемне ышандыра алмаячаксың. Башкаларын камил итеп, моны да өстәсәң, сәнгатьчә дөреслек дигән нәрсә килеп чыгачак.

Рәссам күпме генә фикер каршылыгын җинмәсен, ничек кенә реалистик планнан читләшмичә эшләргә тырышмасын, һәрхәлдә, үзен моңа ышандырмасын, нинди генә табигый төсләрне киндеренә төшермәсен, әмма картина тулысынча импрессионизм алымнары белән язылган булып чыкты.

Даһи Пушкин «Евгений Онегин» романын язып бетергәндә:

— Нишләтте бит мине Татьянам: тотты да кияүгә чыкты! — дип үзе үк шаккаткан сыман, илленең өстенә баскан Урманче шулай ук хәйран калды.

Әмма аңа карап соклануы һич тә кимемәде.

Үзгәрәк күренеш килеп чыкмасмы, дип өметләнеп, өр-яңадан язып карады — иҗатының җимеше, өлгереп җиткәч, нәкъ шундый ук килеп чыкты. Рәссам үзенең күңеле катып бетмәгәнгә эченнән генә сөенеп куйды, анын ай шикелле тулы йөзенә канәгатьлек билгесе булып елмаю җәелде.

Күр инде төсләр ни рәвешле оста сайланган да колориты нинди бай! Моны һәр нәрсәдә күрергә мөмкин. Алатау үзе генә дә ни тора бит: анарда өзлексез рәвештә төсләр уйный, гүя һәр ташка, һәммә нәрсәгә җан иңгән: минут саен үзгә төскә керә — әле генә күксел-ак иде, кай арада тауның тигезле-тигезсез сыртлары алсуланып килеп чыга, табигый матурлыгына масаеп тагы да югарырак калкына; Кояшның көлтә-көлтә нурлары тауның мәһабәт чал түбәләренә орынып-орынып кына китәләр дә еракларга агылалар; тауның бер өлеше гүя Кояш нурларыннан качып, кичке зәңгәргә төренгән; тауның итәгенә сыенган агач вә куаклар гүя Алатауны төрле афәтләрдән саклаучы пәһлеваннар — мәгърур кыяфәттә урыны-урыны белән кара-кучкыл булып, урыны-урыны белән йомшаграк төсләрдә калкынып торалар; ерганакның бихисап тармаклары өлешчән алсу-ак шәфәккә уралган, өлешчән исә үтә күренмәле зәңгәр челтәр ябынган, һәм әнә шул зәңгәр челтәр гүя чишмәләрнең челтерәп акканын да, тау итәгендә хөкем сөргән илаһи бер тынлыкны да, болытларның әледән-әле чынлап тау сыртына орынып-орынып киткәнен дә тамашачыга ишетергә ярдәм итә...

Озаклап карап торды сәнгатькәр үзенең игезәкләренә. Гүя ул киндерләрендә мәңгелеккә урын сайлаган Кояшның һәрбер угына-нурына, Алатауның ул нурларда коенган һәр пик-сөңгесенә Кояш төшмәгәнгә аптырап-сагаеп-моңсуланып калган кыяларына, өстенә сикерергә әзерләнгән арысландай тоелган ташларына, тау итәгенә сыенган куакларга, тармак-тармак булып җәелгән суга, яр буендагы кеше сурәтләренә караудан һич туктарга уйламый, шуларга карап рухлана-дәртләнә иде. Йөзендәге балкыш, бернигә бирешкесез нурлы балкыш әнә шуны раслый иде.

— Ай-һай, хезмәт бар монда! Тәмам килгән моның камиллеге! Моңа инде симфония дими хәлең юк!..

Тауның никадәр мәһабәт, никадәр кодрәтле, никадәр мәгърур икәнен һәркем күреп инансын өчен, сәнгатькәр уң кул почмакка адәм сыннарын да язып куя. Тау янында адәм баласы көчсез инде ул, хәлсез-дәрмансыз. Ихтимал, авторның, табигать һәм без, Алатау һәм без, дип әйтүеләр — кем белгән бит...

Һәрхәлдә, казакъның Алатауга багышланган җырын Габделбакый гомере буе онытмады, әлеге картинага күзе төшкән саен, тамагын кыргалап, куәтле баритон тавышы белән җырлаудан гомере буе туктамады:

> Гарлы тау кайда гарлы, кайда гарсыз;
> Ир-егет кайда маллы, кайда малсыз...

Тыңлаучыларына шундук үзебезнең телгә күчереп җырлап бирергә дә иренмәде:

Карлы тау кайчан карлы, кайчан карсыз,
Ир-егет кайчан маллы, кайчан малсыз.
Дәрьяның ярга суккан дулкынылай,
Күз салган-күренгәнгә күңел әрсез.

# VII баб

## «Биби ханым мәчете»

*«И-и-и, кара ничек йөри бит!
Яз көне син кызларның ничек
йөргәнен күзәткәнең бармы?
Бөтенләй үзгә бит йөрүләре!»*
Бакый Урманче,
*1980 ел.*

*«Чүти карак әйткән: йөз ел тавык
булып торганчы ун ел әтәч булып
торырга кирәк, дигән».*
Бакый Урманче,
*1975 ел, 26 май.*

Дустым, син уйлыйсыңдыр инде, Урманче карт үзенең киндерләренә чуалып та уралып, ташларына абынып та сөрлегеп яшәгәндер инде шунда, аяз көннәрне дә юньләп күрмәгәндер, татлы шәрабларны да татымагандыр, сылу затларны да кочмагандыр, дип.

Юк, хаталанасың, дустым, нык хаталанасың. Булды андый гөнаһлар, булмады түгел. Эчәсе эчелде, кочасы кочылды. Хәер, сәнгать халкы үткән юллар чокырлы да чакырлы, кайчагында бөтенләй гамәлгә үк сыеп бетми торган, гади укучының булсын анда, яки тамашачының акылы җитмәстәй хикмәтле хәлләр булгалаштыргалый. Мин үземне әлләни тәкъва итеп тә күрсәтәсем килми, әүлия булып та кыланасым юк. Хурлык саныйм андый кылануны ир-егет өчен, әлеге хәлдә үзем өчен. Югыйсә нәрсә килеп чыгар иде бит? Мине Аллаһы тәгалә бер бөек шәхес итеп яраткан да мин шул табигый сәләтиямә таянып, ансат кына кылкаләмемне йөреткәнмен дә йөреткәнмен кебегрәк бер нәмәрсәкәй килеп чыга. Аның бит әле, дустым, кулыңа кыл-каләм алырга сине этәрүче мәҗбүрият дигән бер кечтеки генә илһам дигәне дә булучан. Югыйсә алуын да алырсың кыл-каләмне, тик эшең генә алга китмәс, күпме генә чиләнсәң дә, юньле-рәтле нәрсәне майтара алмассың.

Сәмәркандта булганың бармы синең, әллә теге җәгрәфиядән укып, илгизәрләрдән ишетеп кенә беләсеңме? Шулайдыр, дустым, шулай гынадыр. Иншалла, берәр заман барып күрерсең әле син Шәрыкның әлеге дә баягы мәркәзен. Күрергә кирәк аны сиңа, әлбәттә, кирәк. Сиңа аны барып үз күзең белән күрмичә ярамый. Андагы илаһи матурлыкны, ул кәрвансарайларны, ул берсеннән-берсе мәһабәт мәчетләрне, ул гөлбакчаларны, ул базарларны сөйләп кенә бетерә торган түгел. Мин гашыйк әлеге мәркәзгә. Әле менә бүген дә бөтен гүзәллеге хәзергедәй күз алдымда. Янә дә бер гүзәле... Андый сылуны очратсаң да гомереңдә бер генә очратырсың...

Биш фарыз намазны калдырмыйча мәчет бусагасын таптау без фәкыйрегезгә насыйп булмады. Мәчет картларына мәрхәбә карасам да, андый сынауларны уза алмас идем барыбер: мин әле таза идем, яшь идем, иҗат итү дәртем ташып тора иде үземнән. Син тагын мине саман кирпеченнән өйгән хөҗрәмә бикләнеп, дәрвиш сыман, үз-үземә тәмам мөкиббән китеп, эшкә чумып яшәгән икән Урманче карт, дип уйлый

күрмә. Һич алай бикләнеп-күмелеп яшәгәнем булмады. Халык арасына чыккалап, базарына баргалап, андагы әңгәмәләргә катнашкалап яшәде без фәкыйрегез.

Көннәрдән бер көнне, Регистан мәйданы башланган төштәрәк, базар читендә агай-эне белән әлегедәй гәпләшеп торганда, бер мәлне дерт итеп киттем: янибыздан узып баручы бер сылу минем якка күз сирпеп алган икән. Мин текәлеп караганда, ул инде яны белән борылып өлгергән иде, профилен генә күреп калдым. Тик инде, дустым, андагыдай дәртле чагымда мин, сезнең шикелле, профилен күрү белән генә канәгатьләнмидер идем. Миңа булсын ул фас, миңа булсын, французлар әйтмешли, анфас! Карап калдым сылукайның янбашларын иләбрәк, ипле генә атлап китеп баруларын. Әмма агай-эне алдында күңелдәгене бөтенләй үк ачып саласыларым килмәде. Сизсәләр бит, алар тынгы бирәселәр түгел иде. Сүзнең беткәнен-йомгакланганын сабыр гына көттем дә, базарның эченәрәк юнәлдем соң. Теге чибәркәй китеп барган олы урамга бәләкәй тыкрыктан чыгу юлы таныш иде, әлбәттә. Озын-озак уйламастан, бордырып алдым шул тарафларга. Хатын-кызны аны бит бер сикерүдә үк тотып була. Тик мин алай итмәдем. Моңа ике-өч төрле сәбәп бар иде. Иң әүвәлесе, кайсы яктан суктырып сүз кушасыны хәл иттем. Аннары инде сурәтен ясарга ниятләдем. Янә килеп, чибәркәйнең нәфис буй-сынына, гаҗәеп нечкә билкәенә, ике якка мелт-мелт итеп уйнаклап барган янбашларына, кәс-кәс басып баруларына карау гына да үзе бер ләззәт бирә иде. Өстендә бала итәкле, күгелҗем фонга куе чәчәк төшкән озын күлмәк, җиңнәре терсәген каплаinitialса да беләзеккә җитмәгән. Беләкләре әлләни нәзек булмаса да тупас та түгел, нәфис кенә; салынкырак инбашлары үзенә бер илаһи кыяфәт биреп тора иде. Тицианнарны гашыйк иттергән классик чибәрләрдән бер дә ким түгел.

Ашыкмадым үзенә сүз кушарга. Әле бит сүз кушудан ниләр килеп чыгасын белгән юк, дустым,— анысы Алла кулында. Әллә бәлкем, синең белән бөтенләй сөйләшеп тә тормас...

Илаһым, үзең мәдәт бир!

Тәвәккәлләп, адымны кызуладым, сылукайның уңына чыгып, үземчә елмайгандай кыланып, сүз кушарга тәвәккәлләдем.

— Шушындый чибәр, илаһи зат белән бер төбәктә яшибез икән ләбаса. Кичә үлгән булсам, шуны белми-нитми үлә идем, илаһи затны күрми-нитми фани дөньялардан китә идем.

Бернинди буяу әсәре юк йөзендә. Язгы чәчкә исләре килгәндәй тоелды. Чибәркәй минем тарафларга күз сирпеп алды да:

— Әлләни үкенмәс идегез әле. Тик инде ямьле яз көнендә гүргә кереп ятулары гына... Абау, чирканам!— дип шаяртуын-чынын бергә кушып әйтә куйды.

Миңа шул гына кирәк тә инде. Аның чиркануын чынга алган сыман:

— Хафаланмагыз, туташ. Сезне күрү бәхетенә ирешкәч, Ходай тәгаләдән янә дә бер гомер сорап алмак булам. Шуннан инде сез гүзәлне Ходайның һәр бирмеш көнендә күрергә өмет баглыйм.

Кагылу-орыну юк кызның беләгенә. Фәкать телемә салынам, артыгына сабыр итәм. Ничек дигән бит: әс сабыр — шайтан, сабырсызлык — шайтанга хас, дигән.

— Безнең китапханәгә килеп-китеп йөрсәгез, күрерсездер. Хәер, бездә алай артык мактанырлык зур байлык юк югын. Укырга ярату-ярәтмавыгызны да сорамадым.

Әһә, китапханәче икәнсең ич, белем чишмәсенең сагында торучы, мәгърифәт өләшүче икәнсең ич! Китап дөньясына кереп киткәч, мин инде теләсәң генә кемне авызыма каратам. Бу юлы да былбыл булып сайрарга уйлаган идем уйлавын, әмма чибәркәем сүзне кыска тотты:

— Хәзер мин тыкрыкка борылам, сез турыга китәрсездер. Бүген безнең ял көнебез. Иртәгә рәхим итегез. Мәчет янындагы китапханәне табарсыздыр, шәт? Иртәгә эш беткәндәрәк килегез. Сәгать дүртләрдә.

— Туташ, мин иртәгә таңны аяк өсли каршыларммын, кичке дүртне бер тәгам ризык капмый көтеп алырмын.

Күңеленә хуш килде бугай минем сүзләр, чибәркәем янә бер күз сирпеп алды:

— Зинаһар, ачка үлә күрмәгез, мине шундый юлдашымнан мәхрүм итмәгез,— дип елмайды да тап-тар тыкрыкка юлланды.

Артыннан карап калмаска никадәр генә тырышмыйм, булдыра алмадым, биш-алты адым атлауга ук, аның сылу гәүдәсенә, янбашларын уйнакландырып атлавына борылып карадым, сокланып туя алмадым. Күр инде моны: ике кавын шикелле түм-түгәрәк булып калкуланып-бүлтәеп тора, атлаганда мелт-мелт итепләр китә, нәкъ менә яшь ат сырты...

Шаирә... Исеме, үзебезнең туган якларга алып китте: мишәрдә бит «г» авазы еш кына әйтелми кала. Ул инде сиңа Абдулла, Абделбакый диюдән узмый. Шигырь язучыларга да шаир ди, шаирә ди.Ниләр бар икән туган якларда, Зөя буйларында?..

Ике-өч көн көттереп кенә киттем әлеге китапханәгә. Анда Гомәр Хәйямның искиткеч матур сурәтләр белән фарсы телендә чыккан «Рубагыйлар»ына тап булганымны да, Шәрыкның даһи шагыйрен оригиналда укый алуыма туташның хәйран калуын да сөйләп тормыйм, дустым, рәнҗемә. Китапны алганда Шаирә минем исем-фамилияне, адресымны паспорттан күчереп язарга тотынгач кына, чибәр йөзкәендә көлемсерәү чагылганын әйтеп үтәрмендер. Чөнки мин туташ белән бер тирәдә түгел, бәлки бөтенләй икенче якта, парк артындагы тыныч кына урамда яши идем. Гәрчә эш сәгате бетүгә якынлашса да, укучылар берән-сәрән генә килсә дә, безгә иркенләп бер җаелеп сөйләшеп утырырга җай чыкмады: күрше бүлмәләрдә эшләүче коллегалары әледән-әле кереп, юк йомышларын бар итеп йөрде. Андый чакны мин өстәл өстендәге яисә китап шүрлегендәге басмаларны караштырган атлы булдым.

Эш сәгате беткәннән соң, Шаирә иптәшләренең киткәнен генә көтеп торды да, бергә-бергә кайтырга чыктык. Шунда мин, батыраеп-ирәеп китеп, аның эш урынында күреп сөйләшүләр кыз балага уңайсызлыклар тудыру ихтималын искәрдем, форсаттан файдаланып, аның сынын майлы буяу белән киндергә язу теләгем барлыгын сиздердем. Китапханәсендә өчаяк-этюдниклар белән эшләп утыра алмыйм ич инде. Өенә барып чыгуны уйлыйсы да юк. Шулай булгач, күрешеп сөйләшер өчен, берочтан сурәтен язар өчен фәкать минем хөҗрәм-остаханәм кала.

Бу тәкъдимгә тиз генә күнмәде Шаирә туташ, бераз вакыт уйланып барды. Аннары тәвәккәлләде бугай, башын юргадай селкеп алды да туп-туры карап:

— Кичләрен йөри алмыйм шул мин. Бары тик ял көнем генә кала. Ял көнне, әлбәттә, сезгә дә ял итәргә кирәктер,— диде.

Белсәң иде сөенүемне, дустым! Димәк риза, димәк үземне дә, эшемне дә кире какмый. Җавапны көттермәдем:

— Һәй, туташым-багалмам, безнең һөнәр иясенә ял итү гомумән үк фарыз түгел. Иртә таңнан көтәрмен,— дидем, ике уйларга урын калдырмадым.

— Алай ук иртәләп булмас анысы. Шулай да килми калмам,— диде дә миңа күтәрелеп карады кыз: — Кайберәүләр шикелле көттермәм. Кая килергә икәнен дә әйтсәгез...

— Адресымны үз кулыгыз белән кенәгәгә язып куйдыгыз. Яшәгән урыным да, остаханәм дә шунда.

Таныш тыкрыкка җитәрәк, туташ коры гына хушлашты да кәс-кәс атлап өенә юнәлде. Миңа исә бу юлы йөрәгемә отыры ныграк баскан сыман тоелды.

Рәссамнарның остаханәсендә, менә, иманым камил, бер генә вакытта да тәртип булмый. Картиналарыңны киштәгә дә рәт-рәт тезеп куярга тырышасың инде югыйсә, артык-портыгын, тиз арада кирәкмәстәйләрен

чормага да менгезеп куясың. Минем дә иртә таңнан торып, остаханәмне азмы-күпме игә китерергә маташуым һич кенә дә юньле нәтиҗә бирмәде. Үземчә пөхтә итеп җыештырган хөҗрәмә сәгатьләр буе көткән кунагым килеп керү белән, юк, алай гына түгел, бусагама аяк басуы белән, чибәркәемнең аптыраудан телсез калуын күреп, ни чаклы да шапшак яшәгәнемне шәйләдем, алиһәм каршысында үземне бер җирәнгеч бөҗәк итеп сиздем, бөтенләй югалып калдым. Алдан хәстәрләнгән сүзләрем гүя җилгә очты, үзем бер урында таптанудан гайрене белмәдем, фәкать күзләремдә чибәркәйгә ялвару, аның кырт борылып хөҗрәмнән һәм йөрәгемнән чыгып китмәвен үтенү-ялыну гына җанлы чаткы булып кала бирде. Һәм әнә шул чаткы хур булудан коткарды бугай.

Күзләремдәге инану-ялваруны укып, асыл зат елмаерга тырышты:

— Ярыйсы ук ерак икән сезнең әлеге төбәгегез. Килә-килә аякларым хәлдән тайды,— дип сөйләнә-сөйләнә, кыстаганны-фәләнне көтмичә, түргә узды.

Илаһым, үзең мәдәт бир!

Ошбу илаһи затның сурәтен үзенең гүзәллегенә лаек рәвештә яза алсам, алиһәләргә тиң итеп мәңгеләштерергә хәлем җитсә, алиһәнең үзенең күңеленә хуш килердәй бер әсәр иҗат итә алсам, шуңа ирешсәм, үлсәм дә үкенмәс идем, илаһым!..

Ни рәвешле телгә килгәнемне дә, гүзәлләрнең гүзәленә ниндирәк сүзләр әйткәнемне дә һич хәтерләмим, бигайбә инде. Исемә килгәндә, чәчәкле-чуклы паласка аркасын терәп кунагым утыра, аның каршысында подрамникка тарттырылган, һәйбәтләп грунт салынган, ап-ак хәлгә килгән киндер алдында, сул кулыма палитра, уңына буягыч кыл-каләм тоткан көе, үзем очынып-биеп йөри идем инде. Ихтимал, читтән карагандa, мин баш-аягым белән эшкә чумган, дөньямны оныткан иҗатчы булып та күренгәнмендер. Әмма чынында исә хикмәт бөтенләй анда түгел, киндер алдында очынып йөрүемнең сере-сәбәбе кинәт кенә югалып калуымда, рәссам һөнәрен, Ходай биргән сәләтемне, ничәмә-ничә еллар буена тупланган осталыгымны вакытлыча онытып җибәрүемдә иде. Вакытлыча гына була күрсен инде, илаһым!

Юраганым юш килде. Натурамның ни табигый матурлыгын, ни психологик киеренкелеген юньләп чагылдыра алмадым. Юк, дустым, монда хикмәт минем кинәт кенә югалып калуымда гына яисә анда кояшның нурлары натурага артык мул төшүдә генә түгел. Хикмәт, дустым, рәссамның натураны аңлап-төшенеп җитмәвендә, эчке дөньясына, күңел түрләренә үтеп керә алмавында иде. Фотография булмасын инде ул, булмасын. Югыйсә андый охшашлыкны мин теләсә нинди халәттә дә бирә алыр идем. Ә менә гүзәлкәйнең эчке байлыгын тулаем чагылдырудан,— ай-һай ла! — ерак идем әле, ерак идем...

Әллә син Тициан карт белән Рембрандт югары катлау әһелләренең затлы киемнәрен, пөхтә чибәр йөзләрен тасвирлау белән чикләнгән дисеңме? Һич юк! Алар бит натураның эчке дөньясын гаҗәеп зур осталык белән гәүдәләндерү бәхетенә ирешкәннәр. Менә ни сәбәпле даһи рәссамнар кулы белән язылган портретлар ничәмә-ничә йөз ел буена үзләренең кыйммәтләрен җуймаганнар, җанлы образлар буларак безнең көннәргәчә килеп җиткәннәр.

Ихтимал, син ул даһи рәссамнар яки безнең заманга болайрак, якынрак Винсент Вангог, яисә анда Модельяни очраклы рәвештә генә берәр натураны кәнәфигә яки артсыз урындыкка утыртканнар да, шуларның сурәтләрен язганнар, диебрәк уйлыйсыңдыр? Юк шул менә, дустым, һич тә алай гына түгел. Әйтик, Винсент үзе дә җәмгыятьнең кибән түбәсендә кәеф-сафа кылып яшәүчеләр тарафыннан читкә тибәрелгән. Югары даирәләр аны исәпкә-санга да алмаган. Фани дөньяда көн итү өчен җанарын-тәннәрен сатып яшәргә мәҗбүр ителгән фәхишә-гелбирәләр белән аралашып яшәгән. Ул аларның, булсын тышкы кыяфәтләрен, булсын эчке дөньяларын чамасыз яхшы белгән. Үз заманында бөтен кеше инкяр

иткән, рәсми күргәзмәләргә үткәрмәгән киндерләрнең аукционда бүгенге көндә әллә ничәшәр миллион долларга сатылуы, Европаның, Америкаsuccessиның хәйран затлы салоннарында урын алуы тикмәгә түгел. Хәер, энесе Теога язган хатларында үзе иҗат иткән әсәрләргә Винсент хаклы бәя бирә. Сиңа укырга кирәк, дустым, Вангогның хатларын, аларга хәйран зур мәгълүмат, акыллы фикер салынган. Ә-ә-ә, укыганың бармыни? Өстәленнән төшмимени? Бәрәкалла, шулай була күрсен. Шулайдыр дигән идем аны...

Әйтәсе килгәнем шул, дустым, һәрбер һөнәр иясе, һәр иҗат кешесе үзенең хезмәтенә иң кырыс, иң дөрес бәяне дә үзе бирә. Вангог ук булмасам да, Модельяни шикелле кыюлык күрсәтмәсәм дә, әлбәттә, үз эшемнән һич тә канәгать түгел идем. Син сизгәнсеңдер инде, эшләгәндә бит мин сөйләшмим-нитмим, күземә ак-кара күренми. Натурадан язган чагында әйтәсе дә юк инде. Шулай бер-ике сәгать чамасы натурама сокланып, мөкиббән китеп караган көе аның сурәтен язып маташтым-маташтым да, берни барып чыкмаганын абайлагач, тактикамны бераз үзгәртергә ниятләдем.

— Әйдәгез, туташ, чәйләп алыйк булмаса. Минем дә кулга бераз ял бирү зыян итмәс, сезне дә ялыктыргынмындыр,— дип, җәһәт-җәһәт кенә электр самоварын көйләп җибәрдем.

Хикмәтле хәл инде, шушы яшемә җитеп асыл затларга хәмерише нәрсә тәкъдим иткәнем булмады. Хатын-кыз халкын аздыручы мин түгел. Гомумән, натура белән мөнәсәбәт кылганда һәр рәссам үзен иркен тота икән, дигәнгә мин үзем каршы. Ренуарны гына ал син. Иң затлы француженкаларны шәрә көе мәңгеләштергән. Әмма алар һәммәсе дә аның сөяркәләре булгандыр, дигән фикердән мин ерак торам. Чөнки ул күбрәк гаилә дуслары, кардәш-фәлән белән эш иткән. Әйтик, балдызының сурәтен төрле позада язып калдырган. Алар әле бүгенге көндә дә сәнгатьтә гүзәллек өлгеләре булып кала килә. Мәңгелек алар, дустым, мәңгелек...

Үзем һич тә канәгать булмаган портретны гүзәлкәйгә бер дә инде менә күрсәтәсем килмәгән иде. Апамның сурәтен, кайбер табигать этюдларын күрсәтеп кенә котылмакчы булган идем. Кая ул! Туташым, алиһәләр гүзәллегенә ия булу белән бергә, әле тагын өстәвенә үз дигәненә ирешмичә туктамый торган зат булып чыкты. Син үзең уйлап кара, дустым, шундый асыл зат берәр нәрсә таләп итә икән, аңарга каршы тора алырмын, дип башыңа да китермә. Күрсәтергә туры килде эшемне. Әле бетмәгәнен дә искәрттем, киләчәктә, сеансларны кабатлагач, юньлерәк килеп чыгасына өмет баглавымны да әйттем. Тик бер дә юкка хафаланган булып чыктым. Натура үзенең сурәтен шулайрак язуымнан канәгать иде. Әй, үзеңә әйтергә дә онытып торам икән ләбаса, чибәркәемнең исеме Шаирә иде. Әйттеммени? Әйтсәм, ярар.

— Охшаган бит, Бакый әкә. Тагы ни кирәктер, аңламыйм... Ә-ә-ә, белдем-белдем, күлмәгемнең бизәкләрен төшереп җиткерә алмагансыз, шуңа көенәсез,— дигән нәтиҗә ясады Шаирә.

Бер караганда, натураның портретны хуплавы, кабул кылуы мине сөендерергә тиеш иде кебек. Әмма иҗатчы буларак мин андый фикер белән килешә алмый идем. Шушындый да асыл затның сәнгать әсәренә бәя бирү мәсьәләсендә фотографиягә куйган таләпләр белән чикләнүе күңелемне азмы-күпме рәнҗетте рәнҗетүен, тик мин моны сиздермәдем. Хәер, ул аны аңламас та иде, ихтимал. Юк, аңламас иде. Меңләгән кеше бит даһи импрессионистларның картиналарын аңлый алмый азаплана, шул ук вакытта һәр сызыгы күренеп торган, һәммәкие үз урынында булган урта кул әсәрләргә мөкиббән китә, алар алдына тезләнеп сәҗдә кылырга әзер...

Огюст Ренуар язган картиналардан төзелгән альбомны мин Шаирәгә алай ашыгып күрсәтмәдем. Гомумән, импрессионистлар сәнгатен беренче күрешүләрдә телгә алмадым. Хәер, сәнгатьнең тарихын тулаем биш

бармагым шикелле белгәч, теләсә нинди дәверне тәфсилләп сөйләрлегем бар иде. Сәнгатьне сайрарга тотынгач, дустым, аның сүзләре дә бит мәрҗәндәй тезелә дә тора, сөйләп һич кенә сүзем бетәсе түгел иде.

Ренессанс-яңарыш вәкилләреннән Рафаэль белән Тицианга ныклап тукталырга иде исәбем. Шунда кызык хәлгә юлыктым: Шаирә туташ Рафаэль дигән рәссамның репродукцияләрен гәрчә күргәләгән булса да, Тицианны бөтенләй ишеткәне дә юк икән. Ә мин үзем Тицианның иҗатын барыннан да югарырак куям, аның киң колачлы киндерләрен үлеп яратам. Сәнгать даһиеның әсәрләрен тәмләп-тәфсилләп төшендереп биргәннән соң инде, шул ук дәрт белән, Ренуарга мәдхия җырлау да лазем булырдыр...

Икенче-өченче килүендә мин инде гүзәлкәйнең портретын импрессионизм рухындагы яңа бер ысул белән язып карадым. Гаҗәп хәлләр була бит ул, дустым, гаҗәп хәлләр. Хезмәтемдә әледән-әле камиллеккә ирешә барган саен Шаирә туташның чыраена ризасызлык галәмәте куныл, чибәрлегенә азмы-күпме хилафлык китерде бит. Нишләргә дә аптырадым. Фәкать үземнең элегрәк язылган төрле стильдәге күләмлерәк әсәрләремне күрсәткәч кенә, кул астындагы альбомнарны бергәләшеп актаргач кына, төрле ысулларны төшендергәч кенә, Шаирәм беразь минемчәрәк фикер йөртә башлады бугай. Сәнгать әһелләренең тормышы-көнкүреше белән дә кызыксына башлады сыман. Шаирә атна саен берәр монографияне өенә алып китә торган булды.

Укымышлы кеше белән, китап яратучы зат белән сөйләшүе рәхәт бит, дустым. Икең ике телдә сукаламый, синең сүзләреңә битараф калмый. Үзем сөйләгәннәрне йотлыгып тыңлавын күреп, сөенеп бетә алмадым. Ул да минем тыйнак вә әдәпле булуымнан риза калып, үз-үзен иркенрәк тота башлады. Әйтик, электр самаварын, чынаяк-мазарны үз кулына алып бетерде. Өеннән чүпрәк-чапрак алып килеп, рамнардагы тузаннарны сөрткәләде. Ә инде тора-бара этюдларымны шүрлектән алып, дивар буена тезеп куя торган булды. Яңадан-яңа әсәрләрем белән танышып, аларга карата, минә синең шикелле, фикерләрен әйткәләде.

Кызык бит бу дөнья, дустым, хәйран кызык. Миңа калса, бөтен Сәмәркандында тиңе юк асыл затның атна саен шушылай хөҗрәмә килеп йөрүе, тартынмый-нитми иҗатыма күз салуы, әңгәмә корып җибәрүе генә дә җиткән, шөкранә кылып торырлык иде. Хәер, шуннан артыгына өметләнмәдем, нәфесемне сузмадым. Шаирәнең портретын төрле киемдә, төрле позада ясау бәхетенә тулаем канәгать булып яшәдем. Тик минем әнә шул тәкъвалыгым акрынлап кызның саруын кайната башлады бугай. Остаханәмә ярыйсы ук ияләшеп киткәч, Огюст Ренуарның Лейпцигта чыккан менә шушы альбомны карап утырганда, соклануын яшерә алмады һәм:

— Бакый әкә! Сез минем сурәтемне шушылай ясый алыр идегезме? — дип куйды.

Аны-моны уйламыйча гына, палитра белән кыл-каләмемне тоткан килеш натурама якынлаштым. Хәйран калдым дию генә аз булыр, тәмам телсез калдым. Аның алдында Ренуар хәтле Ренуар өчен дә сирәк килә торган уңышлы сурәт — күкрәк тиненнән ачык, биленә сөлгеме, бүтән нәрсәме ураган, чәчләрен тузгытып җибәргән, гаҗәеп мөлаем йөзле яшь кенә бер чибәркәй сурәте иде.

Минем телсез калуымны күреп, Шаирә туташ кыюлана төште:

— Нигә дәшмисез әле, Бакый әкә? Әллә миннән рәт чыкмас дисезме? Шушылай ук, яным беләнрәк утырсам, сезгә карап елмайсам, тагын да матуррак чыгармыйдыр әле. Риза булсагыз, сөлге ала киләм икенче юлы.

Шуннан мин дә кыюлана төштем, кире уйламасын тагы дип, альбомны бераз актарып, «Анна» дигән мәшһүр сурәтне ачтым:

— Ясагач, аның Ослодагысын ясамыйк инде, туташ, Мәскәүдәгесен, Пушкин музеендагысын кабатлыйк, — дип теләмә салындым.

Шаирә мин күрсәткән сурәтне дә инкяр итмәде итүен, әмма шулай да кызаруын сиздермәскә тырышып, тегесен артыграк санагандай:

— Алай ук килешеп бетмәс. Миңа монысы да җитеп ашкан. Шушылай итеп язарсыз, яме? Ризамы сез шуңа? — дип сүзне очлады.

Риза булмаган кая инде ул!

Синең игътибар иткәнең бардыр инде. Кием белән чибәр күренүчеләр күп бит ул. Әйтик, дөньяның ачысын-төчесен татып өлгергән, үзен ханбикәгә санаучы берәр ханым бик оста тегүчедән үзенә үлчәп тектергән киемнәрен һәйбәтләп киеп җибәрсә, җыен селәгәй егетләрнең күзе төшә инде. Ә минә чишенгәч, анадан тума калгач — анда эшләр бөтенләй икенче. Йә, нидирәк күренеш ачылыр икән? Моңа кадәр биргән бәям акланырмы, юкмы? Әнә шунда бит хикмәт.

Янә бер атнадан, миңа калса, башкаларыннан акрынрак узган атнадан, без фәкыйрегезгә җир йөзендә бер чибәр, сылу затның йомры шома иңбашларын, сабыйлыктан яңарак чыкса да, тәмам җитлегеп өлгергән, мәгәр әле берәүнең дә кулы тимәү генә түгел, күзенә дә күренмәгән күкрәкләрен күрү насыйп булды. Бу чаклы да сылулыкны, нәфислекне бирсә дә бирер икән Ходай тәгалә адәм баласына! Әлеге күренештән беравык миңгерәүләнеп торгандай булдым да сабыр гына, җиң сызганып, эшкә керештем.

Йөз-кыяфәтен ашык-пошыграк язып ташладым, фәкать елмаюын ачыграк чагылдыра алдым бугай. Минем өчен иң кыйммәте, французларча әйткәндә, бюстны мөмкин кадәр сәнгатьчәрәк итеп язу иде. Һәм мин аңа буяуның арада бер нәфисрәкләрен кушып, озаклап тән төсен китереп чыгардым. Әһә, менә хәзер биниһая гүзәллеккә тәңгәл килә бугай. Сызып карыйм — төс ягыннан нәкъ үзе. Тәвәккәл таш ярган, ди бит безнең халык. Тотындым мин тәвәккәлләп язарга. Ай-һай, Бакыйҗан, ничекләр итеп мәңгеләштерерсең икән илаһи нәфислекне, илаһи гүзәллекне?! Ни төсләрне куертасы булма, ни бу оҗмах алмаларын зурайтасы итмә. Табигать ул бозганны-күперткәнне бер дә өнәми. Мохтаҗ түгел аңа. Син аны дөп-дөрес иттереп гәүдәләндер, җанлы итеп. Шунда булырсың егет!

Тырыша торгач морадыма ирештем бит тәки: бер сеанста язып бетердем мин әлеге соклангыч сурәтне. Зурайтмадым да, кечерәйтмәдем дә — нәкъ табигатьтәгечә, үзенеке шикелле җыйнак һәм дә нәфис, җанлы иттереп яздым. Шуннан соң беренче мәртәбә сүз кушып:

— Инде булды бугай, газизем. Үзегез ни әйтерсез тагын...— дип, кыл-каләмнәремне куеп, натурадан читкә борылып, дөресрәге, аңа өстен-башын рәтләргә ирек биреп, картинага текәлдем.

Туташ киенеп бетте бугай: колак төбемдә аның еш-еш сулаганы, уфылдап куйганы ишетелде. Борылып карарга өлгермәдем, ике кулы белән дә беләгемә ябышып, аяк очларына күтәрелде дә буе җиткән төштән үбеп алды. Нарасый үбүе, тыйнак кыз баланың хисләре ташып-ургылып чыгуы иде бу. Мин аны кочмадым да, җавап та кайтармадым. Тыелып калдым. Югыйсә бит, алай үбәләрмени, болай үбәләр аны, дип телемә салынып, ике арадагы мөнәсәбәтләрне катлауландырып җибәрүе бик ансат иде, бик ансат иде...

Үз тәненә һәркем соклана бит. Асыл затлар гына түгел, тупас бәдәнле ир-ат та сокланучан була. Шәрә хәлендә ул үз-үзен беренче мәртәбә күргәндәй, һәр әгъзасын җентекләп караштыра. Өстендә кием булганда көзге каршысына барып, төрле позага керү яисә кыяфәтен үзгәртеп караучылар да була. Сакал яки мыек үстерүчеләрне кая куясың? Бу бит үзләренә үзләре мөкиббән китүнең төп билгесе.

Әмма инде, үз тәненә, үзенең Ходай биргән байлыгына соклану бигрәк тә нәфис затларда көчле. Моны берни белән дә чагыштыру мөмкин түгел. Урынсыз булыр иде андый чагыштыру. Безнең туташ та моңа кадәр егетләр кулы орынмаган тәненең шул чаклы да нәфис икәнлегенә беренче тапкыр хәйран калды. Янә бер атнадан хөҗрәмә килеп

керү белән, һич кыстатып-нитеп тормыйча, түргә узып кына калмады, бәлки өлгер-житез хәрәкәтләр белән шүрлектән соңгы эшне алды, ипләп кенә өчаякка китереп куйды. Комачауламадым. Туйганчы карарга ирек бирдем. Карап туйгач та әле урынына барып утырырга ашыкмады, аяк өстендә кала биреп, күгелҗем жакетының сәдәфләрен бөтергәләп, күземә туры караган көе:

— Бакый әкә, сез теге юлы Пушкин музеендагы вариантка охшатып сурәтемне язарга тәкъдим иткән идегез. Исегездәме? Мин риза...— диде.

Исемдә булмаган кая! Күпне күргән йөрәгем, бу чаклы бәхетнең өстемә ишелеп төшүен сизенеп, мелт-мелт итеп куйды.

— Газизем, сезнең гүзәллегегез җир йөзендә кабатланмый торган гүзәллек ул. Һәм аны фәкать үзегезнең табигый халәтегездә язган очракта гына тулаем чагылдыру мөмкин булачак. Табигать биргән илаһи нәфислегегезгә тәмам тәңгәл килердәй картина язар өчен һөнәремне дә, көчемне дә кызганмам. Инде картинаны язып бетерергә насыйп икән, үлсәм дә үкенмәм.

Аңа утырырга дип урындыкны җайлап кына куйдым да үзем читкәрәк авышып, буяулар хәстәрләргә керештем. Өстенә карап торып оялтасым килмәде гөнаһсыз җанны. Иләшсен әле әкренләп, чирканчык алсын, дидем.

Ул арада Шаирә үзенең тәненә килешеп торган күлмәген дә, эчке киемен дә салып, үзе утырасы урындык башына пөхтәләп кенә элгән, мине көтеп утыра иде инде.

— Газизем, килеш-килбәтегезгә һич сүзем юк, мәгәр кием-салымыгыз анда комачаулык итәрдер. Әнә диван башына күчерсәгез, ничек булыр икән? — дидем. Һич тә дорфалык күрсәтергә, каты бәрелергә исәбем юк иде.

Туташ оялчан гына күлмәген-фәләнен гүя калкан итеп алдына каплады, ике-өч атлады да борылып карады. Тик инде минем ашардай булып карап тормаганымны, подрамникка тарттырылган киндерне мольбертка җайлап маташканымны күреп, бераз кыюлана төште, җайлап кына урындыкка килеп утырды.

Мин аңа ак та димәдем, кара да димәдем, әнә шул үзе теләп, дөресрәге, үз беллеге белән утырган халендә тәмләп кенә язарга тотындым. Гадәттә бит физик эштән йөз чөерми үскән хатын-кызның җилкәләре, нәкъ ирләр иңедәй киңәебрәк китүчән, үзең дә игътибар иткәнсеңдер инде. Ә менә Шаирәнең гәрчә үз өйләре, каралты-куралары, яшелчәҗимеш бакчалары булып, ул кара эштән беркайчан баш тартмаса да, иңбашлары борынгы Рим статуяларындагы алиһәләрнекенә бирешкесез иде. Нәзегрәк кенә озын матур муеннан соң гаҗәеп килешле булып, салынкы гына йомры иңбашлары үзенә күрә бер ямь биреп тора иде.

Әнә шул иңбашларын, куш алмадай өлгергән, житлегеп пешкән күкрәкләрен, искитәрлек нечкә билкәйләрен, әйтеп бетергесез ямь өстәп торган, бер үк вакытта йомры да, калку да янбашларын яхшылап язарга ымсынып, башы-йөзенә артык вакыт биреп азапланмадым — инде күнеккән штрихлар белән генә чикләндем. Тик инде муенын да, иңбашын да ашыкмыйча гына, сабыр гына, шул ук вакытта олуг бер дәрт белән, табигый матурлыкка сәнгатьчә гүзәллек тә өстәп, зур тырышлык белән яздым. Аннары инде кыл-каләмем оҗмах алмаларын тасвирларга тотынды. Монысы, дустым, аеруча зур осталык сорый. Хикмәт менә бит нәрсәдә. Әгәр дә син табигать биргән байлыкны бер дә үзгәртмичә генә, нәкъ шуңарга тәңгәл килерлек итеп тасвирлыйсың икән — фотография килә дә чыга. Әгәр дә син читкә авышасың икән инде — табигый гармониягә хыянәт иткәнеңне сизми дә калачаксың. Икенең берсен сайламый чараң юк. Шуңа мин гүзәлкәйнең күкрәк шәрифләрен әлегә шартлы рәвештә, контурда гына алырга ниятләдем. Шундук француз ватманына карандаш белән шәрехләбрәк ясадым, бөлекләрен-кулларын сызгаладым.

Билен сурәтләү әллә ни вакыт та, көч тә сорамады. Шуннан инде арада бер катлаулы, иң-иң җаваплы өлкәгә, янбашларын язу кадәресенә

килеп җиттем. Берәүләр әйтә, йөз чалымнарын дөрес чагылдыру кыен бирелә, ди. Әйе, кешенең фотографик охшашлыгын бирү белән чикләнмисең икән, эчке дөньясын, рухиятен, холкын-фигылен мөмкин кадәр мәгънәлерәк, тулырак чагылдырырга омтыласың икән, әлбәттә, җиңел түгел. Икенчеләр әйтә, иң кыены — бюстны язу, ди. Анысы белән һәм килешәм. Әле генә сөйләдем, карандашка ябыштым, дип. Әмма портрет язучыларны аптыраштa калдыра торган нәрсә — ул да булса хатын-кызның билдән түбәнге өлешен тасвирлау. Кием-фәлән белән дөрес итеп бирерсең дә, анысына аның фактура да булыша, материянең мөмкинлекләре ярдәм итә. Ә инде бөтенләй шәрә көе сурәтләгәндә — монда инде сиңа һичбер нәрсә булышмый. Пропорцияне чак кына боздың исә — адәм мәсхәрәсенә каласың. Рәссам халкының күпчелеге әнә шул барьерны атлап чыга алмый харап була.

Гәрчә калкынып торган нәфис янбашлары барча игътибарымны, алай дип әйтү генә аз булырдыр сыман, бөтен күз нурымны үзенә җәлеп итсә дә, алай артык мавыкмаска булдым — бераз гына күпертебрәк, үземнең идеалыма якынайтыбрак язу белән чикләндем. Берочтан бот шәрифләрен аяк бармакларына кадәр сызгалап ташладым. Шуннан соң сәгатемә күз салсам — башымны да күтәрмичә нәкъ алты сәгать эшләгәнмен. Үзем ярый инде анысы, ничә әйтсәң дә, эш белән мавыгып киттем, ди. Ә бит Шаирә бар, ул нинди халәттә икән? Иллә дә мәгәр ялыктырганмын туташны. Оят булып китте үземә дә.

— Зинһар, бигайбә, туташ, бигайбә! Сәгатькә карарга онытканмын, мавыгыбрак киткәнмен. Икенче сеанста, шөт, иншалла, тәмамларбыз ук...— дидем, киенергә куштым.

Шаирә, китәргә дип ишек ачкач, мөлаем генә елмаеп, арыганлыгын сиздермәскә тырышып, минем белән баш иеп саубуллашты.

Әмма икенче сеанс дигән өметем акланмады. Бер атнадан кабат килергә вәгъдә биргән Шаирәм килмәде-күренмәде. Иртә таңнан бирле көтеп утыра торгач, өйлә вакытларын да уздырдым, кояшны да остаханәмдә баеттым. Берәр төрле өй мәшәкәте килеп чыккандыр, дөнья хәлен белмәссең, дип үз-үземне юатырга тырышып, сабыр иттем, артык каударланмадым. Ә инде икенче атна да узып, ял көненең кояшы җир шарындагы исәпсез-сансыз таулар артына кереп качканнан соң күңелемә шик-шөбһә төште бит, дустым.

Яңа көнне керфек тә какмый көтеп алдым. Эш сәгате җитәр-җитмәс китапханәгә торып чаптым. Шаирә гүзәлкәем урынында чәченә чал кергән икенче берәүне күргәч, йөрәгем жуу итеп китте. Алмаштырасы китабым юк иде, шуңа беравык аптырабрак кына баскан урынымда таптанып тордым. Күршегә кереп, йомышын онытткан малай-шалайдан бер дә артык җирем дә, ким җирем дә юк иде бугай. Шуңа теге ханым мөлаем тавыш белән:

— Сезгә нинди китап кирәк иде соң, ник әйтмисез? — дип үзе үк сүз кушарга мәҗбүр булды.

Артык авыз йомып тору килешмәс иде. Шуны уйлап:

— Юк, мин туташтан алган китабымны янә дә берәр атнага озайтуын гына сорамакчы идем, нишләптер бүген ул күренми әле,— дигән булдым.

Кыяфәтемә чыгарып өлгергән гамьсезлек билгесе хәлне төшендерде бугай.

— Ул юк шул бүген. Бер атна инде чирләп ята,— диде ханым.

Урамга чыккач та кая барганымны тиз генә абайламадым. Атладым да атладым. Таныш тыкрыкка җитеп, шунда борылып кереп киткәч кенә, исемә килдем шикелле. Тик мин Шаирәмнең өен дә белми идем, белгән тәкъдирдә дә, мөгезсез сыер шикелле, өенә бәреп кермәс идем. Натурачымның гөнаһсыз сафлыгына кер-тузан тидерергә минем хакым юк иде. Уңга-сулга карана-карана тыкрыкның аргы башына житкәнемне сизми дә калганмын. Үткән-сүткән халык истә калмаган. Фәкать минем яшьләрдәге, элек чибәр булып та ярыйсы ук таушалган бер хатынның гына үземә нәфрәт белән төбәп караганын хәтерлим. Нигә алай карады икән? Әллә берәр җирдә үзенә зыяным тиде микән? Булмас димә, дөнья бу.

Шаирәм янә ике-өч атнадан соң гына балкып-нурланып остаханәмә килеп керде.

— Гафу кылгайсыз, Бакый әкә. Вәгъдәсезрәк булып чыктым шул, килә алмадым шул,— дип сөйләнде.

Гүя зарыгып көтүләрем онытылган иде, елмаюга елмаю белән җавап кайтардым:

— Зарар юк, газизем. Тик ятмадым болай үзе, менә бераз эшләп маташтырдым. Бу сеанста, иншалла, очлап та куярбыз,— дигән булдым.

Мин буяулар хәстәрләгән арада гүзәлкәем һичбер тартынусыз-нисез киемнәрен бердәм-бердәм салып та өлгерде, һәйбәтләп кенә диванга җәйгән келәм өстенә илтеп тә куйды.

Аның бусагамны атлап керүен күргәч тә, йөрәгем дерт итеп киткән иде. Инде анадан тума хәлендә күз алдымда пәйда булгач, башларым әйләнеп китте, ни хәтле сагынуымны шунда гына аңладым. Мөлаем йөзкәен, зифа буй-сынын, сөйләшү ысулын гына түгел — мин, карт юләр, гүзәлкәемнең нәфис тәнкәен дә сагынганмын икән ләбаса...

Бер-ике сәгать эчендә бөтен сабырлыгымны онытып, кабат югалтудан котым алынып, күземне дә тәненнән алмаенча, илаһи бер дәрт белән шигъри нәфислекне яздым да яздым. Сынымны турайтып, әле Шаирәнең үзенә, әле үзем җан өргән искиткмәле сурәтенә күз төшереп алдым да:

— Булды бугай бу! Инде үлсәм дә үкенмим, газизем...— дип эчке халәтемне ачып бирергә омтылдым.

Кыл-каләмнәремне урнаштырып, инде өстенә-башына киенгәндер, дисәм, туташ анадан тума хәлендә дивандагы келәмгә сузылып яткан, бер кулы белән чигәсенә таянган. Аптырап калуымны абайлап, гүзәлкәй тыныч булырга тырышты:

— Булды микәнни? Килегез, икәү бергә сокланып шуңа карыйк. Әйдәгез, бергә-бергә күрик сәләтегезне!..— дип сөйләнде.

Әйттеме Шаирәм әлеге сүзләрне, әллә бөтенләй үк әйтмәдеме — һич аңларлык түгел иде. Дөресен әйткәндә, мин инде аны-моны аңларлыктан узган идем. Абына-сөртенә диванга табан атладым, барып җитү белән, гөрес итеп тезләремә килеп төштем, әлеге гүзәллеккә орынырга да базмаенча, аны, чем-кара чәченнән башлап аяк бармакларына кадәр күздән кичердем. Бераз исемне-акылымны җыйгач кына, ни вакыттан бирле иң нык кызыктырган вә янә дә ымсындырган оҗмах алмаларының әүвәл берсенә, аннары, монысы үпкәли күрмәсен тагы, дигәндәй, икенчесенә капландым. Кулларыма кайчан җан кергәнен искәрми калдым — алар гүзәлкәйнең әле беләкләрен һәм аякларын, әле иңбашларын һәм янбашларын назлый-сыйпаштыра иделәр инде. Шаирә ул арада чалкан ятты, башын артка ташлаган көе, нинди хикмәтле хәлләр күрәсене көтеп, бераз сагаебрак калган, тәне сизелер-сизелмәс кенә дерелди иде.

Акны күрдем — абындым, дигәндәй, бәрелә-кадала ябырылмадым, һич тә инде менә, Ходa шаһит, үземнеке итәргә ашыкмадым. Кызык хәл бит, дустым: моңарчы әле шәрә көе күз алдымда утыруы гына да бик җиткән иде; хәзер менә аяк бармакларыннан башлап иңнәренәчә үбүләрем әйтеп бетергесез бәхет бирде, әлеге мизгелне ничек тә озайтасым-сузасыларым килде, гүя без фәкыйрегез бүтән берниге өметләнми иде инде. Мин үзенең бөтен җирен үпкән арада Шаирә тәненең дерелдәвен җиңде, гәүдәсенең һәр күзәнәге миңа табан тартылып, иреннәре ачылып, бинибаа дымланып өлгерде. Үбәр-үбәр дә эшне беттегә санар, шуннан узарга җыенмый, ахры, дип сагая калды бугай, мөлдерәп күзләремә карады да яшьлек дәрте ташып торган гәүдәсе белән миңа сарылып:

— Бүтән бернәрсә эшләтмисеңмени?— дип көч-хәл белән сорарга җөрьәт итте.

— Ашыкма син, бәгырькәем... Үз чиратында барысын да алырсың, җаным фида синең өчен...

— Чишенеп атар идең өс киемеңне... Тиң булыйк бер-беребезгә...

Бәй, үбү-назлау белән мавыгып, чишенергә дә онытып җибәргәнмен икән бит. Кайсы киемнең бавы чишелмичә, кайсының сәдәфе ычкынмыйча газапларга уйлады уйлавын да, тик мин алай аптыраучылардан түгел идем — умырдым алдым, салдым ташладым.

Аягүрә баскан көе, Шаирәмне, үземә насыйп булган хур кызын янә бер сөеп-сокланып күздән кичердем. Ә ул ятсынды, оялды, күзен йомгандай итте, әмма үзе һәр кыймылдавымны күреп торды.

— Илаһым, үзең мәдәт бир! — дигәнемне ишеткәч, түземсезләнеп:

— Кил инде!.. Тилмертмә бу тикле!.. — диде, ике учына бармакларымны эләктерде дә үзенә тартты.

Мәгәр мин тиз генә сузылмадым. Гомер буена беркемгә дә ачылмаган, миңа гына мәрхәмәт күрсәтеп ачылырга торган җәннәт ишегенә орыну үзем өчен ләззәтнең тажы булырга тиеш иде, шуңа кабаланмадым-ашыкмадым, сабыр гына муенын, иңбашларын, оҗмах алмаларын үбә-үбә, иплән кенә, өркетмәскә тырышып кына, дымлы иреннәренә якынлаштым да бар куәтем-дәртем белән җәннәт ишегенә ябырылдым...

— Абау, үләм! Алла, үләм! Җибәр, үтерәсең...— дип инәлү-ялваруларына илтифат итүдән узган идем инде, ычкындырырга уйламадым да...

Синең яшь әтәчләргә колак салганың бар микән, дустым? Алар бит шулай, бер кычкырырга тотынса — туктый белми һич тә. Берәүнең дә кулы тимәгән, җир йөзендә бер гүзәлнең мине тиң итүе үземне яшәртеп җибәрде, гүя мин әлеге дә баягы яшь әтәчкә әйләндем — бәгырькәемне сөюдән вә назлаудан туктый белмәдем. Җәннәтнең берьюлы әллә ничә төрле җимешен — әчесен, төчесен, баллысын татыдым.

Ә инде туктагач, рәхмәтемне белдерү нияте белән күзләреннән үбәргә итсәм — әчкелтем-төчкелтем-тозлы дымга тап булдым. Аптыравымны аңлап, бәгырькәем күзен ачты, мул елмаеп:

— Хафаланма бер дә, бәхет яшьләре ул, әкә җаныем, шатлык яшьләре...— диде. Янә бер тын алу белән: — Мин дә яшәгәнмен икән бу дөньяда, моңарчы шундый куанычтан-шатлыктан мәхрүм булып... — дип тә өстәде.

Ул көнне кичкә хәтле сөешеп-назлашып уздырдык. Табигате шактый сәер булып чыкты бәгырькәемнең: үзе мине иркәли-үсендерә-ирәйтә, мин нығытып торып ябырылган саен:

— Абау! Үтерәсең ич инде! Шул чаклы яман зәһәр кыланмасаң ярамагандыр... — дип зарланырга-ялварырга өлгерми, үзенең шундук дәрте кузгала да, сине чөеп атарга омтылгандай, боргалана, сыргалана, тынгы белмичә үрсәләнә, тузбаштай бөтерелә, сиңа чытырдап ябыша да нидер сөйләнергә-быдырдарга тотына, еш-еш сулу ала, шыңшый, туктаусыз ыңгыраша...

Йа хода! Бирсә дә бирер икән адәми асыл затка шулхәтле хиссият вә маһирлык! Бүтән берәүгә эләксә, һичшиксез, бу бала тыйнак булып кылана гына икән, мәхәббәт өлкәсендә азау теше чыккан икән, сөю-сөешүдә күпне күргән, остаруы тәмам җиткән икән, диебрәк фикер йөртер иде.

— Абау!... Әкә җаныем, үтерәсең!.. Әкә бәгырем, һай рәхәт!..

Сөешеп тәмам хәлдән тайганнан соң ял итеп ятканда Шаирәмнең назлы йөзкәеннән елмаю китмәде. Күзен йомып яткан хәлдә үзенең йөрәк серләрен чишәр булды:

— Күрә алмыйча гүр иясе булам икән, дип ут йоттым. Шунда гына аңладым: натурачы булып кына йөрмим икән синең хөҗрәңә, үлеп гашыйк икәнмен үзеңә.

Беравык тынып торды, мине сыйпаштырды, сынап карады да:

— Башым булса, моны күптән аңларга кирәк иде дә бит югыйсә,— дип яңа кыйссаны башлап җибәрде.— Исеңдәме беренче очрашуыбыз? Мин бит анда халык арасында синең мәһабәт буй-сыныңны, кояштай балкып торган йөзеңне күргәч тә... Юк, алай ук үсенмә, ул чагында гашыйк булмадым әле. Тик шулай да, их, менә шундый мәхәббәтле булсын иде ул булса ярың, дип уйлаганым хәтердә. Менә юраганым юш килде инде. Әле ярый шунда калмагансың, юлыма аркылы төшкәнсең.

һич онытасым юк, рәхмәт яусын! Мине бәхетле иттең, сурәтемне ясадың, хөжрәңә дәшеп, сәнгать өлкәсенә әйдәп алып кердең, мине читсенмичә үзеңә тиң күрдең, инде миңа яр иттең...

— Синдәй алиһәне яратуы, яр итүе үзе бер бәхет, күктән иңгән бәхет...— дип тел тибрәтергә уйлаган идем дә бит, бәгырькәем нәфис бармаклары белән авызымны каплады.

— Күк капусы ачылды, бүген мин генә сөйлим, гаепкә алма... Атна буена саташып ятканмын. Хәлем хәл иде. Бераз игә килгәч, сеңелкәем-гөлкәем әйтте: «Кем ул Бакый әкә дигән кеше? Саташкан чагыңда син гел шул исемне кабатладың...» — диде. Әнкәй бер сүз әйтмәде. Бер мәлне генә: «Күрдем мин синең теге әкәңне... Як-ягына карангалап, турыбыздан узды... Сине күрергәдер инде исәбе...» — диде, әмма үзе төпченмәде.

Сөйләргә ярамый иде әле миңа, баш кагып кына шулай икәнен аңлаттым.

— Әнә шул килүләрең, сагынуларың, мине күрү нияте белән олы башыңны кече итеп йөрүләрең хисләремә ачыклык кертте, ике арадагы читән-киртәләрне җимереп ташлады. Югыйсә бит, кайчан килсәм дә, һич үз итүеңне сиздермәдең, ичмаса бармак очың белән генә дә кагылмадың... Авырганда вакыт күп бит ул — һәркөн сине уйладым.

Сөеклемнең бармакларын учыма алып, назлы итеп кенә берәм-берәм үбеп чыктым да:

— Мин дә сагындым бит, бәгырькәем...— дидем.

Әллә әйттем әлеге сүзләрне, әллә әйтмәдем... Әллә ишетте Шаирәм, әллә ишетмәде... Шулай онытылып-оеп ятканда, талгын җил сыман, акрын гына булып моңлы бер көй күңел кылларыма килеп бәрелде:

— Беләм инде... Гомеремдә дә синнән бүтән берәүне үләргә җитешеп сөймәячәгемне, сөя алмаячагымны аңладым. Синеке булырга хыялланып яттым авыру чагымда да... Бая, сурәтемне язганда, карап туя алмадым... Инде менә, Ходай кушып, сине үземнеке итүгә ирештем. Миннән бәхетлерәк берәр җан иясе бар микән җир йөзендә?!

Дустым, син азмы-күпме шигърият дөньясында чуала торган зат. Шулай булгач, мәхәббәтнең иҗатка һәм дә иҗатның мәхәббәткә тәэсир итүен сиңа төшендереп маташу, лекцияләр уку артыктыр. Шаирә чибәркәй белән кавышу без фәкыйрегезнең дә иҗатына галәмәт нык тәэсир ясады. Сөеклем намена берәр төрле гадәттән тыш нәрсә эшлиселәрем килде. Сәмәрканд — Шәрыкның мәркәзе бит, дустым, музейларга һич бирешкесез: андагы сәнгатьчә гүзәл биналар-корылмалар — бихисаптыр. Җаның теләгәнен сайлап ал да — гүзәллекне хәлеңнән килгәнчә гәүдәләндер.

Сиңа сөйләдем микән, дустым, юк микән, илаһи зур Җәмигъ мәчете бар бит анда. Биби ханым исеме белән кереп калган ул тарихка. Биби ханым... Шул мәчетнең хәрабәләрен беренче күрүемдә үк таңга калырмын, дип һич уйламаган идем. Күкләргә ашкан капка-баганаларының, төп-төз манараларының биеклегеннән генә түгел, гармониягә ия булуыннан, матурлыгыннан тәмам биһуш булдым.

Гомер-гомергә үзем өчен язылмаган бер закон яшәп килә: әгәр дә син рәссам икәнсең инде, сокланып кына калма, күңелеңә хуш килгән нәрсәне тот та кәгазьгә төшер!

Әмма дөнья мәшәкате белән мавыкланып, Җәмигъ мәчетен кәгазьгә төшерә алмый яткан идем. Ихтимал, аңарчы ташлар өемен генә аермачык күргәнмендер әле, күңел күзем берни күрмәгәндер. Андый халәттә кулыңа кыл-каләм, һич югы карандаш алмавың хәерле. Ныклап өйрәнмәгән-белмәгән көе хезмәтең юньле нәтиҗә бирмәячәк, һәм әлеге әсәреңне тамашачы барыбер аңлый алмаячак, ә инде аңлый алмаган әйберен кабул да итмәячәк. Әнә шул өйрәнү дигәнемә вакыт һич кенә тимәде дә тимәде, сузылды да сузылды...

Кызык хәл инде: Шаирә сөеклемнең исеме күңел түремдә ни рәвешледер нәкъ әнә шул Биби ханымның исемен уятты, шуңарга тәңгәл

киләдер сыман тоелды. Хәтта әле сөеклемнең гүзәллеге ханбикәнең хыялдагы образын җанландырып җибәрергә булышты бугай. Менә нилектән, Биби ханымның портретын язарга тотынган саен Шаирә сурәте килеп чыга торган булды. Асыл затның гүзәллеге күземә фәкать шулай булып, алиһәм кыяфәтендә күренде. Шуннан уйга калдым: үз халкының хәтерендә ничәмә-ничә йөз ел дәвамында Җәмигъ мәчетенә бирелгән исем буларак сакланган икән, бәлкем, аның үз портретын ясамыйча, хәрабә хәлендәге мәчетен ясап ташларгадыр? Бәлкем әле, шулай дөресрәк тә буладыр?

Җәмигъ мәчетенең тарихын өйрәнүләре әлләни кыенга килмәде килүен. Җиһангирның үткәнен өйрәнгәннәр, күп итеп язганнар; аның шәхси тормышына бәйле рәвештә, әлбәттә, сарай мөлек ханым, ягъни мәдрәсәләр ачып җибәргән зур укымышлы Биби ханымның да исеме телгә алына.

Бөтен Шәрыкны баш идергән, Җиһангир исеменә лаек табылган, безнең Алтын Урданың мәркәзе Сарай каласын, хөсетлек шаукымына бирелеп, вәйран иттергән, үлгәнче ат өстеннән төшмәгән, кылыч уйнатудан туктамаган Аксак Тимернең каһарманлыгы сиңа, әлбәттә, мәгълүмдер. Сәмәркандны барча мәмләкәтләргә мәркәз булырдай итеп бизәргә омтыла Җиһангир. Кырык метр биеклегендәге Җәмигъ мәчете әнә шундый нияткә тәңгәл килердәй итеп корылган да инде, дустым. Бүгенге көндә ул мәчетне, дөресрәге, аның хәрабәләрен «Биби ханым» дип кенә йөртәләр. Шәфкатьле-мәрхәмәтле булганы өчен, сабыйларга мәгърифәт өләшкән өчен, кылган игелекләре өчен халык телендә мәңгеләшкән. Безнең Сөембикә шикеллерәк бер изге зат булганы бәхәссез.

Хәер, Биби ханымга кемнәрнеңдер гыйшык тотуы халык телендә йөри йөрүен... Истән чыкмаса, анысын да сөйләрмен үзеңә, боерган булса. Ә хәзер мәчетнең ни рәвешле корылуы хакында бераз мәгълүмат биреп китим үзеңә.

Һиндстанга яу чабу уңышлы тәмамлангач, Аксак Тимер үзенең тиздән барча җиһанны тезләндерәсенә тагын да ныграк ышаныч баглый. Мәркәзендә ул гаҗәеп зур, матур вә зиннәтле Җәмигъ мәчете кордырырга ниятли. Бөтен дөнья шаклар катсын әле Җиһангирның кодрәтенә! Меңнәрчә мөэмин-мөселман сыярлык булсын, барча халык шунда җомга намазына йөрсен, бөтен Шәрыкка даны таралсын!

Моның өчен, дустым, төрле җирләрдән ташның телен белгән ике йөзләп мәшһүр останы китерттерә. Янә дә биш йөз кешене тау кисәргә җибәрттерә. Әнә шулар кискән, эшкәрткән, шомарткан зур-зур ташларны филләрдән тарттырып калага кайтара торалар, монда осталар ул ташларны кирәк җиргә салдыра торалар. 1399 елның рамазан аенда изге бер көндә нигез салына Җәмигъ мәчетенә. Биш елдан соң гына эшләр тәмамлана. Аксак Тимер мәчет кору эшләрен башлап җибәргәндә вагына-төягенә хәтле үзе күзәтеп, әмерләр биреп тора-тора да, мәчет саклап утыра алмыйм ич инде дигәндәй, шул ук елны Мисырга яу чаба.

Халык телендә мондыйрак риваять яшәп килә. Аксак Тимер үзе Мисырны яуларга киткәч, имештер, аның баш хатыны — сарай мөлек ханым, ягъни мәдрәсәләр булдырган, зур укымышлы Биби ханым, иренең җиңеп кайту хөрмәтенә гаҗәеп зур мәчет булдырырга ниятли. Менә әмирнең кайтыр вакыты якынлаша, тик әле кырык-илле метр биеклегендәге тышкы ишек-капканың, латинча әйтсәк, порталның (ул шулай атап йөртелә дә) әле һаман эше бетмәгән: архитектор егет сарай мөлек ханымга гашыйк булган да аерылышу көнен кичектерә килә икән. Биби ханым аңардан үтенә, ялвара, тик егетнең бернигә исе китми: бер үптерсәң, тизләтәм, бер үптерми торып, бетерәсем юк, дип бара. Бүләкне әмир кайткан җиргә әзерләп өлгертү бәрабәренә генә үптерә Биби ханым, башка чарасы калмагач кына. Әмма бер генә үбеп тә гүзәлкәйнең бит алмасын көйдереп ала гашыйк егет.

Аксак Тимер, кайту белән, күреп ала хәләленең бит алмасындагы үпкән эзне. Шартлый яза ачуыннан-гайрәтеннән. Әмер бирә нәфеслене үз

катына китерергә. Иәләшкән кылыч сабын кысып тота. Әмма останы күпме генә эзләсәләр дә таба алмыйлар: имештер, егет канатланган да, очып күздән гаип булган...

Бөтен дөньяны таңга калдырырлык гүзәл мәчет кордыручы алтын куллы останың мәхәббәтен тасвирлаган чагында мәрхәмәтле халык, әлбәттә, ул вакытта инде Биби ханымның алтмышта булганлыгын бөтенләй истән үк чыгарып җибәрә...

Риваятьнең барлыкка килүенә гүзәл сәнгать әсәре Җәмигъ мәчетенә һәркемнең дә бинибая соклануы сәбәп була. Мәчетнең тышкы капкасы гаҗәеп киң, биеклеге исә кырык-илле метрга җитә; бинибая матур капка үзе искиткеч җиңел, ә үзе җиде төрле металлдан (алтын, көмеш һ. б.) коелган, ике якка ачылып киткәндә бертөрле көй, моң чыга, азан әйткән тавышлар ишетелә. Җәмигъ мәчетенең дүрт почмагында дүрт манара торгызылып, алардан мәзиннәрнең җомга намазына чакырып азан әйткәне гүя барча мөселман дөньясына, әллә кайларга яңгырап ишетелә. Түбәсен күк гөмбәзедәй итеп эшлиләр. Идәне тоташы белән ак мәрмәрдән түшәлә. Диварлары сокланырлык итеп бизәкле кирпеч-таш белән тышлана...

Әмма вакыт дигән нәрсә шушындый гүзәл сәнгать әсәренә дә һичбер төрле мәрхәмәт-шәфкать күрсәтми: бүгенге көндә мәшһүр архитектура әсәре — хәрабә хәлендә. Шуларга карап Җәмигъ мәчетенең илаһи биеклеген күз алдына китерә алсаң, димәк, син чын-чыннан сәнгатькәр, шул чагында син картина да яза аласың.

Хәрабәләр...

Кайсы гына ягыннан карасаң да, хәрабә булгач хәрабә инде ул, дустым. Тик менә шунда да ташлар өемен күрсәтмәскә иде бит, мәчетнең илаһи матурлыгын, урта гасырларда җир йөзендә бер гүзәл вә мәһабәт корылма булганлыгын тамашачыга түкми-чәчми илтеп җиткерәсе иде. Ният шундыйрак инде минем. Дүрт ягың кыйбла дигәндәй, җаның теләгән якны сайлап ал: мәчетнең шәһәр өстендә ни дәрәҗәдә калкынып торганын күрсәтим дисең икән — фил янындагы тараканнар шикелле бүгенге өйләрне дә күрсәтәсең; дала ягыннан аласың икән инде — биек ташлар өеме белән манара вә диварны язарга мөмкин; капкасын күрсәтим дисәң инде...

Шактый гына уйланып йөрдем шул, дустым, хәрабәләр тирәсендә. Әмма алай күпме генә йөрсәң дә, язылмый бит картина, язылмый. Җиң сызганып эшкә тотынасы. Шуннан катгый бер карарга киләмен: мәчетнең олы капкасын күрсәтүдән дә яхшысы булмас, димен. Әйе-әйе, шау чәчәктә утырган алмагачлар, башка төрле җимеш агачлары ягыннан карагында почмактагы манара да, капканың ни рәвешледер сакланып калган мәрмәр түбәсе дә, мәгърур баганалары да, капка үтәли эчке дәү мәчет бинасы да һәм аның капусы да әйбәт күренә иде.

Репиннан берзаман:

— Илья Ефимович, кар нинди төстә була? — дип сораганнар.

Нинди төстә икәнен аңлатуы озакка сузыласыны уйлап алгач, рәссам:

— Ак кына булмый! — дип кистереп әйткән.

Репин шикелле үк, Урманченың да ак төскә мөнәсәбәте хәйран үзенчәлекле бит, әйе. Мәчетнең манарасын да, капкасын да, эчке бинаны да, аның түбәсен дә, баганаларын бизәп торган ак мәрмәрне дә, хәтта әле шау чәчәктә утырган җимеш агачларын да беленер-беленмәс кенә зәңгәр төстә алып, сизелер-сизелмәс кенә, сыеграк кына саргылт-көрән төсне өстәдем. Акварель белән ясаган шушы рәсемгә күз салсаң, хәзер инде төрле төсләрне әкренләп кенә төсмерлисең: бер караганда — сыек- зәңгәр күк йөзе фонында коңгырт төс калкып чыга; икенче караганда — күгелҗем төс көчәя, өстенлек ала, балкып-матурланып китә. Биби ханым исемен йөрткән мәчет — борын заманнарда яшәгән сәнгать иясенә, осталарга, шунда тирен вә канын түккән, үлеп калган эшчеләргә һәйкәл ул, дустым. Татар рәссамы шушы һәйкәлне иң отышлы ягыннан алып, бөтен гүзәллеге белән гәүдәләндерә. Син моңа үз бәһаңны бирергә

тиешсең. Ә инде Җәмигъ мәчете янында бигрәк кәрлә булып күренгән җимеш агачларын тамашачы җиргә ятып үскән куаклар дип кабул итмәсен өчен, ике-өч кеше сурәтен дә өстимен. Алары агачлардан да бәләкәйрәк килеп чыга. Бу исә мәрмәр һәйкәлгә нисбәтән аның биеклеген вә бөеклеген дәлилли. Хезмәт бар монда, дустым, бар. Иҗади ачыш монда, эзләнү вә табыш.

Җәлләмәдем кыл-каләмне, акварельне — кабат-кабат яздым шул мәчетне. Килеп чыкты гамма аермасы: кайсы аның зәңгәрсурак, кайсы аның алтынсурак. Нигә алай иттең, дип кызыксыныр булсаң, һич җавап таба алмамын. Адәми зат төшенә алмас андый сергә-хыялга. Афәт гүя чолгап алды бар җанымны, иҗатымны. Үз эшемнән канәгать булмыйча, яңадан ябышканмын буяуларга, дияр идем — иҗатым гөрләп чәчәк аткан ул дәвердә инде (1952), шуны абайла, акны карадан аера алырлык хәлдә идем — Шаирәгә тиңләшерлек гүзәл сәнгать әсәре иҗат иткәнемне аңлый идем. Әле бит алай гына да түгел, бүтән берәүнең дә бу чаклы да камиллеккә ирешә алмаячагына шигем-шөбһәм һич юк иде. Музейгамазар сатып алырлар, дип өметләнгән очракта да, бүтән берәү булса, кабат-кабат язып вакыт әрәм итмәс, әзер әсәрдән копияләр күчерү белән канәгатьләнер иде. Ихтимал, тугандаш җирле халыкка, менә без, татар була торып та, ничек итеп ясый беләбез, дип исбатлавым булгандыр? Ихтимал, бик ихтимал...

Сәер инде бу халык: ун елдан артык Алматыда яшәгән дәвердә — син казакъ түгел, син татарсың, дип атлаган саен бәйләнеп теңкәмә тиделәр. Талантыңа гәрчә үзләре баш исәләр дә, бик күп өстен икәнеңне күрсәләр дә, төшемлерәк заказларны, җаваплырак эшләрне шактый калышрак рәссамнарга тапшыралар иде — казакъ кына болсун! Аларга синең сәнгатьтәге маһирлыгың кирәк түгел, бары тик казакъ фамилиясен кую кирәк, шунысы кыйммәтрәк. Абай тематикасын төрле яктан өйрәнгәнемне күрә торып, әзерлегем баштин ашкан икәнне белә торып, андый эшкә һич якын да җибәрмиләр, милли кадрлардан эшләтәләр...

Анда гына шулай кыланалардыр, дисеңме? Юк шул, дустым, юк! Фаҗига диген дә — вәссәлам. Тугандаш халыкларның үземә карата мөнәсәбәтләре — үзе бер олуг фаҗига иде.

Үзбәкстанда мине шулай ук, фәкать үзбәк милләтеннән булмаганым өчен генә, читләтеп узарга маташтылар. Биби ханым мәчетен кабат-кабат эшләвем, ихтимал, әнә шуның гарьлегеннәндер? Әллә бәлкем, аның ише юк-бар рәнҗүләрне читкә куеп, төрле кимсетелүләргә бер дә исем китмичә, онытып-онытылып, мәхәббәткә тиң сәнгать дөньясында яшәргә, борынгы замандагы алтын куллы осталарның иҗат җимешенә мөкиббән китүемне исбатларга омтылу булгандыр? Кем белә бит аны, кем белә...

Ә-ә-ә, Шаирә, дисеңме? Искә төшермә ичмасам... Ул менә монда — йөрәгемдә уелып калды. Биби ханым да булып... Мәңгелеккә... Артыгын сорап йөдәтмә дә, сөйли дә алмам, дустым...

Гомәр Хәйям[1] безнең ишегә нәрсә дигәнне хәтерлисең микән син:


Фәләк[2] аткан сине чит-ят бу җиргә,
Ни бирсә башта, алган ул кирегә;
Мина калган фәкать картлык көнемдә
Богаудай язмышым сөйрәп йөрергә...

*Дәвамы бар.*

---

[1] Нури Арсланов тәрҗемәсендә бирелә.
[2] Фәләк — язмыш, тәкъдир.

## ШИГЪРИЯТ



# Фәйрүзә Мөслимова

### ХАТИРӘЛӘР СҮТЕЛӘ...

### Каршылау

Авылыма кышын кайтсам әгәр,
Ишәлтаудан юллар бар микән?
Әллә инде күкләр белән тоташ
Уйнап торган буран, кар микән?

Авылыма язын кайтсам әгәр,
Ишәлтауда чирәм шытармы?
Мин кайтканны күреп, ян бакчадан
Сыерчыклар каршы очармы?

Авылыма җәен кайтсам әгәр,
Яшел булыр микән Ишәлтау?
Эндәшерме зират наратлары:
— Кайттыңмы,— дип,— бахыр, исән-сау?

...Авылыма кайтып киләм менә,
Ишәлтауга менәм ашкынып.
Күңелкәем ташып тулгангамы,
Каршы ала болыт яшь коеп.

### Иске өй

Өй сүтәләр. Иске өй сүтәләр —
Урын кирәк яңа урамга.
Тик аңламый шуны алабай — эт,
Аякларга өреп урала.

Кешеләрнең сәер гамәленә
Эт акылы ничек җитсен, ди?
Әнә инде, күз алдында кими,
Юкка чыга чүгеп иске өй.

Өй сүтәләр. Өй генә дә түгел...
Ямансулый, әнә, хуҗа да:
Үткән гомер, аккан сулар бит ул —
Уйлана да тагын кузгала.

Балалары үсеп, канат ярган
Җылыдан да җылы оя бу.
Дулкын каккан, давыл кискән чакта
Бирешмәгән ныклы кыя бу.

Карлыгачлар оя корган нигез,
Үрмә гөлләр үскән бакчасы,
Ишегалларында — яшел чирәм...
Юкка чыга менә барчасы!

Өй сүтәләр... Яңа фатирлары
Шәп тә шәбен, иркен, зиннәтле.
Тик сүтелә монда яшь гомерләр,
Хатирәләр сүтелә нихәтле.

Сурәте дә калмый яшь гомернең,
Өе белән бергә югала.
Алабае шуны сизә бугай —
Аягына килеп урала.

Яңа фатир һәйбәт булуына
Эт акылы ничек җитсен, ди?
Урамга да — киңрәк урын кирәк,
Кичер инде, кичер, иске өй.

* * *

Әй-йа халкым, сиңа — һәрбер шаукым
Мәңгелектән килгән канун кебек.
«Югары»дан төшсә бер-бер фәрман —
Әҗәлләрдән саклар дару кебек.

«Фәрман төште» мәчет салырга да:
Гөнаһларны йолыр чамалар бар.
Бер-бер артлы мәчет, мәчет калка,
Авыл саен айлы манаралар.

Әй-йа халкым, «гөнаһларың» — ташкын!
Ташкыныңда ташлар арта тора.
Бу кадәрен уйлар чамалар юк,
Ярлыканыр! — Мәчет сакта тора.

Дөнья җитеш, дөнья түп-түгәрәк!
Тыныч кына мөмкин үләргә дә.

...Күзгә күренмәгән Иблис бии
Мәчетләрдән төшкән күләгәдә...

## Кышкы чишмә

Ап-ак карлар зәңгәр күләгәле,
Челтәр шәлдән яшел чыршылар...
Күңел тагын бер кат иләсләнер,
Көмеш чишмә булып чылтырар.

Ап-ак карга эзләр сала-сала,
Язга таба атлап китәрмен.
Көмеш чишмәм эретер салкыннарын
Зәңгәр күләгәле көртләрнең.

Бөтерелеп аккан зәңгәр бозда
Саубуллашкан кебек ут янар...
Китми тор, кыш! Минем чишмәм әле
Кар астыннан, бәлки, юл табар.

## Их, дөньясы!

Әллә дөнья артык әйбәт,
Әллә үзем начар мин:
Ил күзенә чыккан саен,
Үз өнемә качам мин.

Әллә тормыш — тоташ бәйрәм,
Әллә халкымы — сәрхуш?
Куеннарда шешә булса,
Башларында кәләпүш.

Әллә данга ирештекме?
Әллә төштек мескенгә?
— Син дә шуңа ириш,— диләр,—
Юкны-барны тикшермә!

Әллә, дим соң, төкеримме?
Аһ, коега — төкерек?!
Суы кирәк булмагае —
Кая барма, исерек!

## Һавасыз...

Мин бит сиңа һава кебек идем,
Хәлең ничек хәзер, һавасыз?
Бардыр дустың, бардыр сердәшең дә,
Ә һаваның булмый яңасы.

Мин бит сиңа һава кебек кирәк,
Суламыйча ничек яшисең?

Тел тибрәтеп, кил, дип дәшәр иден,
Миннән башка, беләм, ятим син.

Үз-үземә зур бәядер бәлки?
Әллә сиңа шулай ышанам?
Уйны — уйга, җанны җанга ялгап,
Күңелемнән сиңа юл салам.

Тел тибрәтеп, үзең чакырмагач,
Синең якка юллар өзек бит.
Үрсәләнеп сөрән салуым бу:
— Мин бит сиңа һава кебек! — дип.

## Тукталыш

Бар сәгатьләр туктап калды
Без бәхетле минутта.
Сулыш алмый торды дөнья —
Талды сихри тынлыкка.

Бар сәгатьләр туктап калды
Изге мәлне тоткарлап.
Бер тавышсыз канат кагып,
Очып узды акчарлак.

Тавышсыз гына чайпалып,
Дулкын какты ярларга.
Безнең йөрәк тибеше тик
Китте әллә кайларга.

Әллә кайларда яңгырап,
Кайтаваз булып кайтты.
Туктаган мизгелне узып,
Алсуланып таң атты.

Тынып калган серләр илен
Кузгатты безнең йөрәк!
...Тек-тек итеп, тек-тек итеп,
Йөри башлады сәгать...

## Су өчен генә

Бәйләмә инде туры атыңны
Көн саен безнең капка төбенә.
Белеп торамын, туктыйсың юкса
Кое янына, су өчен генә.

Бәйләмә инде туры атыңны.
Күрәм дә сине, өзеләм генә.
Суга чыгамын атлар-атламас,
Битараф булып күренәм генә.

Атыңны синең күрмичә узам,
Шаян сүзеңне ишетми генә.

Әмма күтәмен синең килүне
Көн саен шулай кичекми генә.

Бәйләмә инде туры атыңны
Капка төбенә су өчен генә!
Үзем дә беләм: янам да көям
Юк өчен генә, юк өчен генә...

## Бары түз!

Мин башкача түзә алмыйм,
Мин башкача көтә алмыйм —
Бер генә сүз әйтче, зинһар,
Боз эрерлек назлы сүз!

Кышлар арты кышлар килә.
Кем өчендер — кошлар килә.
Ә мин чирдән айный алмыйм,
Сөю чире — бары түз...

Ул чиремнән оялам мин,
Яратудан кыйналам мин.
Язны көтмим, һич югында
Ярар иде сары көз!

Кышлар арты кышым көтә,
Үз-үземә һушым китә:
Дөньяда юк сүз телимен —
Боз эретер назлы сүз!



# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



## Ләлә Сабирова [1]

# КӨНЛӘШҮ

хикәя

Укытучылар бүлмәсенә бүген дә бәрелеп-сугылып килеп кердем. Сумкамны ишек төбендәге кәнәфигә аттым да җәлт кенә каршы як стенага ябыштырылган дәресләр расписаниесенә килеп төртелдем, аннары ашыга-кабалана класс журналын барлап алдым.

Берничә укытучы, әсбапларын кочаклап, кыңгырау шылтыраганын көтеп тора иде, гадәттәгечә, миңа сәерсенеп карап алдылар. Аларына артык игътибар итмәдем. Рузалия Кашаповна, завуч өстәле артыннан купмыйча гына тамагын кыргалап, минем якка шелтәле караш ташлады. Аңа да авызымны ачып сүз әйтмәдем, иңнәремне җыерып, кулларымны гына җәйдем: нихәл итим, тормыш бит, янәсе. Соңга калу түгел инде бу, дәрес башланырга төгәл бер минут вакыт бар бит әле...

Инде тәмам тынычланып җиткән идем. Көзгегә карап, өс-башымны тәртипкә китерергә дә өлгергән идем хәтта. Ишектән май кояшы кебек балкып кереп килүче Тәнзилә бөтен кәефемне кырды. Юк, юк, һичнинди зыян салганы юк аның миңа, әллә ни аралашкан кешем дә түгел ул. Шушы кадәрле ыгы-зыгылы тормышта һәммә нәрсәдән канәгать кеше сыман кылануы, ашыкмый-кабаланмый гына бөтенесенә өлгереп баруы чыгырымнан чыгара мине. Бөтен нәрсә уңай килеп тора бит аңа! Борчу-мәшәкатьләре булмагач, билгеле, дәресләренә дә иркенләп әзерләнә, кәеф-сафалары да шәп инде. Әнә, дәрес башланыр алдыннан классына кереп чыгарга да җитешкән, «анысы болай, монысы тегеләй» дип, очына-очына бишенчеләре белән булган хәлләрне сөйләп маташкан була. Кыяфәтенә карасаң, чын-чынлап куана бу, диярсең. Тыңлаучыларын күр әле, уратып алып, җөпләп торалар шуның әйткәннәрен, көнләшүләреннән шартлардай булып тыңлыйлардыр, югыйсә.

Әле бер көнне җыелыш булган иде, Рузалия Кашаповна теленнән Тәнзилә исеме төшмәде. Дәресләрендә әллә нинди яңа алымнар кул-

[1] Ләлә САБИРОВА (1947) — *нигездә педагогик темаларга хикәяләр яза. Алар республикабыз матбугатында басыла килеп, «Кызарган алмалар» исемле җыентык булып дөнья күрделәр. Ләлә Сабирова — «Сабантуй» балалар газетенең баш мөхәррире.*

лана икән, мәктәпкә ул килгәч, укучыларның физика фәненә карашлары бөтенләй шәп якка үзгәргән. Әти-әниләр дә куанып туя алмый, имеш. Түзмәдем, утырган җирдән генә: «Математика белгече физика укыткач, шәптер инде»,— дип төрттереп куйдым. Завуч минем якка күңелсез генә карап куйды, шулай да артык сүз озайтмады. Югыйсә, тагын нәрсә дип әйтергә икәнлеген уйлап куйган идем инде.

Нәрсә, әллә мин аннан ким эшләр идемме? Тормышым анықы кебек шома барсамы?! Хәрби кеше, диләр, Тәнзиләнең ирен, мөгаен, зур дәрәҗәдәгеседер, безнең шәһәргә күчеп килүләре дә тикмәгә түгелдер. Бердәнбер малаен да курчак кебек киендерә. Әле анысы быел беренчегә генә керде, андый бәләкәйләргә кием-салым өчен күп кирәкме?! Кайнана белән тора торган кешегә дә охшамаган, болай ук бәхетле кыланмас иде...

Белмим, эчемнән тагын ничек итеп битәрләр идем икән мин аны, көзге чебен кебек бер-бер артлы килеп йөдәткән эчпошыргыч уйларымнан ярый әле кыңгырау тавышы коткарды. Беренче дәрес үземнең тугызынчыларда иде. Класска эчке ачуым басылмаган көе килеп кердем. Өй эшен эшләмәгән өчен Малик белән Әүзахны битәрләп аттым, көмеш чылбырлы зур алкалар тагып килгән өчен Лилияне бөтен класс алдында тиргәп өлгердем. Арткы партада чышын-пышын бәхәсләшеп утырган ике малайга шундый итеп кычкырдым ки, үз тавышым үземә ошамады хәтта...

Нәрсә, анын кебек балда-майда йөзсәм, Тәнзилә кебек булдыра алмас идемме әллә? Ирем андый зур кеше түгел шул минем, гади шофер гына. Тәнзиләнең ире кебек бер зур начальникны йөртә. Анысы ярый инде, мәктәпкә барганда-кайтканда еш кына мине дә машинасына ала. Командировка-фәлөнгә киткәндә генә кыенрак, шәһәр транспортын көтеп гаҗиз булам. Бүген дә шул троллейбус вакытында килмичә харап итә язды. «Андый чакта иртәрәк чыгарга кирәк»,— дип кисәткән була Рузалия Кашаповна. Бер гадәтләнгән вакытка көйләнәсең инде аны. Ике баланы ике яктан карыйсы бит әле өстәвенә. Әтиләре өйдә юкта аеруча кыен, бакчага берүзем җыендырам. Берсе киреләнә, икенчесе көйсезләнә, әле тиргәп, әле юатып тәмам эштән чыгып бетәм. Аклансаң, Рузалия Кашаповна: «Һәммә кешедә шул хәл бит!» — дип битәрли. Әле җитмәсә: «Өс-башыңны җыйнаклабрак йөрсәң дә ярый»,— дип тә өсти. Анысында ни эше бар инде?! Кыз балаларга үрнәк булырга кирәк, янәсе, алар шундыйларны ярата. Миңа аларның яратулары кирәкме! Дәрес планымны язып өлгертсәм, нәрсә сөйләячәгемне алдан белеп керсәм, бик җиткән инде. Артыгына барыбер рәхмәт әйтмиләр. Алар алдында икейөзлеләнеп, артистланып торыргамы? Бик кирәге бар иде!

Соңгы дәресемне көч-хәл белән генә очлап чыктым. Шушы мәктәп шау-шуын ишетмәс өчен әллә ниләр бирер идем. Кайтыйм, рәхәтләнеп ванна кереп чыгыйм, нервыларымны тынычландырыйм. Ирем дә командировкада, кичке ашны да әзерләп тормам әле.

Ләззәтле уйларым шушы урында кылт итеп өзелде. Коридорда бер төркем укучылар арасында, балкып, тагын шул Тәнзилә басып тора иде! Җитмәсә, минем тугызынчыларым — әле генә чыгырымнан чыгып тиргәгән Маликлар, Әүзахлар, Лилияләр, авызына керердәй булып, аны тыңлыйлар, дәртләнеп-дәртләнеп үзләре дә сүз кыстырып куялар. Айкапчайкап куып таратасым килде бу төркемне. Зәһәрлегем тышыма чыккандыр, ахры. Тугызынчыларым бердән тынып калды. Килеп туктавымны күргәч, Тәнзиләнең дә йөзе сүрелеп киткәндәй булды.

— Менә, физика кичәсе үткәрмәкче булабыз әле,— дип, аклангандай әйтеп куйды.

— Үткәрегез соң,— дидем төксе генә.— Башка дәресләргә зыян сала торган булмагыз түлке!

Үткәрер, билгеле. Әти-әниләрдән кабат рәхмәт ишетер. Рузалия Кашаповна директордан мактау кәгазе дә яздырып алыр. Укытучылар бүлмәсенә кабат очынып килеп керер, юк кына нәрсәне кайта-кайта сөйләр...

Үткәрер, билгеле. Борчу-мәшәкатьләре шул гына булгач. Бөтен нәрсә уңай килеп тора бит аңа...

Тәнзилә физика кичәсен билгеләнгән вакытта нишләптер өлгертә алмады. Аннан алда да мәктәптә өч көн рәттән күренмәде. Беренчедә укучы улы Руслан аша директорга язу җибәргән, ирем авырып китте, дигән.

Хараплар гына булган икән! Ире авырганда да дәрес калдырырга икән! Укытучылар бүлмәсенә кергән саен әле теге, әле бу почмакта шул хакта чышын-пышын сөйләштерделәр дә тындылар. Рузалия Кашаповна гына онытмаган икән, төш авышкач, физрук Рашаттан Тәнзиләнең өенә барып килүен үтенде.

— Коллективтан дип әйт, хәлен яхшылабрак сораш,— ди. Үзе урам исемнәрен, йорт номерларын әйтә.

Шаккатып калдым. Бигрәкләр дә яман кыланалар инде. Ирем түгел, мин үзем авырсам да, хәл белергә килмәсләр иде. Ә моның...

Шунда башыма бер уй килеп төште.

— Китерегез, үзем барам,— дидем дә, Рузалия Кашаповнаның кулындагы төргәккә Рашаттан алда мин килеп тотындым.

Рузалия Кашаповна авырсынып кына ризалашты. Ышанып җитмәде инде, билгеле.

Ышанмасын да! Менә барыйм әле, әйтеп кайтыйм әле эчемдә кайнаганнарның һәммәсен дә. Килеп урнашуына ярты ел да юк, бөтенесен яулап алды. Олысының да, кечесенең дә телендә шуның гына исеме. Иркенләп эшләргә дә юк! Балалар телендә кайчан карама — физика. Без ничек мәхәббәт тәрбиялик ди үз фәнебезгә?

Бөтен нәрсә уңай килеп тора шул аңа.

...Тәнзиләләрне алдан уйлаганча тиз генә табып булмады. Сигез катлы йортлар уртасында калган агач өйле урамда яшп булып чыкты ул. Капка төпләрендә бөкерәя төшкән бер карт утын ваклап йөри иде, кемне эзләвемне сорашкач, урамның теге ягына ымлап күрсәтте:

— Киленме? Ә-әнә судан кайтып килә.

Шулмы бу, түгелме? Чем-кара бөдрә чәчләрен чуар яулыгы астына яшергән, өстендә — тәненә сыланып торган чуар күлмәк. Кара син аны, бизәнмәгәндә дә сөйкемлелеген һич тә җуймый икән тагын үзе.

Тәмам фикерем чуалды. Исәр кеше сыман тик басып торам. Бу халәтемнән Тәнзилә үзе коткарды:

— Ник мәшәкатьләнергә инде! Безгә берни дә кирәкми бит, бар нәрсәбез дә җитә... Наилем генә савыксын менә...

Күтәрелеп карамасам да, сизеп торам: яшенә тыгылды Тәнзилә. Моңа кадәр күз яшен түгел, йөзенең моңсулыгын да күрсәткәне булмагач, әллә ничек уңайсыз булып китте. Хәл-әхвәлен сорашып, күчтәнәчләрен ишек алдында гына биреп кертәсе иде, югыйсә. Аптыраганнан верандага ук ияреп кердем. Тәрәзә кырыенда инвалид коляскасы тора иде, аны күргәч, өстемә салкын су китереп сиптеләрмени! Калганын Тәнзилә өзек-өзек, яшь аралаш әйтеп бетерде:

— Чечня... Монда әткәйләр янында торырга булдык... Чире кабатланып тора шул... Үзебезнекеләр янында ничек тә уңайлырак...

...Укытучылар бүлмәсенә бүген дә бәрелеп-сугылып килеп кердем. Рузалия Кашаповна, гадәтенчә, миңа таба төксе генә карап алды. Зыян юк! Соңыннан иплән аңлатырмын әле, хәзергә вакыт чамалы, дәрескә керәсе бар. Килешли Тәнзиләләр өе аша үтеп, Русланны алып чыгуымны, дәрес башланганчы тугызынчыларга кереп, физика кичәсенә әзерлекләрен тикшерүемне әйтеп вакланып тормыйм мәллә? Кайтышлый аптекага кереп чыгарга да вәгъдә иттем Тәнзиләгә, авыру ирен ташлап чыгып йөри алмас бит инде ул! Миңа нәрсә, өйдә аның кебек кырык эшем кырык якта кырылып ятмый, шәһәр фатирында торам ләбаса!

Үземне әйбер урлап тотылган бала сыман хис итәм. Сорамый алган нәрсәне кире кайтарыр идем дә гафу үтенер идем. Кемнән? Үземнәнме, әллә Тәнзиләдәнме?..

# ХУШ КИЛӘСЕЗ, КЫР КЫЗЛАРЫ!

**Каләм иярәренең җыелышында яшьрәк бер шагыйребез «табигатьтә ата сандугачлар гына сайрый, шунлыктан шигърияттә ир шагыйрьләрнең патшалык итүе бик табигый» дигән сәер уе белән уртаклашкан иде.**

**Чыннан да, ничә гасырлар инде, шигърият тәхетендә — асыл ир-егетләр.**

**Гасырлар белән чагыштырганда, соңгы берничә ел, әлбәттә, мизгел генә. Шулай да, замананың тиз-кинәт үзгәрүләрен искә алсак, мизгелдә дә шигырьнең кая барышын тоярга мөмкин.**

**Язучылар берлеге шигърият остаханәсенең җитәкчесе буларак, мин яшь авторлар белән аралашып, сөенечле дә, көенечле дә хәлне күрәм.**

**Шигырьгә кызлар гына килә диярлек. «Сабантуй» һәм «Ялкын»ның шигырь язучы авторлары — нигездә кызлар. Педагогия университетындагы яшь иҗатчылар арасында бер генә егет тә юк. Казан дәүләт университеты студентларының шигырьләрен тикшердек. Арада Рәис Апуш дигән бердәнбер егет бар иде, әллә инде тәнкыйтьне ошатмады, бүтән күренмәде.**

**Ә кызлар... Күз генә тия күрмәсен. Сандугачтай сайрап, кыр казлары кебек каңгылдашып, тезелеп киләләр. Гөлнур (Хәсәншина), Эльмира Җәлилова, Сәрия Закирова, Илгөлем (Эльмира Әхмәдуллина), Наташа Башурина, Гөлүсә Закирова шигырьләрен тикшерүдә катнашкан шагыйрьләребез Шәүкәт Галиев тә, Рәдиф Гаташ та, Зөлфәт тә, Уфадан килгән яшь шагыйрь Марат Кәбиров та соклануларын яшерә алмадылар.**

**Кыр кызлары килә... Авыл кырларыннан, тугайларыннан.**

**Әлбәттә, шигырьдә гел ямьле яз һәм җылы җәй генә көткән кыр кызларының күбесе поэзиянең кырыс җилләренә түзә алмыйча, өзелеп калачагын да беләм. Әмма иң талантлылары, чыдамлылары, табигатендә шигъриятне саклаганнары калырлар, — китмәскә килерләр!**

**Хуш киләсез, кыр кызлары!**

**Илдар ЮЗИ,**
**Татарстанның халык шагыйре.**



# Илгөлем

## Саумы?

Саумы?.. Саумы син, Кеше?
Сиңа дәшәм, бу шигырьгә
Күз төшерүче!

Саумы син? Тәнең саумы?
«Саумы?» дип сораучың бармы?
Саумы син, Кеше?
Җаның саумы?
Җаның тулы
Игелеккә сусаумы?

...«Саумы?» дигән сүзем бассын
Шул сусавыңны!

* * *

Данлы чакларың булган,
Шанлы чакларың булган.
Илсез калып, җан иңрәгән
Канлы чакларың булган.

Бәхеттә чагың булган,
Тәхеттә чагың булган.
Сатлыкларың агу биргәч,
Ләхеттә чагың булган.

Бәхетлеме син хәзер,
Тәхетлеме син хәзер?
Пыскып янган ялкыныңны
Инде кемнәр тергезер?

Бәхет өмет итәсең,
Тәхет өмет итәсең.
...Бәхет тулы ул хөрлеккә
Халкым, лаек микән син?

Халкым, лаек микән син?!

## Сөю иле

Кояшы — сөю кояшы,
Гөлләре — сөю гөле.
Җилләре дә серләр ташый,
Табигать — сөю иле.

Кошлары да парлы-парлы,
Кондызы, сусары да.
Сөю әлифбасы гүя —
Ак каен тузларында.

Чишмәләре кушыла челтерәп,
Шул сөю көйләренә.
Әйдә, иркәм, без дә керик
Шул сөю илләренә.

Чишмәсеннән авыз итик,
Коеныйк күлләрендә:
Мәңгелеккә калыйк әле
Шул сөю илләрендә!

## Ялкын эзлим язмышыма

Төне кара никтер бүген,
Җирдә якты яз булса да.
Күзләремдә — сары сагыш,
Йөрәк тулы наз булса да.

Йөрәк тулы наз булса да,
Карашларым салкын гына.
Төнге шигъри учагыма
Җитми бары ялкын гына.

Җитми бары ялкын гына...
Кай йөрәктән алыйм аны?—
Чын итәрлек хыялымны,
Яктыртырлык бар дөньяны?
Эретерлек зур бозларны,
Көнләштереп йолдызларны
Балкыр өчен, янар өчен!
Кай йөрәктән алыйм җылы?

...Төне салкын никтер бүген —
Җирдә якты яз булса да.
Ялкын эзлим язмышыма,
Өметем бар — аз булса да...

*Казан дәүләт университетының татар филологиясе бүлеге, 3 курс.*



# Гөлнур

## БИРДЕМЕ БУ СӨЮ ХАКЫН — АЛЛАМ?!

* * *

Кудым сине, дидем: «Кит!»
Син ул чакта күңелемә
Шундый ерак идең бит...

Китеп бардың. Мин калдым.
Китүең белән йөрәккә
Син үтеп керә алдың!

...Хәлләр шул ук. Әйтәм: «Кит!»—
Яннарымнан түгел, хәзер
Җаннарымнан куам тик...

* * *

Ят кочакка тартыласың,
Бүлмәм барыр юлыңны.
Тик анда сине минем күк
Яратучы булырмы?

Ят учакка тартыласың,
Эзлисең җылы, ялкын.
Сиңа минем ялкын түгел,
Ятлар салкыны якын.

* * *

Язлардан соң башым җуеп йөргән идем:
«Тора,— диеп,— дөнья тоташ салкыннардан».
Җылы җәйләр килеп мине үзгәрттеме?
Бирде мәллә кабат сөю хакын Аллам?

Җанда сүнгән учак янә кабынганга
Шулай эссе булды мәллә узган җәйләр?
Җәйләр генә түгел, ике күңел кылын
Өзелмәслек, ныклы итеп сөю бәйләр.

Синле җәйләр генә мине үзгәрткәндер:
Арынды күк дөньям коры салкыннардан.
Җәйләрдән соң башым җуеп йөрим хәзер:
«Тора,— диеп,— яшәү — тоташ ялкыннардан»!

* * *

«Китмә әле, китмә»,— диеп,
Кулларыма кагыласың.
Белгәнгәдер, китү белән
Сине кабат сагынасым;
Сизгәнгәдер, аерылгач,
Күз яшьләрем тамызасым.

Йөрәгемдә ниләр барын
Күзләремнән беләсеңме?
Әллә сагыну-газаплардан
Коткарырга теләп мине:
«Тукта әле, ашыкма...» — дип,
Юлларымны бүләсеңме?!

*Казан дәүләт университетының*
*татар филологиясе бүлеге, I курс.*



## Эльмира Җәлилова

### Көзге яңгыр үтте сибәләп...

Саф хисләрнең гомере бигрәк кыска,
Мәхәббәтнең гомере — күбәләк.
Сөю тулы язлар артта калды,
Көзге яңгыр үтте сибәләп.
Ак каен да сары яфрак коя
Салкын җилдә башын игәләп,
Җәйге айлы төннәр бер төш сыман,
Көзге яңгыр үтте сибәлә.
Сарылган да сагыш җаннарыма,
Бәгыремне кисә телгәләп.
Кышка кереп барган күңелемә
Көзге яңгыр үтте сибәләп...

## Мин бәхетле булалмадым

Минем белән каршыладың тәүге—
Яшьлегеннең сөю тулы гүзәл таңын.
Пышылдадың: куркам югалтудан,
Синсез җирдә мин бәхетле булалмамын.

Ләкин кайчак язмыш ачы була:
Мин әле мең кабат уйланырмын...
Тыңламадым сүзләреңне, мин уйладым:
Бәлки синсез мин бәхетле булалырмын.

Язлар үтте, инде күздә генә
Мин синең пар канатың булалмамын.
Рәнҗешеме синең саф җаныңның:
Мин дә синсез һич бәхетле булалмадым.

* * *

Салкын рәсемеңнән җылы караш
Моңсу гына миңа төбәлгән.
Моңсуланма: сине урлармын мин
Ялгыз үтәр шыксыз төннәрдән.
Гөнаһлардан саклар өчен сине,
Фәрештәләр булып иңәрмен.
Ал таңнарда шәфәкъ нуры булып,
Күзләреңнән синең үбәрмен,
Актык сулышыңда йөрәгеңнең
Соң тибеше булып тибәрмен.

*Казан дәүләт университетының*
*журналистика бүлеге, I курс.*



**Сәрия Закирова**

## Сөю сахрасында

Сагышымның сахрасында йөрим,
Сусавымны басмый хатларың.
Сине эзләп эзләреңнән атлыйм,
Очратмасам иде ятларны.

Нигә дәшмисең соң, әй Мәҗнүнем,
Җиләс җилдәй рәхәт һәр сүзең.
Мең газаплы сөю чүлен гизәм,
Үткәннәрдән качам берүзем.
Йә әйт инде, кемнәр юл күрсәтер,
Калырмынмы Сагыш Илендә?
Ялкынына түзә алырмынмы
Әверелсәм Сөю Гөленә?

### Мин — табигать баласы

Мин бит табигать баласы,
Ул миңа сулыш өргән,
Тик нигәдер күңелемә
Күзләр сагышы кергән.
Әнкәем-табигать мине
Таң чыкларында юган.
Тел ачылгач әйткәнмендер:
Мин — гүзәллектә туган.
Мин бит табигать шәкерте,
Ул кулга каләм биргән:
«Күңелеңдәге хисләрен
Җилгә чәчмәсен», дигән.

*Казан дәүләт университетының*
*журналистика бүлеге, 3 курс*



## Наташа Башурина

### Егетне бүлешәләр

Күршебезгә армиядән
Кайтты бер чибәр егет.
Ә гәүдәсе, күрсәгез сез,
Шварценеггер кебек.
Исеме дә бигрәк матур:
Яңгырап тора — Алмас.
Үземнән беләм, бер кыз да
Аны ошатмый калмас.

Кызлар хәзер чыш-пыш килеп
Егетне бүлешәләр.
«Күрерсез, тиздән минеке
Булачак!» — диешәләр.
Читтән генә көлеп торам:
Үзем дә хәйлә корам.
Алмас минеке икәнне
Әлегә әйтми торам.

## Моңлы азан

Иртән азан тавышыннан
Күңелгә шатлык тула:
Моңлы азан — ил хәтереннән
Кайгы-хәсрәтне юа.

Азаным, моңлы азаным,
Җан өр татар өенә:
Тибрәлсен яңа бишекләр
Моңлы азан көенә.

*Казан дәүләт университетының*
*журналистика бүлеге, 1 курс*



## Гөлүсә Закирова

* * *

Серле төн хан бүген җиһанда.
Күзе — Ай, сихерле елмая.
Йолдызлар серләшә үзара:
«Анда кыз ялгызы моңая?»

Тал-тирәк баш игән елгага.
Сак кына җиләс җил кузгала.
Сагышы чәчемә урала:
«Нигә син бик моңсу, кыз бала?»

Һай әкрен, бик әкрен көн уза,
Сагынып көтәмен кичләрне.
Төн — сагыш йомгагы, җил сүтә
Болай да тузгыган хисләрне...

## Каеным

Ак каеным, синең янга килдем,
Ак урманга язгы ак таңда.
Изге хисләр генә йөрәгемдә,
Бары сафлык, аклык бу җанда.

Ак каеным сагыну җырын җырлый,
Дулкын-дулкын искән җилләрдә:
Сабый бала кебек уйнап-көлеп
Яфраклары җилдә тирбәлә.

Җырлыйм әле кушылып ак каенга,
Басыйм әле йөрәк ярасын.
Ак каенлы агурманда йөрим:
Мин — бу Җирнең гашыйк баласы.

* * *

Ник сынды соң пар канатым?
Йолдыздан көттем җавап.
— Соңгы сулышың өзгәнче
Бирешмә!
        Ярат... Ярат...

Җилләргә чыгып ялвардым,
Сызлангач ялгыз канат.
Чәчәкләрдә чык нурлары:
        — Ярат! — ди, миңа карап...

Тудыр минем пар канатым! —
Рухымнан көттем җавап.
— Сүндермә сөю учагың,
Һаман ярат! — ди.
        — Ярат...

*Казан дәүләт педагогия университетының*
*татар филологиясе бүлеге. 4 курс*



ПУБЛИЦИСТИКА



**Әгъдәс Борһанов,**

Россия Дәүләт гуманитар университеты профессоры, тарих фәннәре докторы

# ТУГАН ЯКНЫҢ ҖИЛЕ ТАТЛЫ

**1996** елның җәендә мин туган якларымда булдым: Татарстан Җөмһүриятенең Лениногорск районында урнашкан «Бәкер» курортында ял иттем-дәваландым. Бу тирәләрдә мин бала чагымнан яхшы белгән авыллар урнашкан. Күпмилләтле (күпчелеге — татарлар) Шөгер — ул кайчандыр район үзәге иде; татар авыллары Иске Иштирәк, Мөэмин-Каратай (әниемнең туган авылы), Сарабиккол (монысы әтиемнең туган авылы, мин дә шунда туганмын); керәшен авылы Федотовка, урыс авыллары Иске Куак, Кузьминовка...

Искиткеч гүзәл як бу! Борынгы бабаларыбыз утырып, тереклек итәр урыннарны сайлый белгәннәр шул. Матур болын-тугайлары белән һушыңны алырлык бормалы-бормалы Шушма һәм Каратай елгалары, дисеңме; төрле җиләк-җимешләргә, киек җәнлекләргә бай урманлы, артык биек тә, артык тәбәнәк тә булмаган таулар, дисеңме! Швейцариядә булганым юк, әгәр дә ул табигате белән безнең якларга тиңләшә икән — чынлап та матур илдер.

Атаклы Сочи Мацесталарына торырлык «Бәкер» курорты хакында бераз мәгълүмат биреп үтү кирәктер.

Татарстан җиренең йөзек кашы булырлык «Бәкер» курорты рәсми рәвештә 1933 елны оештырыла. Чынлыкта исә бу тирәләр хан заманнарыннан бирле шифалы сазлыклары белән дан тоткан һәм, билгеле инде, төрле риваятьләр туута да сәбәпче булган. Шундый риваятьтә болай сөйләнә: бер авыл агаеның аксак аты югалган, имеш. Аны эзләп-эзләп тә таба алмыйлар. Әмма, атна үткәндерме, аймы, — көннәрнең бер көнендә әлеге атны сазлыктан табып алалар. Кешеләрнең исләре китә: ат аксамый, аягындагы кутырлап беткән авыру буыннары төзәлгән, йоннары елык-ялык итеп тора, күзләрендә дәртле очкыннар уйный икән.

Мондыйрак риваять тә бар: бер ханның картаеп эштән чыккан атлары булган. Ул аларны, утардан куып, иреккә җибәрергә боера — үз көннәрен үзләре күрсеннәр, янәсе. Хуш, куып чыгаралар атларны. Берничә атнадан соң ханның хезмәтчеләре гаҗәп хәбәр китерәләр: әлеге атлар көтүе сазлык тирәсендә утлап йөри, үзләре яшәргәннәр, сау-тазалар, дәртләре ташып тора, имеш...

Авыл аксакалларының сөйләүләреннән билгеле: бирегәге сазлык тирәләренә киек җәнлекләр күпләп җыела торган булган. Поши-болан, бүре-кабан, төлке-куян ишеләр, бер-берсеннән курыкмыйча, якын-тирәдә кешеләр күренгәндә, аларга да игътибар итмәстән, үлән чемченеп-утлап, сазлык суын эчеп, сазындаләмендә аунап-буялып йөриләр икән. Кыскасы, бу сазлык һәр җан иясен үзенә тартып торган. Шифалы сазлык тирәләренә төрле җирләрдән күченеп килүчеләр дә авыл-авыл булып утыра башлаганнар, шунда тамырланып тереклек иткәннәр. Халык сөйләкләренә караганда, Бәкер авылына нигезне дә күченеп килгән Бәкер исемле бер татар агае салган. Якындагы Иске Иштирәк, Мөэмин-Каратай авылларын исә аның уллары Иштирәк белән Каратай нигезләгәннәр. Аннары инде

башка авыллар ышанып киткән: татары-урысы, керәшене-мукшысы, дигәндәй — барысы да шушы тирәләргә сыенырга тырышкан.

«Бәкер» курортының даны Татарстаннан ерак төбәкләрдә билгеле. Аның шифалы ләмнәре-сулары белән дәваланучылар бихисап. Чир-авыруларның ниндиләре белән генә килмиләр бирегә!

Тагын шунысын да әйтергә кирәк: «Бәкер» курорты Татарстан нефте чыга башлаган төбәккә урнашкан. Нефть вышкалары күренеп үк тора. Әмма, шулай булуга карамастан, елга-күлләр чиста-саф, урманнар күкрәп үсеп утыра, болынкырлар мул уңыш бирә. Рәхмәт нефтьчеләргә! Алар бу төбәкнең табигатенә зыян-зарәт салмаска тырышканнар. Әле житмәсә, күптән түгел генә, нефть ятмаларының тирәнрәк катламына үтеп барганда атаклы «Нафтуся» суына юлыкканнар. Аны озакламый торбалар аша курортка бирә башлаячаклар икән. Шулай итеп, Сочи-Мацеста сыйфатларына Карпаттагы Трускавец курорты сыйфатлары да өстәләчәк. Бу бит безнең Татарстан жирендә! Рәсәйнең үзәгендә! Һәм әлегә курортка юллама-путевка бәяләре дә бик «тешләми»...

«Бәкер» курортында 430 дәваланучыга 18 табип һәм 56 шәфкать туташы, санитарлар һ. б. хезмәт күрсәтә. Аларның һәрберсе хакында, исемнәрен атап, иң жылы рәхмәт сүзләре кирәк тә бит... Әмма бу язманың максаты ул түгел. Шунлыктан, курортның баш табибы Фаяз Ибраһимов турында гына берничә сүз. Ул, бирегә килгәнче, Бәкердән 10 чакрымдагы Шөгер хастаханәсендә баш табип булып эшләгән. Хастаханәсен районда иң яхшылар рәтенә күтәреп кенә калмаган, хастаханә янәшәсенә мәчет төзетүне оештырып та (иганәчеләрен дә тапкан, кирәксә, прораб вазифасын да үтәгән) дан казанган. Ул мәчетне халык хәзер «Фаяз мәчете» дип йөртә.

Сүзебезне якын-тирәдәге авылларны телгә алудан башлаган идек: Шөгер, Иске Иштирәк, Сарабиккол һ. б. Бу авылларда мин кат-кат булдым.

Әле КПССның Татарстан өлкә комитетында фән һәм уку йортлары бүлеге мөдире булып эшләгән чагымда ук (1959—1960 е.е.), татар һәм урыс авылларындагы тормыш-көнкүреш шартларын чагыштырып, аптырашта кала идем, уй-сорауларыма җавап таба алмый интегә идем. Күрәсең, күпчелек совет кешеләре шикелле, минем дә уй-фикерләрем бер яклырак булгандыр. Без бит,— татармы, урысмы, башка милләт халкымы,— ни өчен ярлы-фәкыйрь яшибез, ни өчен шулай да бер халык хәллерәк, икенчесе начаррак яши, дип уйланмый идек. Менә-менә, тормыш рәтләнер, барыбыз да рәхәт һәм бәхетле яши башларбыз, дип өметләнә идек. Бу ышаныч-өметне халыкның тормыш-көнкүреше чынлап та, бик акрынлык белән булса да, елдан-ел яхшыра баруы белән дә аңлатырга кирәк. Әлбәттә, һәртөрле ялагайларның бүләк-ришвәтләре өстенә, махсус кибетләр-буфетлар, хастаханә-курортлар, квартирлар-дачаларның рәхәтен күреп, балда-майда йөзүче партсовноменклатура (сүзе нинди бит әле, ә!) вәкилләренең тормышы ул вакытта ук коммунизмдагыча иде. Рәсми телдә «революция гегемоны — пролетариат» дип купшы атап йөртелгән ярлы халык, гади халык, махсус кибет-буфетлардан төргәк-төргәк сый-ниггъмәт күтәреп чыгып, кара «Волга» яки «ЗИМ» машиналарына утырып китүчеләр артыннан: «Әнә, безнең хезмәтчеләр — «халык хезмәтчеләре» китеп бара!» — дип, ачы каһкаһә белән көлеп кала иде. Ул вакытта мин дә шул «халык хезмәтчеләре»нең берсе идем. Ачның хәлен тук белмәс, дигәндәй, халыкның тормыш шартлары турында артык тирәнгә кереп уйлый алмаганмын, күрәсең.

Бервакыт шулай КПССның Татарстан өлкә комитетына КПСС Үзәк Комитетының РСФСР буенча Бюросыннан (шундый хикмәтле оешмалар да бар иде ул заманнарда) җаваплы бер иптәш килеп төште. Миңа аны республикабызның район-авылларында озатып йөрергә туры килде. Төрле авыллар аша үтәбез — бар урысы, бар татары. Әлеге җаваплы иптәш авылларның төзеклеге-матурлыгы, фәкыйрьлеге-байлыгы ягыннан бер-берсеннән бик нык аерылып торуларына игътибар итте. Дөрестән дә, аралары 3—5, күп булса 10 чакрым гына булган авыллар инде югыйсә... Төзек-матур йортлары,— арада яңа күтәрелеп килә торганнары да бар,— таза такта коймалы ихаталы-куралары, мунчалары, күкрәп утырган бакчалары, умарта оялары, урам яктагы яшел тал-тирәкләре, еш кына чирәмле, чиста себерелгән урамнары, капка төпләрендә утыручы ак яулыклыалъяпкычлы чиста-пөхтә әбиләре булса — бу, һичшиксез, татар авылы булыр. Аларда тәрәзәләре кадакланган бер генә йортны да күрмәссең. Ә инде күп кенә йортларының тәрәзәләренә аркылы-торкылы «тәре» ясап такта сугылган, еш кына ихаталы-курасы киртәләп тә алынмаган, урамнарында бер агач заты булмаган, бәрәңге сабаклары арасында анда-санда берәр баш көнбагыш кына чайкалып утырган, урамда сазда аунап буялып беткән аклы-каралы ябык дуңгызлары гына мыркылдашып йөргән авыл булса — анысы инде урыс авылы...

Мәскәүдән килгән җаваплы иптәш, үртәлеп: «Нигә болай? Эш нәрсәдә? Урысларны кысмыйсыздыр бит?» — дип сорады. Әйтерсең, урыс авыллары бер Татарстанда гына шундыйлар. Бөтен Рәсәйдә шулай бит ул. Мин: «Юк, кысмыйбыз...» — диюдән ары уза алмадым. Бу аерманың сәбәпләрен ачып бирә алмаудан гаҗиз идем мин.

Бу вакыйга озак еллар шулай күңелемдә уелып кала килде. Җавапны мин бары тик үзгәртеп кору җилләре исә башлап, үзем Россиядәге фәкыйрь тормышның гомуми сәбәпләрен тирәнтен тикшереп өйрәнә-өйрәнә генә таптым шикелле.

«Бәкер» курортында дәваланып, ял итеп кенә ятмадым. Телгә алынган авылларда булып, алардагы хәл-әхвәлләрне үз күзләрем белән күреп кайтырга да ниятләдем.

Алдан ук әйтеп узыйм: тәрәзәләре кадакланган ташландык йортларны бер авылда да очратмадым — ни урысныкында, ни татарныкында. Хәер, татар авылларында андый йортлар электән дә юк иде. Урыс авылларында хәзер кем дә кем китеп бара икән, аның йортын-ихатасын тиз генә сатып алучы бирәр шәһәр кешесе табыла яисә авылдан китүче кеше үзе йорт-җирен һәм бакчасын дача сыйфатында теркәтеп куя. Үзләренең туган төбәкләренә читтән — аерым алганда, «кайнар нокталардан» яки якын чит илләрдән, ягъни СССР таркалгач барлыкка килгән бәйсез дәүләтләрдән (бигрәк тә Казакъстан, Урта Азия якларыннан) кайтып төпләнүчеләр дә бар икән.

Әмма башка чагыштыруларга килгәндә...

Менә аралары бер чакрым булыр-булмас ике авыл: Кузьминовка белән Федотовка. Ә аермалары — җир белән күк арасы. Кузьминовка — урыс авылы — «мин фәкыйрь» дип әллә кайдан кычкырып тора: урамнары чокыр-чакырлы, җыештырылмаган-себерелмәгән, йорт тирәләре янбакчасыз-палисадниксыз, бер генә ихатада да бер генә җиләк-җимеш агачы да күренми, кайбер җилкапкалар баудыр-тимерчыбыктыр ише нәрсәләр белән генә әмәлләп куелган... Ә Федотовка исә — керәшен авылы — байлыгы-туклыгы, кем әйтмешли, йөзенә чыккан авыл: шыңгырдап торган йорт-куралар, күбесендә шомырттыр-миләштер, аллы-гөлле гөлчәчәкләр үсеп утырган ян бакчалар, ягъни йорт алды бакчалары, түр бакчаларында алмагачы-чиясе, карлыганы-курасы, дисеңме — бары да бар. Югыйсә бит ике авыл да бер дин кешеләре: христианнар. Бәкер, Иске Иштирәк, Сарабиккол, Мөэмин-Каратай авыллары да үзләренең бай, мул тормышлары белән күзгә бәрелеп тора.

Урыс авылларының гомуми күренеше, тулаем алганда, элекке еллардагыдан әллә ни үзгәрмәгән диярлек: яңа йортлар яки төзелә торганнары бик сирәк очрый, бер генә яңа чиркәү дә күрмәдем. Кайбер мәгълүматларга караганда, урыс авылларының күпчелегенә хас күренеш бу. Бер сүз белән әйткәндә, барысы да Кузьминовка хәлендә. «Бәкер» курортында ашханәдә өстәл күршем Люба исемле марҗа, мәсәлән, Сарманнан килгән. Ул сөйли: районыбызда бик зур урыс авылы Языково бар иде, ди, хәзер анда, калса, берярым йорт-җир калгандыр, ди. Икенче күршем Спас районыннан килгән Наилә ханым исә болай сөйли: Спас районындагы барлык авылларның чиреге генә татар авыллары. Әмма ул авыллар барысы да бай-мул тормышта яшиләр. Һәр хуҗалыкта 2—3 сыер, 10 лап баш сарык, кош-кортның саны-исәбе юк. Авылларның һәрберсе мәчетле, күбесендә — яңа мәчетләр, бер-бер артлы яңа йортлар калка тора. Ә урыс авылларында төзелеш-фәләннәр күренми, ызбалары иске, ярымҗимерек хәлдә, 20 авылга нибары 2 иске чиркәүләре бар, авыл халкы ярлы-фәкыйрь...

Менә шушы хәлләрдән соң мин уйлана калдым: әллә соң, дим, бу аерманың беренче төп сәбәбе дингә бәйләнгәнме икән? Әлбәттә, урыс халкының шулай начар яшәвендә христиан диненең дә өлешчә гаебе бар. Чөнки урыс дин әһелләре һәрвакытта да урыс дәүләтенең, — яхшымы ул, яманмы — бар эшчәнлеген берсүзсез хуплап килде. Һәм әнә шул «ләббәйкә»лек сәясәте соңыннан диннәрнең үзләренә дә китереп сукты, дин тулысынча дәүләткә буйсындырылды. Әнә Көнбатыш капитализмы үзенең гөрләп үсеше белән протестантлыкка бурычлы.

Шулаен шулай... Әмма бит, әйткәнемчә, керәшен татарлары белән урысларның диннәре бер. Ә менә авыллары әллә кайдан аерылып тора. Димәк, бу очракта сәбәп бер диндә генә дә түгел. Нәрсәдә соң?

Ярлы-фәкыйрь урыс авылларының юкка чыга баруын, авыл халкының читкә китәргә омтылышын мин урысларның чит җирләргә сугыш белән, яулар белән килгән яки күчерелеп китерелгән килмешәкләр булуына, аларның шунлыктан тамырланып китә алмавына бәйләп карарга да тырыштым. Басып алынган чит төбәкләрне үзләштереп, ныклап тамыр җибәрергә дүрт-биш гасыр вакыт бик җиткән кебек югыйсә. Ә менә юк икән шул! Хикмәт анда гына түгел икән. Урыс

бит төп үз жирендә дә — әйтик, чишмә башы, чыгышы булган төбәкләрдә (үзләренчә әйтсәк, Нечерноземье була инде) дә шул ук хәлдә, шул ук фәкыйрьлек-бөлгенлектә яши.

Димәк, тамырлана-төпләнә алмауның әле тагын башка сәбәпләре дә бар. Әлбәттә, җирләре басып алынып, үзләре буйсындырылган халыклар гомер-гомергә,— урысмы ул, башка ят кешеме,— аны кан дошманы итеп күргән, аңа нәфрәт белән караган, җае килгән саен кысырыклап чыгарырга тырышкан. Бүгенге көндә бу күренеш Чечня, Абхазия, Таулы Карабах, Көньяк Осетия, Таҗикстан кебек төбәкләрдә кан коюлар, үтереш-суешлар белән дәвам итсә, башка төбәкләрдә астыртынрак, сиздермичәрәк эшләнә: мисалы — Балтыйк буе илләре.

Урыс халкының бакый гомердән тамырсыз булуының төп сәбәбе, минемчә, аның бер вакытта да җиргә хуҗа була белмәвендә. Шуңа күрә дә урыслар тузганак шикелле «җинелләр», аларга «оҗмах кебек җирләрне» эзләп күченеп китү берни тормый. «Бу җир әйбәт түгел икән, яңасын эзләрбез. Башкалар җире булса соң, кысыла төшәрләр, теләмәсәләр — куарбыз, юк итәрбез! Без күбәү, чиру кебек...» — менә урысларның буыннан-буынга алга сөргән сәясәте.

Урыс милләтенең, урыс дәүләтенең бар булган тарихы яулап алу сугышлары белән бәйле. Сугыш — урыс халкының төп һөнәренә әверелгән шөгыль. Соңгы бер-ике гасырда гына да, кайбер исәпләүләр буенча, Россия 200 ләп халык-милләтне буйсындырган, җирләрен басып алган. Танылган урыс галиме социолог Питрим Сорокин, әнә шул исәпләүләргә нигезләнеп, мондый нәтиҗә ясый: урыс милләте үзенең тарихында һәрвакыт милитаристик милләт, ягъни бөтен дәүләт системасы басып алу сугышы максатларына яраклаштырылып корылган милләт булган, шунлыктан бертуктаусыз диярлек сугышып торган. Ул сугышларда милләтнең каймагы саналырлык, биологик таза, гайрәтле-җегәрле, акыл һәм әхлакый яктан иң сәләтле вәкилләре һәлак була килгән. Әнә шундый «тискәре селекция» нәтиҗәсендә халыкның сыйфаты түбәнәя-начарая барган, фән теле белән әйтсәк, генофонд саеккан. Бу процесс совет чорында тагын да тирәнәя. 1917—1959 еллар эчендә — нибарысы 42 елда! — СССРда 110 миллион 700 мең кеше һәлак ителә. Аларның 44 миллионы сугышларда, ә 66 миллион 700 мене Сталин лагерьларында, тыныч тормыш шартларында кырыла. Һәм, әлбәттә, иң күп кырылганы урыс халкы була. Бүген, инде берничә дистә еллар буена торгынлык һәм үзгәртеп кору сазлыгында бәргәләнеп ятабыз икән, нинди җәмгыять төзергә кирәклеген аңламыйбыз, берниндн төпле-нигезле уй-планнарыбыз юк икән — димәк, без интеллектуаль һәм әхлакый яктан сүнеп-бетеп баруыбызның иң югары ноктасына килеп җиткәнбез дигән сүз.

Ачы хакыйкать шуннан гыйбарәт.

Әмма татарлар да күптәннән инде үз туган җирләрендә тулы хокуклы хуҗа түгелләр бит. Шулай да, Татарстанда яшәүче урыс һәм башка милләт халыклары белән чагыштырганда, хосусый милекчелек хисе аларда тирәнрәк үсеш алган. Татар җиренә ябышып ята, тырышып эшли. Ни өчен шулай? «Ата-бабаларыбыздан калган төп үз җиребез, үз ватаныбыз бу» дигән уй-тойгы, күрәсең, бик тирәндә, күңел төбендә үк ятадыр. Татарның тамыры ыругдашларыбыз-кавемдәшләребезнең бик борыннан шушы туган җиребезгә җибәргән ерак тамырларына барып тоташадыр. Шуңа күрә дә татарлардагы милекчелек хисе, җир хуҗасы булу тойгысы — мәңге онытылмаслык, гомер бакыйлык хис ул.

Баскынчылар-килмешәкләрнең ата-баба тамырлары, әлбәттә, бу җирләрдә юк, була да алмый. Алайса, ул тамырлар үз ватаннарында — Русь иле-дәүләте башланган төбәкләрдә калгандыр, дисезме? Юк шул, һәрвакыт яулап алу сугышлары алып барган Русь дәүләте үз халкына туган җирендә төпләнеп-тамырланып яшәргә мөмкинлек бирмәгән, ул аны дуңгәләк җил-үләнгә әйләндергән — бер җирдән икенче җиргә куып-күчереп йөрткән. Шуңа күрә дә Җир шарында урыс булмаган бер генә төбәкне дә таба алмассың. Шуның өчен дә, күз дә йоммыйча, Борис Ельцинның бер имзасы белән, бер селтәнүдә СССР дигән бөек дәүләтнең биштән бер өлешендә яшәүче 25—30 миллион милләттәшләрен — урысларны үз дәүләтеннән читтә кимлек-хурлыкта, икенче сорт халык булып яшәргә дучар иттеләр. Хәзер инде урыс качакларына ни тегендә, ни монда урын юк... Ә аннан алдагы дистәләрчә еллар эчендә, гомерлек хәерчелектән, түрәләрнең эзәрлекләү-кысуыннан гарык булып чит-ят илләргә китеп барган мөһаҗирләр-эмигрантлар күпме?! Мал-мөлкәте, милке булмаган кеше — ул шул ук бомж, ягъни торыр куышы калмаган, каңгырап йөрергә мәҗбүр сукбай.

Әнә шул тамырсызлык урыс кешесенең барлык төп рухи сыйфатларының нигезе булып торган, тора һәм аның милли үзенчәлекләрен билгели. Мин биредә

бигрәк тә аның тискәре сыйфатларын күз алдында тотам. Укучым мине моның өчен битәрләмәсен, мин бит бу очракта урыс халкының мескен хәленә сәбәпләр эзлим, ул сәбәпләр исә, әлбәттә, тискәре сыйфатларда. Билгеле, урысларның уңай сыйфатлары да аз түгел, әмма аның бүгенге тормыш-көнкүрешен ул уңай сыйфатлар билгеләми. Мин урыс кешесенә дөньяга күзен ачып карарга ярдәм итмәкче булам. Бер генә максаттан — урысларның хәерчелеген һәм хокуксызлыгын идеологик ялган белән каплау максатыннан чыгып, Россиянең һәм урыс халкының бөеклеге хакында лаф оручы хөкүмәт җитәкчеләренең татлы сүзләренә алданып калмыйча, күзен каплап торган ялган пәрдәсен ертып ташлап, үз тормышына гадел-риясыз бер караш сала алса, аяусыз чынбарлыкны урыс кешесе үзе дә аңлар иде, бәлки. Виктор исемле бер урыс «Азатлык» («Свобода») радиосына җибәргән хатында ватандашларына мөрәҗәгать итеп болай яза: «Россияннар, көзгегә карагыз да үзегездән сорагыз әле: без, чынлап та, коммуняк юлбашчылар хәйләләп «олылаганча», шулай бик бөек халыкмы икән соң? Коммуняклар 75 ел буена алып барган сайланыш-селекция нәтиҗәсендә без юньсез алдакчылар һәм тәлинкә тотып яраклашучылар өеренә әйләнеп беттек бит инде. Әйдәгез, үзебезне алдамыйк. Шайтаным, нинди бөек милләт, ди, без?! Акыллы халык ничәмә-ничә еллар буена төрмә һәм лагерьларда үзен юк итүләргә, колхоз басуларында батраклыкта бил бөгүләргә, бер кирәкмәс төзелешләрдә имгәнүватылуларга юл куяр идеме әллә?» Ачы хакыйкать...

Империячел бөеклек чире урыс халкының аңына да, канына да нык сеңгән. Бер яктан, ул үз вакытында Русьне буйсындырырга омтылган чит ил баскынчыларына каршы гадел сугышларда үссә, икенче яктан, күбесенчә исәпсез-сансыз яулап алу сугышларында тамырланган, үскән. Ул сугышлар вакытында, тарихчы В. О. Ключевский сүзләре белән әйткәндә, «дәүләт кан эчеп күбенгән, ә халык хәлсезләнгән, бетерешкән». Шул рәвешле, «бөек империя» чикләрен үзләре рәхәт чигү өчен киңәйткәннән-киңәйтә баручы түрәләр һәрвакыт отышта булсалар, кара халыкка бу «бөеклек» әйтеп бетергесез хәерчелек-фәкыйрьлек, җан өшеткеч үлем хәбәрләре, аяксыз-кулсыз, чукрак-сукыр гарип-горабалар, ятим калган гаиләләр, мәңге бетмәс өметсезлек кенә алып килгән.

Безнең күз алдында Чечняга каршы хурлыклы сугыш та шул ук «бердәм һәм бүленмәс бөек Россия» шигаре белән алып барыла. Юкса бүгенге Россиянең бөтен «бөеклеге» үзе кайчандыр яулап алган җирләр хисабына ике кыйтгага — Европа белән Азиягә җәелеп утыруына гына кайтып кала. Урысның акыллы мәкале бар: «Велика Федора, да дура». Шулай, ыруына күрә йоласы, дигәндәй, безнең татар: «Буйга үскән, акылы үсмәгән»,— дияр иде. «Бөек дәүләтебез» дип, сыктаучы-сыкранучы, ах-вах килеп: «Нинди Россияне югалттык бит?!» — дип такмаклаучы урыс шовинистлары бер нәрсәне оныталар — икътисад өлкәсендә Россиянең «бөеклеге» һәрвакыт бюрократ түрәләрнең зәгыйфь акыллары өреп кабарткан сабын куыгы шикелле генә иде. Берләшкән Милләтләр Оешмасының «Үсеш программасы» төркемендәге белгечләрнең әйтүләренә караганда, теге яки бу илнең үсеш-казанышлары хәзер аның индустриаль, хәрби яки финанс көчкуәтенә генә карап билгеләнми. Санап кителгән сыйфатлардан Россия бары тик хәрби көч-куәте белән генә мактана ала иде. Инде анысы да юкка чыкты: әфган һәм Чечня сугышлары шуны күрсәтте. Хәзер илләрнең үсеш-казаныш дәрәҗәләре «кешелек үсеше индексы»ның төп өч күрсәткеченнән чыгып билгеләнә. Болар — уртача гомер озынлыгы, реаль эш хакы күләме, халыкның белем дәрәҗәсе. Әлеге индекс буенча Россия 174 ил арасында 57 нче урынны алып тора. Ул, Германия, Англия, Франция, Италия, Дания, Швеция кебек тәрәккыятьле илләрдән тыш, Кипр, Барбадос, Чили, Латвия, Фиджи кебек илләрдән дә артка калган ил булып санала. Менә шундый «бөек ил» ул бүгенге Россия...

Урыс кешесенең, үз ватанында үз җиренә хуҗа була алмыйча, мал-мөлкәтсез дуңгызлаклегенең ачы нәтиҗәләре әнә шундый. Ил башындагы түрәләр исә, ил кан түккәндә дә тук кикереп, һәрвакыт «бөек җиңүче» кыяфәтендә утыра бирәләр.

Үз тормышының гасырлар буе шулай дәвам итүе урыс халкының аңындакүңелендә котылгысыз өметсезлек хисе дә тудырган. Иманы белән чикылдап торган урыс әдибе Вадим Кожинов, 1996 елның июлендә булып үткән Президент сайлауларына йомгак ясап, болай ди:

«Урыс булмаган сайлаучылар (татарлар, чувашлар, марилар) үзләре белән бер үк төбәкләрдә яшәүче урысларга караганда киләчәкләре турында төптәнрәк уйлап тавыш бирделәр, урыслар исә, киләчәккә исәп тоту түгел, иртәгесе көн турында уйларга да иренәләр бит». Бу уңайдан урыс шагыйре Федор Тютчевның ачынып язган бер шигыре бик гыйбрәтле:

Уйланма да, кайгырма да!
Тиле эзләр тибәр тартәгә.
Көн ярасын йокы юар —
Ни булса да булыр иртәгә.
Кайгы, шатлык, шөбһәләрең
Үтәр китәр — барсына төкер!
Хыял-теләк нигә кирәк?
Көн үтте бит — Аллага шөкер!

*(М. Шабаев тәрҗемәсе.)*

Мал-мөлкәте, милке булмау урыс халкының күпчелегенең ихтиһат итү мөмкинлекләрен йомшарткан-зәгыйфьләндергән, кагыйдә буларак, «бай абзыйга» бил бөгеп хезмәт итүе сәбәпле, аңарда хезмәткә кимсетеп карау, аны санга сукмау хисләре тәрбияләгән. «Эш — бүре түгел, урманга качмас», — дигән мәкаль дә шуннан килеп туган. Эшкә-хезмәткә шулай төкереп карау, табигый рәвештә, Россиядәге бихисап күп төрле бәйрәмнәрдә айнымаслык дәрәҗәдә эчкечелеккә китергән. Мәсәлән, егерменче гасыр башында андый бәйрәмнәр 267 эш көненә 98 туры килгән, ә кайбер губерналарда хәтта 120—140 тан да ашып киткән. Шул чорда Англиядә 278 эш көненә — 87 бәйрәм көн, Италиядә 298 эш көненә — 67 бәйрәм көн, Франциядә 302 эш көненә 63 бәйрәм көн булган. Шулай итеп, Европа халыклары арасында урыслар бәйрәмнәр саны буенча беренче урында, эш көннәре буенча соңгы урында торганнар. Христиан дине юк кына дини бәйрәмнәрдә дә эшләүне зур гөнаһка саный. Аның карауы, эчә алган хәтле эчәргә рөхсәт ителә. Бу начар гадәт бик борынгыдан килә, күрәсең. 1899 елның 4 июль санында «С.-Петербургские ведомости» газеты, Орел өязендә җирле кулаклар крестьяннарның мул печәнле болыннарын аракыга сатып алалар, дип хәбәр итә. Иң зур дини бәйрәмнәрдән саналган Троица бәйрәмендә нәкъ менә Троицкое авылы крестьяннары күрше баена бөтен болыннарын шулай сатып җибәрә. Барлык аракы шунда ук эчеп тә бетерелә. Ни печән, ни акча...Эчкечелек аркасында авылы-авылы белән утырып янулар, исерекбаштан сугышып үтерелгән-имгәтелгәннәр, эчеп акылдан язганнар, тол хатыннар, ятим-үксез балалар, ишек-тәрәзәләре ватылып-кырылып беткән ярым җимерек йортлар... Кыскасы: «Пить так пить, бить так бить!» — ягъни «эчәргә тек эчәргә, печәргә тек печәргә»...

Атаклы урыс язучысы Федор Достоевский, урыс кешесе артык киң-иркен, аны бераз тарайтырга кирәк иде, дип уфтанган. Чынлап та, шулай бит: урыс кешесе күз яшьләре түгеп кызганучан, берәр мескенгә соңгы күлмәген салып бирердәй юмарт, шул ук вакытта бер сынык икмәк тә бирмәскә мөмкин; җаны-тәне белән община яклы, җәмәгать өчен җанын фида кылырга әзер, шул ук вакытта, йөзлек акчадан тәмәке төреп, мәктәп файдасына бер тиенен дә кызганыр (В. Шишковның «Хәсрәт дәрьясы» романыннан бер күренеш); икенче бер зыялы В. Богданов язганча, «көндез таулар актарып, кичен бар тапканын эчеп бетерергә һәм, житмәсә әле, бурычка батарга бары тик урыс кына булдыра ала»; урыс искиткеч зур кыенлыклар, түбәнсетү-кимсетүләр, мәсхәрә-мыскыллауларны күтәрер; ул гаять түзем, әмма, түземе төкәнсә, уңын-сулын аерып тормас, гаеплесен дә, гаепсезен дә кырып салыр.

Кайбер урыс зыялылары, урыс кешесенә тагын бер сыйфат — артистлык хас, диләр. Холык-табигатенең тотрыксызлыгын, кәефе еш кына алмашынып торуын шуның белән аңлаталар. Бу тотрыксызлык һәрвакыт яңаны эзләү вәсвәсәсенә китерә. Урысның бу милли сыйфаты да әлеге дә баягы тамырсыз дүңгәләк булып гомер итүенә барып тоташа. Социалистик идеяләрнең урыслар аңына бик тиз үтеп керүе дә шул сәбәптәндер, мөгаен. Бигрәк тә ымсындыргыч, матур уйфикерләр бит, житмәсә өр-яңа фикерләр — әкият инде, әкият! Ул әкияти хыялларның гомергә әкият кенә булып калачагын аңларга башлары житмәгән шул — нишлисең бит...

Ә лозунг-шигарьләр нинди кызыктыргыч: «Бетсен хосусый милекчелек! Яшәсен гомуми милек!» Күбесенең үз милке юк, ярлы-ябагайга шул кирәк тә. «Бетсен байлар! Яшәсен тигезлек!» Бу «тигезлек» дигәне ни-нәрсәне аңлата, ул халыкны кайда алып барып чыгарыр — анысын бераү дә белми, белергә дә теләми. Янәсе, ярлылык-фәкыйрьлектә булсак та, барыбыз да бертигез, берәүгә дә көнләшеп карарлык түгел... Бүген дә без әле шул хыялдан аерыла алмыйбыз түгелме?

Нәтиҗәдә кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләре бер-берсенә карата ихтирамсызлыкка әверелә. Ярлы ярлыны, хәерче хәерчене хөрмәт итә алмый. Алар байга да ихтирам-хөрмәт белән карый алмыйлар, бары тик байлыгына гына кызыгалар, шуңа көнләшәләр. Галим А. Маслов:

«...Көнбатышта кешеләрнең бер-берләренә булган ихтирамы, беркемнең дә шәхси тормышына тыкшынырга ярамаганлыгы, аның кагылгысызлыгы гадәти хәл. Россиядә исә дистәләрчә елларга сузылган репрессияләр, бүгенге хакимият җитәкчеләренең халыкка карата булган башка сыймаслык ихтирамсызлыгы — болар барысы да, төптән караганда, кешеләрнең бер-берләренә карата гомуми ихтирамсызлыгы нәтиҗәсе. Исерек урыс юкка гына үзенең шешәдәшен якасыннан алып: «Ты меня уважаешь? (Син мине хөрмәт итәсеңме?)» — дип сорамый. Үз-үзеңә ихтирам, башкаларның сине ихтирам итүенә омтылу-сусау һәрвакыт күңел төбендә ята, чөнки чынбарлыкта ул ихтирам юк. Кеше, акылга ия зат буларак, башкаларның үзен хөрмәт итүенә, ихтирамына мохтаҗ, чөнки ихтирам-хөрмәтнең табигый дәвамы әхлаклылык, рухи сафлык буладыр — шуннан башка кешелек җәмгыяте яши алмый.

Танылган икътисадчы, язучы-публицист Николай Шмелев болай дип яза: «Россияннар, тормышта яшәү максатын эзли-эзли, үз тарихларында мөмкин булган барлык идеяләрне дә сынап карадылар: державачылык һәм территориаль экспансия, ягъни дәүләт чикләрен көч кулланып киңәйтү; «күңелләрендә Алланы йөртүче халык (богоносец)» дип, дини-мистик эзләнү-капшану; казарма коммунизмы һәм бар кешелекне коткаручылар сыйфатындагы мессианчылык... Без бары тик һәр кешегә аңлаешлы бер уңышлы, файдалы идея-фикерне генә таба алмадык. Бары тик бөтенебезне дә берләштерә ала торган шундый идеянең генә киләчәге бар». Һәр кешегә аңлаешлы ул идея бик гади югыйсә: ул — милли байлыкның хосусыйлаштырылуын, ягъни аның һәркемгә һәм барыбызга да тиешле икәнен аңлап, шуны тәэмин итәрлек гадел социаль иҗтиһатлы җәмгыять төзүнең мәҗбүрилеге. Башка илләр шул юлда. Россиянең дә башка юлы юк. Бүтән юллар, революциягә, баш күтәрүләргә китермәсә дә, череп таркалуга гына китерәчәк.

Инде үзебезнең туган якларыбызга яңадан әйләнеп кайтыйк.

«Бәкер» курортында дәваланып, ял итеп алганнан соң, мин балачагым үткән Бөгелмә шәһәренә сугылдым. Шулай да безнең татар халкы таза рухлы, тотрыклы халык. Моның шулай икәненә мин Бөгелмәдә тагын бер кат инандым. Әтиемнең бертуганы булган абзый йорты элек Ленин урамы дип атала, тимер юл вокзалы ягыннан караганда уң яктагы параллель урам Сталин урамы булып — ул шәһәрнең үзәк урамы санала иде. КПССның XX съезды шәхес культын фаш иткәннән соң, Бөгелмә түрәләре Сталин урамын Ленин урамына, ә мин яшәгән Ленин урамын Совет урамына әйләндереп куйганнар. Бу урам исемнәрен яңадан үзгәртергә бик ашыкмыйлар шикелле. Һәм дөрес эшлиләр. Бер Бөгелмәдә генә түгел, шундый хәл бөтен Татарстанга хас. Совет чорыннан калган урам, колхоз, район исемнәре, Ленин һәйкәлләре һаман булса сакланалар. Ни әйтсән дә, исем үзгәртү кебек эшләр күп чыгымнар сорый. Башка төбәкләрдә, кирәкмәгәнгә халык акчасын туздырып, шундый шаукым белән мавыккан бер заманда Татарстан җитәкчеләре андый вәсвәсәгә бирелмәгәннәр. Бер сүз белән әйткәндә — афәрин!

Җөмһүриятебезнең татар авылларында бер-бер артлы матур мәчетләр күтәрелә. Алар, айларын балкытып, еракларда́н, «без — татар, мөселман авылы» дип искәртеп торалар. Җанга рәхәт шатлык хисе тула.

Чыгышым белән муллалар нәселеннән булсам да, мин үзем — атеист. Әтием ягыннан бабам Мирхәйдәр дә, аның әтисе Борхан Дусаев та Сарабиккол муллалары булган. Әнием ягыннан бабам Кашафетдин Кадыйров Мөэмин-Каратай авылында беренче мәчетне төзетүче мөәззин булган. Хәзер бабам Кашафетдин мәчете нигезендә — җиләк-җимеш бакчалы матур тау итәгендә яңа мәчет күтәргәннәр. Авыл зираты да шуннан ерак түгел...

Бабам турында балачагымнан хәтерләп калган ике риваять бар. Беренчесе: Кашафетдин, нәни чагыннан ук сукыр килеш, Коръән хафиз булган, ягъни Коръәнне яттан белгән. Мәчет төзеткән чагында таштан салынган нигезен кулы белән капшап дүрт ягын да чамалап чыккан да: «Нигезнең бер ягы тәбәнәгрәк», — дип эшне туктаткан. Төзүчеләр, аның белән ризалашмыйча, тавыш кубарганнар. Шуннан бабай өяздән инженер китерткән, инженер исә бабайның хаклы булуын раслаган. Кашафетдин йорт-яраклары сата торган бер кибет тоткан, шунда үзе сату да иткән. Кем дә кем, шаяртып, бакыр-көмешләрне яки кәгазь акчаларны буташтырып бирергә маташса, бабай шунда ук фаш итә икән. Менә сиңа сукыр!

Икенче риваять. Бабам олы улы Кыяметдинне (без аны «зур абзый» дип йөртә идек) Бөгелмәгә укырга җибәргән. Реаль училищегә булса кирәк. Кыяметдин, шунда гармун уйнарга өйрәнеп, бер ялында авылга гармун күтәреп кайткан. Ул заманнарда мөселманнарга урамда яки өйдә музыка коралында уйнау тыел-

ган булганлыктан, Кыяметдин, бабайдан качып кына дусларын жыеп, мунчада гармун уйный икән. Уйный да яшереп куя гармунын. Бабай сизеп ала бит моны. Улы өйдә юкта мунчага бара да чарлакка яшерелгән гармунны табып ала һәм мичкә тыгып яндыра. Үзе: «Утка керәсен сизә, шайтан: мичкә тыгарга алып кергәндә юл буе ыңгырашып килде»,— дип сөйли икән. Гармунны яндырса да, Кашафетдин бабай балаларының җыр-музыкага булган мәхәббәтләрен сүндерә алмаган. Кыяметдиннән кала тагын ике улы — Салих белән Хәсәнша (монысы бабайның кайсыдыр туганының, ятим калып, уллыкка алынган баласы була) шулай ук гармунчы булып китәләр. Егетләрнең тавышлары да матур: Бөгелмә янындагы бер совхозда (анда Кыяметдин абзый эшли) яки без яшәгән Камышлы авылында бергә җыелсалар, авыл халкын рәхәтләндереп җырлыйлар. Әнием дә аларга кушыла. Кыяметдин абзый егерменче еллардан алып үлгәнчегә кадәр (1947) Татарстан һәм Башкортстан совхозларында директорлык итте. Үзе эшләгән совхозларда драмтүгәрәкләр оештырып, үзешчән спектакльләр куяр, татар драматургиясенә хас җырлы-гармунлы ул спектакльләрдә үзе һәрвакыт берәр гүзәлнең сөйгән егетен уйнар иде. Сәхнәдә сөю-сәгадәт уеннары, күрәсең, тормышта да дәвам монсу-уйчан булыр иде. Абзый — чибәр, тормыш сөючән, мәхәббәте-дәрте ташып тора торган ир булса, Нюра түтәй озынча ак чырайлы, кайгылы карашлы бер хатын иде, озакламый ул, туберкулезданмы шунда, үлеп тә китте. Кыяметдин абзыйның бу маржа түтәй белән танышуы болай була: егет бик каты авырып китә, Бөгелмә хастаханәсендә үлем белән көрәшеп ятканда, шунда шәфкать туташы булып эшләүче Нюра апа аны аякка бастыра. Шуннан соң кавышканнар... Нюра түтәйнең тышкы матурлыгы әлләни булмаса да, ул эчке бер матурлыкка ия иде: иренең күпсанлы туганнарын ярата, бигрәк тә без, бала-чаганы, урыс акценты белән кызык итеп, татарчалап: «ашагез, ашагез, балалар» дип, тәм-том белән сыйлар иде. Татарчаны әйбәт кенә белә иде ул. Иренә дә ул Сөгъдә исемле бер кыз бүләк итте, аны татарча тәрбияләп үстерде. Хәзер инде Сөгъдә, туган яклардан еракларда яшәп, бөтенләй урыслашкан, исеме дә — Софья. Без аның белән хатлар алышып торабыз.

Тагын бер тарих. Бабам Кашафетдиннең хатыны, ягъни әбием, бик озак урын өстендә авырып ята. Аның киңәше беләнме, әллә рөхсәтен алыпмы — бабай икенче яшь хатын ала. Ул хатыны аңа Рәхим исемле малай табып бирә (Рәхим абзыйның балалары Шөгердә, Лениногорскида яшиләр, хәбәрләшәбез). Әмма әбиебез, үзе бераз тернәкләнгәч булса кирәк, көнләшә башлый һәм бабайдан яшь хатынын аертып җибәртә.

Сарабиккол белән бәйле истәлекләрем дә байтак. Без аннан 1924 елда күчеп киттек. Күчеп китәр алдыннан гына мине сөннәткә утырттылар, челтәрле тактalar белән матурлап эшләнгән болдыр баскычына чыгып канлы пес иткәнем хәтеремдә калган. Авылны икегә бүлеп Шушма елгасы ага иде. Күрәсең, безнең йорт елга аша салынган күпердән ерак булмагандыр, мин шул күпердән авылның аргы ягына да чыгып йөргәнмендер. Балачагымда йоклаганда бик еш кына бер үк төш күреп йөдәтә иде. Имештер, мин шул күпер аша чыгып барам, ә күпер уртасында яныннан үтәргә дә куркыныч алагаем зур тишек... Кирәк бит менә: әле бу кайтуымда да, күпердән чыкканда шоферыбыз зур гына бер тишекне әйләнеп үтәргә мәҗбүр булды. Бу күпер, тимер булса да, җимерелү хәлендә икән, аны без үскәндәге агач күпердән бераз аскарак салган булганнар, ә агач күпернең субай калдыклары әле дә булса судан калкып торалар. Сарабикколның да мәчете өр-яңа, таштан салынган, зур-иркен — мул тормышлы-хәлле бу авылга бик килешле. Авылдашлар аны күренерлек матур урынга күтәргәннәр. Иске мәчет бинасы исә — клуб.

Сарабикколны телгә алганмын икән, әтиемне дә сагынып яд итү кирәктер. Ул бик иртә әтисез кала, бабам Мирхәйдәр мулла үлеп киткәндә Хөсәен белән аның игезәге Хәсәнгә нибары 11 әр генә яшь, тагын бер энеләре һәм ике сеңелләре әле гел сабый гына була. Тормыш авырлыгы Хөсәенне 15—16 яшьләреннән Донбасс шахталарына эшкә куа, озакламый аның артыннан энесе Сөләйман да шул якларга юл тота. Әтием герман сугышы (1914) башлангынчыга кадәр забойщик булып эшли, урыслар арасында яшәп, салгаларга да өйрәнеп китә. Шуннан сугышка алына. Берәр ел чамасы сугышып йөргәч, немецларга әсирлеккә төшә. Кайбер ым-шым гына сөйләнгән сүзләргә карaганда, әти немец гроссбауэры — кулакта ялчы булып эшли һәм тегенең кызына бер малай — «татарчонок-борһанчык» ясап калдыра. Кем белә, ул малай, үсеп җиткән бер немец булып, соңгы сугышта (монысы да «герман сугышы»!) миңа каршы сугышкандыр, бәлки. Әти авылга әллә 1918, әллә 1919 елны, сәяси яктан бик чарланып кайтып төшә. Укый-яза белгән солдатны волисполком рәисе урынбасары итеп куялар. (Кан-

дидатлык диссертациясе язарга материал туплап, Мәскәү архивларында казынып утырганда, 1921 елгы ачлыкта Идел буе ачларына ярдәм оештырылган Помгол Үзәк Комитеты эше белән дә кызыксынып киттем. Шунда очраклы бер фоторәсемгә тап булдым: бер төркем крестьяннар Америка бүләк итеп җибәргән «Фордзон» тракторы тирәсендә басып торалар, трактор янында ук — минем әти. Совет хакимияте америкалыларның ул еллардагы ярдәме турында ни тарихи, ни башка әдәбиятта бик алай иркенләп язарга рөхсәт итми килгән. Соңгы сугышта америкалыларның шундый ук ярдәмен дә гел киметеп-кечерәйтеп күрсәтергә тырыштылар. Шулай да рәхмәтсез халык без! (Әти сәләтле кеше була, урысчаны да әйбәт белә, немецчаны да шактый сукалый (миңа немец теле дәресләрен әзерләргә дә булыша иде). Камышлыга күченеп килгәч, әти авыл җәмгатьчелеге өчен Кыяметдин абзый төзеткән тегермәндә тегермәнче булып эшли башлый. Кыяметдин абзыйның әйткән бер шарты була: Хөсәен (ягъни әтием) үзе үлгәнче шушы тегермәнне тотарга тиеш. Әти кешеләр белән тиз аралашучан: татарын әйткән дә юк, урысыннан, мукшысыннан, чувашыннан, дисеңме — дуслары күп була, салгаларга да ярата (шахтада өйрәнгән «һөнәре»). Шул уңайдан, балачактан истә калган бер вакыйга бар. Безнең гаилә колхозга бер кереп, бер чыгып йөри торгач, әтине тегермәннән дә куалар. Шуннан без Бөгелмәгә күченеп киттек. Әни ягыннан җыр-музыкага булган һәвәслек безгә дә йоккан, күрәсең: мин дә, энем Азат белән сеңелем Җәмилә дә матур гына җырлый идек. Шулай да минем гармун уйнарга өйрәнәсем килә. Әни белән икәүләп ялына-ялвара торгач, әти миңа гармун алып бирергә булды. Киттек без әти белән базарга. Юлда әтинең танышларыннан бер юньсезе очрады бит! «Хөсәен, кая юл тотасың болай?» — дип сорый әтидән. Әти әйтә: «Менә, улыма гармун алып бирмәкче булам әле»,— ди. Ә теге хәерсез: «Кит, әллә юләрләндеңме? Гармун алсаң, ул бит укуын ташлап, көннәр буе шуны шыңгырдатып утырачак»,— дип, миңа ымлый. Әти беркатлырак кеше иде, гармунны башка вакытта алырбыз, дип, мине кайтарып җибәрде дә теге танышы белән китеп барды. Гармунга дигән акчаны эчеп бетереп кайттылар алар... Бераздан мин шешәдер-фәләндер сатып җыйган акчама балалайка алдым, үзлегемнән уйнарга да өйрәндем.

Әйткәнемчә, муллалар нәселеннән булсам да, үзем — атеист. Аллага да, шайтанга да ышанмыйм. Бу, бәлки, минем дини наданлыгымнан киләдер. Шулай да үзем башкачарак уйлыйм: моңа дөньяга карашымның фәнни аң-белемгә нигезләнгән булуы сәбәпчедер шикелле. Аннары шунысы да бар: мин, нигездә, урыс зыялылары традицияләрендә формалаштым. Ә ул традицияләр, православие диненең бик күптәннән дәүләт диненә әверелүе аркасында, атеистик рухтагы традицияләр. Үз халкын гомерлек коллыкка дучар итеп, аны әле булса хәерче хәлендә яшәтүче хакимияткә урыс руханиларының булышлыгы шактый зур. Ул руханилар элек-электән дәүләт файдасына халык өстеннән шымчылык иткәннәр, тәүбә итәргә килеп, эч серләрен бушаткан гади халыкның ышанычыннан әнә шулай оста файдаланганнар. Шуңа күрә, аң-белемле, укымышлы зыялылар Алланың җирдәге бу икейөзле хезмәтчеләреннән ераграк булырга тырышканнар, вәгазьләренә дә ышанмаганнар. Руханилар кылган гамәлләре белән аларны үзләре үк диннән, Аллага табынудан читләштергәннәр, биздергәннәр. Хәзер дә урыс диненең һаман да шул иске яман сыйфатларын саклаган хәлдә яңадан күтәрелүе, үсеше эчне пошыра. Ул дин Аллага хезмәт итми, ә дәүләткә, хакимияткә хезмәт итә. Һич ярамый, килешми торган бу гамәлләрдән мөселман руханилары ерак китә алдымы икән? Минем моңа җавабым юк... Шуны гына әйтә алам: суга кереп — чыланмыйча, пычракта йөреп буялмыйча калу бик авыр эштер...

Үзем атеист булсам да, кешеләрнең элек тә, хәзер дә Алласыз яши алмауларына иманым камил. Башка җан ияләреннән аермалы буларак, кешегә аң-акыл бирелгән. Акыл ике яклы бик көчле корал: аны бер үк дәрәҗәдә яхшы гамәлләргә дә, яманлыкка да юнәлтеп була. Тормыш-көнкүрешнең һаман да әле начарлана гына баруы, гади халыкның ыгы-зыгылы, орыш-талашлы күп төрле тәртипсезлекләр эчендә яшәве аның акылын күбрәк яман гамәлләр кылырга этәрә. Кешеләрнең акыл көчләрен бары тик яхшылыкка гына юнәлдергән көннәр килерме — моны беркем дә әйтә алмый. Әгәр дә кешелек — акыллы кешелек! — үз-үзен дөньякүләм экологик һәлакәткә китереп җиткерсә, без көткән якты киләчәк, тыныч-имин һәм мул-бай тормыш мәңге булмаячак. Шунлыктан, кеше — акыллы җан иясе — үз эшләре белән тыныч-тату яшәр өчен, йә белемлегыйлемле, йә иманлы, ягъни Аллага инанган булырга тиеш. Бу сыйфатларның һәр икесенә дә ия буласы иде дә бит, ай-һай, анысы мөмкин эш микән? Һәр кешенең дә аң-белем дәрәҗәсен тормыштагы барлык сорауларга, бигрәк тә

әхлакый-рухи сорауларга җавап бирерлек итеп үстереп булмый шул әле. Шуңа күрә дә, күпчелек гади халык нинди дер буй җитмәс, акыл ирешмәс изгелеккә инана, Аллага табына, иманга килә. Шулай булмаса, Федор Достоевский әйткәнчәрәк килеп чыгар иде: Алла юк икән, димәк, ни кылсаң да — рөхсәт. Бернинди тыюлар да юк. Ул чагында кешелек тәртипсез-чуалчык хаоска батар һәм җәмгыять яши дә алмас иде. Иҗтимагый хайван дигән кешебез кыргый бер ерткычка әверелер иде. Әле без ерткыч җанварлар белән җир йөзендә ничек тә сыешып яшибез. Ә инде каннибаллык инстинктын бүген дә тыя алмаган, үз ишләре белән туктаусыз сугышып, аларны бихисап үтереп торган, шуның өчен хакимият тарафыннан хупланган, каһарман исеме, орденнар алган ике аяклы ерткычлар арасында ни эшләр идек?

«Аллаһы тәгалә барысын да күреп, белеп тора», «явыз җаннар, гөнаһлылар, имансызлар теге дөньяда тәмуг кисәве булырлар» һ. б., һ. б. шундый инану-ышанулар, ягъни иманлы булу кешенең теләсә нинди гамәл кылырга сәләтле аңын-акылын тыеп тора. Шул рәвешле, дин иң зур әһәмияткә ия булган мәсьәләне — кешеләрне әхлакый-рухи яктан сау-таза итеп тәрбияләү мәсьәләсен хәл итәргә алына. Барлык диннәрнең дә изге бурычлары шул. Халкыбызның хәзерге әхлагы гафу ителмәслек түбән дәрәҗәдә. Патша самодержавиесе тарихындагы барлык әшәкелекләрне бергә туплап-тапкырлап, дистәләгән миллионнарча үз халкын төрмәләрдә-лагерьларда һәлак иткән большевиклар хакимиятенең кешелек һәм кешелеклелек алдындагы гөнаһларын-җинаятьләрен ярлыкауны, изге догалар укый-укый, әле Аллаһы тәгаләдән бик озак еллар сорарга, табынырга тиеш булырбыз.

Кешелек җәмгыяте яшәешенең бөтен катлаулылыгын фәнни аңлауны һәркемнән дә таләп итеп булмый. Күпчелек гади халыкның аңа «теше үтми». Әмма һәр кеше әхлакый-рухи тәрбиягә мохтаҗ. Күп гасырлык тарихи тәҗрибәсе булган төрле диннәр әнә шул тәрбияне бирүдә саваплы эш башкаралар.

Татарларның дине — ислам. Ислам ул мөэмин-мөселман өчен дин генә түгел, ул — тормыш тәртибе, ата-бабадан килгән изге гореф-гадәтләре, йолалары... Үзе урыс динендә булган танылган галим, ислам дине белгече Алексей Малашенко: «Ислам — акылга ятышлы, эзлекле дин, ул табигый кабул ителә, аңа ничектер күбрәк ышанасың... Чиркәүгә кергәләп-чыккалап йөргән күпчелек урысларыбызга караганда, мәчеткә йөргән мөселманнарга күбрәк ышанам мин», — дип яза. Чынлап та, Чечняда канкойгыч сугыш барган көннәрдә чиркәүдә чукындырылган министр Грачевка, кулына шәм тотып аны чукындырып торган урыс руханиена ничек ышанмак кирәк?

Ислам дине — мөселман кешесе һәрвакыт тотарга тиешле әхлак кагыйдәләренә бай дин. Мөхәммәт пәйгамбәрнең аятьләре мөселман кешесенең тормыш-көнкүрештәге әхлак кануннары белән тәңгәлләшә. Бу кануннар — мөэмин-мөселманның Аллаһы тәгалә һәм Мөхәммәт рәсүл алдындагы изге бурычлары, әти-әнисе, гаиләсе, милләттәшләре, туган иле һәм бөтен кешелек галәме каршындагы әхлакый җаваплылык хисе. Иң әүвәл ата-анаңа итәгатьле бул, аларны рәнҗетмә, ата-анага каршы бару — ул Аллаһының үзенә каршы бару белән бер. Динеңне, телеңне, ата-бабадан килгән яхшы гадәт-йолаларны онытма — юкса, милләтеңкавемең юкка чыгар. Вөҗданыңа каршы гамәл кылма, намусыңны-абруеңны сакла, абруйлы кеше — хөрмәтле кеше. Кеше малына кызыкма, аңа зыян салма, буйсындырып-көчләп башкаларның мал-мөлкәтен тартып алма. Эшлә, иҗтиһат ит, эшләгәндә бу дөньяга мәңгелеккә килгән үлемсез зат кебек тырыш, әмма дөньяның фанилыгын исеңнән чыгарма, әҗәлең җитеп, иртәгә үк үлеп китүең бар — теге дөньяга барасыңны онытма. Аллаһы тәгалә башкаларны рәнҗеткән, аларның хокукларын танымаган адәмнәрне гафу кылмас. Адәмнәргә гадел бул, шунда гына инсан бәхетле булыр. Әхлаксызлык адәмнәрне үзара дошманлаштыра, ызгыш-талашлар чыгара. Исеңдә тот: кеше җанын кыю бар дөньяны бетерүдән дә яманрактыр. Хәмер — явызлык-начарлыкларның анасыдыр. Гомереңне бушка-заяга уздыру, ялкаулык — зур гөнаһ. Мал-мөлкәтне әрәм-шәрәмгә исраф итү — шайтан гамәледер. Бер-берегездән көнләшмәгез, бер-берегездән читләшмәгез, арагызга салкынлык кертмәгез, аерылышмагыз, мәхәббәт җепләрен өзмәгез...

Укучым гафу итсен: мин бу үгет-нәсихәтләрне үзем белгәнчә-аңлаганча гына китердем.

Ислам дине хуплаган, игелекле-изге сыйфатлар: дөреслек, тугрылык, хезмәт сөючәнлек, игелеклелек, ярдәмчеллек, киң күңеллелек, тәрбиялелек, әдәплелек, дуслык-иптәшлек, түземлелек, азга да канәгатьлек, өлкәннәргә ихтирам-хөрмәтле вә кечеләргә мәрхәмәтле булу, хокуксызлыкны кире кагу, гаделлек, сакчыллык, вәгъдәчеллек, тәүбәгә килү...

Ислам дине шулай ук кешеләрнең холык-табигатендәге, эш-гамәлләрендәге яман сыйфатларны да санап күрсәтә. Алары: ялган вә хәйләкәрлек, гайбәт вә яманлау-хурлау, урлашу-караклык, кеше үтерү, эчкечелек, комарлы уеннар уйнау, зина кылу вә никахсыз ир-хатын булып яшәү, яла ягу, тәкәбберлек, әрәм-шәрәм итү, көнчелек, теге дөньяда адәм затын тәмугка кертердәй башка гөнаһ эшләр...

Бер-берсе белән аралашып-күрешеп яшәү теләге — кешеләрнең табигый теләге. Безнең халык юкка гына: «Бер күрешү — үзе бер гомер»,— дип әйтмәгәндер. Күрешү-очрашу рәхәтлеге кешеләр өчен иң зур шатлыклы мизгелләр. Дин, күрәсең, бу табигый теләкне канәгатьләндерүдә иң яхшы юлны тапкандыр: кешеләр гыйбадәтханәләрдә (мәчет, чиркәү, синагога һ. б.), бердән, укыган догалары-намазлары аша Аллаһы тәгалә белән элемтәгә керә, «сөйләшә» алалар; икенчедән, үз дин кардәшләре белән очрашып-аралашып, сәгадәтле мизгелләр кичерәләр. Хәзерге заманның имансыз-денсез адәме мондый шатлыклардан мәхрүм. Ялгызлык хисе кешенең аңында туа-тумыштан ук килә, чөнки ул шулай ук үз аңында бөтен дөньяны йөртә. Ничек кенә сәер тоелмасын, ялгызлык тоюе бигрәк тә шәһәрләрдә ачык сизелә. Умарта кәрәзенә охшаш бихисап квартирлы зур йортларда яшәүчеләр еш кына үз катындагы каршы ишек аша яшәүче күршесе белән дә аралашмый. Күрше сүзе «күрешү» сүзеннән ясалган югыйсә.

Ялгызлык хисеннән бары тик иҗади хезмәт, иҗтиһат белән генә котылып булса буладыр, мөгаен. Әмма һәркем дә үзе яраткан эш-шөгыль белән, үз хезмәтеннән тәм табып, иҗади шатлык кичереп яши алмый. Күпчелек гади халык тамак туйдыру өчен мәҗбүри эшләргә дучар ителгән. Ә бит үз хезмәтен яраткан иҗади затлар, гадәттә, озын гомерле булалар. Кызганыч, андый бәхетле язмыш бик азларга гына тия. Без әле бүген тиргәп-каһәрләп йөрткән базар мөнәсәбәтләре алга таба күпчелек халыкны мал-мөлкәтле итә алса, аларны ялланып эшләүче коллар халәтеннән йолып ала алса, иҗатка-иҗтиһатка сәләтле шәхесләр артканнан-арта барыр иде... Әлегә мондый мөмкинлек бик азлар өчен генә шул: беренчедән, җитештерү көчләренең үсеш дәрәҗәсе җәмгыятьнең эшчәнлегенә кагылышлы күп кенә тармакларда иҗади да, нәтиҗәле дә түгел әле; икенчедән, һәр кеше дә үзенең нәрсәгә сәләтле икәнен белми, зәләнергә, «үз ноктасын» табарга аның мөмкинлеге дә юк; өченчедән, чынлап исәпләгәндә, иҗатка сәләтле шәхесләрне табигать күпләп тудыра алмый, талант исә — бөтенләй сирәк күренеш. Кешелек җәмгыяте өчен «эшче кортлар» күбрәк кирәктер шул.

Әлбәттә, Россиядәге башка милләт халыкларына җитмәгән шикелле, безнең татарларга да гомуми мәдәнилек, укымышлылык-зыялылык, тәрбияле зәвык җитенкерәми. Бу уңай белән әтием ягыннан булган әбием искә төшә. Әбиебез бик эшлекле, нык-таза, акыллы кеше иде. Берсеннән-берсе кечкенә биш баласын кочаклап, бик иртә тол калса да, ул аларның барысын да үстереп аякка бастырган, кеше иткән. Кызларын мул бирнәләр белән кияүгә биргән, уларын һәркайсын башка чыгарып өйләндергән, әтиемнең игезәге Хәсән абзыйны мөгаллимлеккә укыткан. Бу эшләрне майтарырга әбиемнең мулла хатыны — остабикә булуы да ярдәм иткәндер. Бәлки, ул әле Коръәнне дә әйбәт белгәндер, мәхәллә хатын-кызларын хәреф танырга, ислам кануннарына өйрәткәндер. Ә менә поп хатыннары — попадьялар андый эшләр белән «вакланып» тормаганнар. Революциягә кадәр күп элек татарларның күпчелеге укый-яза белгән икән — димәк, моңа мөмкинлек булган. Мондый «грамоталылык» урысларның ир җенестәгеләренә дә бик сирәк эләккән шул...

Без байтактан күченеп килеп яшәгән Камышлы авылына Сарабиккол шактый ерак — 100 чакрымнар чамасы иде. Атка утырып килгәндә дә шактый ерак ара бу. Шуңа күрәдер, әбиебез сирәк килә иде. Килдеме, кочаклап алыр, аркадан сөяр иде дә, кулыма зур бакыр биш тиен тоттырыр иде. Без, биш-сигез яшьлек күрше балаларын да ияртеп, авылыбыздан 4—5 чакрымдагы Татар Димскәендәге кибеткә чабар идек. Шул биш тиен бакырга татлыдан да татлы, баллыдан да баллы конфетлар сатып алыр идек. Сатучы биш тиенгә күпме конфет бирә торган булгандыр, әмма барыбызга да берәр конфет тиядер иде шикелле. Бервакыт әби килер алдыннан гына минем бик каты тешем сызларга тотынды. Ә табиплар район үзәге Баулыда гына, әле анда теш табибы бардырмы-юкмы — белгән юк. Әтинең 25 чакрымдагы Баулыга шундый «вак-төяк» өчен барып йөрисе дә килми. Менә әбиебез килде. Минем хәлемне күрүгә, ул әнидән эре тоз сорап алды, мине бот арасына келәшчә белән кыстыргандай кысып алды да, юеш бармагын тозга манып, акырта-бакырта, теш казналарымны ышкырга тотынды. Мин бик озак кан төкереп йөрдем, әмма теш сызлавым шунда ук басылды һәм, Аллага шөкер, шуннан бирле теш сызлауның нәрсә икәнен белми яшим.

Әбием турында тагын бер вакыйга сөйләр алдыннан, бераз аңлатма биреп үтим. Аракы эчү, хәмер куллану барлык халыклар өчен дә зур бәлаләр, кайгы-хәсрәт китерә торган шөгыль. Хәмер эчү Коръән тарафыннан катгый тыела. Шул сәбәпле, әбиләребез заманында эчеп йөргән мөселман татарына, борын-борыннан «эчү — күңелле эштер, эчмәгән кеше юктыр» дип яшәгән урыс кяферләренә караган кебек караганнар. Әмма урыслар бу яман гадәтне акрынлап башка халыкларга да «сеңдергәннәр», һәр җирдә кабаклар-сыраханәләр ачып, халыкны аздырганнар. Егерменче гасыр башларында безнең татарлар арасында, бигрәк тә аның авыллардан читкә — зур шәһәрләргә, шахта-рудникларга акча эшләргә китеп йөрүче «зимагурлары» арасында бу күренеш шактый тиз тарала бара. Шул рәвешле, урыслардан йоккан бу чир һаман да тирәнгәрәк үтә — нәкъ менә шунысы кызганыч та, хәвефле дә.

Моннан җитмеш еллар элек китеп барган туган авылымда,— йә хода! — исерек-сәрхүшләр арасында татар хатын-кызларының да көннән-көн ишәя баруын күреп бик көендем... Элекке заманнарда, эчеп-исереп йөрү түгел, чаршау артыннан да чыгарга җөрьәт итмәгән инсафлы-саф хатын-кызларыбыз бит болар! Милләтнең киләчәк язмышы аларда бит... Революциягә кадәр, хәер, диншәригать ныклап кысрыкланганчы, әле революциядән соңгы елларда да, урамда тәмәке тартып, эчеп-исереп йөргән татарны аксакаллар хөкеме белән яткызып, таяклар белән кыйный торган булганнар. Әмма дин туздырылган, исерекләргә күнегә барганнар, аларга иярүчеләре дә ишәйгән...

Инде әбиебезгә әйләнеп кайтыйк. Исерекбашларны аның җене сөйми иде. Эчеп йөрүчеләрне ул, үзенчә, үтерерлек бер сүз белән генә атар иде: «Мажик!» Үз туган-тумачалары арасында шундый «мажик» килеп чыккан очракта, әби нишләргә тиеш? Әбинең төпчек улының хатыны Хаҗәр апа сөйләгән бер вакыйга истә калган. Хаҗәр апаның ире Сөләйман абзый,— өйләнгәнче күпмедер вакытлар «зимагурлыкта» йөреп кайткан кеше,— өйләнеп озак та үтми, дус-ишләре белән бераз «кәефләнеп» өенә кайта. Хатыны берәр сүз әйткән булса кирәк, ул аны кыйнап ташлый. Хаҗәр апа әбигә килеп елый-зарлана. Әби исә, күп сорашып тормастан, кулына дилбегә ала да, Хаҗәр апаны ияртеп, аларга китә. Барып керсәләр, Сөләйман абзый тәмләп йоклап ята икән. Әби аны, яңагына чабып уята да, ишек алдына алып чыгып, бер баганага дилбегәсе белән уратып бәйләп куя, абзыйның үз дилбегәсен алып, шундый итеп яра тегенә, абзый мескен, бөтен авыл ишетерлек итеп ялына-ялвара, «әнекәем, яңадан бер дә сугышмам» дип ант итә. Хаҗәр апаның сөйләвенә караганда, чынлап та, озын-озак бергә гомер итеп, Сөләйман абзый аңа бер генә дә кул күтәрми. Ә-һә-һәй!.. Кайда сез хәзерге шундый әби-әниләр? Һәр «мажик»ка берәү булсагыз, нинди шәп булыр иде, ә! Юкса, ул «мажик»ларны бер «ярты»га хуҗалыкта кол-ялчы итеп эшләтергә дә, сәясәттә, уңны-сулны белмәстән, тамагы ярылганчы кычкырырга да бик җиңел сатып алып була ич... Әйе, ни кызганыч, исерекбашлар, бер кинофильмда Юрий Никулин җырлаган җырны: «А нам все равно, а нам все равно! Все остальное — трын-трава...» — дип мыгырданып йөри бирәләр. Кыскасы, арба ватылса — утын, үгез үлсә — ит. Сәрхүшләрнең бөтен мәсләкләре шул. Ә хакимият башындагы сәясәтче түрәләргә шул гына кирәк тә.

Истәлеккә тартым бу язмаларымда мин, бәлки, нәрсәләрне булса да арттырып-күпертеп, яки, киресенчә, иң кирәклеләрен онытып та калдыргганмындыр. Алай булуы да бик ихтимал. Чөнки автор, фән теле белән әйткәндә, субъектив шәхес, ул чынбарлыктагы объектив күренешләрне дә үзенчә кичереп, үзенчә берьяклы гына бәяләргә мөмкин. Әмма бер нәрсә бәхәссез: макталган мөэмин-мөселман кардәшләребез дә, искәртеп җитмәстән безнең кулыбыздан ычкынган «мажик»ларыбыз да — барысы да үзебезнекеләр, үз туганнарыбыз. Без алар өчен җаваплылар... Ни әйтсәң дә, үз чыпчыгың ят сандугачтан кадерлерәк...

Әгәр дә туган җиребездә, уртак Ватаныбыз Татарстанда, туган халкыбызда нәрсәләрдер без теләгәнчә үк түгел икән, әгәр дә без аны бар барлыгыбыз белән үзгәртергә теләмәсәк, ул һаман шулай булып кала бирәчәк. Ә без уңайга үзгәрешләрне бик нык теләргә тиешбез, бик нык! Бәлки, мин үз кардәшләребезне матуррак итеп күрсәтергә дә омтылганмындыр. Чөнки милләттәшләремнең моңа тулы хакы да, үсәр-тәрәккый итәр өчен җегәре-мөмкинлеге дә бар. Мин халкыма ышанам.

Кыскасы, туган якның җиле татлы...

*Бәкер — Мәскәү — Малино.*
*Июль-август, 1996 ел.*

Фатих Хөсни

# ЙӨЗЕК КАШЫ

## АВТОРДАН

**«Йөзек кашы» исемле бу кечкенә повесть, дөресен әйтим, минем иң бәхетле «балаларым»ның берсе булып чыкты — аны укыйлар, аны сорыйлар, аның турында укучылардан күп кенә хатлар килеп тора. Бу кечкенә генә китап мисалында мин, язучы буларак, бер хакыйкатьне тагын һәм тагын төшендем: тик кешеләр язмышы турында язылган китаплар гына кешеләргә якын булып җитә ала икән!**

**Китапханәләрдә эшләүче иптәшләрдән һәм, гомумән, укучылардан килгән күп кенә сорауларны искә алып, өченче басмасыннан соң шактый гына сагындырып, менә аны «Сайланмалар»ыма тәкъдим итәм. Бу басмага бирү алдыннан мин аны, укучыларның кайбер тәнкыйть фикерләрен искә алып, төзәтеп карап чыктым. Беренче басмасында, яшьлек аркасында, күз җитеп бетмәгән урыннарга үтеп керергә тырыштым. Шул «операцияләрдән» соң ул, йолкынган Хуҗа Насретдин кошына әверелеп калмыйча, әүвәле яңалыгы, «яшь чагындагы» дәртлелеге белән укучы күңеленә керә алса, миңа шул бик җиткән.**

*Әгәр Диана безнең авылның тегермән буасына килеп су коенса, без аны да урлап киткән булыр идек.*
(Эпиграф урынына.)

Каберлек өстендә үсеп утырган карт агачларның ак бәскә күмелгән ботаклары, хәрби оркестрның каты яңгыравыннан куркынган төсле, кинәт калтыранып куйдылар, алардан кар тәлгәшләре коелды. Оркестр соңгы мәртәбә Шопенның матәм маршын уйнады, озата килүче кызылармеецлар авыр гына кузгалдылар, кайтып киттеләр, тын агачлар һәм салкын кыш кочагында тагын бер җылы кабер калды...

Кечкенә тактага:

Бөек Ватан сугышы көннәрендә фашист варварларына
каршы батырларча сугышып берничә җәрәхәт алган,
курку һәм хыянәт белмәс тугры йөрәкле

**Айдар ШАЯХМӘТОВ**

күмелде монда.
Тыныч йокла, солдат!

дигән сүзләр язылган иде. Миңа кинәт әллә ничек бик моңсу булып китте. Чаңгыларымны бордым да, йомшак кар өстеннән әкрен генә шуып,

каберлектән чыгып киттем. Ләкин ул яңа кабер янында ниндидер фаҗигале чынлык, сугыш чорының авыр һәм кырыс романтикасы калган кебек булды, кырлардан, тау араларыннан әйләнеп кайтышлый әлеге билгесез каберне тагын сәламләп китәргә булдым.

Мин икенче кат әйләнеп килгәндә, ул кабер янында шинель кигән бер ханым — ак йөзле, әллә нинди яшерен моң белән тулган кара күзле, шактый өлкән яшьләрдәге бер хатын басып тора иде. Кигән киемнәренә, знакларына карап, мин аның ул елларда Казанда ачылган күп санлы хәрби госпитальләрнең берсендә эшләүче хәрби врач икәнлеген белеп алдым, шуннан башкасы билгесез иде һәм шулай билгесез булганга күрә дә ул миндә берьюлы күп төрле кызыксыну уятты.

Мин аңа якынлаша төштем, ул баскан урыныннан аз гына да кузгалмыйча тора бирде, бары тик күзләре генә, «читтәнрәк узып китәргә булмадымы сезгә?» дигәндәй, җиңелчә генә шелтәләп карыйлар иде. Миндә, ниндидер җылы сүз табып, бу иптәшнең кайгысын уртаклашырга теләү хисе кузгалды. Озак уйлап тормастан:

— Менә бу солдатка хәзер берәү дә комачаулый алмый,— дидем, яңа каберкә ымлап.

Ханым, аптырау катыш гаҗәпсенү белән, миңа күтәрелеп карады һәм, минем фикерем белән килешкәнлеген сиздереп, ягымлы гына елмайды.

— Йә, солдат, йә бала үлә,— дип авыр гына әйтеп куйды ул, кабер ягына күз салып.

Бу аның минем алда беренче сүзе иде, уйлары урыныннан купкан кеше икәнлеген белү өчен шушы берничә сүз дә бик җиткән иде. Үлемгә каршы кизәнү ишетелеп калды аның бу сүзләрендә. Ак чырайлы ханымның үлемгә каршы кизәнүе ул инде кечкенә нәрсә түгел. Юкка гына кара күзле булып тумагандыр ахры ул.

Без шәһәргә бергә кайттык һәм, сөйләшә торгач, яхшы ук нык танышып та өлгердек. Аның күп заманнардан бирле тик үз күңелендә генә саклап йөртә торган мәхәббәт романтикасы бар икән, башта бик үк ышанып җитмичә, ничектер кыюсыз гына, соңга таба мавыкканнан мавыга барып, ул миңа үзенең хатирәләреннән кайбер сәхифәләрне ачып ташлады.

— Әйе, ул да солдат иде һәм, миңа калса, начар солдат та булмаган. Язмыш шуклыгы, дип әйтергәме, хәтта исемнәре дә туры килеп тора, ул да Айдар исемле иде,— диде ул, сөйләгәннәренә йомгак ясаган кебек итеп.

Һәм минем чын күңелдән кызыксынуымны аңлап, шуның янына тагын әдәбиятка азмы-күпме катнашым барлыгын да белгәч, ул миңа үзендә саклана торган бер дәфтәрне бирергә булды.

— Мәрхүм үзе исән чакта госпитальдә язып яткан. Шундый чуар йөрәкле бер кеше иде инде ул. Малай чагыннан ук шулай иде, еллар аны үзгәртә алмады. Истәлек булсын, дип соңыннан миңа тапшырдылар, ә мин ул дәфтәр белән нишли алам? Җан көеге генә ул, укыган саен йөрәкне генә телгәли. Ә сез — шуның өстендәге кешеләр, сезгә, бәлкем, эшкә ярап куяр.

Шулай да миннән аерылып үз юлына киткән чакта ул бер нәрсәне кабат-кабат исемә төшерде:

— Ләкин, укып чыккач, үземә кайтарып бирерсез... Ни дисәң дә, аныкы ул, минем балалык дустымныкы...

Ханым сүзендә торды — тиздән ул мавыктыргыч дәфтәр минем кулыма керде. Мин ул дәфтәрне үзем укып чыгу белән генә, әлбәттә, канәгатьләнә алмадым,— бу тыйнаксызлыгым өчен мәрхүм мине гафу итәр, дип уйлыйм. Ул дәфтәрдә, барыннан да элек, тынгысыз йөрәкле кешенең, үз акылы белән үз йөрәген бергә куша алмыйча, бары тик бунтарь йөрәге артыннан гына чабып йөргән һәм шуның аркасында үз гомерендә күп

кенә аяусыз ялгышлыкларга, үкенечле югалтуларга дучар булган кешенең, минем һәм синең таныш түгел дустыбыз Айдарның кызыклы язмышы бар. Үрнәк булырлык язмышмы соң бу, диярләр миңа акыллы башлы тәнкыйтьчеләр. Алдан ук әйтәм, түгел. Киресенчә, аның күп кенә яклары минем үземә дә ошамый. Ләкин тормыш — шуның өчен дә тормыш ул, аның законнары минем яки синең кәеф белән генә исәпләшеп тора алмый. Әйе, тормышта Айдарлар да бар. Үрнәкме алар, түгелме? Ләкин андыйлар бар һәм, димәк, тормышның бүтән яклары белән бергә аларның да җырга кереп калырга хаклары бар. Ә дөрес нәтиҗәне укучы үзе ясый алыр, дип уйлыйм мин — авызына чәйнәп салганны көтеп утыра торган яшьтә түгел ул хәзер.

## I

«...Безнең Янбулат авылында Айдарлар бер мин генә түгел. Мине, Кәҗә Шаяхмәт Айдары, дип йөртәләр иде. Ни өчен — Кәҗә Шаяхмәт? Анысын менә хәзер белерсез. Берчакны шулай, минем әти Теләче базарыннан безнең авылның Гыймай Сәләхиләренә утырып кайткан (безнең үзебезнең атыбыз юк иде шул). Барысы да исерек булганнар тегеләр. Теләче базарына бар да исереп тә кайтма, имеш. Сүз иярә сүз чыккан, бәхәс киткән. Дуамалрак кеше иде минем әти.

— Их, ит ашыйсым килә, әгәр булса, бер кәҗә ашап бетерер идем,— дип ташлаган.

Авызы ипигә туймаган ярлы кешене котыртырга күпме генә кирәк соң! Тегеләр тотыналар моны кыздырырга:

— Бетерәсеңме дә бетерәсеңме?

Әти:

— Бетерәм булгач, бетерәм!

— Бетерсәң, сиңа бер кәҗә, бетермәсәң, син безгә бер кәҗә,— диләр тегеләр.

Шалт та шолт. Кайталар да, җиңел кулдан — бисмиллаһи аллаһы әкбәр... бер кәҗәне егалар да суялар. Башкасын белмим, әмма ләкин әйткән сүзеннән кайтмый торган ие минем әти. Бер кәҗә итен бер утыруда ашаган да бетергән шул. Әле җитмәсә, кичкырын кайдандыр алып тагын бер стакан аракы төшергән дә, Сәләхиләргә барып:

— Аның шулпасы да булырга тиеш, нигә миңа шулпасын бирмәдегез,— дип дау кубарып йөргән.

Әнә шуннан бирле безне Кәҗәнекеләр, Кәҗә Шаяхмәтнекеләр, дип йөртәләр. Хәер, төкерергә. Авылда кушаматсыз кеше буламыни. Кәҗә Шаяхмәт малае гына булсам да, үскәнмен әле. Таякны ат итеп уйнауларны, мулла бакчасыннан алма чәлдерүләрне сөйләп тормыйм. Алма, дигәннән, безнең Янбулат авылына берчакны шулай алма сатучы килде. Әллә шуннан башлап китәргәме? Әй, шуннан башлап китимче әле. Июль ахырлары микән, август башларымы, әйе, алма сатучы килде. Аты яхшы — тимгел-күк. Ялы — көлтә төсле, утырып кына тора. Шлеясыйөгәне — барысы да тәңкәле. Арбасын карага буяган, тимерле арба. Ә арбада — зур-зур әрҗәләр, ә әрҗәләрдә — берсеннән-берсе эрерәк алмалар. Кып-кызыл. Ул исе, ул исе... Бөтен авылга җәелде исе. Госман, безнең күрше малай, ис сизәргә дигәндә аңардан да җәһәт кеше юк инде. Алма исе иң элек аның курнос борынына барып кергән, ул, читән өстенә басып, миңа кычкырды.

— Әй...Айдар, алма сатучы килгән. Әйдә, киттек!

Әйтүе булды, шул якка элдерүебез булды. Алма сатучы, атын җай гына атлатып, урам буенча бара да бара, үзе: «Алма сатам, ал-ма!» — дип кычкыра. Кешеләр күбрәк җыела төшкәч, атын туктатып, сату итә башлый. Ә безнең авыл кешеләре, дөресен әйтим, алманы элек-электән яраталар. Карты-карчыгы, баласы-чагасы, килене-кызы — барысы да йө-

герә. Кайсының кулында ике-өч йомырка, кайсысы чиләк төбенә салып ясмык алып чыга, ә кайбер шуграк малайлар әбиләренең сәдакага дип адарынып куйган ике тиенлек, өч тиенлек бакырларын чәлдереп чабалар. Әбиләре артларыннан капка төбенә чыгып кычкырып кала: «Сәдакага дигәнем генә ие, кая алып олактың, муеның астына килгере!» Ә алма сатучы, мондый шау-шуларга бер дә исе китмичә, товарын мактап-мактап сата да сата. Үзе дә бик көяз кеше иде шул, каһәр. Каракүл бүрекне кыңгыр салган, өстендә трико кәзәки, кәзәки кесәсеннән сәгать чылбыры салынып тора, ә телгә дисәң, товарын мактарга дисәң, авызына шайтан төкергән инде. «Бу алманы сез моңа чаклы күрмәдегез, моннан соң күрәчәк түгелсез, алып калыгыз»,— ди. Безнең авыл кешеләренә шул җитә кала, этешә-төртешә кабаланалар. Янәсе, миңа үлчә дә миңа үлчә.

Без, малайлар, арба артыннан ияреп йөрибез. Алманың исен иснәгән өчен акча сорамыйлар, алманың үзен алырга акчабыз юк, арба артыннан да ияреп йөрмәгәч, безгә ни кала соң?

Атын күргәнмен, арбасын күргәнмен, алмасын күргәнмен, ә менә алма әрҗәләре арасында кысылып утырган кечкенә генә кызны, түгәрәк ак беләкле, кап-кара күзле, башына салам эшләпә кигән кызны моңа чаклы күрмичә торганмын. Алма сатучының үз кызыдыр инде ул, шөпшә төслерәк икән. Алай дисәң, шөпшәнең күзләре кара булмый бугай. Нинди була соң әле шөпшәнең күзләре? Аты әйбәт, арбасы әйбәт, алмасы әйбәт, ә кызы барыннан да әйбәтрәк. Шөпшә төсле, дип юри генә әйттем мин, бөтенләй шөпшә төсле түгел.

Бүтәннәр алма карыйлар, мин кыз карыйм. Кыланчык нәрсә икән, эшләпәсенә ал тасма бәйләгән булган. Безнең авылныкы булса, мин аның эшләпәсен чәнчә бармак белән эләктереп алыр ием дә, өй түбәсенә атып бәрер ием. «Алып бир дә алып бир»,— дип, соңыннан минем тирәмдә тик бөтерелеп йөрсен. Безнең авылныкы түгел шул. Әллә, алма караган булып, якынрак килеп карарганмы? Әтисе күрер каһәрнең. Алма чәлдерергә йөрисең, дип борынга чиртер. Шулай да арбага якынрак елышам, арт карамага тотынам. Бушаган әрҗәләргә поса төшеп, кызга якыннанрак карап торам. Шактый ук озак карап торам, ә ул күрми дә күрми. Ә күрсен иде, каһәр. Бер дә булмаса әтисе күрсен иде. Ә болай берсе дә күрми. Әллә арба тәгәрмәченә басып карарганмы? Бастым. Кинәт үсеп киттем. Кызны хәзер колак йомшакларына чаклы күрә башладым. Әллә агач ботагында алма белән бергә үстеме икән ул? Битләре нәкъ алма төсле. Чәчен зәңгәр тасма белән кушып үргән, маңгае ап-ак, күзләре түгелергә торган төсле. Ә үзе шул кечкенә генә куллары белән үлчәү тәлинкәсе тирәсендә маташкан була. Герләр алып сала, алма тутырыша, мине ичмасам бар дип тә белми. Ачуымны китерсә, чәчүргеченнән тартырмын әле. Уйлавым булды — тартуым булды. Карамас жиреннән карады кызың. Карады, аннары көлеп җибәрде. Тешләре уенчык төсле ап-ак. Алма ашап шулай агарып беткәндер инде ул, дим эчемнән генә. Ә үзем, күземне терәп, карап тик торам. Кыз үлчәү тәлинкәсе тирәсендә бераз маташты да тагын борылды, тагын миңа карады. Бу юлы инде мин аның бит очындагы кечкенә миненә чаклы күреп калдым. Әйбәт кыз, әйбәт. Безнең авылныкы булса, мин аның хәйләсен табар идем, колак йомшагыннан гына тешләп алыр идем, безнең авылныкы түгел шул.

Дөресен генә әйткәндә, әлләни эшләдем мин. Алманың исен сизми башладым, үземнең Кәҗә Шаяхмәт малае гына икәнлегемне оныттым, ә Госманнар әнә һаман шул тирәдә чуалалар. Берсе, берәүгә дә сиздермичә, эләктерде дә бугай, ахры. Алма сатучы килер дә китәр, иптәш малайлардан аерылырга ярамый. Ачык авыз, дип соңыннан үртәп йөдәтүләре бар үземне.

Мин арбадан бер читкә китәм, берсенә дә карамаган бер төс белән басып торам. Кыз күтәрелә дә карый, тешләрен күрсәтә. Үзем дә сизми калганмын, минем дә тешләр күренеп киткән тегеңә. Шуның артыннан

озак та тормады, ул кыз, бик зур, бик матур бер алманы сайлап алып, әтисе күрмәгәндә генә миңа атып бәрде.

Мин инде бик әйбәтләп кенә тотып алдым. Аннары нәрсә булган — берсен дә белмим. Нигә, дисәң, кинәт башым әйләнеп китте минем, өйгә йөгердем. Малайларның әйтүенә караганда, аннары ул алма сатучы, атын җай гына атлатып безнең авылдан чыгып киткән. Кая киткән? Берәү дә белми. Авылдан чыккан чакта аның кызы бушаган әрҗәләр өстенә утырып, арбадагы бөтен әйберләрдән, әтисенең үзеннән дә, атның дугасыннан да биегрәк булып, озакка, бик озакка чаклы күренеп барган. Аның зәңгәр тасмалары белән җил уйнаган, ә ул үзе басу капкасын чыкканнан соң да каерылып-каерылып безнең авыл ягына таба карап барган.

Ә Госман, курнос борын, мине мыскыл итмәкче була.

— Алма сатучының кызы алманы сиңа дип атмады, үлчәү тәлинкәсенә салам дигәндә кулыннан ялгыш төшеп китте,— ди.

Мәтәштерми генә тор! Ялгыш кына төшеп киткәч, нигә соң ул минем кулга килеп эләккән, нигә Госман кулына эләкмәгән?

Дусын дус та син, Госман, шулай да әллә нәрсә генә бар синдә. Нигә инде кешене алай үртәргә? Бүген алма сатучы узган, иртәгә кыяр сатучы узар. Безнең Янбулат урамы киң ич ул. Шулай да, күп бәхәсләшеп тормыйча, әйдә, су кереп кайтыйк әле. Әллә нәрсә, бик эсселәп торам мин бүген.

Күз ачып йомганчы без, Госман белән икәү, тегермән буасына су керергә йөгерәбез. Ә теге алма һаман кулымда.

## II

Аннары ул менә болай була.

Кыш узып, яз җиткәч, сабан чәчүләре беткәч, безнең яктагы авылларда, борынгы гадәт буенча, җыеннар, сабан туйлары башланып китә. Яшь киленнәр чүпләмле сөлгеләрен әзерлиләр, колмак турында, сыра утырту, бал әчетү турында сүз китә — алары аның олы кешеләр эше. Ә бит Янбулат авылында безнең ише койрыксыз әтәчләр дә җитәрлек. Хәер, Госман белән без әллә кайчан ук сөйләшеп куйдык инде. Җыеннар башланса, ат чаптырырга барабыз. Тизрәк җитсен генә

Көтә торгач, җитте тагын. Элек безнең авылда җыен булды — бездә шауладылар, аннары күрше авылларда җыен булды — аларда без шауладык. Әти, ат чаптырырга барасы булма, дип алдан ук колак итемне ашап куйган иде дә, әче бал пары кереп кызып киткәч, әти мине оныткан, мин — әтине. Безнең якта шундый итеп әчетәләр балны, эчкәннән соң баш туктый, аяклар гына эшли башлый. Ә минем әти ул, туры килгәндә, әче балны «мичкәсенә чумыймсана» дип эчә торган кеше.

Теләсә ни булсын, быел теләгемә ирештем. Җиңел сөякле малай, дип гел мине эзләп йөриләр. Рәхәт тә соң ат өстендә килү! Бөтен халыкның күзе синдә. Атның кайнар ялы синең битеңә сирпелә. Ә алда, биек колга башында, берсеннән-берсе матур булып сөлгеләр күренәләр. Кайдадыр кычкыралар:

— Каула, Айдар, каула!

Йөри торгач, без Мамалай җыенына ук барып чыктык. Анда Госманның анасы белән бертуган апасы бар икән, аларга кереп бераз сыра эчтек. Сыраларына нәрсә булса да берәр усал нәрсә кушканнар булса кирәк, эчкәч кәеф килеп китте. Аякны тыеп торып булмый, кәҗә бәрәне кебек гел сикерәсем генә килә — Кәҗә Шаяхмәт малае түгел, диген син! Кеше ничектер, мин үзем азрак кәефләнсәм, шулай инде, чикерткә дә — чикерткә, мин дә — чикерткә. Тыпырдап йөри торгач, арадан берәр танышбелеш килеп чыгуы да бар. Былтыр әнә алма сатучының кызы күңелне әллә нишләтеп китте бит. Төшкә кереп йөдәтеп бетерде, каһәр. Күземне

йомар хәлем юк, әллә кайдан килеп чыга да тешләрен елтыратып көлеп тик тора. Ничек кенә булмасын, җыенда рәхәт.

Кызлар тирәсендә чуалып йөри торгач, бер усал хатынга очрап, аның белән талашып та алдык. Кулы бар, имеш, аның, кашытсаң — арканы кашыйсы. Хәер, төкерергә. Шуның өчен җыен ич ул. Шулай да гарьләндем, әй. Белгән малайлар, Госман күрсә, кая керер җиреңне тапмассың. Госман ул, үзенә күрә почык танау түгел, авызын ерып кешене мыскыл итәргә генә тора.

Бөтен кешеләрдән аерылып, япа-ялгызым, бер читтә пәке белән юнышып йөрдем. Үзем шулай йөрим, үзем уйланам: матур кызлар нигә болай сирәк булалар да әнә шундый усал хатыннар нигә күп булалар? Ә бит кирәсенчә кирәк ие.

Йөри торгач, онытылып кала язганмын, ат җибәрер вакыт җиткән икән. Тизрәк мәйданга, халык арасына йөгердем. Госман инде бер атка менеп тә алган. Колагына яулык бәйләгән, ал күлмәген балкытып, атның аякларын кыздырып йөргән була. Ә күзләре — халыкта. Янәсе, күрәләрме аны. Яратмыйм шулай болганып йөрүне. Йөреп-йөреп баш килсәң, тагын бер хәл. Ә иң актыктан сөйрәлергә калсаң, егыл да үл инде. Иң яхшысы: егетлекне кинәт күрсәтү, кеше көтмәгәндә күрсәтү. Язгы яшен төсле ялтырыйсың, аннары югалсаң да ярый.

Хәер, ни генә булса да, Мамалайда булмасын инде. Теге усал хатын белән талашканнан соң нинди егетлек турында уйлап торасың ди. Шулай да колакларым үз урынында икән әле.

— Кая, минем атны кем алып бара? — дигән бер тавыш ишетеп калдым.

Икеләнеп торулар бөтенесе коелды:

— Бир, абый, үзем! — дип кычкырдым.

Ике минуттан мин инде ат өстендә идем.

Атның аякларын кыздырып тормадым. Хуҗасы үзе дә таякны тиз сындырырга ярата торган кеше икән.

— Әнкәсен, бик чая мал, дип сатканнар ие. Йөрәгендә булса, аягында булыр. Әйдә, атлан да кит, — диде.

Аты болай җиңел күренә. Тояклары да түгәрәк, борын тишекләре дә парлы, бәлки, нәрсә булса да чыгар.

Китә башлагач, атның иясе мине туктатып, колагыма тукыды:

— Кара аны, баш килерлек булмаса, хайванны юкка яндырма. Тот та, аермадан ук сулга каер, авылның аргы башында мин үзем каршы алырмын.

Җавабым юк, дөрес сүз. Булмастайны камчылаудан ни файда? Киттек. Барыбыз җидәү: Госман, мин, калганнары ят малайлар. Атлар барысы да — күрер күзгә ягымлы маллар. Уйнаклап кына баралар. Арада бер озын торыклы байтал мине бигрәк тә куркыта. Еш-еш пошкыруыннан, башын чайкап баруыннан ук сизенәм — чапак хайван булса кирәк.

Малайларның үзара сөйләшеп барулары да колагымны кытыкламый түгел.

— Кибәхуҗалар килмәс, диебрәк чыккан идек, болай булгач, безнең борынга суктыгыз инде сез.

— Без сукмадык, байтал сукса — сугар.

Аннары алар эч пошыра торган татулык белән тагынниләрдер сөйләшәләр. Мин бер сүз дә дәшмим. Дәшә алмыйм мин. Кешеләрнең үзеңнән узып китүләре турында алдан ук мондый тыныч итеп сөйләп бару өчен эчеңдә җаның булмаска кирәк. Яратмыйм мин мондый татулыкны! Йә дәшмим, йә сугышам.

Госман, тегеләр белән сөйләшеп бераз бара да, аннары арткарак калып, атын минеке белән тигезли. Сер итеп кенә әйткән кебек, авыз эченнән генә пышылдый:

— Монда, малай, рәт чыгара алмабыз ахрысы без. Барысы да шомарган таш күренә. Әнә теге кашка байтал әйләнә-тирәдә бер атны да чыгармый, ди.

— Күренер әле, барып карыйк,— дим мин, сүзне юри кыска тотам.

Бераз җир сүзсез барабыз. Бу сүзсезлек Госманга ошамый, ул, атын сикертеп, алгарак китә.

Барып җиттек. Тезелдек. Чыктык. Башта, бер-ике чакрым җирне барыбыз да тигез килдек, дип әйтерлек. Бу араны атлар җиргә түгел, хәйләгә басып килделәр. Бер-беребезнең чамасын тарттык, йомшак якларны капшадык. Госман, чыгу белән дип әйтерлек, камчысын айкый башлады, ара-тирә йөрәксеп кычкырып та җибәрә, тик шулай да ул берәүне дә куркытмый. Аның түшәмен без шунда ук күрдек. Моннан соң ул, ничаклы тырышса да, артык сикерә алмаячак. Ул бездән, бер җир буе дип әйтерлек, алда бара, тик шулай да мине ул түгел, арттан уйнаклап килүче теге кашка байтал шикләндерә. Үз атымның чамасы үземдә, камчы тидерергә ашыкмыйм — бар нәрсәнең дә вакыты була бит.

Ниндидер юл аермасын үттек, берәү шунда кинәт кенә:

— Һа! — дип кычкырып җибәрде.

Колагыма җил бәрелде, тояклар ярсу белән тупырдадылар. Күземне ачып йомарга өлгермәдем — кашка байтал минем алга сикереп чыкты. Аның арт тоякларыннан балчык атылып минем битемә бәрелде, бераз вакыт күземне ача алмыйча бардым, ә күзне ачарга вакыт бик җиткән иде.

Алда, берничә чакрым ераклыкта, колга башындагы сөлгеләр чагылып киттеләр. Күренделәр, аннары тагын югалдылар. Хәйлә бетте, безнең аяк астында хәзер җир, җитмәсә тагын нинди җир! Йә күтәрә ул, йә башыңны яра. Мин, ике бармагымны тешемә кысып, сызгырып җибәрдем һәм беренче мәртәбә атыма камчы селтәдем. Уен түгел икәнлекне ат та сизде булса кирәк, кинәт сикереп алды, мин чак кына артка очып калмадым. Күз алдымда нәрсәләрдер тиз генә яктырып киттеләр, кинәт сүнеп калдылар, битемә үз атымның әчкелтем пары килеп бәрелде. Тагын шул: теге аермадан узып бер-ике генә сикердем, Госманның артына килеп бастым. Аның атының ухылдавы ишетелә — бу дәртлелек түгел, хәлсезлек билгесе. Минем Госманнан көләсем килде, тик көлгәнче тагын бер сикерәсе бар иде әле. Атыма тагын бер селтәнеп җибәрдем — без хәзер аның белән тигез барабыз. Тагын бер селтәнсәм, мин аны артка калдырачак идем. Госманга бу ошамады. Атына шәп кенә пар өстәмәкче булып селтәнде дә, минем атның алга сузылып бара торган борынына сукты. Ачу белән ярсып, Госманның битенә камчым белән селтәп җибәрдем. Ул чайкалды, аты өстеннән очып төшеп калды. Соңыннан гына белдем, каты сугылган икән мескенгә, алты ай буена яңагын бәйләп йөрде, ә соңыннан гомерлек яра эзе калды.

Госманнан, тагын берничә ярканаттан җиңел генә узып китсәм дә, кашка байталдан узу ансат булмады. Ул сөлек сыман сузылган, ничектер агып бара. Өстендәге малае да бөҗыр кебек. Кадаклангандай утырган да, кулларын як-якка болгаштырып, очып кына килә. Атны борчымый, телен белгәндәй, әллә нидә бер кычкырып кына җибәрә.

Сөлгегә килеп җитәргә ярты чакрым чамасы җир калганда, без икебез дә бер тигезлектә бара идек. Мәйдандагы халыкның умарта кортына тиң гөжләве ишетелә башлады. Кемдер ярсулы тавыш белән:

— Каула, Айдар! — дип кычкырып җибәрде.

Кауларга кирәк икәнен мин үзем дә бик яхшы белә идем, шулай да ул ярсулы тавыш ярап куйды, тартып алгандай булды ул. Мин, тешләремне кысып, селтәнеп җибәрдем, нидер аугандай булды, бөҗыр күк малай артка шуды, сөлгегә ярты җир буе калды, дигәндә, минем атым кашка байталның алдына сикереп чыкты. Күзләремә яшь килде — үзем өчен түгел, кашка байтал өчен.

Мине ат өстеннән кочаклап алдылар, ә атның муенына бик озын сөлге эленде. Кайсысыныкы булгандыр, әйбәт сөлге иде ул. Әле хәзер дә, авылны, бала чакны искә төшергән минутларда, бүтәннәр белән бергә, күз алдымда һаман шул кызыл башлы озын сөлге җилфердәп тора кебек...

Әйтерсең лә, әллә ни эшләгән — мине рәхмәт белән коендыралар гына. Аннары коры рәхмәттән юеш әче балга күчәбез. Атның хуҗасы — Исмәгыйль абзый, дигән кеше — кайдадыр күргәнем дә бар бугай ие үзен. Аема-ваема куймыйча, мине үзләренә кунакка алып китте. Бай гына кешеләр икән, өйләре калай түбәле, капкалары буяулы, идәннәре дә буяулы, мин элек басарга да кыймыйча торган ием дә, бераз кунак булганнан соң, биеп тә җибәргәнмен тагын.

Исмәгыйль абзый үзе гаҗәп күңелле кеше икән, мине җырлый-җырлый эчерә. Ул җырлаганда, мин аның авызына карап утырам. Иреннәре әллә ничек, миңа таныш төслерәк селкенә, кайда гына күрдем соң мин бу кешене? Хәтерләп карыйм, юк. Берни дә искә төшми. Барысы да юылган. Мамалай балын эчкәнем юк иде, шулай икән шул, барысын да юып төшерә икән.

Ашагач-эчкәч, мин инде кайтып китмәкче булып ишеккә карый башладым. Кунак булу рәхәтен рәхәт тә, шулай да ишек дигән нәрсә бар бит дөньяда. Кергән ишектән вакытында чыгып китә белергә дә кирәк.

Тик Исмәгыйль абзый минем сүзне ишетергә дә теләмәде. Бүген бездә кунарсың, иртәгә ихтыярың, теләсәң кая бар, ди. Әллә чынлап, әллә юри әйтә: кичен менә кызлар уенына барырсың, дип ычкындыра. Хәйләкәр төлке син, Исмәгыйль абзый, бер утырып бал эчтек, мине колак йомшакларыма чаклы белеп бетердең. Кайдан белгән соң ул минем кызлар яратканны?!

Шулай да мин сүземне бирмим:

— Китәм булгач, китәм! — дим.

Исмәгыйль абзый үзенекен:

— Җибәрмим булгач, җибәрмим!

Мамалай балының тагын бер кызык ягы: эчкәч аяклар тик тормый икән. Биегән булдым, селкенгән булдым, ә аякларым һаман тыпырдап торалар. Имеш, аларга эш тап. Ишегалдына чыгып киттем. Матур гына бакчалары бар икән. Алма, шомырт, миләш, карлыган, чия — баш тыксызыз. Шулай да кердем. Аптырап тик торам. Дөресрәге, бүрегем белән киңәш итәм: китәргәме, калыргамы? Китәр ием, баллары бик әйбәт, аннары тагын кызлар уйнаган җиргә дә барасы килә. Китмәс ием, мин аларга кем? Коры бер тыпырдавык. Идән таптаучы. Шулай уйланып, бүрек белән киңәш итеп торганда, кинәт бер яфрак селкенеп китте. Аннары икенче яфрак селкенде. Аннары куе булып, төптән чыгып үскән бер карлыган агачы дерелдәп куйды. Карлыган агачы белән бергә минем йөрәк тә дерелдәде. Ни булыр бу? Басып тик торам. Миннән киңәш шул: андый хәвефле минутларда басып тик торудан да файдалысы юк икән. Карлыган агачы тагын селкенде, мин ни дип әйтергә дә өлгермичә калдым, бер кул күренде. Кечерәк кенә кул. Башта мин аны кош дип торам, кул икән. Кызлар кулы булса кирәк, йөрәгем шулай ди. Басып тик торам. Башыма бер карлыган ботагы килеп төште. Тагын берәү. Тагын.

— Шаярмагыз! — дип кычкырып җибәрдем.

Ничек кычкырмаска ди соң, ул бит бөтен карлыган агачын сындырып бетерер. Ә теге кул шаяра да шаяра.

Мамалай балының сез белми торган тагын бер гаҗәп ягы — карлыган бакчасында калтыратып калдыра икән. Калтырап тик торам, әй. Шулай да бераздан атладым. Үзенә таба якынлашуымны күргәч, теге кулның иясе агач төбеннән кинәт пырхылдап килеп чыкты. Ул — карлыган куагының теге ягында, мин — бу якта. Карлыган куагы безнең билебездән генә.

— Мин сиңа бервакытны алма белән бәргән идем, исеңдәме? — ди ул, вак кына тешләрен күрсәтеп көлә.

Карлыган куагы безнең билебездән генә, кыз инде шактый ук үскән, күкрәге беленеп килә.

— Сез безнең авылга алма сатырга килгән идегез, — дим мин.

Ул арада баскыч төбеннән: «Вәсилә, син кайда? Өйгә кер!» — дигән тавыш ишетелә.

Шулай итеп шул, кош дигәнем Вәсилә булып чыкты. Әйбәт, бик әйбәт.

Вәсилә китмәкче булды, китмәде, тагын посты. Ә бераздан пышылдаган тавыш белән:

— Син китмә! Кун бездә, кун,— дип кыска-кыска гына итеп әйтеп куйды.

Үзе тагын карлыган куагы төбенә посты. Мин ни дип әйтергә дә өлгермичә калдым, ул, агачларга поса-поса, бакчадан чыкты да йөгереп өйгә кереп китте.

Узган елдан бирле байтак кына су аккан, аз-маз гына акыл да кергән, шуның өстенә тагын сабан туе вакыты, кош дигәнем Вәсилә булып чыкты. Вәсилә дигәнем минем төшемә кереп йөдәтеп бетергән алма сатучы кызы икән, болай булгач, коры идән таптаучы гына түгел инде мин.

Өйгә кердем дә, Исмәгыйль абзыйны күреп әйттем:

— Бүген кунам инде мин сездә, Исмәгыйль абзый,— дидем.

## III

Кундым. Ә кунмасам, яхшырак буласы икән. Вәсилә аш өе белән ике арада әле анысын, әле монысын ташыган булып чабуланып йөрде дә, кич белән яңа күлмәген киеп, ишегалдында бөтерелергә тотынды. Чандыр гына кыз, бу хәтле купшылык каян килгән, диген. Чәчләрен тасмалар белән күмгән. Өстендә аклы күлмәк. Җитен чәчәге төсле вак-вак кына — бөрчекләр төшкән. Челтәрләп, иңбашларына каплавычлар салындырып теккән альяпкыч.

Үзем унбиш яшьлек малай, ә эчемдә шайтан утыра. «Кысып карарга иде бу кызны, сыңар учка сыеп бетәр иде микән?» — дип уйлыйм.

Аннары алар күрше кызлары белән, чыр-чу килеп, әллә кая чыгып киттеләр. Ишегалды бөтенләй бушап калды. Капка төбенә чыктым. Утырып тордым. Аннары әйләнеп кергән булдым. Ә Вәсилә күренми дә күренми. Йолдызлар яктыра башладылар. Әллә нинди искитмәле йолдызлар. Үзләре яшькелт, үзләре баш очында гына диярлек, катырак җырлап җибәрсәң, өстеңә коелырга торалар. Безнең Янбулат авылында мондый йолдызларны һич күргәнем юк ие минем. Чынлап та әллә нинди генә булды ул кич.

Шул кичне, иптәш кызлары белән уйнап кайтышлый, Вәсилә минем янга туктап, миннән:

— Син ни атлы? — дип сорады.

Мин исемемне әйтеп өлгермәдем, ул, балаларча чытлыкланып, икенче сүзгә күчте:

— Безнең атны тәки баш китерден бит син! Ничек курыкмадың?

Мин ни дип тә әйтә алмадым, ат өстендә килү кызлар белән сөйләшүгә караганда чүп кенә икән. Вәсилә үзе шулай чикерткә генә булса да, батыр булып чыкты.

— Нигә сөйләшмисең, сөйләш, сөйләш инде! — дип минем янымда таптангалап торды да, ахырында миңа кулы белән төртеп, ишегалдына йөгерде.

Сөйләшә алмасам да, кулга киткәч бирешмим инде мин. Песи кебек сикереп торуым булды, кызыйны капка баганасына китереп кысуым булды. Чырылдаган була, үзе шундый җиңел, шундый җиңел!

— Безгә тагын кил, яме, Айдар! — ди бу миңа.

...Юк, мин аларга ул җәйне тагын бара алмадым. Нигә, дисәң, киемем әйбәт түгел минем, оялдым. Ул чук төсле, ә мин әти кәзәкиеннән бозып теккән кыска җиңле камзулдан. Бөтерелеп йөрер-йөрер дә, ахырында бер көнне әйтер: «Син, малай, әтиеңнең кәзәкиеңнән калмыш камзулын киеп минем тирәдә йөрмә әле»,— дияр. Әйтмәсә дә, үзем беләм мин — кызлар

сөйсен өчен иң элек бер пар ялтыравыклы итек, бер тужурка, сатин күлмәк, хәтфә кәләпүш кирәк...

Җәйге эшләрне бетергәч, иң кимендә әнә шуларны эшләп кайту нияте белән, шахтага китәргә булдым. Әти белән әни каршы торып караганнар иде дә авызларын тиз томаладым. Җилкәм үсте, синең искеңнән бозып теккән камзулга сыймый башладым, дидем. Шуннан үзләре аңладылар тагын. Эш хәзер конторда, пашпорт алуда. Баштан ук шикләнгән идем, дөрес шикләнгән икәнмен, конторда күземне дә ачырмыйлар. Яшелрәк әле син, диләр. Тагын бер-ике җәй Янбулат кояшы астында пеш, аннары шахта тишегенә таман гына булырсың, дип көләләр. Мәтәштермәгез, бар пешүем житкән минем, китәм булгач — китәм. Контор идәннәренә төкермәдем дә ичмасам, пашпортсызнисез киттем дә бардым.

Юлда Кәче авылы кешеләренә очрап, алар белән бардык. Безнең ярты авыл шахтада, үзебез урнаштырырбыз, диделәр. Яшькә яшь булсам да, буем бар минем, кулларым да бар. Кәче кешеләре ошатып ук куйдылар. «Афарин, йөрәгең житкән»,— диләр.

Голубовка дигән шахтага килеп җиттек. Чынлап та, Кәче кешеләре баскан икән үзен, килгән көнне үк җыелып эчтеләр, мин — бердәнбер Янбулат малае — бөтенләй югалып калдым. Эчтеләр, эчтеләр дә аннары Эт бистәсе дигән урынга кайтып сугыштылар. Барысын да эчемә җыеп кына торам. Хәер, эчкә җыярлык әллә нәрсә дә юк. Кәҗә оясы хәтле генә өйләр, стеналары балчыктан, тәрәзәләренең ватылган өлгеләренә иске мендәрләр тыгып куйганнар. Ул бала, ул чебен — ерып йөргесез. Нужаны мин безнең авылда гына дип уйлаган идем, монда да бар икән ул нужа, монда әле озынрак сакаллысы көтеп торган икән.

Беренче тапкыр клеткә утырып шахтага төшкәндә, әти белән әнине искә алуымны, ходокның түшәменә маңгаемны бәреп күземнән утлар күренгәнне, лавага кереп җиткәч, лампам сүнеп, нишләргә белмичә аптырап калуымны язып тормыйм. Карт шахтерлар әйтәләр, башта ул шулай була, диләр. Беренче көннәрдә үземне дә түгел, кешеләрне дә түгел, атларны кызганып йөдәдем. Сукыр атлар. Мескеннәр, гомерләре буена шунда җир астында вагонетка тартып интегәләр икән. Күзгә карагандай мөлдерәшәләр җаннарым. Болар янында безнең җир өсте атлары кунак кызлары икән. Якты кояш астында рәхәтләнеп эшлиләр, яшел тугайларда утлап йөриләр. Ә сабан туйларында инде үзләре дә ирек ача, кешене дә ирек ачтыралар. Кинәт Вәсиләләрнең чабыш аты исемә төшә. Их атланыр идем дә туган-үскән җирләремә кайтып китәр ием.

> Атландым атның биленә,
> Киттем сахра җиренә...
> Их!

Килүемә ун көннән артык түгел, әле беренче получканы да алмаган, ә күңел, читлеккә керәсе килмәгән кош кебек, әллә кайда очып йөри. Барысы да, барысы да синең өчен бит, Вәсилә! Аллы-зәңгәрле тасмалар тагып, шомырт кара күзләреңне сирпеп, сикергәли-сикергәли әллә кайдан гына килеп чыктың да мине менә монда, җир астына китереп тыктың. Ялтыравыклы итекләр киеп кайтсам, үзеңнең дә үзәгеңне өзәрмен әле өзүен.

Өмет тә киң, кесә дә тирән — акча гына аз. Беренче получкадан соң: «Бу нишләп болай гына?» — дип телемне кузгатмакчы булган идем дә арт яктан кемдер килеп иңбашымнан тотып алды.

Әйләнеп карасам, Рахман абзый тора. Минем белән бергә килгән Кәче кешесе. Азрак төшереп тә алган үзе, күзләре елтырый. Көлә бу.

— Маңгаеңда тир, аяк астында җир исән булсын, диген, тиле малай, акчаны монда санап кына бирәләр,— ди.

Якташ итеп, үзе белән яртыны сындырырга чакыра. Бармадым. Кешене белмим, минем үз исәбем — үземдә. Кием-салымны рәтләрлек акча җыеп булса, монда — җир астында тончыгып ятасым юк. Китәм, буразнама кайтам. Төннең-төн буе йокламыйча акчамны исәпләп чыктым — мин дигәнчә түгел. Иртәгесен, бүтән бер кешене дә күрмәгәч, техникка бәйләнә башлады.

— Ни өчен болай? — дим.

Шаркылдап көлә генә.

— Безнең җир астында ни өчен болай дигән сорауга җавап бирү гадәте юк ул, — ди.

Китте дә барды. Бары тик итекләре генә күз алдымда ялтырап калды.

Тырышсам, әнә шундый итекләргә тырышам инде мин. Басканда шыгырдап тора торган булсын, кунычында кояш нуры уйнасын. Тик менә җир астында «ни өчен?» дигән сорауга җавап бирмәүләре генә хәтәр икән.

Эчмәдем, тартмадым, ике ай дигәндә саф унбиш сум акча җыйдым. Ә теге техникка һаман ачуым кабарып йөргән көн. Штраф дип бөтенләй юк нәрсәләр өчен минем өстән язып чыгара икән. Астан шулай язып чыгаргач, өстә синең белән сөйләшеп тә тормыйлар. Әгәр шул ләгънәт төшкән штрафлары булмаса, минем акчам егерме биш сум булыр иде инде. Получка саен кесәдә икмәклек-тозлык, чәйлек-шикәрлек калдырам да, калганын әйбәтләп кенә төреп, бүрек түбәсенә, эчкә тегеп барам. Кәче кешеләре — картрак шахтерлар — миннән көләләр.

— Синдәй яшь бер егет, моннан элек тә шулай, ашамыйча-эчмичә акча җыйды-җыйды да, җыелган акчасы җир өстендә, ә үзе лава ишелеп җир астында калды. Аша-эч, әти тапкан мал түгел, үзебез тапкан җәл түгел, — дип дусларча җилкәмә кагып куялар.

Бөтенләй читкә этеп ташламасыннар тагын, дип буш чакларда алар белән кәрт уйнаштыргалыйм. Этлекне дә белә башладым. Күз ачыпйомганчы бер кәртне икенче кәрт белән алыштырып куям. Күрсәләр — ипи шүрлегеңә эләгә, күрмәсәләр — бөтен кон минеке. Бүрек түбәсе һаман калыная бара дигән сүз.

Берсе өстенә икенчесен тегә-тегә берчакны шулай бүрекнең эче бөтенләй кечерәеп калды. Кешеләр көләләр, нигә синең бүрегең баш очында гына эленеп тора, диләр. «Хәере белән торсын, сезгә дә шуны телим», — дим эчемнән генә.

Тамагымнан кысып, алдашып, арысын аударып, биресен түнтәреп тотырган идем, бушавын бик тиз бушады.

Ә ул болай булды.

Берчакны шулай баракларда шау-шу купты. Имештер, Урал ягыннан атаклы картежник килә. Безнең Голубовкага түгел — кая ул безгә андый атаклы кеше килсен. Үтеп барышы, имеш. Түземсезлек белән көтеп тора башладык. Әллә нинди имеш-мимеш хәбәрләр таралды. Эт бистәсе туйга әзерләнгән кебек әзерләнде. Берзаман менә ул килеп тә төште. Кып-кызыл мыеклы, күзләре ут уйнап тора, үзе байларча: ак яка, чылбырлы сәгать, ботинкалары ялык та йолык. Күргәч тә йөрәгем жу итеп киткән ие, тикмәгә булмаган икән. Ламповойга качып ике төн уйнадылар, кермичә йөрдем. Йөрәк каһәр суккан бит минем, түзми. Йокларга бирми, песи баласы кебек, сикереп чыкмакчы була. Ахырында түзмәдем, кердем. Кергәндә бүрегем баш очында гына тора иде, чыкканда күзләремә чаклы батты. Шулай итеп, йөрәк тыпырдаудан туктады, бүрек эче иркенәеп калды. Ә теге атаклы Кызыл мыек безнең шахтерларның барлы-юклы акчаларын сыпырды да барыбызны да эчерде, аннары үзе икенче шахтерларга күчеп китте.

Кызыл мыектан соң мин акчаны бүрек эченә текми башладым. Нигә, дисәң, бүрек эченә кәгазь тутырып адәм көлдереп йөргәнче, бар күк тапканны ашап, аннары тагын иптәшләр белән әллә нидә бер төшергәләп йөрүдән дә яхшысы юк икән. Елап утыра торган балаларым юк әле.

Шулай да Васила искә төшә, каһәр. Теге чакны, аларның капка төпләрендә, үпми дә калдым бит үзен. Курку, дисәм, юк, куркуның ни икәнен дә белмим мин. Әллә нәрсә генә булды шунда. Каушадым, ахры. Йолдызлар бик түбән төшкәннәр ие шул ул кичне, уңайсыз ие.

Табылмаган мал тау чаклы, диләр. Әтиләр дә, кайт та кайт, дип хат артыннан хат тупырдатып торалар. Пашпортсызларны бик нык тикшерәләр икән, дигән хәбәр дә йөри. Василәне дә сагындым, кайтмый булмас ахры. Алдагы получканы алгач, өс-башны бераз караштыргалыйм да — сәфәр.

Шундый яхшы ният белән йөргәндә теге, безнең штольняның техникы тагын аякка килеп чалынды бит. Имеш, мин терәүне дөрес салмаган. Терәүләр салырга җыенам әле мин сиңа, черек теш. Получканы алып, өзәсе эшләремне генә өзим. Үземә үзем ант итеп куйдым: арт сабагын укытам мин ул дуңгызның.

Җае да туры килде. Расчеттан соң, иртәгә китәсе дигән көнне, иптәшләр белән бераз төшердек тә урамга чыгып киттек. Байтак кына болганып йөрдек. Берчакны шулай, иптәшләрдән аерылып, тар гына урам буенча үзем генә килә идем, күземә күренәме, дип торам, бу сөйрәлә. Кинәт антым исемә төште, уч төбем кычыта башлады. Каршына килеп бастым. Торам. Якасыннан каптырып алдым:

— Безнең Эт бистәсендә ни эшләп йөрисең син?— дим тегенә. Шүрләде бу, ык та мык килә.— Берәр нәрсә чәлдерергә йөри торгансың әле,— дидем дә, икенче кулым белән яңагына чалтыраттым да.

Учымның кычытуы басылып ук китте. Теге кычкыра башлады, мин тагын берне. Кычкыра икән, туеп җитмәгән, дигән сүз. Нигә бирмәскә? Квартальныйның Эт бистәсендә пычагым эше дә юк, тавышка үзем белән бергә эчкән иптәшләр килеп чыктылар.

— Киткәндә бу таш маңгайның итеген киеп китәрмен, дигән антым бар ие, булышыгыз әле, егетләр,— дим.

Егетләр тегенең авызын томалап тордылар, мин әйбәтләп кенә ялтыравыклы итекләрен салдырып алдым.

Ничек кенә булмасын, сүземдә тордым, авылга ялтыравыклы итекләр киеп кайттым.

## IV

Кайтып бер-ике көн тормадым, Кәҗә Шаяхмәт малае кайткан икән, баеп кайткан икән, дигән хәбәр бөтен авылга таралып та өлгерде. Мыек астыннан гына көлеп тик йөрим, әйдә, дан китсен, дим. Мыек, дип юкны сөйлим, кайда әле мыек. Шәп-шәрә малай. Ә чынлап та, борын астында сызылып киткән кара мыек булса, начар булмас ие. Кара мыек, ялтыравыклы итекләр, сатин күлмәк, кесәле чалбар, куллар — чалбар кесәсендә. Урамнан узасың, бөтенесенең күзе синдә: «Әнә, әнә, Айдар узып бара!»

Башкасы бар, мыек кына юк. Хәер, төкерергә. Болай да бик әйбәт йөрим әле. Кичә Сабир кызыннан, Хәдичәдән, хат алдым. Кәгазьне чәчәкләп тутырган. «Әльхат, нисфел-мәлакать, кабул күрсәң, укып бак, кабул итмәсәң, утка як»,— дип теленә салынган. Утка якмадым ягуын, шулай да ертып ташладым. Киндер күлмәкле Хәдичә торып торсын әле, анда минс, яшь тай сыман, ефәк чукларга күмелгән Васила көтеп торадыр.

Әйдә, Мамалайга, синең апаңнарга кунакка барабыз, дип Госманга әйтеп караган ием, риза булмады.

— Ни атна, ни шимбә, килешми ул, без эш кешесе,— дигән була.

Ә мин әйтәм, килешә, дим. Киттем дә бардым.

Авылдаш, дигән булып, Госманның апасына, Ниса түтигә төштем. Бер яулык белән бер исле сабын тоттырдым — эреде дә китте. Аяк

астына ятып үлимсәнә, дигән кебек йөри. Ул чаклысы кирәк түгел, шулай да минә бу кош теледәй хат кисәген Василәнең үзенә генә илтеп бирче, Ниса тути.

Ярты сәгать тә узмады, Ниса тути, шундый ук «кош теле» тотып, әйләнеп тә кайтты. «Кичкә чишмә янында очрашырбыз, шунда кил»,— дигән.

Түзә алмыйм, сезнең Мамалайда кич тиз буламы соң ул, дип Ниса тутидән сорашасым килә. Ә ул — наян хатын — үзе кыбыр-кыбыр эшләп йөри, үзе сөйләнә:

— Чәчен тарап утыра, чәче биленә төшкән... Хатны укыгач, бөтенләй аптырап калды, чәчен дә үрмәкче була, хат та язасы бар. Ишекле-түрле йөгереп йөри кызың. Ә үзенең биле сыгылып тора, буе-сыны коеп куйгандай. Каушау килешә икән тагын үзенә: ике бите алма төсле булып кызарды. Күтәрелеп карамый да үзе, шулай да күреп торам: сөрмәле күзләреннән дәрт ява.

Җитәр, Ниса тути! Синең сүзләреңне тыңлап бетерә алмам, сезнең кичегезне көтеп тәкатем җитмәс. Аякка ялтыравыклы итекләрне киеп, өскә зәңгәр сатин күлмәкне элеп, күлмәк өстеннән билгә чук асып урамга чыгып киттем. Урамның нәкъ уртасыннан барам — булды, урамның читеннән күп йөрдек, уртасыннан йөреп карыйк әле.

Василәләрнең өй турыларына якынлашам, йөрәгем дөп-дөп тибә. Күрә микән, юк микән? Кичен очрашырбыз без, ул турыда сүз дә юк, көндез, кояш яктысында күреп кал син мине!

Узып киттем, бераз чиркәнчек алгандай булдым. Матур кыз дигәннәре кызык кына нәрсә икән — йөрәккә кереп утыра да, чыкмый да чыкмый.

Шулай да кич җитте тагын. Итекләремне ялтыратып, сатин күлмәк өстеннән пиджак элеп чыгып киттем. Чишмә буена барып бастым — кызлар су китерергә тотынганнар гына. Бераздан, гармонь уйнатып, берничә егет тә килде. Рәтлерәкләрен сугышка алып бетергәннәр, ахры, болары корырак сөякләр. Шулай да, эт оясында батыр, дигәндәй, миңа таба кырын күзләрен салгалыйлар. Кайдан килгән чыпчык бу, янәсе. Исем дә китми, басып тик торам. Авызымда папирос, кулларым чалбар кесәсендә. Яшькә яшь булсам да, гәүдә бар миндә. Күләгәм коточкыч озын булып сузылган. Тегеләрнең күләгәләре минем күләгәм янында чебеш кенә.

Бераздан ак чиләкләрен асып килүче Василә дә күренде. Әллә кайдан ук таныдым — төшемә кереп йөдәткән кыз. Нык кына үскән, тулыланган, аяклары җиргә әллә тия, әллә юк — шул, нәкъ шул үзе.

Дөньядагы бөтен нәрсәне оныттым, сикереп каршысына чыгып бастым. Элек икебез дә телсез калдык, аннары икебез дә берьюлы сөйләшергә тотындык. Мин аңа нәрсә әйттем, ул миңа нәрсә диде — берсен дә белмим. Шахтада күргән азаплар онытылды, ялтыравыклы итекләрем дә онытылды, ахрысы, Василә аларны бөтенләй күрмәде дә бугай.

Аннары ул, озак торырга ярамый, әнкәйләр ачулана, дип чиләкләренә су алып кайтып китте.

Ул икенче әйләнеп килгәндә, без тагын сөйләшергә, вәгъдәләшергә тиеш идек тә ул икенче әйләнеп килергә өлгермичә калды. Минем Василә белән озак кына сөйләшеп торуым теге кыска күләгәле абыйларга ошап җитмәгән булса кирәк, алар миңа якынрак килеп, мине үчекли башладылар. Әллә кайдан сизенәм, кесәләремнән кулларымны чыгартасылары килә аларның.

Дәшми-тынмый гына торам. Ни генә димә, кунак бит. Тыйнак буласы килә. Ә тегеләр һаман тел озайталар. Арада гармонь тотканы бигрәк тә юха нәрсә икән — турыдан түгел, читләтеп-читләтеп кенә канымны кыздыра.

— Исмәгыйль кызы бер зимагур өчен саргая, дигәннәр иде, шушы икән инде зимагуры.

— Ябышып чыгам, дип әйтә, имеш, ди.

— Нигә исең китте, чыгар. Әнә итекләре икәү ич. Берсе бер итектә, икенчесе икенче итектә рәхәтләнеп торырлар.

Басып тик торам, ә тик торуы шундый читен. Кулларым шундый кычыта, ичмасам, син дә тизрәк әйләнеп килмисең, Василә!

Гармоньчы егет инде иптәшләрен үчекли башлады:

— Кул юк бездә, тел генә бар. Кунакларга колга таба алмыйча йөргән андый салам сыйраклар элек безнең авылга утыз теш белән килсәләр, егерме биш теш белән кайтып китә торганнар иде.

Үчекләү бар, бөергә төртү бар. Бусы инде бөергә төртү. Кеше минем бөергә төртсен, мин үз күләгәмә үзем сокланып торыйм, имеш. Рәхмәт инде Мамалай егетләренә, мин үз тешемне калдыруга караганда, кеше тешен чүпләүне артыграк күрәм.

Дәшмәдем, сүгенмәдем — тегеләрнең каршына килеп бастым. Торам. Берсенә-берсе карашалар. Кулларын күрмим — артка яшергәннәр. Үз кулымны да күрсәтмим — сугышырга дип килмәдем мин. Шулай ук тешемне чүпләтергә дип тә килмәдем. Каршыларында басып торам, дәшмим.

Ахырында чыдамадым, дәштем:

— Йәгез, абзыйлар, алай теш белән уйнашырга яраткач, уйнашып карыйк алайса.

Гармоньчы егет, гармонен тартып җибәргән булып, терсәге белән янындагы егеткә төртте. Сизенәм, егетләрнең уйнашырга исәпләре юк түгел. Берсе минем артыма табарак авышты, икенчесенең кулы кесәсеннән чыгып минем якага таба күтәрелә башлады. Гармоньчы, бакаларына басып, гармонен тартып җибәрде, тик ябарга өлгермәде. Мин, тиз генә пәке алып, гармоньны урталай ярдым да салдым.

...Сугыш шулай башланды, мине салкын кладовойга ябып кую белән очланды. Минем пәке бер чыккач гармоньны урталай яру белән генә калмаган, икенче бер егетнең яңагын да телеп төшергән. Ул икенче егет дигәнем староста малае икән. Аларга контор кешеләре, урядник килгән чак булган. Яңагы теленеп кайткан егет аларның берсенә дә ошамаган. Мин Ниса түтиләргә кайтып, бәрелгән-сугылган җирләрне юып маташканда, ишекне каты итеп кагып, урядник килеп керде.

— Кайда ул кеше чәнчүче бандит? Мин аны төрмәдә черетермен!

Урядникның акырынуы мине ике тиенлек тә куркытмый, тик мена төнне Василә кочагында үткәрәм дип торганда, монда, таш кладовойда үткәрү генә ачуны китерә.

Ә уйлап карасаң, минем ни гаебем бар? Сөям. Сөйдем, сөячәкмен. Василә барыбер минеке булыр. Маңгаем белән таш стенаны ватармын, ә Василәне кешегә бирмәм!

Шулай да таш кладовойда яту бик үк җайлы түгел икән. Пиджакны аска җәеп ятып карыйм, күзгә йокы керми. Төрмәгә эләгәм дип куркудан түгел, төкерәм мин аларның төрмәләренә. Бер башлангач, староста малаеның икенче яңагын да телеп төшерәсем калган икән. Ә шулай да әйбәт сугыштым. Гармоньның телле яңагы бер якта, бакалысы икенче якта аунап, тапталып калды. Өчәүләп ташландылар, берсенә дә үпкәләрлек булмады.

Җенләнеп ята торгач, йокыга киткәнмен. Төннең бер вакытында, тәрәзәдән әкрен генә дәшкән тавыш ишетеп, уянып киттем. Сызылып ай яктысы төшкән, итекләрем ялык-йолык итеп яталар. Дәртләнеп үк киттем. Тәрәзә янына бардым, пыяласы юк, бары тик тимер рәшәткәләр генә. Тәрәзә артында, нindидер бакча булса кирәк, агачлар күренә. Ә кеше-фәлән күренми.

— Кем бар анда? — дип ачу белән кычкырдым.

Тәрәзә артында моңсу гына тавыш, хатын-кыз тавышы:

— Бу мин... Василә. Син әкренрәк, Айдар. Югыйсә... сизүләре бар.

Аптырап калдым, кичә өч егет берьюлы өстемә ташланганда болай аптырамаган идем.

— Син монда нишләп йөрисең, Васыйлә?

Ул, тәрәзә рәшәткәсенә якынрак килеп, пышылдый:

— Чыккач, Айдар, чыккач. Хәзер үк ишеккә бар, мин ачкыч алып килдем.

Берничә минуттан без — Васыйлә белән икәү — бакчада, агачлар арасында идек инде. Монда кеше-кара ишетеп торуы бар, әйдә, читкәрәк китик, дип ул мине кулымнан җитәкләп тау астына алып төште. Анда биек-биек өянкеләр үсеп утыралар, тын гына булып су ага, кайдандыр су тегермәненең салмак кына гөжләве ишетелеп тора. Без карт бер өянке төбендә туктадык.

Васыйлә әле һаман сизелерлек булып дерелди, сүзен башлый да, әйтеп бетерә алмыйча, бүленеп кала. Минем бурыч барыннан да элек аны тынычландыру — тик сүз белән түгел. Җиңел гәүдәсен үземә якынрак тартып алам, кысып кочаклыйм, аннары без икебез дә берьюлы, нишләптер, суга карап калабыз...

— Кибетче Чирайныкыларга каберең якын булмасын... Бөтен түрәләрне сатып алган кешеләр... Шуның аркасында сугышка да бармыйча калды. Ә син кулыңны озайткансың.

Васыйлә миңа үпкәли, ә үзе куркынган кош кебек, бөрешеп калган — шулай да миңа караганда акыллырак кеше булып чыкты ул.

Җиңел генә гәүдәдә, кайчандыр алма әрҗәләре арасына кысылып, авылдан авылга йөрүче кечкенә кызда, учка кереп бетәрлек бу күбәләктә шундый дәрт булыр дип кем ышаныр — ул кинәт сүзсез калды, сулышын еш-еш ала башлады, күзләре әллә нинди саташкан яшь белән тулдылар:

— Кит моннан, Айдар җаным, кит! Югыйсә сине Себер җибәрүләре бар.

Аның кайнар сулышы минем битемә бәрелде, нидер әйтмәкче иен, әйтә алмадым — Кәҗә Шәяхмәт малае гына шул мин.

Киттем. Шул китүдән авылдан ук киттем. Таң атып килә. Ә ай һаман батмаган. Юл, яп-якты булып, сузылып ята. Әкрен генә атлап кайтып барам. Васыйләгә әйтергә дип уйлап та, әйтелмичә калган сүзләр берсе артыннан берсе искә төшәләр. Аһа, дип, әллә ничә йөз чакрым җирдән саклап алып кайткан бүләгем дә кесәмдә онытылып калган.

Ә мин аны инде кайчан күрәм? Күрәмме, юкмы?

Ачуым да бик килгән ие, пәке белән уйнауның ахыры турында да уйлап, шул китүдән мин, үз авылыма кереп тә тормыйча, җәяүләп Урал ягына юл тоттым. Итекләрем чыдарлык, калганы турында уйлап та бирмим.

## V

Шул китүдән ике елга якын йөрдем. Әтиләргә дә, Васыйләгә дә бер хат та язмадым. Әтиләргә ник язмадым? Бүләсе малым булганнан түгел, үзем акча җибәрә алмаудан хурланып язмадым. Ике имана җирне сөрдерү өчен яз саен байлар алдында бишкә бөгелгәнен белеп торам бит мин аның. Ә мин йөрим-йөрим — тапканым үземнән артмый.

Васыйләгә нигә язмадым — үзем дә белмим. Әллә нинди кеше булып барам мин. Кемнәрдәндер үч аласы килү, билгесез ачу кайный миндә. Китсен, җәһәннәмгә олаксын Васыйләсе, дим кайчакта. Бар тапканымны эчеп, оттырып бетерәм дә аннары берәмләп таба башлыйм.

Шулай да Васыйлә, магнит сыман, яңадан мине авылга тартып кайтарды. Йә солдатка алып куярлар, күреп калырга кирәк, дип уйладым.

Кесәмдә әллә ни рәтем юк, шулай да өс-башым рәтләдем. Кайтуым ярап куйды тагын. Мамалайда гөрләтеп туй итеп яталар. Васыйләне

Сатыш авылының кибетче Зариф малаена кияүгә биреп куйганнар. Менә хат язмый йөрсәң. Ачуымнан нишләргә белмим. Эчтә бертуктаусыз кайнап йөргән билгесез ачу хәзер әзрәк билгеле була башлады инде. Чәйнәп ташларга кеше дә бар — кибетче Зариф малае.

Шулай да иң элек Вәсиләнең үзен күреп сөйләшергә кирәк. Ниса түтине җибәреп чакырттым, килде. Агарып калган кызый. Күз карашлары авыр, керфекләре тагын да озыная төшкән, бала чактагы ялкыны эчкә киткән, эчтән яна белә башлаганга охшый. Үзе башлап бер сүз дә дәшмәде, үпкәләгән булса кирәк. Иреннәре әйтеп тора. Ә үзе шундый матур, шундый матур — каршымда май ае төсле балкып тора. Эчемнән генә әйтеп куйдым: «Ни туры килсә, шуны эшлим, ә сине кешегә бирмим!»

Болай үзем шактый ук усал кыланам:

— Туеңа кайтып өлгердем тәки, Вәсилә, әйе бит,— дим.

— Кайтып өлгергәч, яхшы инде,— ди ул, күтәрелеп карамыйча гына.

Салкын итеп, ачу китерә торган итеп әйтә.

Мин юри, кызны үчекләргә теләп, телемә салынам:

— Кибетче Зариф малае бөтен яктан кәеф булыр инде ул. Хәзер үк авызыңны прәннек белән тыгылдырган, сөйләшә дә алмый башлагансың.

Вәсилә кинәт, яшеннән курыккандай, сискәнеп куя, нидер әйтмәкче була, әйтми, бер читкә карап тагын тынып кала.

Нәрсәдер бар кызда: куркырга да, кире кайтырга да уйламый. Барып ике иңбашыннан тотам. Шундый рәхәт, салкын күмер тотып катып беткән кулларым йомшап ук киткән кебек булалар. Кулларым гына түгел, күңелем дә эри. Әллә нинди яхшы сүз әйтергә телим, тик тел очыма гына килми.

— Их, Вәсилә, Вәсилә. Тагын әзрәк көтмәгәнсең бит. Мин сине үзем белән алып китмәкче булып кайткан идем.

— Бернинди хат-хәбәр җибәрмичә тагын әзрәк йөрер иден,— ди бу, һаман шулай күтәрелеп карамыйча гына. Аннары кинәт күтәрелеп карый, күзләрендәге җәһәннәм очкыннары барысы да берьюлы минем өскә чәчелгән шикелле булалар.

Ә мин кем? Акчасыз кесә. Менә кем мин. Андый җәһәннәм утларына ничек чыдап торыйм:

— Ярый, хуш алайса,— дидем дә ишеккә таба атлый башладым.

Вәсилә кинәт үзенең балалыгына кире сикергәндәй булды. Кузгалды, җиңел гәүдәсе белән очып минем муеныма килеп асылынды. Кочаклый, үбә, үзе елый-елый сөйләнә:

— Айдар, бәгырем, бәхетсез итмә башымны! Алып кит моннан. Иртәгә кияү килергә тиеш, ә син бүген алып кит. Синнән бүтән кеше юк минем өчен. Булмады, булачак түгел. Китик, җан кисәгем!

Болай булгач, шатланырга, көләргә кирәк, ә ул, тинтәк кыз, елый. Күзеннән тозлы су агыза. Яратмыйм мин күз яшен.

— Ярый, авызың прәннек белән тыгылмаган булгач, бик яхшы. Бүтәнен рәтләрбез. Иртәгә кичкә әзерләнеп тор. Атка салам да, алам да китәм.

Кызны шулай тынычландырдым да үзем, кешегә-карага күренмичә, тиз генә авылга кайтып киттем.

Икенче көнне, Сәфәргали җизнинең күк айгырын төпкә, Госманнарның кара туры алашаларын прәшкәгә җигеп, пар ат белән киттек тә бардык. Әни:

— Кая болай җенләнеп йөрисез?— дип төпченмәкче булган иде дә:

— Кайткач күрерсең, җыеныбрак торыгыз,— дигәч, үзе шуннан аңлады бугай инде.

Госман, мин, атларны тотып торырга тагын бер малай алдык. Кирәкярак булса, дип аракы алып тыккан идем, авылны чыккач та аны бүлеп салдык. Әйбәт үк булып китте — атлар икенче төрлерәк элдерә башладылар. Караңгы төшеп килә, йолдызлар калка, әкрен генә кечкенә җил

исә, биткә рәхәт, ә күңелгә аннан да рәхәтрәк. Әйбәт тә соң безнең як! Төннәре куе, караңгы, кыз урлаучыларны да, ат каракларын да яшерә. Шулай уйланып, дәшмичә-тынмыйча гына барам, колагымда тояк тавышлары, ә күктә малай чакны искә төшерә торган йолдызлар...

— Исән-сау ерып чыгып булса, кызның менә дигәненә тиенәсең инде син, малай,— дип, әледән-әле минем салпы якка салам кыстыра Госман.

Исән-сау ерып чыксак, имеш. Пычагым булсынмыни безгә!.. Мине икенче нәрсә борчый. Әни аңлап калган булса ярый, хәзерләнеп торыр. Аңламаган булса, эш харап — яңа кеше алдында сынатабыз. Хәер, төкерергә. Мәңге торасымыни ул монда. Барып та җиттек. Әле ярый, Ниса түтиләрнең өйләре басу капкасы төбендә үк. Атларны ишегалдына кертеп, туармыйча гына куйдык. Теге малайны атлар янына бастырып, Госман белән без бакча артлатып кына киттек. Алай-болай булса, дип, кесәмә биш кадаклы гер тыккан идем, кирәкмәс йөк кенә булды.

Исмәгыйль абзый минем иске таныш, ничек йөрергә кирәк икәнне азрак беләм. Аннары тагын Василә белән кичәнәк сөйләшенгән. Сәгать ун белән унберенче ярты арасында, яңа өйнең бакчага таба карый торган тәрәзәсендә, түбәнге өлгедә, рамда минем ак саплы пәке кадалып торырга тиеш. Шул пәкене күргә, Василә, комган тоткан булып, тышка чыга. Бакчага керә, карт шомырт агачлары, карлыган куаклары — безнең иске танышлар, алар безне яшерәләр. Без, бакча коймасы аркылы төшеп, элек Ниса түтиләргә, ә аннан безнең авылга китәчәкбез.

План шулай иде, эш бераз бүтәнчәрәк килеп чыкты. Госманны койманың теге ягында калдырып, үзем койма аша бакчага төштем генә, кайдан сизеп калды, диген, үләт тигере, ишегалды ягыннан эт өрә башлады. Бөтенләй әйтеп тора бит, үләт җан, авызын бакча рәшәткәсенә таба сузып, елап-елап өрә. Озак уйлап тормадым, кесәдән теге герне алдым да этнең маңгаена кундырдым. Чинап бөтен ишегалдын тутырды, берничә тапкыр бөтерелгәләнде, аннары бер читкә китеп тынсыз калды. Шул арада, мин, алдан сөйләшенү буенча, тәрәзәнең түбәнге өлгесенә, рамга үземнең ак саплы пәкемне китереп кададым. Өйгә күз төшереп алдым, утлар яна, ыгы-зыгы килеп хатын-кызлар чабулый, бизәкле чаршаулар эленгән, ястыклар, табында бавырсаклар, төшләр. Морҗа күренә — ап-ак, хатын-кызлар күренә — ап-ак.

Ул арада, эт елаган тавышка, аш өеннән берничә ир кеше килеп чыкты. Кулларында фонарьлар. Исмәгыйль абзый үзе дә шунда. Утлы фонарьларын тотып, караңгы ишегалдында әрле-бирле әйләнеп йөрделәр, ә бераздан Исмәгыйль абзый кар базы артыннан этнең үлгән гәүдәсен өстерәп алып чыкты. Бакчада, карлыган агачы төбендә посып кына утырам — катырак сугылган икән шул мескенгә.

— Акыллы хайван иде җаным, ни булды икән бу Актырнакка?— ди Исмәгыйль абзый, фонарь яктысында этнең үлгән гәүдәсен селкеп тора.

Этне дә, картның үзен дә кызганып куйдым.

Тагын берәр кат яктыртып уздылар да тынычландылар, ахрысы, кереп киттеләр. Ә минем пәке, тәрәзә рамына кадалган килеш, тора да тора. Аның үткен йөзе тәрәзә аша төшкән ут яктысында тагын да ялтырыйрак, койманың теге ягында Госманның куркынып мышнаганы ишетелә, ә Василә чыкмый да чыкмый.

Бераздан, кайдандыр еpéктан, эреле-ваклы кыңгырау тавышлары ишетелә башлады. Исерек авазлар күтәрелде, юлга тупырдатып баскан тояк тавышлары урам өстендә яңгырап калды. Кияүне алып киләләр, кияү кайдадыр шушында, якында гына. Йөрәгем дөп-дөп тибә, әгәр Василә чыкмаса, Исмәгыйль абзый этен генә югалтып калмас бүген.

Юк, чыкты. Әнә бакчага таба килә. Нәкъ сөйләшенгәнчә, кулында комган. Әнкәсе баскыч төбенә чыгып, йомшак кына итеп нидер дәште дә кереп китте. Кереп китмәсә дә, барыбер алып китәчәк идем кызын. Тудырган, үстергән — аның эше бетте, үскәч алып китү — безнең эш.

Вәсилә нечкә генә итеп тамак кырып куйды. Күз ачып-йомганчы ул минем кулымда иде инде. Күтәреп алып бардым да җайлап кына бакча коймасының өстенә куйдым, койманың теге ягыннан Госман кулын сузган.

Кызның уңганлыгына тагын бер кат иман китердем — очынып кына тора. Ник кенә куркып карасын. Ә бит без аны кияүнең авызыннан диярлек тартып алып китәбез.

Кыңгырау тавышлары колак төбенә үк килеп җитте инде. Кемдер, урамны яңгыратып: «Киләләр!» — дип кычкырып җибәрде. Ишек тавышлары, хатын-кызларның үзара пышылдаулары ишетелде: «Вәсилә! Син кайда, Вәсилә?»

Вәсилә койманың аргы ягында инде, аны тиз генә таба алмассыз. Ишегалдында ыгы-зыгы, ә мин, Вәсилә белән булышып, тәрәзә рамына кадалган пәкемне онытып калдыра язганмын.

— Йә инде, Айдар, калсын инде,— дип куркынып дәшә Госман.

Нишләп пәке калдырырга? Ишегалдында кияү егетләре, хатын-кызлар, малайлар. Ишегалдында чыр да чу. Ә мин коймадан тавышсыз-тынсыз гына сикереп керәм дә, агачлар арасыннан кача-поса килеп, тәрәзә рамына кадалган пәкемне алам.

Ун минуттан без инде юлда идек. Атлар пыр тузып чабалар, чаба бирсеннәр, шулай рәхәтрәк.

## VI

Бүген инде безнең өйдә ыгы да зыгы. Әни йөри чабулап, Зөһрә апа йөри чабулап, мәче йөри чабулап. Иртәдән бирле мич яна, чаж да чож таба тавышы, минем тавышка урын да юк. Мәш киләләр. Килен үзе дә җиңнәрен сызганып алган, итәк кыстырулы, кулы кулга йокмый. Әнинең авызы колакта, бер тиенсез өйгә килен кайткан, янәсе.

Хәер, үземнең дә кәеф күтәренке — өйләнәм дигән сүз бит.

Элек карт-коры, күрше-күлән, туган-тумача җыелып үзләре генә утырдылар, безне кертмәделәр. Кич белән без утырдык, картларны кертмәдек. Мулла никахны укыды, Вәсилә хәзер минеке инде, теге вакыттагы кебек, алма белән атып кына китә алмас.

Әни ак келәткә бик әйбәтләп урын җәеп куйган, узганда-барганда кырын күзне салып йөрим. Шулай да кызны алып кайтышкан иптәшләрне, аннары тагын җәйнең эсселегеннән авызлары кибеп йөри торган барлык авылдашларны бер сыйламыйча ярамый бит. Утырыгыз, эчегез, уйнагыз, җырлагыз, бу кем туе, дигәндә, пәри туе, дип әйтерлек булсын.

Әти миннән качырып әзерләгән булган, мин әтидән качырып — аракы су урынына ага. Егетләр телләренә салына башладылар, болай сыйлагач, иртәгә без сиңа тагын бер кыз урлап алып кайтып бирәбез, диләр. Ул мине мактау, ул әтине мактау, фәрештә сөтеннән оешкан кешеләр булдык та калдык. Тамак төбе кычыта кычытуын, сүзләрем дә бар, дәшеп кенә булмый. Үз туеңда үзең тавыш чыгару күңелле түгел.

Үземне мактауга чыдап та утырган булыр идем, бервакытны Госман Вәсиләне мактый башлады. «Кызга тиендең инде, Айдар, кадерен белеп кенә тор, билен сындыра күрмә. Кичә, койма өстеннән күтәреп алганда, ялгышлык белән кулым биленә тиеп киткән иде, малай, ай бил үзендә, ай бил, җан кисәгем»,— ди. Тагын әллә ниләр лыгырдый. Түзмәдем, өйалдына чакырып чыгардым тегене.

— Йә телеңә салынмыйча гына утырасың, йә мин сине тәрәзәдән атам,— дидем.

Җебүе җиткән каһәрнең, шаркылдап көлә генә.

— Мактаганга нигә кылтаясың, кәләшеңне мактыйм ич. Мактарлык җире булганга күрә мактыйм,— ди.

— Сүзеңне үлчәп сөйләмәсәң, күр дә тор, телеңне суырып алып, колак тишегеңә тыгып куярмын.

Һаман тыелмый бу, ә күзләре шундый хәтәр ялтырый.

— Телемне өзеп алганчы, әйтәсе сүземне әйтеп бетерим, дип тырышкан ием, ярый инде алай булгач, әйтәселәрен дә әйтми калдырам.

Өйалдында сукыр ут кына, шулай да күрәм: башын исереккә салып кылануында нинди дер шик бар аның. Эчемдә нидер кайнап уяна, бервакытта да болай булганы юк иде. Мин хәзер аңа тик тор дип түгел, сөйлә дип бәйләнәм. Ә ул, юри минем ачуымны китереп, күзгә карап тик тора.

— Мин сине сөйләтермен. Әйтмәгән сүзләреңне, бугазыңны буып, әйттерермен!

Госман селкенми дә, минем кунагым булганга күрә шулай батыр кылана ул. Шулай да теленнән ычкынып китте:

— Нигә миннән әйттерергә, иялэшә төшкәч, Василәң үзе дә әйтер аны.

Сулышым эчемә сыймый, йөрәгемдә мең төрле елан берьюлы кузгала, ә аларның берәвесе чыкса да эшең харап синең, Госман! Мин Госманның якасыннан каптырып алам, күзләрем аның күзләрендә.

— Син ни дидең, курнос танау? Әйт, син ни дидең?

— Вакыты җиткәч, Василәң үзе дә әйтер, дип әйттем ич инде.

— Тел төбеңдә нәрсәдер бар синең. Әйт, Василә турындамы?

Минем йөрәгемдә мең төрле шик кайный, ә ул ыржаеп тик тора. Тешләрен күрмәс ием, каһәрнең. Якасы кулымда, нишләтергә дә белмим.

Күзне күзгә терәп күпме торганбыздыр, берчакны бу, берни дә булмагандай, уен-көлке белән кушып, әйтеп тә ташлый:

— Нигә ул чаклы ярсырга аңа. Үзең дә тик кенә йөрмәгәнсеңдер әле, җае чыкканда кымтырыклый йөргәнсең. Василәнең дә җаны бар ич. Син булмасаң, монда без калдык.

Моннан да артыгы кирәк түгел. Йә ул моны ничек булса да күрсәтеп бирә, йә мин үземнең бөтен еланнарымны берьюлы аның өстенә җибәрәм.

Эшнең шуңа таба баруын ул үзе дә сизде ахрысы, кулын минем нәкъ күзләрем алдына китереп тирәде. Аның чәнчә бармагында кашы йөрәк шикелле итеп коелган көмеш йөзек ялтырый иде.

— Укы! — диде ул, миңа йөзек кашын күрсәтте. — Монда нәрсә дип язылган?

Чынлап та, йөзек кашында кечкенә генә булып гарәп хәрефләре белән Василә дигән исем янып тора иде.

Кинәт айнып киттем, кулымны Госманның якасыннан ычкындырдым. Янган баганадай тик басып торам, кайдан тотынырга, нәрсәдән элеп алырга икәнен белмим. Ә Госман, йөрәкне бозып, һаман сөйләнә:

— Ихтимал, ул сине кайтмас дип уйлагандыр, ике елга якын бернинди хәбәрсез йөрдең бит. Көтмәгәндә генә кайтып төштең, ул чагында йөзек минем бармакта иде инде. Син юкта бер-ике тапкыр сабан туе булып алды, ә сабан туйларында Мамалай кызларының ничек кыланганын үзең беләсең. Бигрәк тә кунак егетләре белән...

Бер сүз дә дәшмим, басып тик торам. Каршымда сукыр ут яна, әллә шул сукыр уттан тотыныргамы?

Күпме басып торганмын, чайкалып, башымны күтәреп җибәрдем. Өйдә шаулашалар, ник шунда асты өскә килми. Госман кереп китте. Ә мин нидән тотынырга белмичә торам да торам.

Василә чыкты. Чыннан да кояш төсле иде, мине күргәч, бөтенләй коелып төште.

— Нишләп болай үзең генә торасың, Айдар? Башың авыртамы әллә? — ди бу.

Куллары белән минем башыма сузыла. Кулларын кире этәрәм.

— Бар, кереп кит, — дим.

Ул кереп китми, минем янымда басып тора, үзе дерелдәгәннән дерелди.

— Кереп кит, диләр сиңа! — дип кычкырып җибәрәм.

Тавышымнан өйалдындагы сукыр ут сүнә. Без караңгылык эчендә күмелеп калабыз. Василә хәзер үзе күренми, бары тик калтырап чыккан тавышын гына ишетәм:

— Нигә болай үпкәләдең, Айдар? Әйт, ни булды сиңа?

Кулларым белән капшап аның кулларын табам — җылы, ачуны баса торган йомшак куллар. Ул арада Госманның теге сүзләре исемә төшәләр — куллары салкын бакага әйләнгән кебек була. Җилкәсеннән этеп, Василәгә келәтне күрсәтәм:

— Синең белән сүз соңыннан булыр, бар, келәткә кер дә көтеп утыр.

Ул, һичбер каршылыксыз, келәткә кереп китә. Бераздан аның, келәт ишегенең элгечен эчтән төшереп, бикләнгәнлеген ишетеп калам. Ярый, ныклап исәпләшәсе кешем хәзер минем кулда. Калганын әкренләп сүтәрмен әле.

Бөтенесен бозып ташлау өчен берничә юл бар. Берсе — башны исереклеккә салып өйгә керергә дә Госманны тәрәзәдән тотып бәрергә. Ошамый. Госманның ни гаебе бар монда? Кыз үзе кочакка атылып кергәч, Госман кочагын җәйми нишләсен? Аннары тагын, ни генә димә, ул бит минем кунагым. Үз кунагыңны үзең тәрәзәдән ташлау безнең Янбулатта булган хәл түгел. Икенче юлны беләм, анысы да ошап бетми.

Бөтен бәлам дә шунда: мин эшне уйлап эшли алмыйм. Өченчесе ошыймы-юкмы дип тормадым, йөгереп урамга чыктым да, зур гына бер таш табып, шуның белән үз тәрәзәбезгә — ялт. Пыяла чалтырап коелды, калганын мин күрмәдем. Өйгә әйләнеп кергәндә, мәҗлес тузгыган, кешеләр ташны кулдан кулга йөртеп берсенә берсе карашалар, тәрәзәгә каршы якта утырган Саттар башын тотып изалана, аның бармак араларыннан кан бәреп чыккан. Таш бөтенләй гөнаһсыз кешегә эләккән икән, чамаламыйчарак җибәргәнмен шул.

Пыяла куючы безнең үзебездә, безгә унбиш тиен зыян, аңа унбиш тиен файда, ә шулай да мәҗлесне тузгыту өчен ярап куйды бу таш.

Кешеләр үзара буталышкан арада, мин тиз генә таеп өлгердем. Келәткә, Василә янына кереп бикләндем.

Ул келәттә ялгыз елап ята-ята, шешенеп беткән, сүзләрен дә рәтләп әйтә алмый, ә миңа ничек кенә булса да аның сүзләрен ишетергә кирәк.

Йомшак тәнле ул кыз тырнак өчен зур, йодрык өчен кечкенә, ә гаебе аның ни эшләсәң дә торырлык. Шулай да мин аңа тырнак белән дә чиертә алмадым, кулым күтәрелмәде, ир кеше кулы өчен артык юка иде шул ул. Аннары тагын кыйнашу өчен кызлардан бүтәннәр дә җитәрлек ич.

Үч алуның икенче юлын да беләм мин. Көйдерә торганрагын.

Ләм-мим сүз кузгатмыйча, янына киллем. Биленә кулымны салдым — янып тора кыз. Келәтнең кечкенә тәрәзәсеннән ай күренеп китте, эти ясап куйган юкагач караватның ак аягы чагылды. Дөньяда ачу килү бар, үч бар, шуның белән бергә тагын дөньяда караватның ак аягы, юаш кына ай, сулышын еш-еш алып сине көтеп утыручы дәртле кыз бар.

Башымда шундый уйлар буталып киткәнен беләм, бүтәнен белмим. Бөтенләй җебеп кала язганмын, утка янсын караватт аягы! Күпме вакыт узгандыр, ай болыт астына кереп качты, келәт эче караңгыланып калды. Бая, утка баскандай чабулап йөргәндә, итегем белән ташка бәрелгән идем, ертылмаганмы, дип шырпы сызып итекләремне карадым. Шунда, шырпы яктысында, ялгыш кына күзем төшеп китте: Василә, куркынып, караватка ятар-ятмас аптырап калган, аның кара-кара чәчләре, ак мендәр өстенә яртылаш тузгып, таралып төшкән иде.

Ичмасам күзләрем күрмәсен, дип шырпыны тиз генә сүндереп ташладым. Бер сүз дә дәшмичә аягымны салып киендем.

— Син нишләп болай торасың, Айдар? — дип, нидер сизенеп, борчылган тавыш белән дәшеп куйды ул.

Мин, тәмам киенеп бетмичә, җавап бирмәдем.

Киенеп беттем, чыгып китәсем генә калды, аягым атламый да атламый. Теге йомшак тавыш тагын кабатланды:

— Син нишләп болай... Айдар?

Аңлаша башласам, озакка китәр, йә тагын, мәлҗеп куеп, кочагына егылып төшүең бар, үч булгач — үч булсын, үзенә түгел, караватына да борылып карамадым.

— Мин хәзер әйләнеп керәм, — дидем дә келәттән чыгып киттем.

Бу минем Василәгә беренче мәртәбә ялганлавым булды, икенче мәртәбә ялганларга да, дөресен сөйләргә дә туры килмәде.

Шул чыгып китүдән, беркемгә дә әйтмичә, мин тагын Донбасс ягына юл тоттым.

## VII

Йөри торгач кайбер хәлләр булмаган булса, ул эшләрне шуның белән бетте, дип әйтергә дә ярар иде. Василәне мин башкача беркайчан да күрмәдем, тик онытып та булмады ул алма сатучы Исмәгыйль кызын. Ниндидер бер дә сүнми торган ут ягып калдырды ул минем йөрәккә.

Авылга кире әйләнеп кайтмадым, кайтсам да, элеккечә каршы алмаслар, дип уйладым. Күп кенә эшләр башына җиткән кеше бит мин, уйлап карасаң, уйларга җитәрлек. Шуңа күрә уйлап кына карамыйм.

Үземнән артып калган чакларда әтиләргә акча җибәргәлим. Акчасы аз, сүзләре аннан да азрак була: «Минем кайда икәнлекне сорамагыз, җибәргәнне кабул күреп алыгыз». Ә Василә турында ләм-мим. Йөзек кашын укып торсын. Шулай да, үзара гына әйткәндә, сагынам мин ул кызны. Төшләремә керә. Тик элекке кук көлеп түгел, үпкәләгән булып керә. Әллә хаксызга рәнҗеттемме икән кызыйны? Әнә шулай уйланып, кайчакларда төне-төне белән йокламыйча борчылып чыгам, җәяүләп эзләп китмәкче булам үзен, ә иртәгесен яңа мәшәкать килеп туа да үпкәләгән кызны әллә кая, артка куып җибәрә.

Шулай да берчакны, җир астында чиләнеп туйгач, әллә авылга кайтып буразнага аякны тыгаргамы, дигән уй чын-чыннан башка килгән иде. Котомкамны җилкәгә асып, станциядә болганып йөргәндә, пашпортсыз, дип, җилкәмнән каптырып алдылар. Хәер, пашпортлыларны да озак сайратып тормый башлаганнар иде ул чагында — сугышта турый торалар, моннан патша хәзрәт дигәннәре безнең ишеләрне тыга тора. Ә миңа инде, пашпортым да булмагач, авыз ачып сүз әйтергә дә бирмәделәр, буйны-сынны үлчәп карадылар да:

— Ярый бу, алдык! — диделәр.

Таш казармаларда әле алай, әле болай дагалый торгач, башкалар кебек, миннән дә солдат килеп чыкты булса кирәк. Әле нинди генә солдат, «отчайный татарин», дигән булып, салпы якка салам кыстырып, кавалерист итеп куйдылар. Сугыш җиренә барып чыкканнан бирле атлы разведкада хезмәт итәм. Приказ буенча барып, берәр нәрсә майтарып кайткан саен, офицерлар мактап куйган булалар: молодец, гололобый, барысы да бөек империя өчен, патша-атакай өчен, рус коралының даны өчен. Теге дә бу... Кем өчендер, анысында минем эшем юк. Әмма шунысы шәп — кинәндем ат өстендә йөреп.

Кем уйлаган диген, Госман белән бер частька туры килдек. Баласычагасы турында сөйли, авыл турында, туган-тумача турында сөйли, ә Василә турында ник кенә тешен агартсын. Иске тунны кузгатмыйм, тузаны чыгар, ди ахрысы.

Шулай да беркөнне сөйләштек. Шундый итеп сөйләштек, икенче сөйләшергә урын да калмады. Барысы да ачылды — теге чакта ачылмый калганнары да.

Ә бу болай булды.

Беркөнне разведка командиры минем янга килде дә әйтә:

— Эш бар сезгә, солдат Шаяхметов,— ди.

Күзгә карап тора бу. Минем иреннәрем яна башлаганчы шулай карап торды, сыный, янәсе.

— Сезнең үзегезгә генә, ну, аннары тагын бер кешегә,— дип өсти бу, бераз карап торганнан соң.

Үзе эшнең нидә икәнлеген әйтми дә әйтми, күрәсең, хикмәтледер. Була бирсен, мин үзем дә эшнең хикмәтлерәк, куркынычрак булуын яратам.

Офицер, минем белән артык сайрашып торырга теләге юклыкны белдереп, шул ук вакытта мәче баласына майлы калҗа күрсәткәндәй:

— Сделаешь, крест на грудь и на побывку,— дип китеп барды.

Крест дигәнен башына капласын, шулай да, авылга кайтырга, дигәч, колак торды, әй.

Кыскасы: җәйге төнгә каршы без, Госман белән икәү, урман артындагы поляк авылында ята торган немец батальонына «кунакка» киттек. Бурыч ачык: флангларда үтеп, батальонның артына төшү өчен юллар капшарга, батальон штабының кайда урнашканлыгын дөрес итеп белеп кайтырга.

Киттек. Госманны, минем авылдаш, дип үзем сайлап алдым. Төн бик әйбәт — кызлар белән генә сөйләшеп утыра торган төн. Шундый төннәрдә яшь чакны искә төшерәм мин, авыл урамнарында кычкырып җырлап йөрисем килә башлый. Ә бу төнне кычкырып җырлау түгел, кычкырып сөйләшергә дә ярамый. Немецның колагы үзе белән.

Урманны чыгып җитәрәк, атларны эчкәрәк кертеп, карт бер имән төбенә бәйләп калдырдык. Авыл шунда, урман янында гына дип әйтерлек. Читтән караганда, ялтыр башлы костелын искә алмаганда, өйләре җиргә сытылып кергән шикелле. Тик әллә нидән бер ишетелеп киткән ят тавышлар гына авылда җан иязәре барлыкны, авылның әле сытылып бетмәгәнлеген белдереп тора. Кайдадыр, якында гына, немец телендә берничә тапкыр команда тавышы яңгырады, часовойлар алмашынды булса кирәк.

Урманнан чыккан кечкенә чишмә, авылга җитәрәк инешкә кушылып, зур гына суга әйләнеп китә. Суның уң як ярлары куе таллар белән күмелгән. Шуларга ышыкланып, авылга якынайганнан якыная барабыз. Авыл — елганың сул ягында, без — уңда. Менә инде без ындыр турына да килеп җиттек. Келәтләр, зур-зур амбарлар күренә башладылар. Часовойлар үткәләп торалар. Ахрысы, монда немецларның складларыдыр. Мин кесәдәге шырпымны капшап куям. Шырпы белән уйнау минем бурычка керми керүен дә, шулай да якындарак торсын әле.

Таллар, елганың уң як ярлары буйлап, һаман сузылалар. Без инде нәкъ авыл турында. Тик су аркылы үтү өчен басма да, күпер-фәлән дә күренми. Ахрысы, түбәнрәктер. Без һаман, су буйлатып, алга барабыз.

Чынлап та, күпер түбәнрәк, авылның көньягындарак икән. Монда инде, тау аслатып, яртылаш таштан салынган складлар, яшелчә базлары тезелеп китә. Теге якта, авылның арт урамыннан килеп күпергә таба сузыла торган юл буенда, таш кое кала. Изгеләр коесы булса кирәк, өстендә часовня, аның очында тәреләр ялтырый. Бу тирәдә часовойлар күренми, немецлар бу яктан бик шикләнмиләр, ахрысы.

Күпер чыдарлык, таллар безнең файдага, яртылаш җиргә сеңеп беткән ташландык складлар берәүне дә кызыктырмыйлар булса кирәк, әнә шул берәү дә кызыксынмый торган яктан кинәт кенә без кызыксынсак, начар булмаячак. Мунча табып булмый торган бу поляк җирендә немецларны шәп кенә бер парлап алырга бик ярар иде.

Авылның бу ягын шулай өйрәнгәннән соң, ерактан ук әйләнеп, икенче ягына күчтек. Ул ягы әллә ни уңайлы булмаса да, шулай да, саклык белән эш иткәндә, авылны төреп алырлык юллар бар. Урыннарны билгеләдек, разведка үзенең бурычын үтәде диярлек. Инде хәзер авылның эченә керергә кирәк. Озак уйлап торырга вакыт юк, тиз кирәк, күзеңне йомып, тәвәккәлләү кирәк.

Нәкъ шулай тиз кирәк вакытта Госман минем белән озак итеп бәхәсләшеп тормакчы булды. Имештер, мин бер дә кирәкмәскә әҗәлнең күзенә барып керәм. Күпме өмет итеп, азыннан да колак кагарбыз, җитәр, борылыйк, ди бу. Атларның чалынып, буылып торулары бар, дип тә карый. Мин аны тыңларга да теләмим. Ахырында бу ялынырга ук тотынды:

— Айдар! — ди бу, үз тавышыннан үзе куркып пышылдый. — Айдар, ник тилерәсең син? Алай беркатлы булуның нигә кирәге бар? Җибәрделәр, килдек. Үтәрдәен үтәдек тә. Инде хәзер штаб эзләп йөрмәкче буласыңмы? Ышан миңа. Авылда безне чат саен әҗәл сагалап тора. Аннары тагын үз башың белән уйлап кара. Штаб кайда? Кара мунчада түгел. Кайда булса да авылның уртасында, калай түбәле берәр йортта. Кайтабыз да шулай дип әйтәбез. Иртәгә безне кем тикшереп йөри? Чортым да тикшерми.

Аңлап җитмим: уйлап әйтәме соң ул моны, әллә мине сынап кыланган буламы? Әгәр чынлап булса, мин сиңа күрсәткән булыр ием калай түбәне!

Борылдым да тегенең каршысына килеп бастым:

— Син моны чынлап әйтәсеңме, авылдаш, әллә маташтырган буласыңмы?

Госман катып тик тора, ник кенә бер сүз әйтсен. Күзгә-күз карашып шулай тордык та, аннары киттек. Тик озак та узмады, бу тагын сыкранырга тотынды. Бу юлы инде тавышы бөтенләй калтыранып чыга, гөбедән сөйләгән төсле.

— Үлгәнче сиңа әйтеп каласы бер серем бар ие. Вәсилә турындагы сер. Ичмасам, шуны да әйтмичә калам икән инде.

Чамалап әйтте ул моны. Шундый куркыныч минутларда Вәсилә исеме ишетелү мине бераз йомшартмасмы дип әйтте. Чынлап та, һич тә көтмәгәндә Вәсилә исеме яңгырап китү бераз исертеп ташлады мине, кайдадыр Вәсилә бар бит әле. Әти ясаган юкагач караватның ак аягы бар, юаш кына ай, мөлдерәп карап калган күзләр бар.

Үзем дә белмим, әллә нинди көч уянып китте миндә. Артыма борылдым да, Госманга кул селтәп, кычкырдым:

— Бар, атлар янына кайтып мине шунда көтеп тор, үзем генә барам. Эшлисе эшләрне бетергәч тә, хәзер әйләнеп кайтырмын.

Госман, шуны гына көтеп торган икән, борылды да, кәҗә кебек, тизрәк су буена, таллар арасына йөгерде, ә мин, тәвәккәлләп, бер үзем авыл эченә кереп киттем. Эшлисе эшем шактый күп, штабның кайсы өйдә урнашуын дөрес билгеләүдән тыш, Госманның курнос борынына чиртеп күрсәтергә дә кирәк. Әгәр ул авылга минем ялгызым гына кереп, эшлисе эшне ялгызым гына булдырып чыгуыма ышанмый икән, аның борынына чиртеп, ничек булса да ышандырырга кирәк бит инде.

Бер шырпы сыздым — ике эш эшләдем. Тәвәккәл солдат барысын да эшли ул. Ярты сәгать тә узмады, немецларның бер складлары дөрләп яна да башлады. Ялкынның теле күккә күтәрелде: менә, күрмәсәң күр инде, Госман!

Шау-шу купты, берсен-берсе этә-төртә солдатлар йөгерешергә тотындылар. Шул ыгы-зыгыдан файдаланып, мин штабның кайсы өйдә урнашканлыгын белеп тә алдым, ә бүтәне миңа кушылмаган.

Урманга, атлар янына әйләнеп кайтканда, Госман мескен китәргә дә, китмәскә дә белмичә аптырап тора иде. Мине күргәч, кычкырып җибәрде:

— Неужели син исән? — ди.

Искитәрлек нәрсә тапкан, пычак булсынмыни миңа?

Менә инде без, атларыбызны әкрен генә атлатып, урман юлы белән кайтып барабыз. Матур гына булып таң атып килә, теге чакны, Вәсиләне Мамалайдан урлап кайтканда да таң нәкъ шулай булып аткан ие. Вәсилә, дигәннән, бая Госман миңа Вәсилә турында бер сер сөйләмәкче булган ие бит.

— Йә, икебез дә исән чакта теге серенне сөйләп кал әле,— дип мин аңа карыйм.

Ул, әллә нинди уйларга күмелеп, дәшмичә-тынмыйча гына барган жиреннән дерелдәп уянып китә, текәлеп минем күзләремә карый. Көнгә яктылык төшеп килә, мин аның күзләрен аермачык күрәм, аның күзләре нинди дер булганчык күл төсле.

— Дөресен генә әйткәндә, пустяк,— ди бу, сөйләмичә котылып калмакчы була.

Мин үз сүземдә нык торгач, ахырында чыдый алмады, башлады. Әллә кайлардан уратып-уратып сөйләп алып китте. Дәшмичә генә тыңлап барам, очы чыгар әле, дим. Шулай булды да.

Урманны чыгып житеп килә идек, бар күк серләр урманда коелып калсын, дип ахрысы, ашыктыра башлады ул:

— ...Син дә шул бер дә юкка гына кызның да киттең ул чакта. Кызыксыну юк, сорашу юк, кыз ташлап кит, имеш. Кызы нинди кыз әле тагын, сусыз кашык белән суырып йотарлык.

Ул үзе сөйли торган сүз белән үзе үк мавыгып китте, ахрысы, тавышы шуны әйтеп тора.

— Дөресен генә әйткәндә, ике куянны берьюлы тотмакчы булган идем мин. Синнән үч тә алмакчы идем, кызда да өмет юк түгел. Теге сабан туен хәтерлисеңме? Мамалайда ат чабыштырырга барган идек бит. Син шунда камчы белән минем битемә суктың, нәкъ алты айга барды ярасы. Ә ачуы бетмәде. Кайдадыр эчтә ятты да ятты. Үсте дә үсте. Менә берзаман үч алырга жай чыкты. Без синең белән Мамалайга кыз урларга киттек. Хәтерлисеңме, син эчтә, бакча ягында, ә мин койманың тышында, Вәсиләне койма аркылы чыгарабыз. Ул мескен — әллә куркудан, әллә каушаудан — берни белми. Кулын суза. Ә мин, тукта, ярап куяр әле бу, дим. Теге ыгы-зыгы килгәндә, бармагыннан йөзеген шудырып алам. Тәмам алгысыган кызый, пычагымны да тоймады. Соңыннан сиңа, кызу кешегә, шул йөзек житә калды.

Ул моны шундый тәмләп сөйли, әйтерсең, авызында сүз түгел, конфет. Сөйләрлеге дә бар, оста эшләгән ул. Миңа хәзер бары тик баш селкергә генә, бары тик гажәпләнергә генә калган. Гажәпләнмәслек тә түгел, карсак кына бер кешенең эчендә ничаклы явызлык йөргән бит!

Борын кимерчәкләрем сикерә, сизенәм, яхшыга түгел. Югалган беренче төн өчен, Вәсиләнең чәч чуклары, үземнең жәяү йөрүләрем өчен — барысы өчен дә, барысы өчен дә берьюлы өзәсем килә.

Тик мин авыз ачарга да өлгермичә калам, урман кинәт гөрселдәп куя. Минем атым жиргә капланып төшә, мөлдерәгән күзләрен генә күреп калам атның. Үземнең мавыгыбрак китүемне хәзер генә, немец засадасының тозагына килеп капканнан соң гына, сизендем, ярдәмчем — билемдәге гранаталар гына.

Минем, дошманга бирелмичә, кулыма граната тотып засада өстенә баруымны күргәч, Госман, елаган тавыш белән, кычкырып жибәрде:

— Башың бармы? Айдар? Икебезне дә харап иттерәсең бит!

Әйләнеп карасам, аның ике кулы да күтәрелгән, тезләре дерелдәп тора.

— Беренчесе менә сиңа, куркак жан! — дип, жан ачуым белән аның өстенә гранатаны томырдым.

Граната, иртәнге урманны яңгыратып, шартлады. Ут, туфрак, аннары тагын безнең авылның курнос Госман — барысы бергә буталып, һавага очтылар.

Миндә тагын өч граната, бер йөрәк калды.

— Мәгез, бусы сезгә!

Үзебезнекеләр килеп житкәннәр, мине үлемнең авызыннан тартып алганнар. Туган-үскән якларга күптән үк кайтканым юк иде, санитар поезд белән кайтарып ташлаганнар. Үзем дә белмим, әллә кайчаннан бирле инде госпитальдә, ак палатада ятам. Бик шәп бер хирург киләсе, шул карыйсы, диләр, тизрәк килсен, төзәтсен ие. Аннары тагын ишек кинәт ачылып китсен ие дә, кояш төсле балкып, Василә килеп керсен ие. Шәп хирург дигәннәре кирәк тә булмас ие ул чагында, терелер идем. Билләһи, терелер идем! Килмәс шул инде ул, ачулангандыр ул миңа. Их син, яшьлек! Яшьлек!

Мәрхүмнең дәфтәре, тигез-тигезсез хәрефләр белән берсе артыннан икенчесе тезелеп киткән юллар, ник язганын үзе дә рәтләп төшенмәстән, госпитальдә озак ятып эче пошканнан, бары тик вакытны үткәрү өчен генә язылган бу искиткеч матур тарих шунда бетә.

Ромен Роллан бугай, әйтә: «Һәрбер кеше үзенең күңел тирәнлегендә үзенә генә аерым бер каберлек асрый»,— ди. Кеше монда бик сирәкләрне генә күмә һәм, бер күмгәч, ул аны күңеленнән казып чыгара алмый. Үзенең чая гомерен, таудан ага торган шарлавык төсле, тиз һәм шаулап уздырган ул тәвәккәл егет минем күңелгә дә әнә шулай нык булып утырып калды. Ә кем белә, бәлки, гомерем буена мин аның каберен, авырыксынмыйча, үземдә саклап йөртермен.

Язгы розалар төсле, матур-матур уйлар туарлар, мәхәббәт турында яңадан-яңа риваятьләр язылыр, кешеләр берсе дә берни дә белмәс, ә яшь розалар дымны минем күңелемдә саклана торган әнә шул каберлектән алырлар.

Шундый уйларга күмелеп калган хәлдә, урамда очраган берәүгә дә күтәрелеп карамыйча, әлеге дәфтәрне куеныма кысып, теге ак чырайлы хәрби врач янына барам. Теләк — әгәр җае туры килсә, ул ханым белән азрак сөйләшеп утыру. Аның әллә нинди яшерен моң белән тулган күз карашлары әле безнең беребезгә дә ачылып җитмәгән серләрне яшереп саклый кебек. Һәрхәлдә мин тагын бер сорауга җавап табарга тиеш. Василә соңыннан ни эшләп кала?

Бәхеткә каршы, аның бик җайлы вакыты туры килде. Эштән кайтып, ашап-эчеп кенә тора иде. Кәефе дә бик яхшы чак икән, без, берәр стакан кофе ясап куеп, шуның янында озаклап сөйләшеп утырдык.

Баштарак:

— Василә турында мин үзем дә, сезнең кебек үк, әнә шул дәфтәрдән укып кына беләм,— дип, тыйнаклык саклап торса да, соңыннан ачылды тагын, барысын да сөйләде.

Василә дигәне шушы кара күзле ханым үзе булып чыкты, ә Айдар Шаяхмәтов үзе, теге вакытта алган сугыш яраларыннан һәм, бәлки, яшьлегендә ясаган хаталарының үкенечле яңаруыннандыр, шушы үзебезнең якларда, ләкин үз Янбулатына кайтып җитә алмыйча, үлеп калган.

...Берничә минут без икебез дә тын утырдык. Бу тынлык һәр икебезнең дә рухи халәтенә бик яхшы туры килә, нинди генә акыллы сүз булмасын, бу берничә минутлык тынлыкның изге мәгънәсен алыштыра алачак түгел иде.

Мин, гомумән, ни турында сүз алып барырга да белмим. Кызыксындырган сорауларга җавап алынып беткән, ни дә булса бүтән темага сүз кузгатыр идем, Василә ханымның рухына туры килмәгән нәрсә килеп чыгып, аны рәнҗетермен, дип шикләнәм.

Ә Василә ханымның, киресенчә, сөйлисе килеп утырган икән. Йөзен күтәрә төште ул, моңлы күзләрен миңа таба бер сирпеп алды, аннары, бүлмәнең бер почмагына текәлеп суынып калган хәлдә, әллә нинди тонык бер тавыш белән, әкрен генә сөйләргә тотынды:

— ...Бәхет турында бик күп сөйләнә бездә. Урыны белән дә, урынсыз да сөйлиләр. Шул сөйләгәннәрнең барысына да колак сала китсән, бездә хәзер бәхет буявына буялмаган сыңар тычкан да табып булмый. Ә менә шуны, сез, малярлар, ясап куйган тоташ бәхетне, авыр аякларым белән ерып, ничәмә-ничә еллар буена мин аны эзләп йөрдем. Бүтәннәр берсе дә күземә күренмәде, күренсәләр дә, алар бары тик күңелгә вакытлы юаныч кына бирделәр. Ә Айдар — ул минем балачагым, ул минем беренче йокысыз төннәрем иде. Балачакны онытып булмаган кебек, аны да онытып булмады. Балачакны кире кайтарып булмаган кебек, аны да кире кайтарып булмый. Әйбәт киңәшләр бирүчеләр булмады түгел, ләкин мин кеше сүзенә колак салмадым. Бәхет турындагы ялкынлы шигырьләр мине бары тик рәнҗеттеләр генә, чөнки Айдардан аерылып калуым белән мин баштанаяк бәхетсез идем һәм шул бәхетсез көйгә, бүтән кешеләрдән калышмыйча, атлап килдем. Җиңел булды дип уйлыйсызмы? Һич түгел. Яисә менә еллар буена эзләп йөреп тә, соңыннан аның турында шушы дәфтәрдән башканы таба алмау җиңел дип уйлыйсызмы? Әгәр шулай уйласагыз, нык ялгышасыз. Шәхси бәхетсезлек булды, бар, киләчәктә дә булыр. Мәсьәлә анда түгел, мәсьәлә әнә шул аерым бәхетсезлекләрне ерып чыга алуда, үзеңдә шуларны ерып чыга алырлык көч, ихтыяр булдыруда. Бәхет — әнә шул ул. Беләм, аягыма Айдар мәрхүмнең кабер балчыгы ябышыр, йөрәгемдә аның ачы хәсрәте сакланыр, ләкин, ничек кенә булмасын, мин сездән калышмам...

Ялкынланып сөйләгән җиреннән кинәт тукталып калды ул, сәер генә итеп миңа карап торды, аннары өстәде.

— Әгәр аның ул язмаларын чынлап та матбугатка чыгарырга уйласагыз, бернәрсәне үтенеп сорыйм: зинһар өчен, кершән-иннек ягындырмыйча, ни бар — шуны чыгарыгыз. Барыннан да элек кеше иде ул, кеше көенә калсын.

Мин ул кечкенә бүлмәдән бик соң киттем, шулай да башым йокымсырау белән түгел, уйланулар белән тулган иде.

Шуннан бер-ике ай узгач, якшәмбеләрнең берсендә, мин тагын, яз башын котлап, әлеге теге минем өчен билгесез булган Айдар Шаяхмәтовның кабере янына килдем. Тирәсе яхшылап чистартылган, кабер өсте яңа гына өзелгән язгы ландыш чәчәкләре белән күмелгән иде. Мин килгәнче бирегә кемдер килеп киткән иде инде. Бөек Ватан сугышы батырының каберенә чәчәкләр куеп киткән кеше миңа, ни өчендер, Василә ханымдыр кебек тоела иде.

*1942.*

**ИСКӘРМӘ**

Татарстанның халык язучысы Фатих Хөснинең (1908—1996) бу мәгълүм әсәре журналның «Татар хикәяләре хәзинәсеннән» бүлегендә бастырырга әзерләнгәндә, әдип вафат булды. «Йөзек кашы»ның журналда кабат чыгуын белгәч (ә әсәр «Совет әдәбияты»ның — хәзерге «Казан утлары»ның — 1942 елгы өченче санында беренче тапкыр басыла), Фатих абый бәхетле «бала»сының көр күңел белән хөр яшәвенә бик тә сөенер иде. Бу шатлык хәстәгә егылган олуг әдибебез әсәренен укучыга һәрчак үз булачагына ышанычын ныгытыр иде. Тик нишләмәк кирәк...

Әйе, «Йөзек кашы», Фатих абый, үзе әйткәнчә, аның иң бәхетле әсәрләреннән берсе. Ул, 1945 елдан башлап, язучының җыентыкларында берничә мәртәбә басыла, аерым китап булып күп данәдә чыга. Мисалга — 1954 елда укучы әсәрнең өченче басмасын кулына ала, 1964 елда рус укучысы Татарстан нәшрияты Н. Малышакова тәрҗемәсендә «Перстень» исемендә чыгарган китапны (кырык биш мең данә!) җылы кабул итә.

Автор, төрле басмаларга кереш сүзендә, әсәрен соңыннан төзәткәләве турында искәртсә дә, «Йөзек кашы»ның беренчел төсе саклана, кайбер үзгәртүләр «бала»ның, үсә төшкән саен, киеменә хаҗәтле бизәкләр-чуклар тагу кебек кенә

тоела. Хәер, «бала» гүзәл булып тугач, аның төсенә-кыяфәтенә, килешенә-кыяфәтенә чибәрләү операциясе ясауның кирәге дә юк лабаса. Аннары шунысын да искәрик, әсәрнең төп герое Айдар Шаяхмәтов — үзенчәлекле холык иясе, ул әйткәненне тыңламаска да мөмкин, аның үз иманы. Әнә, Фатих абыйның өч томлыгының (1966—1968 еллар) икенче томында Айдарның фамилиясен әсәр башында һәм ахырында «Корбанов»ка алыштырырга тырышып каралган, ләкин әсәр уртасында ул беренчел фамилиясен саклаган! Шуңа күрә без дә Айдарга үз фамилиясен «кайтару»ны тиеш таптык.

Бу басмага әсәр өч томлыкның икенче томыннан (1967 ел) алынды һәм беренче басмасы (1942 ел) белән чагыштырылды. Без кабатланучы кайбер сүзләрне мәгънәдәшләре белән алыштырырга гына тәвәккәлләдек.

Инде укучыда туачак бер сорауга җавап бирергә тырышып карыйк. Хикәя жанры турында күп язган, хикәягә төрле яклап бәяләмә биргән Фатих абый — аның хәтта, хикәя бер утыруда укып чыгылырга тиеш, дигән сүзләре дә хәтердә — «Йөзек кашы»н «повесть» дип атады. Повесть жанры гасыр башында татар әдәбиятына ят була, ул бездә, нигездә, утызынчы елларда урнаша башлый, күләмлерәк чәчмә әсәрне шушы сүз белән атауга күчелә, моңарчы «хикәя» һәм «роман» жанрлары хакимлек итә. Мисалларны укучы классик язучыларыбыз иҗатыннан җиңел таба ала. Күләмле әсәрләрне, роман исеменә һәр тарафтан җавап бирүенә карамастан, «повесть» дип билгеләү, бәлки, гел дә тыйнаклык чагылышыдыр.

Ничек кенә булмасын, бу очракта без «Йөзек кашы»н, татар әдәбиятында повесть жанры булуы-булмавы турында озын-озак бәхәс кузгатмастан, «Татар хикәяләре хәзинәсеннән» бүлеген бизәрдәй әсәр икәнлегенә инанып тәкъдим итәбез. Шунысын да әйтик, әсәр Фатих абыйның хикәя турында югарыда китерелгән бәяләмәсенә дә туры килә, «Йөзек кашы»н бер утыруда укып чыгасың.

Кечкенә бер хатирә. Фатих абый бу әсәреннән өзекләрне укучы-тамашачы алдында, иш-иптәшләре белән әдәбият турында чәй янында әңгәмәләрдә-мәҗлесләрдә еш кына яттан сөйли иде. Бу чакларда ул тирә-юньне оныта иде, аның өчен әсәр вакыйгасы гына кала иде. Башын бераз югарырак күтәрер иде дә әсәр дөньясына текәлер иде ул. Басым ясалырга тиешле төштә йомшак тавышына кулының йомшак хәрәкәте ишарәле кушылыр иде, биек маңгаеннан тир бәреп чыгар иде... Әсәрен ул күңелдән сөйләү өчен махсус ятламаган, дип беләм. Хәер, йөрәк хәзинәсен барлап-актарып туган әсәрен ятлау кирәкмәгәндер дә ана...

**Мәгъсүм ХУҖИН.**
*23 сентябрь, 1996 ел.*



ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

# ПРОЗА ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

Әдәбиятыбызның проза жанрындагы бүгенге хәлләр күпләрне борчый. Уңышларыбыз да, борчуларыбыз да җитәрлек. Шуны искә алып, редакция байтак кына әдипләргә түбәндәге сораулар язылган анкета тараткан иде:

**1. Бүгенге прозаның кайсы яклары Сезне сөендерә? Соңгы елларда басылган кайсы проза әсәрләрен яратып укыдыгыз? Нинди яңа авторларга аеруча зур өмет баглыйсыз?**

**2. Бүгенге прозаның нинди җитешсезлекләрен күрәсез? Аларның сәбәбе нәрсәдә дип уйлыйсыз?**

**3. Прозабызны үстерү өчен хәзер нәрсәләр эшләргә кирәк дип саныйсыз?**

Гыйнвар санынннан башлап редакциягә алынган җавапларны урнаштыруны дәвам итәбез.

Әдипләрне, галимнәрне һәм укучыларны шушы сөйләшүдә катнашырга чакырабыз.

Ләбибә ИХСАНОВА:

1. Яхшылыкка, яктылыкка, изге күңелле кешеләргә тәмам сусалган икән. Шуңа күрә Фоат Садриевның прозасын яратып укыйм. Шундый ук нечкә зәвыклы, лирик каләмле Тәбриз Мөбәрәков әдәбият күгендә якты йолдыз булып атылды. Аның «Хәтер аланы» повесте һәм «Аю мәхәббәте» дигән хикәясе сусаганда салкын су эчкән кебек тәэсир итте. Айдар Хәлимнең «Кыйбла» хикәясе әйбәт. Аккош кебек парлап гомер иткән карт белән карчыкның мөнәсәбәтләре күздән яшь китерерлек.

2. Проза әсәрләре күп языла. «Казан утлары»ның сан саен яңа роман бирүе куанычлы. Ләкин авторлар әлегә өстә ятканырак хәлләр турында язалар кебек. Эчтәлекләре төрле булса да, мәгънәләре бер үк. Көн дә күреп торган хәлләргә язучы каләменнән төшкән әйбәт иллюстрация. Укырга күңелле үзләре, туеп бер читкә куймыйсың. Әмма вакыт үткәч онытыла.

Дөнья чуалчык, катлаулы, күп нәрсәләрне аңлап, бәя биреп бетереп тә булмый. Моның өчен бераз вакыт, ара, уйлану кирәк. Шул чагында алтын фондта калырлык әсәрләр туарга мөмкин. Ә менә хикәя жанры бөтенләй кызганыч хәлдә. Бастырырга газит-журналлар да күп югыйсә. Китап булып чыкканын көтеп ятасы юк. Конкурс игълан итү дә әлләни җанлылык тудырмады. Хикмәт нәрсәдә икән? Хәер, татар әдәбияты элек-электән хикәяләргә ярлы булды бит.

3. Язучылар үз эшләренә бикләнде. Кульязмаларны укып үзара фикер алышу да юк, матбугатта чыкканнарына да тәнкыйть күренми. Китап бастырудагы кыенлыклар прозаның үсүенә зур тоткарлык ясый. Мондый шартларда әдәбиятның бер жанры да алга китмәячәк. Тукай кебек бөек зат кына пәйда булып шаккатырмаса инде... Хәер, Тукайлар заманында да әче-әче тәнкыйтьләр булган бит.

Кояш ТИМБИКОВА:

Журналның, бүгенге чәчмә әсәрләребез турында сүз кузгатып, фикер алышулар башлап җибәрүен хуплаган хәлдә, сөйләшүне бары тик яңа табышларга гына кайтарып калдыру мөмкин булмастыр. Ник дигәндә, минемчә, язучыларны да, әдәбият сөючеләрне дә иң нык шатландырган яңалыклар үткәннәргә, тарихыбыз-

га, соңгы 5—10 еллар эчендә башка юнәлешкә борылган сәясәткә тоташа. Чынбарлыкның һичнәрсәгә буйсынмас кануннары безне бүгенге әсәрләргә дә тарихилыктан чыгып бәя бирергә этәрә. Шулай фараз кылсак, мин әңгәмә өчен алга куелган беренче сорауга, һич икеләнмичә, бүгенге чәчмә әсәрләребез арасында җанымны иң сөендергәне — мәшһүр Гаяз Исхакыйның «Зиндан» китабы, дип җавап бирәм. Ни кызганыч: без, бичара татарның берничә буын әдәбиятчылары (әдәбият сөючеләрне әйткән дә юк инде!), төрки әдәбияты дөньясында үзәк биеклекләрне тоткан бу талант иясенең исемен дә ишетмичә яшәп ятканбыз. Аны бит хәтта тәнкыйть итеп тә телгә алмыйлар, бөтенләй белмәмешкә салышалар иде. Баксаң, чыннан да, аны укучыдан яшерү өчен башка чара булмаган да икән шул. Исхакыйның исемен телгә алдыңмы — бу инде татарның бай тарихын да, горур табигатен дә, дәрьядай мул әдәбиятын да ачып салу дигән сүз. Аны ярым-ярым хәлдә генә искә төшереп тә, хәтта яманлап та булырлык түгел.

«Зиндан»га әдипнең хезмәтләре өлешчә генә кергән. Китаптагы библиографиядән күренгәнчә, аның әле чит илләрдә язган берничә романы, күпсанлы хикәяләре, мәкаләләре бар. Бәхетемә, миңа аның әле китап булып чыгарга өлгермәгән кайбер романнарын да (машинкада басылган хәлдә) укырга туры килде.

Исхакый әсәрләре белән танышкан саен җанны, бер яктан әрнүле, икенче яктан горурлык уятучан хисләр бөтереп ала. Әрнүле, чөнки моңарчы әдәбиятыбыз нинди зур хәзинәдән, өйрәнү чыганагыннан аертылып яшәгән. Горурланырлык, чөнки «Татар кем соң ул?» — дисәләр, түш киереп: «Әнә, Исхакыйны укып кара, белерсең татарның кемлеген!» — дияргә мөмкинлек ачылды. Бу әсәрләр татар әдәбиятының нинди булырга тиешлеген генә күрсәтеп калмый. Исхакый әсәрләре татарның элекке тормышын да без моңарчы ишетеп яшәгән ялганнардан арындырып, чын-дөресенчә тасвирлап күрсәтә. Баксаң, татар дөньясы да гел хәерчеләрдән вә «канэчкеч капкорсаклар»дан гына тормаган. Аның җанга рәхәтлек иңдерердәй үз милли тирәлеге яшәп килгән. Үз читеген оныгы аягына җайлаштырып бирүче, шул сабыен мәчеткә, намазга озатып калучы сөйкемле карчыклары да, ярлыларга сәдакә өләшү өчен аерым көннәр билгеләп яшәүче хәлләләре дә, иренең икенче хатынын үз күреп көн итүче, акыллы остазбикәләре дә булган. Ул чорның Казан тормышын да Исхакый бөтен яктан дөреслеккә туры калып тасвирлый. Моңарчы укылган чәчмә әсәрләрдә без йә заводта бил бөккән, йә ишегалды себереп кенә тамак туйдырган бичара татарны танып ала идек. Кайда соң бу Казанның урыс прозасындагы дворяннар кебек, әзрәк хәлле, әзрәк кенә булса да укыган кешеләре? — дип, кызыксына да алмадык. Ярамады. Татар башың белән Казанның укымышлы кешесе, хәлле кешесе булыр иде мәллә?! Әнә сиңа — печән базары, йөр шунда капчыгыңны сөйрәп! Бик кызыксына башласаң, шундыйрак җавапны ишетерсең кебек иде.

Исхакыйның «Теләнче кызы» романы бу төр сорауларга да ачыклык кертә. Булган лабаса татарның да бик күркәм тормышы! Шәһәрендә дә мәш килеп, укып та, театрларына да йөреп бик матур яшәгәннәр лабаса! Хәтта кунар җир таба алмый интеккәннәргә, хәзергечә әйтсәң — «бомж»ларга махсус йортлар да тотканнар. Ачсыннар иде әле хәзер шундый кунар җир, торба эчләрендә, күпер асларында, чүплек башларында азапланып яшәүче һәм билгесезлектә үлеп калучы йөзләрчә бичаралар мең бәладән котылыр иде. Кызганыч ки, совет чоры үзгәрешләрендә мондый изгелекләр тәмам онытылган.

Гаяз Исхакыйның һәр әсәре бүгенге күпсанлы сорауларга килеп тоташканга күрә дә мин аларны соңгы еллардагы иң зур табышларыбыздан санарга мәҗбүр. Шунысын да әйтергә кирәк, без бу әдибебезне «кайтаруда» урыслардан нык соңардык. Алар бит үзләренең Бунинннарын, Булгаковларын, Набоковларын беренче «җепшеклек»тән соң ук дөньяга чыгардылар. Татар әдәбиятына «бәйләнгәндә» үк, күрәсең, үлчәү берәмлекләре башка, шовинистик рухта булгандыр: урысның Тургеневы да, Достоевские да уку программаларында торып калган лабаса. «Бәйләним» дисәң, аларга бик рәхәтләнеп «бәйләнеп» булган булыр иде. Шулай чагыштырыбрак карасаң, татар әдәбиятының икеләтә кыерсытылуы күзгә ташлана. Хәйран калырлык: әле дә ничек саклана алган ул безнең әдәбият? Зур вә укымышлы, әдәби яктан да биниһая киң колачлы тәрбия күргән халык шул без. Бабайларга мең рәхмәт. Барын да мулдан биреп калдырганнар. Совет властеның җитмеш-сиксән еллык җәберләве дә, гәрчә татарның үзендә үк Исхакый кебек асыл затларына каршы чыгарлык бәдбәхетләрне «үстереп» өлгерсә дә, әдәби көчләрне тәмам корытырга җитенкерәмәде. Аллага шөкер!

Чәчмә әсәрләр арасында җанга сихәт бирердәйләренең соңгы вакытта язылганнары да, әлбәттә, сәясәткә, сүз ирегә була башлауга, коточкыч цензураларның бераз йомшара төшүенә турыдан-туры бәйле рәвештә язылдылар. Мин бу юлы

тарихи әсәрләргә һәм сәяси гаепләнгән әдипләребезнең истәлек-язмаларын күздә тотам. Инануымча, әгәр заманалар үзгәреп, социалистик реализм дигән каһәр суккан ысулга нокта куелмаса, без Җ. Рәхимовның — «Батырша», В. Имамовның — «Сәет батыр», Батулланың «Сөембикә» романнарын да, М. Хәбибуллинның тарихи әсәрләрен дә укый алмас идек. Мин үзем дә әле 1965 елда ук бәгыремне көйдерә башлаган «Диңгез баласы» исемле повестемны бары тик 1992 елда гына бастырдым. Аны «Сөембикә» журналы дөньяга чыгарды. Кырым татарларының кешс ышанмаслык гаделсезлеккә дучар булуы сурәтләнә анда. Аны мин, Гурзуфка ял итәргә баргач, бер украин карчыгы авызыннан ишеткән җан тетрәткеч хикәяткә нигезләп язып куйган идем. Әмма еллары нинди булды бит: Кырым татары язмышы түгел, язучы үзе кичергәнне дә сөйләп бирә алмый иде.

Мәгълүм ки, илленче елларның азагында безнең ин талантлы әдипләрне черетеп яткырган төрмәләрнең ишеге ачыла башлады. Исән калганнар кайтты. Тик ул җәһәннәм чокырында ни күргәннәр, ни кичергәннәр — ләм-мим, авызларыннан бер сүз дә чыкмады. Берсендә, КПСС өлкә комитетының идеология секретаре Мирзаһит Вәлиев Хәсән Туфанны мактап сөйләде:

— Күрәсезме Хәсән аганы?! Сез анардан үрнәк алыгыз! Унтугыз ел тоткында булуына карамастан, партиягә һичнинди үпкә дә белдерми, гел елмаеп кына йөри, шундый якты фикерләр белән чыгышлар ясый — искитәрлек! — диде.

Секретарь барын да белеп бетермәгәндер инде, обкомга соңрак килде ул. Ә Хәсән ага «Искәндәр» псевдонимы белән ихлас шигырьләрен чыгарып караган иде бит. «...Казанский радионың радиусы бәләкәй...» кебек «тешсез» генә юмористик юллар иде алар. Шул да ярамады, мөхәррирләрне утлы табага бастырдылар, шагыйрьгә дә эләкте: «Күңелеңдә явызлык булмаса, псевдоним белән чыгармас та идең син!» — дип бәйләнделәр. Шул кечкенә генә «тәҗрибәдән» соң Хәсән абый елмаеп йөрүчәнгә әйләнде дә инде. Ник елмайганын үзе генә белгәндер. Еллар узды — «тегендә» ниләр күргәнен берәүгә дә сөйли алмыйча мәңгелеккә күчте. Мондый аянычлы язмыш ана гына түгел, совет чоры тоткынлыгын татыган башка күпсанлы әдипләребезгә дә кагыла. Исхакыйның чит илгә китүен аңлый алмыйча, аны тәнкыйтьләп чыккан, соңра, барыбер үзе дә төрмәгә эләккән Галимҗан Ибраһимовтан башлап, сандугачларга гашыйк Гарәфи ага Хәсәновка кадәр ничәмә-ничә язучыбыз, ул чорга бәддогаларын белдерә алмый вафат булды: Кәрим Тинчурин, Фәтхи Бурнаш, Галимҗан Мөхәммәтшин кебек уннарча егетләр, Гөлчирә Гафурова, Заһидә Бурнашева, Сәрвәр Әдһәмова, Абруй Сәйфи кебек кызларның рәнҗүләре кемгә төшәр?! Арадан берсен — Мин ага Шабайны — хәтта урыс язучысы китабына керткән. Хәтерегезгә төшереп үтәсем килә, чөнки мондый хәл, ягъни урыс агаеның татар язучысын үз әсәрендә унай яктан күрсәтүе — сирәк очрый торган вакыйга. Бу «дәрәҗәгә» ирешү өчен татарга, әлбәттә, урысны шаккатыру, сокландыру кирәк булгандыр. Сүзем Варлам Шаламовның «Левый берег» китабындагы «Курсы» дигән хикәясенә карый. Мәгънәсенең төсмеренә дә хилафлык килмәсен өчен мин В. Шаламов сүзләрен нәкъ китаптагыча китерәм. «...Человек не любит вспоминать плохое, — дип башлый ул. — Это свойство людской натуры делает жизнь легче... Из многих лет моей колымской жизни лучшее время — месяцы ученья на фельдшерских курсах при лагерной больнице близ Магадана... За первым столом на первом месте от прохода сидел Мин Гарипович Шабаев — татарский писатель. Мин Шабай, осужденный по статье «аса», жертва тридцать седьмого года. Русским языком Шабаев владел хорошо, записывал лекции по-русски, хотя, как я выяснил через много лет, писал он прозу на татарском языке. В лагере многие скрывают свое прошлое. Это объяснимо и логично не только для бывших следователей и прокуроров. Писатель, как интеллигент, как человек умственного труда, «очкарик» в местах заключения всегда вызывает ненависть и у товарищей, и у начальства. Шабаев понял это давно, выдавая себя за торгового работника, и в разговоры о литературе не вмешивался — так было лучше всего, спокойней всего, по его мнению. Он всем улыбался... Одним из первых он начал приобретать отечный вид — «опухать», — приисковые годы не прошли даром для Мина Гариповича. От курсов он был в полном восхищении.

— Понимаешь, мне сорок лет, и впервые узнал, что печень-то у человека одна. Я думал — две, всего ведь по два.

Наличие у человека селезенки приводило Мина Гариповича в полный восторг...» (В. Шаламов. «Левый берег», Москва, «Современник», 1989 ел, 85—91 битләр.)

Варлам Шаламовка мең рәхмәт, сөйкемле Мин Шабаевның кайларда «утыруы»н, анда да елмаеп йөрүен белдереп куйган, ичмасам. Мин ага үзе берни яза алмый «китеп барды». Исән-имин кайткан иде бит ул. Безнең янга, редакцияләргә кергәли, гел елмаеп кына йөри иде. Әмма язмышы хакында берни дә сөйләми иде.

Югалтуларыбыз иксез-чиксез, әмма без, татарлар, ни барына шөкер итәргә өйрәтелгән. Совет төрмәләреннән исән кайтканнарның кайберләре эчләре тулы сагышны укучыга җиткерә алды бит: Ибраһим ага Сәләхов — «Колыма хикәяләре»н, Аяз Гыйләҗев — «Йәгез, бер дога»сын, Гурий Тавлин «Афәт»не язып күзләребезне ачтылар.

Ибраһим ага бу әсәрен озак еллар буе язуы турында сөйли. Яшерен рәвештә, берәүгә дә сиздермичә язган ул. Авызын бер пешсә, салкын суны да өреп кабасың, дигәннәре шулдыр инде. Бу очракта да татар язучысына урысларга караганда саграк кыйланырга туры килә. Шул ук Ибраһим ага сөйләгән иде: «...иҗат йортында Женяны очраттым (Евгения Гинзбург турында сүз бара. К. Т.). Ул да тоткында булды бит. Бу әйтә, мин, ди, күргәннәремне яздым да, чит илдә бастырып та чыгардым инде, ди. Әйдә, яз, бир мина, чыгарабыз, ди. Тәвәккәлли алмадым. Урыс язучысына яраган, татарга батып бетми ул...»

Әлбәттә. Төрмәгә Казаннан киткән Гинзбургның ул язмалары — «Крутой маршрут» — әллә ничә телдә басылды, сәхнәләштерелеп, АКШ тамашачыларына да күрсәтелде инде. Шулай тиеш тә. Андый ерткычлыклар кабатланмасын өчен шулай тиеш. Безнекеләр, әсәрләре урыс язучы-тоткыннарыныкыннан һич тә ким булмасалар да, хәтта көчлерәк язылсалар да, кызганыч ки, әллә ни көчле яңгыраш алмадылар. Анысы — мәсьәләнең башка ягы, әмма аларны, һичшиксез, әдәби елъязмаларыбыз арасындагы иң кыйммәтле хәзинәдән санарга тиешсез. Мине аеруча Аяз Гыйләҗевның «Йәгез, бер дога»сы тетрәндерде. Чөнки мин ул язманы озак еллар көтеп алдым. Белә идем: Аяз илленче еллар азагында, «котылып» кайтып, кабат университетта укый башлады. Нәкъ мин укыган өченче курска туры килде ул. Озын чәч тубалы бәсләнгән, үткен күзләре һәрнәрсәгә шикләнеп карый, үзе гел... елмая.

Мин бу әдипләрнең гел елмаеп йөрүләренең серен хәзер генә аңлыйм кебек. Алар кичергәннәргә, гел җитди хәлдә яшәргә калсаң, ничек чыдамак кирәк?! Ярый әле кешегә җанындагы аянычлы хисләрен каплабрак торырга елмаю кебек матур пәрдә бирелгән! Аяз шат та, шаян да ул. Университеттан «Чаян» журналына эшкә китүен генә кара син аның! Инде, шул «сәфәр»дән соң утыз-кырык еллар узгач, «Йәгез, бер дога» кебек әсәр дөнья күрде. Мәгълүм ки, язучы һәр әсәрен йөрәге, канының һәр тамчысы аша үткәреп яза. Димәк, Аяз да, Ибраһим ага да, Гурий абый да, әсәрләрен безгә җиткерер өчен, шул җәһәннәм тормышын кабат кичергәндәй иткәннәр. Әйтергә кирәк, бу каһарманлыкны алар үзләре өчен түгел, укучының күзен ачар өчен һәм, әлеге дә баягы, андый гаделсезлекләр илдә кабатланмасын өчен.

Инде, аларның бу изге теләкләре тормышка ашсын, дисәк, калганнарыбыз да тырышлык куйсын иде. Җәмгыятьнең бүгенге тормышы тотрыклы түгел. Халык соңгы үзгәртеп коруларның асылын — шәхес иреген, сүз ирегенең кыйммәтен — тиешенчә аңлап та бетерми, чөнки аңа, беренче чиратта, тамак вә көнкүреш кайгысы якынрак күренә төшә. Ә илдәге матди хәл тәмам буталып бетте. Икътисадның тотрыксызлыгыннан элекке коммунистлар үз властьларын торгызыр өчен файдаланмакчылар. Шуңа да курку узмый. Менә, менә кабат цензура яңартылыр, гәзит-журналлар ябыла башлар, китапларга чикләү кертелер, тегеләр яки бу хакта язулар тыелыр кебек. Шикләнмәслек тә түгел. 1991 елда гына ГКЧП булып алды бит: сәгать эчендә мөхәррирләрне җыеп сөйләштеләр, инде типографиягә тапшырылган кайбер язмалар төшерелеп калдырылды, Мәскәүнең үзендәге әллә ничә гәзитне бөтенләй чыгармаска боердылар. Булды, бары да булды. Татар язучысы үз теләгәнен бер алдына, биш артына карый-карый яки базга төшеп, сукыр лампа яктысында гына язу кебек саклану чараларыннан арынып та өлгермәгән әле. Ихласлыкка өндәп күп алдадылар бит инде — кан катып беткән.

Шуңа да без — татарларга ашыгырга иде. Чәчмә әсәрләрнең киләчәктә дә укучы күңелен дәртләндерерлек, аңа гыйбрәт бирерлекләрен һич тоткарламыйча чыгару чарасын тудырырга иде! Араламыйча, элеккеге кебек темасын-фәләнен чикләмичә, авторларга «бәйләнмичә» укучы карамагына тапшырырга кирәк. Тарих үзе сирәкләр. Язылган булгач, яхшы булгач, әнә, кайтты бит Исхакый әсәрләре. Тик алар да дөнья күрә алмый, укучыга ирешә алмый яталар. Ярый, Татарстан китап нәшриятының 1997 елдагы эш планына Исхакый әсәрләренең 15 томлыгын баса башлау, беренчесен чыгару теркәлгән. Димәк, әдипнең мәҗмугасын шул рәвешле чыгарсалар, унбиш (!) ел көтәргә туры киләчәк. Моннан да аяусызрак мөнәсәбәтне, көндез шырпы кабызып эзләсәң дә, табып булмас.

Әлбәттә, аңлашыла: акча юк. Исхакый акча эзләр иде — үзе дә юк. Ничек чыгармак кирәк? Исән язучыларның кайберләре спонсорга, ягъни китап чыгарырлык акча бирүче байларга таяна бит. Татар әдәбиятының язмышы шундый, күрәсең: башын алса — койрыгы, койрыгын алса, башы сагызга ябыша. Бу очракта, минемчә, һичкемнең рәхим-шәфкатен көтеп тормыйча, укучылар арасында киң аңлату эшләре җәелдерергә иде. Нигә без, һәр мәдәниятле халыклардагыча, Исхакый әсәрләренә язылу оештырмыйбыз икән? Эшне җайга салып җибәрергә менә дигән этәргеч булыр иде бу. Яшерен-батырын түгел, Гаяз Исхакыйны укучыбыз аңлап та җиткерми әле. Чөнки җитмеш-сиксән ел буе алып барылган урыслаштыру сәясәте, әдәбиятның милли йөзен бозып бетерү сәясәте үзенең «һәйбәт җимешләрен» биргән, укучы Гаяз Исхакыйча язу алымын аңламас хәлгә җиткерелгән. Аның китапларын тарату, иҗатын аңлату юнәлешендә бик теләп, ихластан эшләүче укытучылар, әңгәмә оештыручылар кирәк. «Кирәк» тә «кирәк» инде... Чынбарлыгыбыз шундый бит. Чәчмә әсәрләребезнең яңадан-яңалары язылсын, язылган бере дөнья күрә торсын өчен, минемчә, тагын шул ук сүзне кабатларга туры килә: иң әүвәл аларны журналларда бастыру кирәк. Аннары — китап итеп чыгару һәм халыкка тарату. Боларын тормышка ашырганда хөкүмәтнең матди ярдәме тиеп торсын иде! Ул гына биреп бетерә алмаганда, мәрхәмәтле байларыбыз игътибар итсен иде! Хыялларның иге-чиге юк. Мин кайчак уйлап куям: әй, татарыбызда бер укымышлы бай барлыкка килсен иде дә, Исхакыебызның шушы унбиш томлыгын чыгарырлык акча бүлсен иде! — дип хыялланам. Бер карасаң, әллә ни дә түгел бит инде...

Хәзергә, хыялларыбызның яктылыгына канәгатьләнеп, киләчәккә өмет багларга гына кала. Җәмгыятебезнең, тарихыбызның һәм бөтен әдәбиятыбызның ялганчы дәвер баткагыннан котыла баруына шөкер итик тә, алда бер җае чыгарына ышанып, җанда булганнарны саф күңел белән ак кәгазьгә төшереп куйыйк. Ихласлык, фидакарьлек үзенекен итми калмас, мөгаен.

**Нәҗибә САФИНА:**

Бүгенге проза турында сөйләшү дигәч тә, өстәмә тау-ташлары, кар-бозлары белән тау ишелгәндәй булды. Чөнки бүгенгенең прозасы Кеше кадәр кешене күмеп китте дә, әдәбиятыбызга кешесез генә әсәр пәйда була башлады. Ничек инде алай диярсез. Һәм сез дә хаклы булырсыз. Әмма сез соңгы еллардагы татар прозасыннан заман герое булып, һәммәбезнең күңелен яулаган кемне атый аласыз? Ә соңгы еллардагы прозада мин рәхәтләнеп Мәхмүт Хәсәновның «Язгы ажаган» герое Иргалине, Ибраһим Сәләховның «Колыма хикәяләре»ндәге татар зыялыларын, арабыздан вакытсыз киткән Җәмит Рәхимовның «Батырша»сын, Фоат Садриев әсәрләрендәге авыл дөньясы геройларын атый алам. Безнең мәйдан тоткан прозаигыбыз Гариф Ахуновның Габбас мулласы гына да ни тора! Ә татар әдәбиятында үзе лирик, үзе унай һәм тискәре герой булып безнең күз алдыбызга баскан автор-төп герой Мөхәммәт Мәһдиевне кем белми! Күренекле язучы-галимебез Нурихан Фәттахның соңга калып булса да дөнья күргән «Кичү» романы күз йөзеннән читтәрәк калды сыман. Бу романда Кеше бар, җәмгыятьтә үз урынын эзләгән шәхес язмышы бар.

Әлбәттә, соңгы еллар прозасының иң зур вакыйгасы Гаяз Исхакыйның кайтуы булды. Ул да бүгенге прозабыз икән ләбаса! Без бүген дә шул ук «Зиндан»да яшибез. Фәкать ул чор, ул заман белән чагыштырганда күпмедер матди байлыкка ирешкәнбез дә, рухи хәерчелеккә төшкәнбез, җаннарын шайтанга сатканнар саны, имансызлар арта төшкән. Г. Исхакыйның бер буена торып басуы хәтта Галимҗан Ибраһимов дигән кояшка да күләгә төшергәндәй итте. Әмма кояшны күләгә генә каплый алмаганлыгын сукыр да белә. Әдипнең «Безнең көннәр», «Казакъ кызы», «Тирән тамырлар», «Кызыл чәчәкләр» әсәрләреннән башка татар әдәбияты турында фикер йөртү, кем дигәндә, бер яклы булыр иде.

Алардан безнең көннәргә күпер булып яткан Шәриф Камал, Мирсәй Әмир, Фатыйх Хөсни, Ибраһим Гази, Шәйхи Маннур, Кави Нәҗми, Гомәр Бәшировлар, Әмирхан Еники биеклеген саклый алдымы безнең бүгенге проза? Бүгенге көн күзлегеннән караганда, бу язучыларның кайбер әсәрләре сәеррәк тә тоеладыр. Ул башка төрле була алмый да. Чөнки заманның эстетик зәвык өскормасын тәшкил иткән көнкүреш үзгәрә. Гади халык телендә тормышны «кайталы да китәле» диләр. Ташкын үз ярларына кайту белән су баскан урыннарда утырып калган

әйберләр безгә ул «сәерлекләр»нең дә серләрен аңларга мөмкинлекләр ача — мода кайта. Әмма үзәгендә Кеше — олы герое булмаган әсәрне андый язмыш көтми. Алар ташкын өстендәге күбек кебек күренеп кенә алалар да югалалар.

Әгәр дә соңгы бер-ике ел прозасы турында сүз әйтергә телибез икән, нәкъ менә шундый күбек — прозадан качу өчен Кеше эзләү, олы әдәби герой эзләү прозасы ул дип әйтәсе килә. Эзләү икәнлекне берничек тә инкарь итеп тә булмый. Чөнки әдәбиятка анализ ясаучы булган тәнкыйтьче Тәлгать Галиуллин да эзләп-эзләп таба алмагач, үзе үк зур күләмле әдәби әсәр язып, шул житмәгән геройны мафия, җинаятьчеләр арасыннан эзләп карамаганмыни? «Тәүбә» романын мин нәкъ шулай кабул иттем.

Бәлки «Ат каралары» арасыннан таба алыр язучылар андый чын геройны? Әмма олы бер милләтнең символик героен һич кенә дә карак итеп күрәсе килми. Бәлки Зәки Зәйнуллинның бу әсәре әдәбият кысаларыннан чыгып, фәнни әсәргә үк әверелә аладыр? Рәсәй империясе мөселман халыкларын гомер-гомергә шулай бер-берсе белән бәрелештерергә омтылган. Бу — тарихи факт.

Эх, шул провокациягә бирелмәгән татар булсын иде ул герой! Татар тулаем алганда провокациягә бирелмәгән дә ул, бирелми дә, бирешми дә. Әдәбиятта типиклык төшенчәсен югалту әдәби әсәрне югалтуга тиң. Ярый әле бу әсәрдә ат карагы төп герой түгел икән.

Эзләү юлында «Казан утлары» профессионал язучыларга гына мөрәҗәгать итми. Р. Айзатуллин, Р. Гарипов, Г. Гомәр, М. Әмирхан әсәрләре шулай дөнья күргәннәрдер.

Олы геройны эзләү хикәя жанрында да бик үзенчәлекле чор кичерә. Үткән елда гына да «Казан утлары»нда берничә хикәя дөнья күргән. Әмма журналның 11 санында хикәяче Мәгъсүм Хуҗин «Татар хикәяләре «хәзинәсе»нә мөрәҗәгать итеп, иң яхшы дигән хикәяләрне журналда бирен барырга дигән тәкъдим ясаган. Һәм чын геройлы олы хикәя үрнәкләрен бүгенге укучыга күрсәткән дә. Мин моны журналны укучы профессионал язучыларга да мөрәҗәгать дип кабул иттем.

Эзләү, эзләнү... Тик ул да ике яклы. Чөнки тирә-ягыбызда бөтен дөнья сокланырлык гаҗәеп олы шәхесләребез барында әдәби геройларны тормыштан түгел, ә әдәбияттан эзләү уңышка китереп җиткерә алмастыр. Суфиян Поварисовны «Яшьлек иртәсе» романын шундыйлар рәтенә кертәсе килә. Бу очракта Мохтар Ауэзовның «Абай» романындагы яшь Абайга тәэсир иткән үлем фаҗигасе кабатлана. Ә нигездә Галимҗан Ибраһимовның «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» дип аталган өйрәнчек хикәясендәге идея-мәгънәви йөккә тагы ни өсти алган соң гаҗәеп матур телгә ия олуг язучыбыз?

Бүгенге көн прозасын үстерү өчен ниләр эшләргә кирәк, дип сорый «Казан утлары». Әйтим. Чын әдәби әсәрләргә лаек геройларны үз арабыздан эзләргә һәм табарга кирәк. Л. Толстойның, киләчәктә әдәби әсәрне уйлап чыгарып түгел, ә булганны тасвирлап кына язарлар, дигән фикерендә зур хаклык күрәм мин. Төртеп күрсәтәсе түгел, безнең дөнья күләменә күтәреп күрсәтер Гаяз Исхакый, Роальд Сәгъдиев, Нәкый Исәнбәт, Илһам Шакиров, Фәридә Кудашева — тагы күпме атаклы шәхесләребез бар. Алар безнең арада яшәмиләрмени! Аларның рухи, милли, дөньяви фаҗигаләренең эченә кереп яза алырлык язучыларыбыз бармы?

## НУРМӨХӘММӘТ ХИСАМОВКА 60 ЯШЬ



**Шушы елның 24 мартында күренекле әдәбият галиме, шагыйрь һәм публицист, Язучылар берлеге әгъзасы Нурмөхәммәт Шаһвәли улы Хисамовка алтмыш яшь тула. Әдәбият сөюче киң җәмәгатьчелек аны урта гасыр татар әдәбияты, XX йөз башы шигърияте һәм хәзерге татар поэзиясенең барышына кагылышлы хезмәтләре аша беләләр.**

**Бу галим Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» дастаны турында урыс һәм татар телләрендә ике зур китап бастырды. Аның берсе Мәскәүнең «Наука» нәшриятында дөнья күрде. Татар әдәбият белемендә һәм халыкара тюркологиядә югары бәя алган ул хезмәт «Поэма «Кысса-и Йусуф» Кул Али» дип атала. Ә Казанда 1984 елда чыккан зур күләмле тикшеренүе «Бөек язмышлы әсәр» исемле. Алга таба әдип Кол Гали поэмасының хәзерге әдәби телебезгә шигъри тәрҗемәсен эшләде. «Йосыф-Зөләйхә» дигән драма язды. Бөек ядкяребезнең урысчага тәрҗемәсе дә аның җитәкчелегендә башкарылды. Ул шулай ук «Татар әдәбияты тарихы»ның I һәм IV томнарында фәнни мөхәррирләрнең берсе булды.**

**Шигърият сөючеләр аны шигъри җыентыгы һәм фәлсәфи-лирик шигырь бәйләмнәре аша беләләр. Шагыйрьнең күп кенә шигырьләренә Нәҗип Җиһанов, Рөстәм Яхин, Сара Садыйкова тарафыннан җыр язылды.**

**Җөмһүриятебезнең суверенитет өчен көрәш елларында Н. Хисамов кайнар рухлы публицистик мәкаләләре белән халкыбызның дәүләтчелеккә хокукын, сәламәт әхлак һәм рухани традицияләрен яклап матбугатта чыгышлар ясады.**

**Галим һәм әдип, үзенең күпьеллык тикшеренүләрен гомумиләштереп, узган елның ноябрендә «XIII—XV йөз төрки-татар шигъриятендә «Йосыф-Зөләйхә» сюжеты (версияләр проблемасы)» дигән темага Мәскәүнең Дөнья әдәбияты институтында докторлык диссертациясе яклады.**

**Күп еллар дәвамында журналыбызның актив авторы буларак язышып килүче каләмдәшебезгә сәламәтлек, озын гомер һәм яңа иҗади казанышлар телибез. Хөрмәтле укучыларыбыз игътибарына аның соңгы хезмәтләреннән бер үрнәк тәкъдим итәбез.**

**Нурмөхәммәт Хисамов,**
филология фәннәре докторы

# XIV ЙӨЗ ШИГЪРИЯТЕНДӘ КЕШЕ ИДЕАЛЫ

XIII гасыр башыннан бирле бер дәүләт эченә кергәнлектән, Идел буе белән Хәрәзм уртак мәдәни тормыш белән яшәгәннәр. Шунлыктан, кайсы гына төбәк-

тән чыксалар да, шагыйрьләр уртак әдәби телгә нигезләнгән бердәм әдәби барыш эчендә иҗат иткәннәр.

Идел буеның тулы канлы әдәби тормышы, монгол яулап алуы аркасында, бары йөз елдан соң гына аякка баса алган. Шигърият иҗтимагый-инсани мәсьәләләрнең куелышы җәһәтеннән дә, сәнгатьчә үсеш ягыннан да Кол Гали ирешкән биеклектән кузгалып китә. Аның поэмасындагы үзәк мәсьәлә, белгәнебезчә, иҗтимагый гаделлек идеясе булса, жанр һәм тема җәһәтеннән ул урта гасыр төрки шигъриятен Низами казанышларын үзләштерүгә бик якын китереп җиткерә.

XIV йөздә төрки әдәбиятның фарсы әдәбияты белән бәйләнеше тагын да тыгызрак, аерылгысыз һәм эзлеклерәк төс ала. Чөнки фарсы телле халыкларның күпчелеге төрки дәүләтләр эчендә кала һәм шагыйрьләр асылда Фирдәүси чорыннан бирле төрки хөкемдарлар идарәсе шартларында иҗат итә. Шунлыктан төрки авторларның аларга бөек мәдәният ияләре итеп кенә түгел, бәлки иҗатта үзләренең иң якын кардәшләре итеп тә карау өчен тулы нигезләре булган.

Төрки шигъриятнең үсеш логикасын фарсы әдәбияты тарихы гына түгел, бәлки төркиләр җәмгыятенең иҗтимагый-эстетик ихтыяҗы да билгеләгән. Мәсәлән, төрки әдәбият Фирдәүси мирасына чынлап торып бары XVI йөз башында гына мөрәҗәгать итә. Кыскасы, XIV йөз Идел буе төрки әдәби процессы иҗтимагый-тарихи һәм эстетик җәһәттән кануниятле күренеш булып тора. Үз иҗатларында шушы чорның барлык төп үзенчәлек һәм тенденцияләрен гәүдәләндергән иң зур шагыйрьләр Котб, Хәрәзми, Хөсам Кятиб һәм Сәйф Сараи булган.

## Котб

Әлеге төркемнең беренче бөек вәкиле булып Котб санала. Ул 1342 елда Низаминең иң яхшы әсәрләреннән хисапланган «Хөсрәү вә Ширин» поэмасын ирекле тәрҗемә кыла. Бу тәрҗемә исә үзенең күп сыйфатлары белән нәзыйрәгә, ягъни шигъри ярыш яки иҗади җавап традициясенә тарта. Шушы вакыйга урта гасыр болгар-татар шигъриятенең һәм асылда бөтен төрки әдәбиятның сәнгатьчә югары дәрәҗәдә өлгергәнлеген чагылдыра иде.

Поэманың төп темасы, Низами әсәрендәге кебек үк, фарсы патшасы Хөсрәүнең һәм әрмән патшасының кызы Шириннең уртак мәхәббәте. Халыктан чыккан Фәрһад останың сюжетка килеп керүе белән фабуланың әлеге сызыгы традицион гыйшык өчпочмагы рәвешен ала. Гадел идарә нәтиҗәсендәге иҗтимагый бәрәкәт — поэманың үзәк мәсьәләләреннән берсе. Әмма шагыйрьнең иң мөһим эстетик максаты кеше идеалын эзләүдән гыйбарәт. Әйе, күрсәтүдән түгел, нәкъ менә эзләүдән гыйбарәт. Аның эзләнүе шуның белән мәгънәле һәм кызык та: ул, әйтик, Йосыф Баласагунлы сыман әзер формула һәм рецептлар бирмичә, кешенең камиллеккә баруын, аның тормышка карашы, әхлакый тәртибе һәм рухи сыйфатлары яхшыруын күрсәтә. Ул моны патша мисалында гәүдәләндерә. Хөсрәү патшаның һәм акыллы, бөтен холыклы патша кызы, соңрак исә үзе патшабикә Шириннең караш һәм гамәлләрен адым саен бәрелештереп, ул Низаминең сәнгати сюжет материалыннан эзләнүнең үтемле һәм тормышчан тирән өлгесен сайлап ала. Каһарманнарның барлык гамәлләрендә җанны хәрәкәткә китерүче көч итеп мәхәббәт тасвирлана. Шушы хис рәхәт тормыш яратучы чуар йөрәкле Хөсрәүгә бөек омтылышларны татырга һәм хөкемдәр буларак үзенең олы бурычын төшенергә, ә Ширингә исә патшалык итүче азгын чибәрне нык торып һәм чигенүсез рәвештә төзәтергә, аны гаделлеккә чынлап хезмәт итүгә юнәлтергә, сөеклесендәге фидакяр һәм затлы хисси батырлыкны аңлау һәм бәяли белүенә ирешергә ярдәм итә.

Котб Ширин сөйләменә патша хакимиятенең һәм мәхәббәтнең бергә сыешмавы хакында трагизм һәм кырыс гаепләү тулы сүзләр сала. Ширин, Хөсрәүнең үз нәфесен канәгатьләндерү өчен хакимияттән файдалануын һәм йөгәнсез кыланышларын күздә тотып, болай ди:

Гашыйклык берлә шаһлык раст кәлмәз,
Ики эшдин бирин кыл, йукса булмаз.

Йосыф Баласагунлы һәм Кол Гали кебек элеккерәк авторлар гаделлекнең статик моделен бирсәләр, Котбта без гаделлеккә баруның читен һәм катлаулы юлын җанлы сурәттә күрәбез.

Поэмада кеше идеалы эзләү төрле юнәлештә бара. Әсәрнең үзәк каһарманнары патшалар булганлыктан, идеалның беренче һәм төп билгесе итеп бурыч хисе алына. Бу төйгынның сыналуында барлык үзәк персонажлар: Хөсрәү дә, Ширин дә, Фәрһад та катнаша. Бурыч хисен тирән итеп төшенүче һәм аңа бер тап та төшермәүче каһарманнар икәү генә: алар — Ширин һәм Фәрһад. Хөсрәү исә мондый төшенүгә бик күп борма, сикәлтәләр һәм хилафлыклар аша килә. Вафат апасы Мөһинбану урынына тәхеткә утыргач, Ширин хөкемдар буларак үз бурычын шулай үти:

Мөһинбану илин ким билди Ширин,
Җавуктурды халайык ара гадлин.
Улус — ил гадле берлә шад булды,
Камуг зинданлыклар ул көн азад булды.
Зулумдин тыйгды залимләрнең әлкин,
Тутуб мәзлумларның ул гадле дадын.
Буйурды, татгавыллар куйды бажын,
Суйургаб алмады илдин баражын...
Аның гадлендә бүри бирлә куй су
Ичиб йурүрләр ирди хуш йанәшү
(Мөһинбану илен кабул итеп алгач Ширин,
Халыклар арасында гаделлеге белән дан алды.
Гаделлеге белән ил шат булды,
Барлык тоткыннар ул көнне азат булды.
Залимнәрнең кулын золымнан тыйды,
Гаделлеге белән мазлумнар күңлен яулады.
Боерды, ясак җыючылар салым алмады...
Аның гаделлегендә бүре белән куй
Хуш янәшә су эчеп йөрделәр).

Күренә ки, Котб феодаль җәмгыятьнең икътисадый мәсьәләләре хакында үтә бер катлы хөкем йөртә. Әмма ул феодал һәм ханнарның зиннәтле тормышын һәм өзлексез сугышларын тәэмин итеп торучы игенче һәм һөнәрчеләрнең авыр салымнардан интегүен, шушы йөктән бушану хыялында яшәвен чагылдыра. Ә гаделлек формуласын биргәндә, ул «Котадгу белек» дәрәҗәсендә кала. Аның фикеренчә, җәмгыятьтәге гаделлеккә табигать тә юмартлык белән җавап бирә.

Ширин хискә чумып үз дәүләте каршындагы җаваплылыгын оныткан Хөсрәүгә зур сабаклар бирә, фетнәче авантюрист Бәһрам Чубингә мәрхүм атасы шаһның тәхетен басып алырга юл куйган өчен патшалыкка варис саналган сөеклесен ул каты битәрли. Каһарман кыз бәйләнчек шаһ улына, аның төп бурычын исенә төшереп, кайнар канын сүрелдерергә тырыша. Ул, фольклор эпосы рухында, җан ризалыгының төп шарты буларак егеттән тәвәккәллек, батырлык, иле һәм сөйгән кызы каршында зур хезмәтләр таләп итә.

Ишитмәзмән бу йулда һич сүзүнни,
Качан дәүләт билә күрсәм йузүнни,
Ушул дәүләт билә биргәй сәнә җан...
Бурун җәһд итку ким дәүләттә булгай,
Морад аты күнүлчә сонча булгай...
Маңа булуб кәрәкмәз, мунда калсаң,
Атаңның таж-у тәхтен йава кылсаң...
Дәрига! Мән катында булмагаймән.
Йигит сән, шаһлык итмәк бар башыңда,
Катыйглан, булма каһил үз ишиндә!
Кылыч әлгә ал, хак йари биргәй...
(Ишетмим мин бу йулда) ризалык хакында. — Н. Х.) һич сүзеңне,
Кайчан дәүләт белән күрсәм йөзеңне,
Шул дәүләт белән генә сиңа җанымны бирермен...
Беренче тырышлыгың дәүләттә булсын,
Күңел максатың соңыннан булсын...
Монда калсаң, миңа син кирәкмәячәксең,
Әгәр атаңның таҗ вә тәхтен җуйсаң...
Аһ, мин катыңда булмам.
Егет — син, башыңда шаһлык итү бар,
Катылан, булма ваемсыз үз эшеңдә!
Кулыңа кылыч ал, хак ярдәм бирер...).

Бу сүзләрдән гарьлеге кузгалып, Хөсрәү Румга юнәлә, Рум патшасының кызы Мәрьямгә өйләнә һәм, румлылар гаскәре ярдәмендә Бәһрамны җиңеп, атасы

тәхетен кайтарып ала. Шул рәвешле ул тәвәккәллеккә ирешә, илен гадел идарә итә, әмма Ширингә булган мәхәббәтен шулай да тапсыз көе саклый алмый. Әрмән патшасының кызы шаһлык белән гыйшыкның сыеша алмавы турындагы хөкемнәрендә хаклы булып чыга.

Хөсрәүнең патшалык итүен Котб болай тасвирлый:

Бу күтәрелүдән котланды бәхте,
Кулына керде яңадан үз тәхте.
Халыклар арасында гадел даны җәелде,
Барлык илләргә изге аты чыкты.
Гаделлек белән әмерен шулай йөртте ки,
Аның әмереннән ярлылык тынды.
Замана аның шаһлыгына куанды,
Анушпрван йәнә терелде дип санады.

Ләкин, күргәнебезчә, боларның барысы да гүзәл һәм акыллы Ширин аркасында ирешелгән, чөнки хис белән мавыгып киткән Хөсрәүне ул үгетләп килә. Поэмада затлы гамәлләрнең иң куәтле этәргече итеп мәхәббәт тасвирлана. Бу хиснең көче һәм тирәнлеге каһарманнарның әхлакый сафлыгына бәйле. Шушы хакыйкать кеше идеалын эзләүнең бер яссылыгын тәшкил итә. Әлеге сыйфатның сыналуына бер Ширин белән Фәрһад кына бирешми. Каһарман кыз үз намусын акыллы һәм нык саклый.

Әмма җан белән нәрд уйнау ярамас,
Күңлем хуш кичсен дип, ычкыну ярамас.
Бу дөнья изге ат белән хуш ул, бел,
Егетлек вакытында ат казану файдалы.
Кирәкмәс бер теләккә баглы калу,
Без ике пакьне яман атлы кылу.

Әрсез Хөсрәүгә үгет биргәндә, Ширин зирәк фикерләр әйтә. Котб бу очракта Низами хөкемнәрен остазына тәңгәл үткенлек белән бирә.

Шириннең Хөсрәүгә гыйшкы һәм тугрылыгы кырыс сынаулар аша үтә. Ул сынаулар кыз өчен күп өлеш корбанчыл тәсмергә ия. Хөсрәү сыгылмас горур һәм тугры Ширингә үпкәсен янә бер мавыгу — Шәкәргә никяхлану белән чыгармакчы була. Каһарман кыз бу яраны да батырларча сабыр кичерә. Хөсрәү белән барлык бәрелешләрдә дә ул үзен гыйззәтле тота, шул ук вакытта сөеклесенең горурлыгына да азык бирә:

Йакын бел, бу тәнемгә җан сән, әй шаһ!
Ни тик җанны теләмәгәй тән, әй шаһ?

Кыз шаһның төрле юмалавына каршы үз йөрәгенә юлның бары никях аша узуын әйтә:

Сәнең күңлүң катыг таш, мән тимур җан,
Катыглыкда ирүр икиси бир сан.

Фәрһадның Ширингә гыйшкы өч каһарман өчен дә җитди сынау була. Шул шартларда Ширин Хөсрәүгә тугрылыгын эзлекле рәвештә һәм тапсыз саклап кала. Ә шаһ исә, Фәрһадның Ширингә мәхәббәте хакына максатына якынаюын, ягъни таш кыя аша юлны салып бетерүен күреп, әшәке мәкергә бара: егеткә сөеклесенең «үлемен» хәбәр иттереп, көндәшенең кыядан ташланып үлүенә сәбәпче була. Кыскасы, ул аны һәлак итә.

Халыктан чыккан талантлы оста, рәссам Фәрһад үзенең гыйшкы хакына зур батырлыклар эшли. Бу останың үз дәрәҗәсен белеп эш кылуы Хөсрәү патшаны аңа ихтирам белән карарга мәҗбүр итә. Шагыйрь рәссамның төп өстенлеге итеп аның сатылмавын күрсәтә. Ширин, сараена чаклы сузып арык үткәргән өчен, Фәрһадны үзенең кыйммәтле зиннәтләре белән бүләкләргә тели, әмма егет ул асылташларны кызның аяк астына сибә. Хөсрәү, Ширингә гыйшкыннан баш тартсын өчен, остага алтын тәкъдим итә, тик егет тәкъдимне мәгърур рәвештә кире кага.

Шагыйрь биредә иҗатчы остада югары әхлакый идеаллар иясен күреп, үзе дә кешенең бөеклегенә соклана. Фәрһадның иҗат батырлыгын тасвирлагач, ул менә нәрсә ди:

Бу адәми затның шәхесе гаҗәп:
Адәминең кулында булат балавызга әйләнә.
Эш башланганчы гына авыр, шуны бел,
Нинди генә эш башланса да, төгәлләнә, әй дус.
Һичбер эш бу адәм улыннан котылмас,
Тик үлсә генә чара юк.

Максатка ирешү юлында котычкыч киртәләрне җиңгәндә, Фәрһад дөньяның корылышы, кешенең тәүге башлангычы, аның җан җилкенеше, инсанлыгының башлангычлары хакында трагизмы ягыннан үтә тирән сораулар куя.

Ахыр мин кайдан? Бу гыйшык кайдан?
Кем туйдырды мине татлы җанымнан?
Тоташ ялкындамын, көл булганчы яндым,
Бу көюдә тереклектән туйдым.

Олы җанлылык һәм затлылык әсәрдә әхлакый идеалның асыл үзенчәлекләреннән берсе итеп тасвир кылына.

Үзенең дошманы Бәһрамның үлүе уңаеннан өч көнлек матәм игълан иткәндә, Хөсрәү зирәк патша булып күз алдына баса. Өченче көндә ул илгә үз хәзинәсендәге малны тарата.

Белеп Бәһрам үлемен, күп уфтанды,
Тәхетеннән төшеп, өч көн матәм тотты,
Дөньяга ышаныч юк, дип күңле төште.
Замана җәбереннән зарланды,
Соңыннан үләргә туры киләчәген уйлады.

Шагыйрь шул ук вакытта хәбәр китерүче авызыннан Йосыф Баласагунлы рухында бүтән чорлар өчен дә гомумкешелек һәм гамәли әһәмияттән җуймаслык фикерләр әйттерә.

Дусларың мең булса да, аз дип бел,
Дошманың бер генә булса да, аннан саклан.
Янә дошман үлеменә шатланма,
Чөнки үлемнән үзең дә азат түгелсең.

Үзенең көндәше Мәрьямнең үлемен ишеткәч, Ширин ю шулайрак хис итә.

Хәбәр Ширингә килеп житкәч, аңлап,
Дөнья эшенә хәйран булды таңлап.
Бер яктан карап күңле шат булды,
Чөнки көндәш дошманыннан котылды.
Янә бер яктан уйлады кайгы йотып,
Бу көн безгә дә киләсеме, дип.
Икенчедән, Хөсрәү хәтерен дә саклады,
Сөенүдән кулын һәм телен тыйды.

Котб кеше идеалы төшенчәсенә белемгә омтылуны да кертә. Хөсрәү шаһның акыл иясе Бозорг Өмид белән әңгәмәсен ул тикмәгә генә әсәр азагында китерми. Каһарманнар инде бу чорга үз максатларына ирешеп өлгерәләр. Шаһ һәм патшабикә мәхәббәтләрен язмышның барлык киртәләре аша исән-сау саклап уздыралар, гадел хакимият белән шәхси, гаилә бәхетенең гармониясенә ирешәләр. Ләкин камиллеккә омтылу моның белән генә чикләнми. Котб өчен, Низамидәге сыман ук, өзлексез гыйлем туплау, дөньяга карашны даими киңәйтеп тору, хәятнең, әхлакның һәм җан җилкенешләренең иң тәүге чыганакларын танып белү мөһим. Кыскасы, аныңча, яшәүнең һәм бәхетнең тулылыгы бары шәхеснең рухани камиллеге аша гына күз алдына китерелә. Шуның белән бергә дөньяның корылышы турында чорның инсанилек дәрәҗәсен билгеләрлек фикерләр әйтелә.

Хөсрәү акыл иясенә: «Дөньяның башы нәрсәдә?» «Бу күк чынлыкта нидән гыйбарәт?» «Бу йолдызлар нидән гыйбарәт?» «Мин һәр йолдыз бөтен бер дөнья тәшкил итә, башка җир һәм күкләрдә дә, безнеке сыман ук, тереклек бар, дип ишеткән идем» кебек тирән сораулар куя. Аннары үз алдына кайчандыр үз-үзенә, язмышына һәм дөньяга Фәрһад куйган сорауларга охшаш мәсьәләләр тезә. Ягъни шагыйрьнең барлык хуплаулы каһарманнары бер үк серләрнең төбенә төшәргә, бер үк хакыйкатьләрне ачарга омтылалар.

Котбның урта гасыр татар шигърияте, бөтен төрки шигърият алдындагы бер бөек хезмәте шуннан гыйбарәт ки, ул Низаминең энциклопедик белемнәрен, иң югары өлгеле сәнгатьчә тәҗрибәсен һәм инсани ният-фикерләрен төрки укучылар малына әйләндерә. Төрки шагыйрь бер үк вакытта иҗади мөстәкыйльлеген дә зур куәт белән чагылдыра алган. Шул рәвешле Низами поэмасының сюжеты идея яктыртылышы җәһәтеннән дә, көнкүреш реалийләре өлкәсендә дә, шигъри эшләнеш яссылыгында да жирле, төрки төсмерләргә өртелә. Поэмада тел үзенчәлекләре ягыннан татар теленең мишәр диалекты белән бик күп уртаклыклар табабыз[1]. Әсәрдә болгар-кыпчак этнографик реалийләре белән сугарылган детальләр аз түгел. Мәсәлән, тантаналы каршылау вакытында тәңкә сибү, кунакларны кабул иткәндә, патшаның тәхеттә патшабикә белән янәшә утыруы, хуҗага хөрмәт һәм итагать йөзеннән баш киемен салу, патша мәҗлесендәге ашлар үзенчәлеге, Идел һәм Урал арасына хас ау җәнлекләре h. б. Шагыйрьнең күп кенә чагыштырулары, аллегория һәм метафоралары кешеләрнең көндәлек тормыш тәҗрибәсеннән алынган.

Мәсәлән, Хөсрәүне гаделлеккә үгетләп, Ширин болай ди:

Җиһанны башта төзек кылдың, хуш,
Соңыннан золым белән хәрап кылма...
Әйтик, бер сыер башта сөт бирсә,
Соңыннан үзе үк тибеп сөтен җиргә түксә.

Хөсрәүнең хәбәрчесе Шауыр Ширингә артык сүздән тыелу турында шундый киңәш бирә:

Матур сүз аш эчендә тәмле тоз ул,
Күп булса, тәме китә, азы урынлы.

Мөһинбану — сеңлесе Ширинне Хөсрәү алдында кызулыктан шулай кисәтә:

Нык бул, йөзеннең нуры китмәсен —
Миче кайнар булса, икмәк көя.

Котбта, Низамидәге кебек үк, тотрыклы рәвештә әсәрнең буеннан-буена сузылган чагыштыру һәм метафоралар бар. Аларның барысы да шагыйрьнең сокланычы һәм идеалларының төп чагылдыручысы булган Ширин тасвиренә карый. Һәр очракта ул ташка урнаштырылган алмазга тиңләнә. Менә Ширин Хөсрәүне көтеп тору вакытына дип төзелгән калгачыкка килеп җитә:

Сарай исемле зинданга җитте,
Гәүһәр сыман, үзен ташларга уйды.

Икенче очракта, шул ук метафораны төрләндереп һәм каһарман кызны Кол Гали поэмасындагы Йосыфка чагыштырып, күренешнең фаҗигачел төсмерен көчәйтә:

Чи ташларга ул гәүһәр катылган,
Йосыфтай кайгы коесына атылган.

Әйтергә кирәк ки, шагыйрь «Кыйссаи Йосыф» белән тирәнтен таныш, аның фикри-хисси рухы һәм шигъри гыйбарәчелеге белән нык сугарылган. «Хөсрәү вә Ширин»дә Кол Гали поэмасының башламындагы юлларны, бетемендәге укучыга төбәлгән мотив һәм структур элементларны, «Кыйссаи Йосыф»ка хас рифмаларны очратырга мөмкин[2].

Кол Галинең үз каһарманнарыннан Йагкуб белән Йосыфка карата кулланылган «йарлы» (бичара) теләктәшлек эпитеты Фәрһадка бәйле рәвештә файдаланылган. Карчык Фәрһадкә Ширинне «үлеме» турында ялган хәбәрне тапшырганда, аңа: «Йә йарлы Фәрһад!» — дип эндәшә.

Котбның урта гасыр төрки поэтикасын моңарчы күрелмәгән биеклеккә күтәргән кыйммәтле яңалыгы Низаминең катлаулы метафоралар эшләү тәҗрибәсен

---

[1] Кара: Таһирҗанов Габдрахман. Тарихтан — әдәбиятка. Казан, 1979, 106—109 б.

[2] Бу турыда кара: Хисамов Нурмөхәммәт. Бөек язмышлы әсәр. Казан, 1984, 291 б.

ижади файдаланудан гыйбарәт. Мәсәлән, көн белән төн алмашынуын ул теге яки бу гаскәрнең җиңүе рәвешендә сынландыра Таң атуны ул менә ничек тасвирлый:

Таң шаһы чыгу белән
Дөньядан качты негрлар гаскәре,
Яңа көн төлкесе күтәрде башын,
Сата башлады галәмгә ул комачын.
Фирүзә күк гөмбәзе капусын ачты,
Дөньяга алтынын берьюлы чәчте.
Йөздән пәрдә бөтенләй күтәрелгәч,
Җиһанга ас тулды, китте кеш күздән.

Шагыйрь биредә сынландыру принцибын Низамидән алса, метафораларга Идел буе төркиләре чынбарлыгына хас төсмерләр кертеп, аларның фактурасын үзгәрткән. Таң ату күренеше һәр очракта яңа метафора ярдәмендә тасвирлана.

Таң әтәче аваз биргәч тә,
Дөнья гашыйклар йөзе төсенә керде,
Төннең йозагын ватып, көн чәчәк бөресен ачты.

Башка очракларда шагыйрь гомуми төшенчәләрне җисемләштерә. Кәефсафага чумган шаһның, хәбәрчесе Шауыр килгәч, шатлануын ул менә ничек бирә:

Мәлик сөенеп сикермәкче булды,
Гакыл якасыннан тотты, селкетмәде.

Татар халкында «сүзне колакка элү» дигән гыйбарә бар. Нәрсәнедер хәтердә калдыру, нәрсәгәдер игътибар итү мәгънәсендә. Мөһинбануның Ширингә Хөсрәү белән очрашу алдыннан биргән мәгълүм киңәшенә сеңелесенең мөнәсәбәтен шагыйрь шулай метафоралаштыра:

Аның киңәшен колакка алка кылды.

Котб, сүз белән эш иткәндә, зур осталыкка ирешә. Бу бигрәк тә аның омонимик рифмаларында һәм, аларны кулланганда, мәгънәви төсмерләрне нечкә тоеп, сүз уйнатуында аеруча күзгә ташлана.

Асылда эпик яңгырашлы шушы поэмада лирик башлангыч та гаять көчле. Ул Ак Урда хөкемдарларына мөрәҗәгатьтә дә, шагыйрьнең үз каһарманнарына һәм, гомумән, кешенең сәләтенә соклануында да, үз җаны кичергән иҗат шатлыгы тасвирында да яхшы төсмерләнә. Кыскасы, Котб шигырьгә шундый тулы яңгыраш биргән һәм бәяләү таләбен шундый югары куйган ки, моның тәэсире һәм нәтиҗәсе XIV йөзнең бөтен төрки шигърияте͏ндә тирән чагылыш тапкан.

## Хәрәзми

Котбның кеше идеалы юнәлешендәге эзләнүләренә һәм лирик мәктәбенә үз чорының талантлы лиригы Хәрәзми кушылып киткән. Бу шагыйрьнең Алтын Урда ханнары нәселеннән булган Мөхәммәт Хуҗа бәккә багышланган «Мәхәббәтнамә» поэмасы 1353 елда Сыр Дәрья буенда язылган. Әсәр күләме белән зур түгел, 900 юлдан чак кына артык. Аның анык кына сюжеты да юк. Композицион яктан фон рәвешендә аны бәк мәҗлесе бер бөтенгә туплый. Шагыйрь әледән-әле мәҗлес хуҗасына мөрәҗәгать итә, ә гомумән исә хатын-кыз гүзәллеген данлый һәм лирикасы адресатына өметсез гыйшык хисләрен түгә. Әсәрнең керешеннән күренгәнчә, Хәрәзми — фарсыча да, төркичә дә иҗат иткән ике телле шагыйрь. Автор тарафыннан китерелгән бәк сүзләренә караганда, бу чорга инде шагыйрь киң танылган иҗатчы булган. Поэмасының шигъри яктан югары җитлеккәнлеге дә моны күрсәтеп тора. Әсәр, бәк үтенече буенча, аны данлау өчен язылса да, аңарда кыйммәтен җуймас гомумкешелек идеяләре яктыртыла.

Кеше идеалын эзләүнең барлык юнәлешләрендә дә Хәрәзминең Котб белән шигъри авазлары очраша. Хатын-кызның ул табигый матурлыгын данлый.

Аның кем ал иңиндә миң йаратты,
Сачыны айак илә тиң йаратты.

Мәхәббәтне сөеклесе сурәтенә бәйләп хөкем йөрткәндә, шагыйрь аның серле һәм җәлеп итүчән шәхесендәге рухи көчне шулай сурәтли:

Мәхәббәттән туа мең төрле сер,
Күңел серләрен җан белән саклый.

Әсәрдә ир егет идеалы тәвәккәл, эшлекле, гадел һәм юмарт бәк сурәтендә гәүдәләнә. Каһарманның шушы сыйфатларын чагылдыручы чагыштыру һәм метафоралар көнчыгыш фольклоры һәм әдәбиятының камил үрнәкләре нигезендә эшләнгән. Панегирик адресат юмартлыкта, мәсәлән, Хәтәмтайга тиңләштерелә. Дөрес, талантлы мәдхиячеләрнең максаты һәрвакытта да макталган затларны данлау гына түгел, күбрәк аларга легендар үрнәк ярдәмендә җәмгыять мәнфәгатьләрен истә тотып тәэсир итү булган. Шунсы кызык, шагыйрьнең замандашы булган реаль шәхеснең лирик сурәте хакында сүз барганда, безнең каршыбызга Алтын Урда чоры каһарманының мактаулы сыйфатлары өлге рәвешендә килеп баса. Дәһшәтле сугышчанлык та шушы сыйфатларга керә.

Әгәр дисәм сине Рөстәм, йарарсың:
Кылычың бирлә сафларны йарарсың[1].

Зирәклек һәм көч бәкнең тиң сыйфатларыннан санала:

Улус тоттың камуг[2] гаклың көчендин,
Чәриктә[3] кан тамар камчың очындин.

Поэмадагы үзәк кыйммәтләрнең берсе лирик каһарманның үз сурәтендә, иҗатчы, сәнгатькәр шагыйрь образында чагыла. Хәрәзми аның бәйсезлеген, сатылгысыз горурлыгын данлый. Биредә ул халыктан чыккан Фәрһад оста сурәтенә гаҗәеп дәрәҗәдә охшый.

Бәкнең шаһларга хас кодрәтен данлаганда, авторның үзен дә падишаһ дип атавы зур кыюлык түгелме?!

Кылыч тик тел белә тоттым җиһанны,
Канәгать мөлке эчрә падишаһ мин.

Ул, үз дәрәҗәсен яхшы төшенеп, бәккә болай ди:

Ни дәрәҗәдә бөек солтан булса да,
Мал өчен мактау һәм данлау сүзе әйтмәм!

## Хөсам Кятиб

**XIV** гасырның икенче яртысыннан башлап, Идел буе төрки шигърияте үзенең позициясен активлаштыра төшеп, тормышның комик якларына да игътибар юнәлтә башлый. Поэтикада күзгә бәрелеп, юмор, ирония, сарказм калкып чыга. Бу юнәлешне башлап җибәрүче һәм аның иң күренекле вәкиле чама белән 1370 елда тәмамланган «Җөмҗөмә солтан» поэмасы авторы Хөсам Кятиб булган. Әсәрнең сюжеты патшаның баш сөягенә бәйле тарихтан гыйбарәт. XII гасырда шул ук сюжетка фарсы шагыйре Фәридетдин Гаттар да бер поэма язган була. Е. Э. Бертельс фикеренчә, поэма Алтын Урда ханнарының сарай тормышын, аларның купшы эиннәтләрен күпертеп тасвирлый.

Солтан бер фәкыйрьнең хәтерен калдырган өчен җәза рәвешендә авырып китә һәм кинәт үлә. Ул шундук тәмугка эләгә. Хөсам Кятиб тасвирлаган тәмугның аерым детальләре Дантенең «Илаһи комедия»сендәге күренешләрне хәтерләтә. Гайсәнең үтенече белән Аллаһ Җөмҗөмәне янә терелтеп, икенче тапкыр яшәргә мөмкинлек бирә. Солтан, мәгарәгә кереп, гомерен гыйбадәттә үткәрә.

Хөсам Кятибне үзенең элгәреләре белән кеше идеалын хөкемдар сурәте нигезендә эзләү берләштерә. Шәхесендәге әйдәүче сыйфатларга һәм үз-үзен тотышына караганда, каһарман гадел патша булган. Ул халыкны туендырган, беркемне дә кыерсытмаган, теләген канәгатьләндерми торып, һичкемне бусага-

---

[1] Ярырсың.
[2] Барсы да.
[3] Гаскәрдә.

сыннан борып җибәрмәгән. Һәр дәрвишкә һәм хәерчегә ул кием һәм ат биреп җибәрүчән булган.

Йәнә бар ирде мәнем хуш гадәтем,
(Ул сәбәб чыкмыш иде изге атым),
Кем килер әйди йомыш: кайда әсир
Булса, мискин йә гарип йахуд фәкыйрь,
Көн дә мең килсә иде дәрвиш, йәтим,
Алмайынча китмәс ирдә тун, атым...
Кичә көндез гадел-дад ирде эшем,
Барча галәм йиәр ирде су-ашым.

Солтанның зиннәтле тормышын шагыйрь болай үзе гаепләми. Менә патша бер тапкыр гыйш-гыйшрәттә онытылып, фәкыйрьгә вакытында илтифат итеп өлгерми һәм шунлыктан ходай тарафыннан яман чир белән җәзалана, үлеп тәмугка эләгә. Гаебен төшенүгә, патша хәерчене эзләп тә карый, әмма таба алмый. Әсәрнең гыйбрәте дә шунда: хөкемдар үз карамагындагы ил кешеләрен бер мизгелгә дә онытмаска тиеш, алар хакында кайгырту — аның иң беренче бурычы. Шагыйрь, шул рәвешле сәнгатьчә үтемле итеп, кешеләрнең барысы турында да тигез кайгыртудан, гади халык ихтыяҗларын онытмаудан гыйбарәт инсаният идеясен гәүдәләндерә алган. Кыскасы, поэманың иң көчле идея сөземтәсе кечкенә кеше ихтыяҗларына илтифат патшаның барлык мәнфәгатьләреннән дә өстен, дигән фикердән тора.

Хөсам Кятиб эчтәлек материалы белән осталарча эш итә. Каһарманының яшәү һәм идарә рәвешен аның туры сөйләме аша тасвир иткәндә, ул үзенең ирониясен дә аермачык сиздерә. Мәсәлән, җариясе белән мавыгу мизгелен Җөмҗөмә шулай хикәяли:

Алдым аны яныма зәукъ итәргә,
Бергә ятып, кочып гыйш итәргә.
Көтмәгәндә, бер олы хезмәтчем кереп әйтте:
«Бер фәкыйрь килде, хәер сорый».
Мин үзем шул чаклы мәшгуль идем —
Галәм дә күземә күренми иде;
Әйттем: «И ахмак, хәер вакыты түгел бу,
Сиңа да, бүтәнгә дә игътибар вакыты түгел бу!»

Шагыйрьдә феодаль җәмгыять бозыклыкларын фаш итүнең диапазоны гаять киң. Гадел хөкемдәр мәсьәләсе әсәрнең үзәгенә куелса да, ул аерым бер максат булып тормый, ә бәлки җәмгыятьтәге барлык катлауларның да әхлагын савыктыру нияте эчендә карала. Автор феодаль җәмгыятьтәге рибачылык (ростовщиклык), тәкәбберлек, һавалану, ялган фәлсәфә сату, яла, гайбәт, караклык һәм кеше талау ише социаль һәм әхлакый чирләрне кырыс рәвештә тамгалый. Тәмугта аның рибачылары ут һәм ялкын йота. Бигрәк тә юлбасарлар рәхимсез җәзалана.

Тәкый бер кавем азак үзрә торыр,
Бер тынмас, утлуг кылыч берлә орыр:
Башларыны тәннәрдән айырыр,
Йәнә хакъ кодрәтедин баш битүрер.
Аңлар ирмеш кем болар: юлда торып,
Баш кисеп, кан түкмешләр багый[1] булып.

Күршеләрен рәнҗеткән кешеләрне теге дөньяда аяксыз, кулсыз калдырганнар. Ялган фәйләсүфлар исә телсез, кулсыз, аяксыз калып җәзаланалар. Юмартлык барлык сыйфатлардан да өстен куела. Төрки фольклорда макталган халык гадәте — кунакчыл югары әдәп хуплана.

Халык хәленә битараф патшалар иң каты җәзага тартыла: аларны ялангач калдыралар, яра һәм шеш тулы тәннәреннән кан саркый. Тәмугка эләккән барлык адәмнәрнең күзләре шуларга текәлгән.

Беркүпме вакыттан соң, идарәсе чорында кылган игелекле эшләре өчен, бер Җөмҗөмәне генә азат итәләр.

Кятиб хөкемдарларга аларның халык алдындагы бурычын бик үтемле итеп төшендерә. Бердәнбер гаебе өчен дә теге дөньяда Җөмҗөмәнең башына утлы бүрәнә белән китереп тондыралар. Бу — асылда шагыйрьнең үз замандашларыннан һәм аларның оныкларыннан булган тере патшалар башын таранлавы.

---

[1] Багый — юлбасар.

Поэманың азагында китерелгән халык мәкале («Һәр кем ирсә нә иксә-ургай аны») барлык кешеләрне дә кисәтә һәм исән чакта игелекле эшләр кылырга чакыра. Шуны онытмаска тиешбез: урта гасырларда китап сүзенә изге сүз итеп караганнар, шунлыктан ул тылсымлы тәэсир көченә ия булган.

Поэманың керешендә куелган риторик сорау бөтен әсәрнең камертоны булып яңгырый.

И «җиһан бакыйдыр» дигәннәр каны?
Ишетең дөнья эшен, белең аны;
Кани ул Адәм? Кани Нух вә Хәлил?
Бакый калмас хакыйкать иллә җәлил...
Кани Хөсрәү, Ширин, Зөлкарнәйн[1], Гад?[2]...
Йахуд кани ул Нәүширван[3] шәһрийар[4]?
Кани ул Мәхмүд — дин шаһы Газнәви?...
Кани Чиңгиз? — та һәлак булды камуг...
Киттеләр бер парә бүзгә чолганып,
Тәннәри үз каннарига болганып...
Чөнки килдең дөнйайа — китмәк кирәк,
Бар көчең йиткәнчә хәйр итмәк кирәк.

Шул рәвешле, Хөсам Кятиб, бөек инсанчы буларак, иҗтимагый гаделлек һәм әхлак сафлыгы мәсьәләсен кеше сурәте аша куйганда, «Кеше тормышында нәрсә кыйммәтрәк?», «Кеше хәятенең мәгънәсе нәрсәдә?» кебек сорауларга җавап эзли. Поэмадан исә бер генә җавап килеп чыга: «Үзенеңнән соң изге ат калдыруда».

Тапмас ирде кеше дөнйадин морад,
Бәс калыр ирмеш җиһанда изге ад.

Шушы бәрәкәтле һәм яшәешнең нигезен ныгытучы фәлсәфи формула алмашка килгән буыннарда игелекле әхлакый башлангычларның мәңгелек күчемлелеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

Шагыйрь өчен патша гадәттән тыш өстен кеше түгел, ә шундый ук гади зат. Шунлыктан гаделлек, игелек, юмартлык турында сүз барганда, аның гадәти кешелек бурычы күздә тотыла. Поэма каһарманы үзенә кабат бирелгән гомерен тикмәгә генә тыйнак һәм тәкъва гыйбадәтче булып үткәрми. Саф вөҗданлы тыйнак тормыш чиксез нигъмәтләр эчендә патшалык итүдән өстен куела. Сюжет барышында каһарманның үз-үзен тотышындагы мондый борылыш — әсәр проблематикасы планында — мантыйклы һәм сәнгатьчәлек җәһәтеннән көчле алым. Кятибнең инсани фикерләвендәге максимализм шартларында иҗтимагый пассив гамәлнең мондый кискен чиге шәхсият күзлегеннән чикләнмәгән хокуклар белән башкаларның дәрәҗәсен таптап гомер итүгә караганда әхлакка ятышлырак булып күренә. Әмма хәлиткеч нәтиҗәләрдәге мондый максималистик килешмәүчәнлек гомумидея планында иҗтимагый пассив чиккә алып бара. Ягъни, халык турында кайгырту үзеңнең шәхси тәкъвалыгыңны кайгыртуга алмаштырыла. Шагыйрь, шаһанә затны хакимияттән мәхрүм итеп, халыкны да яклаучысыз калдыра.

Кятибнең иң характерлы сәнгатьчә алымы — ул гипербола, ягъни күпертеп тасвирлау. Патшаның идарә куәтен ул санлы күпертүләр ярдәмендә шаккаттыргыч итеп күз алдына бастыра. Мәрхүм Хатип ага Госман әдәбияттагы мондый күренешне урта гасыр авторының җан диалектикасыннан хәбәрсезлеге белән аңлата иде[5]. Соңгы вакытта урта гасыр әдәбияты белгечләре бу фикергә житди төзәтмәләр кертте.

Кятиб шигырьнең зур остасы булып күз алдына баса. Поэманың бер генә җирендә дә ритмик сөрлегү яки стилистик төртелү ише нәрсәне сизмисең. Шигырь җегәрле, омтылышлы һәм җиңел агыла. Аваздаш (омоним) рифмалар белән ул элгәреләренең лаеклы көндәше булып эш итә. Аның каһарманы, үз-үзен гаепләп, шуны икърарлый:

---

[1] Искәндәр Македонлы.
[2] Тәүрат һәм Коръән буенча, әфсанәви (легендар) кавем башлыгы.
[3] Нәүширван — мәгърифәте һәм гаделлеге белән дан алган Иран шаһы.
[4] Шәһрияр — патша.
[5] Кара: Татар әдәбияты тарихына материаллар. Җөмҗөмә солтан. Казан. 1970, 16—17 б.

Әсрү йавыз хәлдә йаттым ул кичә,
Ул белер, кем үз башындин эш кичә.

Бередә исем белән фигыль рифмалаша. Шагыйрьнең шигъри юллары бигрәк тә патшаның кәеф-сафалы тормышын аның хатирәләре аша сурәтләгәндә тулы камиллеккә ирешә.

Хөсам Кятиб әсәренең безнең халыктагы аерым абруен бары аның сәнгатьчә югары дәрәҗәсе һәм бәрәкәтле фикри-әхлакый җегәре белән генә аңлатырга мөмкин. Татар халкы арасында Алтын Урда чорының сирәк ядкярләренә насыйп киң таралышны без аның күпсанлы кульязма күчермәләреннән күрәбез. Казанда ул басылып та чыккан. Шушындый әсәрләргә зур ихтыяҗ булу бер үк вакытта халыктагы югары укучылык мәдәнияте хакында да сөйли.

## Сәйф Сараи

Хөсам Кятибтән шулай ук ироник-саркастик табигатьле шагыйрь Сәйф Сараига бер генә адым кала. Шушы автор шигъриятендәге тональ палитра элгәреләрендәге комик үткенлекне дә, фәлсәфи тирәнлекне дә, лирик назлылыкны да, сурәт нәфислеген дә бердәй көч белән үзенә туплый. Аның иҗаты Котбтан Кятибкәчә булган XIV йөз шигъриятендәге бөтен үсешнең йомгагы һәм кануниятле дәвамы сыйфатында барлыкка килә. Бу чорда төрки әдәбият фарсы әдәбиятының идея-сәнгатьчә казанышларын аның феодаль тормышны тәнкыйтьләүче бөек вәкиле Сәгъди иҗаты аша үзләштереп, шуны үз шигъри күренешенә әверелдерү ихтыяҗын тоя.

Тәхәллүсе үк күрсәтеп торганча һәм шагыйрьнең үз сүзләреннән дә күренгәнчә, Сәйф Сараи шагыйрь буларак Алтын Урда башкаласы Сарайда формалашкан. Галимнәр фикеренчә, ул 1321 ел тирәсендә туып, якынча 1396 елда вафат булган. Туган җире итеп шагыйрь Камышлыны атый. Тикшеренүчеләр Идел буеның урта гасырда төзелгән карталарында шушы исемдәге берничә авыл һәм шәһәрчекне күрсәтәләр[1]. Алтын Урданың таркалу чорындагы күп кенә мәдәни эшлеклеләре сыман, шагыйрь Мисырга күчеп китә һәм үзенең укымышлы дуслары, каләмдәшләре киңәше белән «Гөлстане бит-төрки» (Төрки Гөлстан) әсәрен язуга керешә. Кыскасы, Идел буеннан чыккан шагыйрьләр дә, мәмлүкләр Мисырындагы сәнгатькәрләр дә Сәгъди «Гөлстан»ын төрки шигъриятнең үз милкенә әверелдерү кирәклеген нечкә тойганнар. Сәйф Сараига бирелгән заман ихтыяҗы рәвешендәге шушы иҗтимагый әманәт Алтын Урданың хакимияте һәм өстен әхлагы тулысынча төшү һәм таркалуга барганда, әдәбиятта тәнкыйди тенденциянең тирәнлеген күрсәтә.

Сәгъди «Гөлстан»ының төрки тәрҗемәсе Йосыф Баласагунлының «Котадгу белег»еннән соң җанлырак һәм үтемлерәк эчтәлекле һәм чагыштыргысыз югары шигъри дәрәҗәдә башкарылган икенче гаять мөһим вакыйга булып тора. Сәйф Сараи урыны-урыны белән фарсыча өлешләрнең төрки тәңгәлләрен эшли, яки тулысынча үзенчәлекле мөстәкыйль парчалар бирә. Боларның һәрберсен ул виртуозларча башкара. Аның әсәрендә төрки шигырьнең куәте урта гасыр шартларында үзенең иң югары тыгызлыгына һәм тапкыр үткенлегенә ирешә. Тарихи шәхесләр тормышыннан алынган яки гыйбрәтле вакыйгалар хакындагы чәчмә белән тезмә аралашкан хикәятләргә нигезләнгән сабак һәм фикерләр гаять зур тәэсир көченә ияләр.

Гадәттә Сәйф Сараи, Сәгъди кебек үк, феодаль җәмгыять бозыклыкларын фаш итә, диләр. Мондый рух ике бөек шагыйрьнең дә әсәрләрен сугара, билгеле. Мәгәр әлеге бәя, алардагы уңай максатны истән чыгарганда, тулы була алмый. Ул максат исә җәмгыятьне социаль һәм әхлакый җәһәттән савыктырырга кайнар ашкынудан гыйбарәт. Чөнки бу шагыйрьләр үз чорының тискәре күренешләрен тасвирлап кына калмыйлар — аларның асыл максатлары да бу түгел — бәлки үз идеалларын гәүдәләндергән каһарманнар сурәтен дә алга бастыралар.

Сәйф Сараида кеше идеалын эзләү яңәшә куеп карау яки каршы кую аша башкарыла. Мондый контекстта уңай шәхеснең өстенлекләре күзгә бәрелеп торырлык һәм инандыргыч булып ачыла. Шагыйрьнең хикәятләрендә, баштарак ялгыш фикердә торып та, гыйбрәтле вакыйга һәм сабаклардан соң мәсьәләне

---

[1] Кара: Миңнегулов Х. Ю. Сәйф Сараи. Тормышы һәм иҗаты. Казан, 1976, 25—26 б.

элек урынсызга читкә тибәрелгән зат файдасына хәл кылуга өченче тараф та катнашучан. Мәсәлән, бер хикәяттә мәликнең үзенең өч улыннан зифа буйлы һәм чибәр ике улын гына яратуы, ә кыска буйлы өченчесенә кимсетеп каравы тасвир ителә. Читкә тибәрелгән соңгы улы үткен акыллы була. Әтисенә ул: «Озын буйлы ахмактан кыска буйлы гакыйл яхшырак»,— ди. Һәм озакламый аңа үзенең чын өстенлеген күрсәтү җае чыга. Илгә дошман явы бәреп керә. Патшаның кече улы батырларча сугыша, тик дошманнар күбрәк булганлыктан, мәликнең гаскәре качарга ниятли. Кече углан сугышчыларның горурлыгын кузгатырлык шигырь әйтә:

Углан әйтте: «И ирәннәр, йат чәригә[1] ут орың!
Йә барың, гъәурәт комашын[2] киеп әүдә утырың!

Гаскәргә бу нык тәэсир итә, һәм мәликнекеләр җиңә. Патша сөенеченнән кече улын кочаклап ала һәм күзләреннән үбә. Ә көнче агалары энеләрен агулап үтермәкче булалар, ләкин күзәтүчән сенелләре бәлане булдырмый кала. Мәлик өч улын төрле өлкәгә башлык итеп җибәрә. Шагыйрь бу хәлләрдән патшалар һәм гади кешеләр гамәлен каршы куюга корылган янә бер афористик гыйбрәт чыгара:

Сыйгар бер хөҗрәгә ун ике миһман,
Бер икълимә сыйгышмас ике солтан.

Моннан алдагы өзекнең рифмаларыннан күренгәнчә, автор сүз уйнатуда элгәреләреннән дә уздыра.

Сәйф Сараи нигездә үзеннән алдагылар куйган мәсьәлә һәм сорауларны ук куя, әмма аның идеал эзләве игелек һәм әхлак таләпләренең яңа яклары белән баетыла. «Төрки Гөлстан»дагы күп кенә хикәятләр шуны раслый ки, кешенең тышкы җитешсезлеге шәхес буларак төссезлеген чагылдырмый, ә, киресенчә, катлаулы очракларда аның ялт иткән дошманнарыннан әхлакый өстенлеге ачыла. Шигъри фикерләүнең шушындый оппозитивлыгы сораулар куелышының тапкыр үткенлеген һәм фикри сөземтәләренең инандыргыч җитдилеген тәэмин итә. Боларның җәмгысе бергә XIV йөз әдәби хәрәкәтендә шагыйрьнең аерылып торган үзенчәлеген хасил кыла.

Сәйф Сараидагы комизмга үтергеч көлү түгел, ә инсанчыньң (гуманистның) дустанә елмаюы хас. Аның бер хикәятендә карчыкның җитмешкә җиткәч чәчләрен буявы бәян ителә. Шагыйрь, әбине шелтәләп, ходай каршына бару өчен лаеклы рәвештә әзерләнергә куша. Карчык, гаепле елмаеп: «Нишлим соң, яшәүдән туймадым»,— дип җавап бирә. Автор бередә — кече күңелле. Әмма кешеләрнең үз-үзен тотышында кычкырып торган гайре табигыйлекне күрсә, аның сарказмы үтергеч була. Мәсәлән, бер хикәятендә ул җитмеш яшьлек байның яшь гүзәлгә өйләнеп, бөтен илгә хур булганын яза. Ул үзен дә хикәяттә катнашучы буларак тасвир кыла һәм картка болай ди:

Әйа ахмак кийәү, йитмеш йәшәр сән,
Әлең тетрәк, ничек энҗе тишәрсән?!

Күренеш һәм персонажларны үзара каршы куеп, Сараи нәрсәнең — нәрсә, кемнең кем булуы һәм игелек белән сафлыкның нәрсәдә чагылуы, чын кешенең кемлеге һәм җәмгыять, дәүләт, кешеләр язмышы өчен кемнәр һәм нәрсәнең кыйммәтлеге турындагы сорауларга җавап бирергә тырыша. Шагыйрь шул рәвешчә әхлакый-этик кодекс эшли. Ул кодексның күп кенә яклары урта гасыр өчен генә түгел, соңгырак чорлар, шул җөмләдән безнең чор өчен дә әһәмиятен җуймый. Әдип кеше гамәлендә бар нәрсәдән өстен итеп зирәклекне саный. Патшада булса, ул — гаделлек, гади кешедә — игелек. Сугышчы ир-егетнең яки хөкемдар якыннарының өстен сыйфаты рәвешендә кыюлык, батырлык, үткен акыл, читен хәлдән чыга белү тасвирлана.

Сараиның сәнгатьчә принципларындагы диалектик башлангыч күренешләрне бәяләүдәге нисбилектә (относительность) чагыла. Матурлык аныңча барлык кешеләр өчен абсолют төшенчә түгел, ә аның бәя үлчәме шулай ук нисбәтле.

Шагыйрьнең бер парчасында патшаның Ләйлә-Мәҗнүн хәлләре белән кызыксынуы хикәяләнә. Мәлик Мәҗнүннән кайнар гыйшкының сәбәбен сораша, ан-

[1] Чәригә — гаскәргә.
[2] Комаш — тукыма, кием.

нары Лəйлəнең үзен дə күрү телəген белдерə. Каршысына кызны китерəлəр, əмма, аны күргəч, патшаның гайрəте чигə. Мəҗнүн шунда: «Əй мəлик, Мəҗнүн күзенең дəрəҗəсеннəн Лəйли җəмаленə нəзар кыйлмак кирəксəн, хəтта мөшаһəдə сирри сəңа тəҗалли кыйлгай» (Əй мəлик, Лəйли матурлыгына Мəҗнүн күзенең тəрəзəсеннəн карарга кирəк, шунда гына сиңа күреп белүнең сере балкып ачылыр),— дип җавап бирə.

Соңрак матурлыкның шəхес кыйммəтенə бəйле нисбəтлеген даһиларча тирəн итеп Тукай ача:

> Бирмəде Лəйлə кеби мəхбубəгə дөнья бəһа,
> Ул болай бер кыз гына, каршында Мəҗнүн булмаса.

Сəйф Сараи афоризмнарындагы парадокслар шулай ук диалектик мəгънəгə ия. Ачы тəҗрибə аны хатын-кыз хөкемнəренең объективлыгына шиклəнеп карарга өйрəткəн. Хатын-кызның гүзəллеген, көчле холкын һəм нечкə акылын данлаган камил əсəрлəр белəн янəшə аның хикмəтлəре арасында шундыйларын да очратабыз:

«Хатунлар билə мишварəт кыйлмак мусибəт кəтүрүр, даги фасикъларга сахавəт кыйлмак мəгъсиəт булур.

> Тиши итти бүригə кем тəрəххум
> Кыйлур булса, итəр ул куйлара зулм».

(Хатыннар белəн киңəш итү бəла китерер, бозыкларга юмартлык кылсаң — гөнаһ булыр.

> Хатын-кыз бүрегə рəхимлек кылса,
> Куйларга золм итəр).

Мондый кискенлектə күбрəк шагыйрьнең фарсы элгəрелəренə хас традиция чагыла. Мəсəлəн, Котб хатын-кызның акылын, тугрылыгын, нык холкын ирлəрнекеннəн өстен куйган. Һəр хəлдə Сəйф Сараиның əлеге хикмəте — аның үз чоры чынбарлыгын төрле яклап иңлəгəндə дикъкать иткəн бер тарафы, дияргə кирəк.

Шагыйрьчə, чын кешелек хисе иҗтимагый-сословиечел хорафатларны белми, бəлки, киресенчə, аларны баштүбəн əйлəндереп салырга сəлəтле. Менə аның шушындый бер парадоксы:

> Чөнки сəүде хуҗа җаннан колны бик,
> Хуҗасы кол булды, колы булды бик.

Шагыйрь, үзенең элгəрелəре сыман ук, юмартлыкны бөеклек нигезе дип, сатылмас тугрылыкны — яхшылык нигезе дип саный.

> Бу дөнья тəркин[1] орган заһид[2] ирнен
> Катында булса алтын таг — бакмас.
> Җиһанга ихтиар орган кем ирсə
> Үзене алтын өчен утка йакмас.

Шагыйрь хөкемдарга иң югары талəпне куя. Аның үз-үзен тотышындагы үрнəк көчендə ул иҗтимагый əһəмияте ягыннан искиткеч зур нəтиҗəлəр мөмкинлеген күрə.

> Рəгыйəт[3] багының солтан алып йисə бер алмасын,
> Йөз армудын[4] йигəй бер кол, берене элмəйен тешкə.
> Бойырса биш йомыртканы алырга көч билə солтан,
> Нүкəрлəре[5] тотып санчар йикерми казны бер шешкə.

Сараи гади халыкны «гадел мəликнең куəтле гаскəре» дип атый һəм хөкемдарга табигатьнең, вакытның гадел һəм сүзеннəн кайтмас хөкеме ярдəмендə нəсихəтлəр бирə. Урта гасыр төрки шигъриятенең «хөкемдар илгə, халыкка

---

[1] Тəрк — баш тарту, ташлау, кую.
[2] Заһид — гыйбадəт белəн мəшгуль.
[3] Рəгыйəт — дəүлəттəге халык.
[4] Армуд — груша.
[5] Нүкəр — хезмəтче.

үз-үзен аямыйча хезмәт итәргә тиеш» дигән фикерен кыю һәм үтә җыйнак рәвештә тәкърарлый.

Бу рәгыйәткә мәлик чубан [1] ирер,
Ул ничә кем күп вилайәтни биләр.
Куй дәгел чубан өчен, и зөфөнүн [2],
Бәлки чубан куйлара хидмәт өчен...
Бер кеше бакса, ачып, гүр эченә,
Белмәгәй: йаткан — мәликме йә гида.

Шагыйрь үз чорының ерткыч хөкемдарларын, аларның барыннан элек гади хезмәт халкына газаплар һәм бөлгенлек алып килгән басып алу сугышларын кискен гаепли. Мәсәлән, «Сөһәйл белән Гөлдерсен» дастанында Аксак Тимер яуларын тасвирлаганда, игенчеләрнең өйләре януга, бодай басулары харап булуга, канның җир буйлап судай агуына аның җаны тетри.

Сараиның шигъри хәзинәсе гаять бай. Ул «Төрки Гөлстан»да табигать күренешләрен, бигрәк тә язны, аерылып торган ачык төсләр белән тасвир кыла.

Булып матриб [3] гөлистаннарда былбыл,
Кыйлыр мең төрле нәгъмә [4] берлә гол-гол [5].
Йәнә фирдәвес әгъла [6] тик булып баг,
Зөмәррәд [7] рәнген [8] алды тигмә бер таг.

Катлаулы, тыгыз, нәфис метафора — Сәйф Сараи шигъри тасвирында даими кулланылучан чаралардан.

Сәңа бу шивәләр [9] берлән күңел алмак кем үгрәтте?
Җәмалеңне күреп, заһид тотып гыйшкың йулын кәсте.
Мәнем кауме кабилемнең камусы галим ирделәр.
Сәнең бу гыйшкың устады мәңа шагыйрьлек үгрәтте.

Яки:

Гариф[10] иргә, бел, җәһәннәмнең газабы берлә тиң
Кермәке куңшы[11] айагы берлә җәннәт багына.

Сәйф Сараи, Котб сыман ук, үз әсәрләрендә Шәрекъtә ирешелгән гыйльми фикер казанышларын туплап биргән шагыйрьләрдән. Мәсәлән, «Сөһәйл белән Гөлдерсен» дастанында кызның егет тирәсендә мамыктай бөтерелеп очуын ул җирнең кояш тирәсендә әйләнүе белән чагыштыра. Галимнәр моның Коперник ачышларыннан күп элек язылуына игътибар итәләр.

«Ядкярнамә» җыентыгында, әле аталган поэмадан тыш, Сараиның талантлы замандашларыннан калган әсәрләр һәм аларга бөек шагыйрьнең иҗади җаваплары да урын алган. Ул шагыйрьләр белән ярышта «Төрки Гөлстан» авторы тиңдәшсез оста булып күз алдына баса. Мәсәлән, Әхмәд Хуҗа әс-Сараиның искиткеч музыкаль ритмлы, чагыштыру һәм метафоралар ягыннан үтә нәфис, рифма җәһәтеннән тапкыр касыйдәсенә язылган нәзыйрә цезураль сафлыгы, охшаш авазлар һәм эчке рифмалар белән тыгыз бизәлеше, һәр ритмик буынның шушы аһәңгә каймалануы, омонимик рифмаларда аваз уйналышы ягыннан әлеге өлгене күпкә уздыра. Сәйф Сараи шигыре, алмаз бөртекләре сибелгәндәй, җемелдәп тора. Анардагы сыман ритмик сафлыкны — Акмуллада, ә шигырьне эшкәртүнең камил шомалыгын Дәрдемәндтә күрәбез. Менә Сараиның гүзәл әсәреннән бер өзек:

---

1 Чубан — чабан, көтүче.
2 Зөфөнүн — фәннәр иясе.
3 Матриб — музыкант, җырчы.
4 Нәгъмә — моң, көй.
5 Гол-гол — фарсыда сандугач сайравын аңлаткан аваз ияртеме.
6 Фирдәвес әгъла — олуг оҗмах бакчасы.
7 Зөмәррәд — зөбәрҗәт, изумруд.
8 Рәнген — төсен.
9 Шивәләр — назлы кыланышлар.
10 Гариф — акыл иясе.
11 Куңшы — күрше.

Дилбәремнең зөлфе сөнбел, чәһрәсе[1] гөлзар ирер,
Буйина гашыйк сәнаубәр[2], йөзенә гөл зар ирер.
Агзы фәстук[3], күрке тансук, үзе мөшфикъ йар ирер,
Хөсненең жавы Хита вә Чин эчендә бар ирер.
Аслы алчын[4], сүзләре чын, күзләре татар ирер,
Мең йәшәр һәр кем дудагы[5] ширбәтен татар ирер.
Гыйшкының илчесенә күңлем мөнәккаш[6] дар ирер,
Зөлфенә төшкән күңелләрнең мәкаме дар ирер...

Бу мисалдан һәм башка үрнәкләрдән күренгәнчә, төрки поэзиянең тасвир чаралары өч шигъри мәдәниятнең (гарәп, фарсы һәм төрки) үзара бәйләнешы нигезендә байый. Әлеге процессның үзәгендә озакка сузылган әдәби тәҗрибә тарафыннан үстерелгән һәм камилләштерелгән төрки фольклор поэтикасы тора. Без үз вакытында Кол Галинең сәнгатьчә хәзинәсендәге төрки һәм фарси элементлар үрелешен ачыклаган идек, шулай ук Котб метафораларының да фарсы чыганагын күрәбез. Әлеге үрнәктә исә фарсыдан килгән башлангыч нәрсәдә чагыла соң? Чәчләрне — «сөмбел», йөзне яки яңакларны — «гөл», кызның бәләкәй авызын «фестә» рәвешендә сынландыруда. «Буена гашыйк сәнаубәр» (урта гасыр Шәрекъ шигъриятендә «сәнаубәр-нарат», «сәрви-кипарис» кебек үк, зифалык өлгесе санала) һәм «йөзенә гөл зар була» кебек метафорик гыйбарәләр өстенлекне чагылдыручы чагыштыру булып тора, һәм фарсы шигъриятенең мәгълүм калыбында эшләнгәннәр. «Аның гүзәллегенә кояш гашыйк», «Йөзенең аклыгына ай гашыйк», яки «Йөзеннән ай көнләшә» кебек гыйбарәләр — фарсытаҗик классик шигъриятенең иң таралган мисалларыннан. Омонимик сүз уйнатуда шагыйрь төрки һәм гарәп-фарсы лексикасына таяна. Мәсәлән, югарыда карап үткән өзектә «дар-дар» (өй һәм асу җайланмасы) омонимын гына искә төшерик.

Кыскасы, Сәйф Сараи иҗаты идея ягыннан да, сәнгатьчәлек җәһәтеннән дә XIV йөз Идел буе төрки шигъриятенең иң югары казанышы булып тора. Шагыйрь үз чорын гаделлек һәм әхлаклылыкның гали бәһа үлчәме белән коралландырган. Ул эшләгән критерийләр күп яклап әле дә әһәмиятен җуймаган. Тормышның олы зирәклеген үзенә туплап һәм шунда Сәгъдинең даһи мирасыннан көч алып, шагыйрь кеше гомеренең төрле яшенә яраклы акыллы гамәл һәм яшәү рәвешенең үзенә күрә бер кодексын эшләгән, дөньядагы төрле хәлләргә муафыйкъ чаралар формуласын булдырган.

Аның нәзыйрәләре ярдәмендә безгә Мәүлә Казый Мөхсин, Мәүла Исхак, Мәүла Гыймад, Габделмәҗид, Әхмәд Хуҗа әс-Сараи, Туглыхуҗа һәм Хәсән углы кебек үзенчәлекле шагыйрьләрнең берәр әсәре килеп җиткән. Алар XIV йөз төрки шигъриятенең фәлсәфи-сәнгати сурәтен тулырак күзалларга ярдәм итә. Ул үрнәкләр дә әле генә без күздән кичергән бөек шагыйрьләрдәге инсани эзләнүләр контекстына ипле ятыша. Котбның «Хөсрәү вә Ширин»ен Мисырда күчереп язганда, Бәркә-Фәкыйһ тарафыннан өстәлгән шигъри кисәкләр исә сәнгати иҗат белән мәшгуль зыялыларның феодаль кыпчак җәмгыятендәге җинел булмаган хәле турында хөкем йөртергә мөмкинлек бирә.

XIV йөз Идел буе төрки шигърияте үзенең сәнгатьчә үсешендә шундый зур биеклеккә күтәрелә ки, XIX һәм XX йөз башына чаклы бүтән ул дәрәҗәгә ирешә алмый. Бары шушы ике гасыр дәвамында иҗат иткән шагыйрьләр генә һәм хосусан Тукай казанышлары гына, күпгасырлык үсеш һәм чигенешләр юлын талантлы йомгаклап, принципиаль яңа, иҗтимагый актив һәм тормышны раслаучан шигъриятькә бөек сикереш ясыйлар. Моның өчен болгар-татар халкына феодаль таркаулыкның, урта гасыр йомыклыгының, Аксак Тимер афәтенең, XVI йөз уртасында дәүләтчелек югалтуның, дини һәм милли көчләүләрнең барлык авыр сынауларына бирешми узарга, башка халыклар белән бергә азатлык көрәше алып барырга, мәдәниятне аурупалаштырырга һәм әдәбиятта көнчыгыш-көнбатыш синтезын эшләргә кирәк булган. XIV йөз шагыйрьләренең инсани эзләнүләре, шигъри мотив һәм гыйбарәви традицияләре соңрак Акмулла, Дәрдемәнд һәм Тукай иҗатында мул очрый.

---

[1] Чәһрәсе — йөзе.
[2] Сәнаубәр — нарат.
[3] Фәстук — фестә (фисташка).
[4] Алчын — лачын.
[5] Дудагы — ирене.
[6] Мөнәккаш — бизәлгән.



# ТАТАРСТАННЫҢ БАШ МӨГАЛЛИМЕ

**Татарстан мәгариф министры, педагогика фәннәре докторы, профессор Васил Габдулла улы ГАЙФУЛЛИН белән журналыбызның редколлегия әгъзасы Салих МАННАПОВ әңгәмәсе**

*— Васил ага, бу сөйләшү Сезгә түм-түгәрәк 60 яшь тулар алдыннан бара, һәм ул өлешчә шул "олуг юбилей мөнәсәбәте белән" бәйле дә булса кирәк. Һәрхәлдә, журнал редакциясе миңа Сезне бераз "сөйләштерергә" һәм материалны нәкъ менә шушы санга өлгертергә кушты. Бу йомышны миңа йөкләгәндә, ихтимал, Сезнең белән хезмәт вазифасы буенча беркадәр бәйләнештә булуыбызны да истә тотканнардыр. Әмма сүзне эштәге хәлләр турында фикер алышып, "проблемалар эзләү"дән башлыйсы килми. Шул ук вакытта, очрашуыбыз алдыннан, яшермим, ни-нәрсәләр хакында гәп корырбыз икән дип, уйлап-икеләнеп тә калдым. Сезне галим, укытучы һәм хөкүмәт әгъзасы буларак гомумән белсәм дә, тормышыгыздан, шәхесегездән бөтенләй диярлек хәбәрсез икәнмен. Хәер, миңа гына түгел, журнал укучыларга да Татарстанның баш мөгаллиме белән якыннанрак танышу кызыклы булыр, бәлки? Булачак министрның мәктәпкә беренче тапкыр аяк басуыннан ук башлап китик әле...*

— Балачак сугыш вакытына туры килде инде безнең. Укырга керүем дә 44 нче елда; сугышның әле авыр вакыты иде. Мәктәпкә 7 яшь тулгач керү башланган гына чор, аңа кадәр 8 - 9 яшьтән кергәннәр бит. Әмма мине, 7 яше тулуга ук бирмәсәк тә ярый, әзрәк үссен, нығысын дигәннәрме, нигәдер сабыр итәргә уйлаганнар. Укытучы бервакыт урамда күреп: "Энем, син Гайфуллин Васил булырга тиеш, син бит безнең мәктәп исемлегендә бар, иртәгә укырга кил",— диде. Уку башланып атна-ун көн узган булгандыр инде... Ул вакытта балалар күп. Безнең башлангыч мәктәптә (Мөслим төбәге, Югары Табын авылы) 120 ләп бала — дүрт класска. Әлбәттә, укытучыларга хөрмәт бик зур иде ул вакытта. Укытучыны Аллаһы Тәгалә урынына күрә идек. Мин инде башлангычта укыганда ук үзебезнең укытучыга чын күңелдән гашыйк булган кеше.

Шунлыктан, ике төрле уйлау юк, укытучыга охшарга тырышу, укытучы булырга теләү бала чакта ук күңелгә керде дә утырды. Тагын бер сәбәбе бар. Минем апа Минзәлә педучилищесына укырга киткән иде. Аның юлыннан, аның янына мин дә бардым. Минзәләдә чын педагоглар укытты безне. Ул заман традицияләре әле хәзер дә дәвам итә. Педучилище чын мәгънәсендә тәрбияче әзерли адәм баласыннан. Педучилище бетермәгән кеше булса, институтта ул сыйфатларның яртысын да ала алмый дияр идем. Педучилищедан соң мин җидееллык мәктәптә эшләдем. Мөслим районының Ташлыяр дип аталган авылында. Башлангыч класста рус теле белән хезмәт укыттым. Мин чигү дә чигәргә өйрәтәм, рәсем ясарга да өйрәтәм. Физика белән биологияне һәм җыр дәресен дә укытам. Җәмәгать эшләренең дә күбесе миндә — пионер, комсомол эшенә җитәкчелек итәм, укучыларның үзеш-

чән сәнгатен оештыручы да, драмтүгәрәк житәкчесе дә үзем. Педучилищеда алынган чыныгу, тәрбия, күнекмәләр миңа эшләргә бик нык ярдәм итте. Мәктәп мәшәкатьләренә баш белән күмелеп, шул кадәрле яратып эшләдем. Шулай да укуны дәвам итәргә кирәк иде. Мәктәптән вакытлыча аерылып, Казанга — педагогия институтының физматына барып кердем. Педучилищены да, институтны да мин бик әйбәт билгеләр белән (с отличием) тәмамладым. Институтта калдырырга бик тырышсалар да, туган якта эшлисе килү теләге мине Мөслимгә алып кайтты. Физика укытучысы, завуч булдым, директор вазифасын башкардым. Аннан соң җиде елга якын мәгариф бүлеге мөдире булып эшләдем.

*— Бу кадәресе генә дә үзе бер кеше гомеренә җитәрлек ләбаса. Ә Сез бит әле җәмәгатьчелек күз алдында галим һәм югары мәктәп (вуз) мөгаллиме, ниһаять, министр булып танылган зат. Фән, институт мәшәкатьләре һәм хөкүмәт эше белән яшәү "кайсы гомерегездә" булды?*

— Мәгариф бүлегендә эшләгәндә, 34 яшьтән узып барганда (гаилә, ике бала), башка бер фикер килде. Мин бит кандидатлык минимумы имтиханнарын биргән идем, Мәскәү, Ленинград, Казан белән дә язышып торам. Һәрберсеннән аспирантурага кил дигән чакырулар бар иде. Ленинградка юри генә барып карыйм әле дип киттем. Аспирантурага 2 генә кеше алырга тиешләр икән. 18 кеше имтихан бирдек, нәтиҗәсен белмичә кайтып киттек. Күпмедер вакыттан соң җавап килде: "Укырга килегез",— дигәннәр. Ә мине эштән бушатмыйлар. Янәсе, рононы башка кешегә тапшырып булмый һ.б., һ.б. Обкомга кадәр җитеп юл ачарга туры килде. Аспирантураны бетергәндә үк кандидатлыкны яклап кайттым. Аннары 90 нчы елга кадәр пединститутта: ассистент, өлкән укытучы, доцент, декан урынбасары, декан һәм кафедра мөдире.

*— Җәмәгатегез Тихния апа да — мөгаллимә кеше, атказанган укытучы, татар теле дәреслеге авторы. Ул тәрбияләгән йөзләгән укучы бүген үзе татар телен укыта. Арада Зөлфәт, Асия Минһаҗева кебек шагыйрь шәкертләре дә бар дип беләм... Балаларыгыз да Тихния апа белән икегезнең юлдан китмәделәрме, Васил ага?*

— Балаларның юллары икенче төрлерәк булды. Кызыбыз медицина институтына керде. Улыбыз — университетның юридик факультетына. Балалар бик тәртипле, акыллы булдылар, икесе дә медаль, кызыл диплом белән укып чыктылар. Кызыбыз балалар врачы булып эшли. Улыбыз башта Әтнәдә, прокурор ярдәмчесе булып эшләде. Аннан Югары Советка өлкән референт итеп чакырдылар. Диссертация яклаганнан соң, финанс-экономика институтында хокук фәннәрен укыта.

*— Балалар үз юлын сайлаган. Ә шәкертләрегез? Хөкүмәт эше Сезне остазлыктан, укытудан аермадымы?*

— Минем шәкертләрдән физика, математика укытучысы булып киткән кешеләр шактый күптер дип уйлыйм. Чөнки, инде 61 нче елдан укыта башлаган килеш, хәзер дә туктаганым юк. Хәзер дә аспирантларым, диплом яклаучыларым бар. Физматта махсус курс алып барам. Укыту эшеннән бөтенләй аерылу, хуҗалык һәм житәкчелек эшләренә генә күчеп бетү — үзеңне, тормышыңны фәкыйрьләтү булыр иде. Лекцияләр уку, мәкаләләр һәм дәреслекләр язу — ул инде канга сеңгән. Хөкүмәт эшеннән бик арып кайтканнан соң бераз ял итеп, иҗат дулкынына күчү өчен, икенче шөгыль табып торасың: музыка тыңлап, йә телевизордан берәр җиңел әйбер карап, яки килгән газеталарны актарып маташасың да, язасы әйбергә утырырга тырышасың.

*— Фән белән шөгыльләнү, шагыйрь әйтмешли, "төп эштән соң башкарылган төп эш" булып чыга инде. Ә ял сәгатьләрендә...*

— Ял сәгатьләрендә мин әдәби китап укырга яратам. Элегрәк спорт дигән әйбергә кызыксыну зур иде. Заманында әзрәк көрәшеп тә йөрдем, гимнастика белән дә шөгыльләнеп карадым. Чаңгыда йөрим, волейбол, шахмат уйнарга яратам. Шахматны шактый мавыгып, йокламыйча уйнаган чаклар бар иде.

*— Васил ага, Сезне, бигрәк тә яшь чакта, җырларга яраткансыз, дип ишеткәнем бар. Имештер, хәтта радио фондында күптәнге язмаларыгыз саклана икән...*

— Педучилищеда безгә музыка дәресләре керде. Шунда мин мандолинада, пианинода, скрипкада уйнарга өйрәндем. Минзәләдән соң авылга кайтып эшләгәндә һәр атна саен бер концерт, йә бер спектакль куярга туры килә иде безгә. Аннан мин тальян гармун, хромка, баян алдым, шуларны уйныйм. Үзем кешеләрне җырлатам, үзем кушылып җырлыйм. Институтта укыганда сәнгать түгәрәкләренә йөри башладым. Укытучылар йортында үзешчән сәнгать буенча бик яхшы коллективлар бар иде. Ул заманда Хәбиб абыйның эстрада группасы бар, драма, бию түгәрәкләре эшли. Бер кышны вокал түгәрәгенә дә йөрдем. Горький исемендәге клубта Сара апа Садыйкованың хоры барлыгын ишетеп, анда йөри башладым. Шул елларда Казанда беренче тапкыр халык театры оешты. Театрга һәвәскәрләр туплаганда Мехкомбинат клубында 500 ләп кешене төрле яктан: тавышын да, сәхнә сәләтен дә, сөйләү куәсен дә, музыкага һәвәслеген дә тикшерделәр. Шул конкурстан үтеп, мин сезон ярым халык театрына йөрдем. Җәләл ага Садриҗиһанов музыка җитәкчесе иде, Разия апа Яруллина — хор җитәкчесе, Али Гыйззәтуллин — балет, биюләр буенча җитәкче иде. Ә төп оештыручы, режиссер — Хәким ага Сәлимҗанов. "Кандыр буе" спектаклен әзерләп, бик күп урыннарда куеп йөрдек. Ә бервакыт опера театрында хор группасын киңәйтергә уйладылар. Конкурс булды. Мин дә кереп карадым. Алдылар. Анда бик катлаулы, җидешәр тавышлы партияләрдә җырлау — бу инде зур мәктәп иде.

Студент өчен үзешчән сәнгатьтә йөрүнең "табышлы" ягы да бар. Опера театры хорында катнашучыларга 20 сум булса да акча түлиләр. Хәбиб абый безне атна саен бербер авылга алып китә, ипи-чәйлек эшләп кайтабыз. Өйдән ярдәм юк бит инде — колхозда "таяк"ка эшлиләр,— ашау-эчү генә түгел, киемгә дә акчаны үзең табасы. Әле өйгә дә ярдәм итәбез. Әлбәттә, тамак кайгысыннан бигрәк, рухи ихтыяҗ зур иде. Мөслимдә эшләгәндә дә үзешчән сәнгатьтә бик күп катнашылды. Безнең мәктәп ул яктан бик көчле иде. Район күләмендә дә урып-җыю чорында агитбригадалар оештыралар. Билгеле, райком мине алырга тырыша инде, чөнки анда кеше күп кирәк түгел, күпкырлылык кирәк. Анда бер пәрдәлек пьесада уйнау да кирәк, сөйләү дә, җыр-музыкада да катнашу...

*— Бер үзегез бөтен бер "оркестр" булгансыз икән! Ә шулай да радиодагы язмалар — алар кайсы заманга карый?*

— Алар — төрле вакытта язылган. Беренче тапкыр язылу 60 нчы еллардан башлангандыр. Горький исемендәге клубта баянчыбыз Кәрим Сафин белән әле беркайда да яңгырамаган бер-ике җыр өйрәнәбез дә, радиога барып яздырабыз. Тагын яңаларын өйрәнәбез. Шулай итеп, минем 20 дән артык язма барлыкка килде радиода. Фондта сакланганнар күп түгел, минем белүемчә, 6 - 7 язма бар анда.

*— Студентлык, яшьлек хатирәләрегез арасында берзаман Президент булыр бу дип уйламастан танышкан бер шәхес тә бар... Ул — Минтимер Шәрип улы Шәймиев. Хәзер дә Сезне "Шәймиев кешесе" диләр. Бу сүзгә нинди мәгънәләр салынган?*

— Мин аны (Шәймиевне) беренче мәртәбә 58 нче елда күрдем. 58 дә чирәм җирләрдән кайттык без икебез дә. Ул чорда "целинага" йөрү бар иде бит. Мин үзем студент отрядлары белән ике ел бардым... Без июль башында ук китә идек тә, җәй буе шунда эшләп, октябрь ае кергәч кенә кайта идек. Ул вакытта чирәм җирләрдә икмәк бик шәп уңа, эш күп иде. Без, авыл малайлары, бигрәк тә тырышып эшли идек. (Мин әле хәтерлим: физматтан Илгиз Мөдәррисов, Мансур Хөснетдинов — без ел саен 400 - 450 шәр хезмәт көне эшли идек. Чөнки безгә көн дә юк, төн дә юк. Машина килде икән, йокыдан торып та чыгып чаба идек өчәү...). Менә шулай, "целинадан" кайтып киләбез. Сарапулга җиттек. Сарапулдан мин Чаллыга төшәм, Чаллыдан Мөслимгә кайтам. Ә Минтимер Шәймиев Чаллыдан Актаныш — Пучы юнәлешендә кайткан булса кирәк. Мин менә шундагы беренче очрашуны хәтерлим.

Аннан, укуны тәмамлап, 61 дә мин эшкә кайтканда, ул инде инженер булып Мөслим РТСында эшли иде. Кичләрен бергә чыгабыз, бергә туган көннәр уздырабыз. Менә шулай аралашып яши торган бик матур коллектив бар иде безнең.

Минтимер Шәрипович яшьтән үк хезмәте белән, тырышлыгы белән күтәрелде. Тормыш баскычларының барысын да үтеп, бик лаеклы рәвештә Президент булды. Минем элеккеге танышлыкны берничек тә файдаланганым булмады. Эшем буенча аңа бернинди дә кыенлык китерәсем килми. Безнең бергә үскән егетләр булдыра алмаган дип ишетелмәсен өчен, үземнең тарафтан бернинди дә кимчелек булмаслык итеп эшләргә тырышам.

*— Сүз сөрешебез шул якка тарта: хәзерге эшегез турында да сөйләшми булмас ахрысы, Васил Габдуллович... Министрлыкка килгәндәге хыял һәм ниятләрегезне тормышка ашыра алдыгызмы? Әллә заманалар үзгәреп китү комачау иттеме?*

— Юк. Заманның үзгәрүе бер яктан хәлләрне читенләштерсә, икенче яктан файдалы да булды. Элек Мәскәү белән киңәшмичә, Мәскәү белән хәбәрләшмичә бер адым да ясау мөмкин түгел иде. Министрлык үткәрә торган һәр чара Мәскәү белән килешеп кенә башкарылган. Мин исә үземчә эшләп, һәр мәсьәләне мөстәкыйль хәл итәргә омтыла торган кеше. Хәзер нәкъ менә шундый мөстәкыйльлеккә мөмкинлек бар. Милли мәгариф, милли кадрлар әзерләү юлындагы кыенлыклар — безнең йөрәктә әллә кайчан ачынып йөргән уй иде. Шул кыенлыкларны җиңеп, кулдан килгәнне эшләү бу елларда иң төп максатларымның берсе булды. Район хакимияте башлыклары белән көрешеп сөйләшәмме, сессия, семинар кебек зур чараларда катнашаммы, — һәрберсендә мин шул юнәлешкә нык басым ясыйм. Әйтик, районда милли состав ничек сезнең, дип сорыйм. Бик гади генә сорау. Ә милли состав — татар мәктәпләренең саны, балаларның ана телендә уку проценты ничек дигән сүз. Башлыклар: теләк бар инде, менә шулар эшләнергә тора, дигән сүзләрне әйтәләр. Ләкин кайберләренең күңелендә моны эшләми калсаң да ярар иде дигән уй-ният сизелгәне бар. Үзегез беләсез, район хакимнәренә, бүген менә шушыны эшлә, дип әмер бирү бигүк мөмкин дә түгел.

Мин аларга,(мисал өчен, Казанның Киров районында) милли мәгарифнең үсеш программасын төзеп кабул итегез, дим. Алар кабул итә. План-программада гимназия, татар мәктәбе, татар классы ачу һ. б. каралган. Инде, тиешле вакыт үткәч, теге сессия карарының ничек үтәлгәнен тикшереп тә, эшләтеп тә була. Әле кайчан гына Казанның Мәскәү районында, Түбән Камада, Чаллыда, Чистайда милли мәгариф эшләре бик авыр бара иде. Бүген күрәбез: эшләгән эшнең нәтиҗәсе бар, иншалла, алга таба барабыз.

*— Милли мәгариф өлкәсендәге казанышлар турында саннар һәм мисаллар китереп Сез дә, урынбасарларыгыз да чыгыш ясый тора. Шул ук вакытта үзегезнең бер чыгыштан ук "тискәре" сан: республикада 33 мең татар баласы мәктәптә үз туган телен өйрәнә алмый... Менә шуларга таянып, милли хәрәкәт вәкилләренең кайберләре: безгә милли мәгариф министрлыгы кирәк, дип, азмы-күпме башкарылган эшләрне дә инкяр итәләр кебек. Хакыйкать, күрәсең, һәрвакыттагыча уртада ятадыр...*

— Күрергә теләмәүче, тәнкыйтьләргә генә йөргән кешеләр дә бар, билгеле. Ләкин алар үзләре эшләп карамаган, тыштан гына милли булып йөрүчеләр. Күңел күзе сукыр булмаганнар аңларга тиеш: ничек иде — ничек үзгәрә. Бүген татар балаларының 45 проценты үз ана телендә белем ала (бу сан ел саен үсә бара). Барлык укучыларның 90 процентган артыгы татар телен фән буларак атнага 3-5 сәгать өйрәнә. Әлбәттә, кыенлыклар бар. Бигрәк тә руслар күпчелекне тәшкил иткән район үзәкләрендә. Мәсәлән, Октябрь Норлатында әлегә татар мәктәбе юк. Бөгелмә, Зеленодольск, Чистай, Кама Тамагы, Югары Осланда, Биектауда, Алексеевскида рус класслары күбрәк, татар класслары азрак. Хәзер Казанда 30 % ка якын бала татарча белем ала. Кемгәдер бу да аз тоеладыр, әмма мин моны уңыш дип саныйм. 1990 елда Казанда бер генә татар мәктәбе бар иде. Ул да булса — районнардан китереп укытылган 10 нчы интернат. Яңа Бистәдәге 35 нче мәктәп — белем бирү рус телендә алып барыла торган татар мәктәбе иде. Бүгенге көндә Казанда 24 мөстәкыйль татар мәктәбе яки гимназия бар. 117 мәктәптә татар класслары эшли. Бу бит бик зур сан. Аларның бит һәрберсе зур тырышлык белән яуланган. Татар мәктәбе ачарга тотынсаң, иске, мескен биналар бирелә иде. Хәзер бит яңа, шәп биналар сала башладык. Карагыз сез, Түбән Камада, Чаллыда, Әлмәттә, Чистайда, Бөгелмәдә, Зеленодольскида яңа биналар өлгерде. Казанның үзендә ничә яңа бинага күчте инде татар гимназияләре. Быел махсус проект белән эшләнгән бина өлгерергә тора.

*— Биналы, түбәле булу — ифрат хаҗәт нәрсәләрнең берсе. Тикмәгәме:"Урыс баеса — сала чиркәү, вәләкин әүвәле — мәктәп",— дигән классигыбыз... Татарның да, ниһаять, мәктәп салырга керешүе — рухи фәкыйрьлектән чыгу юлын табуыдыр, бәлки. Әмма милли мәгариф системасы дигән бинабызның төзелеше ни хәлдә? Аның "түбәсе" ябылганмы?*

— Зур халыклар үз балаларын өендә дә, балалар бакчасында да, мәктәптә дә,

вузда да үз телендә тәрбияли. Әлбәттә, югары белемне чит телдә алырга теләгән кешеләр булырга мөмкин. Әмма ул бит төрле сәбәпләр, максатлар аркасында, гомуми кагыйдәдән читкә чыгу.

Татар баласының югары белемне үз телендә алырга хакы булуын әйтеп тору да артык сыман. Элек шулай иде бит ул. Татар группалары бар иде бик күп уку йортларында. Мәсәлән, 1988 елда пединститутның физматында декан чагымда, татар группаларында укуны үзем керттем. 2 группа математиклар һәм 1 группа физикларны бөтен фәннәрдән дә татарча укыта башладык. Иң читен, иң сәер ягы шунда булды: Балтач балаларының да, Актаныш балаларының да рус группасында укыйсы килә. Татар төркемнәренә мәҗбүри җыя-җыя укыттык. Хәзер ел саен шул факультетта 50 математик, 25 физик татар телендә укып чыга. Алабугада да, Чаллыда да шундый группалар бар. Димәк, тырышканда була. Икенче уңай күренеш бар: Татарстанның бөтен вузлары да кабул итү имтиханын баланың туган телендә ала. Рус телен белмәү аркасында гына укырга керә алмау дигән сәбәп юк. Әлбәттә, имтихан биреп керү генә түгел, татар телендә югары белем алып чыгу өчен дә шартлар булырга тиеш. Татар авиация институты, рус авиация институты дип бүлү, бәлки, уңайлы түгелдер. Ләкин шул ук авиация институтында татар төркеме дә, рус группасы да булу мәҗбүридер дип саныйм. Кайбер институтларда бу эш акрынлап юл алып бара да инде.

Мәктәптә рус телле балаларны татар теленә өйрәтү дә тамыр җәеп килә. Инде бишенче класска кадәр җиттек. Тагын биш елдан урта мәктәптә татар телен фән буларак барлык балалар да укып бетерәчәк. Әле без аның имтиханын да кертәчәкбез. Алга таба, татар теленә өйрәнүне вузда да дәвам итү кирәк дип саныйм мин. Аңлашылмаучылык тел белмәүдән, белергә дә теләмәүдән башлана ич. Үзебезнең Мөслим төбәген мисалга китерәсем килә. Бездә 3 - 4 рус авылы, район үзәгендә аз гына санда руслар бар. Алар барысы да рәхәтләнеп татарча бии, җырлый, сөйләшә беләләр. Шундый руска карата бер генә татарның да начар карашы булырга мөмкин түгел. Аларга хөрмәт күбрәк тә әле. Менә шулай телеңне дә белсә, гореф-гадәтеңне дә хөрмәт итсә генә инде ул якын, тигез дус була ала.

Безнең республикада удмурт, мари, чувашларга карата да шундый мөнәсәбәт булырга тиеш. Без үзебезнең республикада һәр милләт баласын үзе теләгән телдә укыту өчен шартлар булдырырга дигән принципны куйдык. Шушы принцип буенча эшлибез. Әйтик, соңгы алты-жиде ел эчендә безнең республикада чуваш мәктәпләре ике тапкыр диярлек артты. Хәзер 20 район һәм шәһәрдә 142 чуваш мәктәбе бар. Тагын ачабыз диләр икән, без аңа шартлар тудырабыз. Укытучы җитми икән, чуваш министрлыгына, чуваш пединститутына чыгабыз, үзебездән чуваш балаларын җибәрәбез, аларны алуга булышлык күрсәтәбез. Мари белән, удмурт белән дә шулай. Мари балаларының 42 проценты, ә удмуртның 62 проценты үз телендә белем ала. Ләкин аларның 9 класстан соң дәреслекләре юк, әле 9 нчыга кадәр дә күп фәннәрне русча дәреслектән укыйлар алар. Шуңа күрә укыту русча-чувашча, русча-удмуртчарак бара. Ә ун ел буе чуваш, мари, удмуртка үз телен өйрәнү мөмкинлеге бездә генә, аларның үзләрендә дә юк. Моннан ике-өч ел элек удмуртлар килеп, Кукмара районындагы бер мәктәптә "Удмурт мәктәбе һәм аның киләчәге" дигән темага семинар уздырыйк әле, үзебездә уздырырлык урын юк дигәч, без әлеге семинарны әзерләп биреп, уздырып күрсәттек. Болай да мөмкин икән, дип, аларның һушлары китте.

*— Тел белү дигәннән, Васил Габдуллович, Сезгә бик мәгълүм хәл: татар мәктәбендә ничә буын чит тел "укып" чиләнсә дә, чит телдә ике авыз сүз өйрәнә алмый чыкты. Һәм бүген дә күпчелек авылларда алга китеш юк бугай. Физкультура, география укытучыларының эш сәгате тулмаган өчен генә "гутен таг" өйрәтүләре бер бәла булса, иң төп сәбәпче — чит телне икенче бер тел (рус теле) аша укытып азаплау түгел микән...*

— Безнең халык чит телне белергә тиеш. Татарга тылмач (тел ачучы) кирәкми, дигән әйтем бик белеп әйтелгән, һәм ул, чыннан да, татарның телләр өйрәнүгә һәвәслеген танудан килеп чыккандыр.

Мәктәпләрдә чит тел өйрәнү бар шикелле ул. Ләкин аның методикасы чит телне үзләштермәслек итеп, махсус эшләнгәндер кебек. Менә безгә чит телне ничек өйрәтергә икәнлеген төрекләр аңлаттылар. Төрек-татар лицейларында алар беренче елны төрек һәм инглиз теленә өйрәтәләр. 9 айда икесенә дә менә дигән итеп өйрәтеп өлгерәләр. Шуннан соң балалар төрек телендә — 3, инглиз телендә 4 фән укый, рус

телендә — 2 фән, калганнарын татар телендә өйрәнәләр. Менә бу бик гыйбрәтле мисал. Димәк, чит тел буенча аралашу, сөйләшү юлы белән яхшы итеп һәм тиз өйрәтә торган методика булырга тиеш.

Соңгы елларда кадрлар әзерләүдә дә шактый проблемалар чишелде. Пединститутлар белән сөйләшеп чит тел белмәгәнен дә чит телләр факультетына укырга алу практикасын керттек бит без. Яңа гына тагын бер педагогик уку йорты ачтык. Колледж дип башлаган идек, ул да хәзер институт бит инде. 4 педучилищеда шундый чит телләр укытучылары хәзерләү группалары ачтык. Җыйсаң, шушы юнәлештә эшләүче сигез уку йортыбыз бар дигән сүз. Өстәвенә быел Казан дәүләт университетында да чит телләр факультеты эшли башлады.

*— Республикада әле дә булса чит ил теленнән 600 ләп укытучы җитешми, имеш. Югыйсә, педагогия институтында "инфак" (чит телләр факультеты) күптәннән эшләп килә бит инде. Бик зур әзерлек белән генә керәләр бугай анда, — мәртәбәле-престижлы факультет. Шунда ел саен диплом алган белгечләр — яшь укытучылар комга сеңгәндәй юкка чыга баралармы соң...*

— Институтның чит тел факультетына ашкынучыларның күпчелеге бик уңайлы гына чит илдә эшләп булмасмы, бездәге чит ил фирмаларына ялланып яки чит илдән килгән делегацияләрне озатып-каршылап йөрүчеләр булып булмасмы дип керәләр алар. Шуңа күрә мәктәпкә укытырга баручылары бик аз. Димәк, әлеге факультетка керү тәртибен шактый үзгәртәсе бар. Ул бит педагогия кадрлары әзерләүче уку йорты, аны тәмамлаганнан соң мәктәпкә һәм беренче чиратта авыл мәктәбенә барырга тиеш бит яшь белгеч. Аны укытуга шул кадәрле күп көч куела һәм акча түгелә. Шул ук вакытта ничә еллар буе 540 урта мәктәбебездә чит телне теләсә кем укыта, яки гел укытылмый. Әйткәнемчә, мәсьәләне хәл итүдә педагогик колледжларга зур өмет баглыйбыз. Без аларны контрольдә тотабыз. Укып чыккан һәр яшь белгеч үз районына, үз авылына кайтырга тиеш. Шулай итеп, күп дигәндә ун ел эчендә беренче мәртәбә мәктәпләрдә чынлап торып чит тел укытуны тәэмин итәрбез. Вакыт кирәк, чөнки без әлегә бөтенләй бушлыкны тутырырга тиеш булабыз.

***— Васил ага, Сез мәгариф системасының һәммә баскычларын диярлек тәпи-тәпи атлап үткәнсез: башлангыч класс укытучысыннан алып министрга кадәр. Мәгариф өлкәсендә эшләү Сезнең өчен һөнәр, кәсеп дәрәҗәсеннән узып, яшәвегезнең мәгънәсен тәшкил итәдер дип уйлыйм. Бүгенге укытучы, мәктәп җитәкчесе хакында фикерегез ничек, аларга нинди теләкләрегез бар?***

— Мәгариф системасы миңа бик якын һәм яхшы таныш, әлбәттә.

Пединститутта мин бит мәктәп җитәкчеләренең белемен күтәрү факультеты деканы булып та җиде елга якын эшләдем. Анда без роно мөдирләре, мәктәп директорлары белән бик күп аралаша идек. Аларныниләр борчыганы, нәрсә белән кызыксынулары — шул чакта ук мәгълүм иде. Шуңа күрә, инде Мәгариф министрлыгында эшләгәндә әлеге мәктәпне узган булу миңа нык ярдәм итте. Шул уңайдан күңелдә борчулы уйлар да туа. Иң элек милләтнең тату булмавы күңелне әрнетә. И күп килә инде татар мәктәпләреннән шикаять-хатлар: директор өстеннән язалар, укытучы өстеннән, әллә кемнәр өстеннән язалар. Шулкадәр ваклык, көнчелек, бер-береңнән шикләнү, тар күңеллелек белән тулы ул хатлар. Нигездә, гаепне башкаларга аударырга маташу, тырнак астыннан кер эзләү, эшкә бернинди дә файда бирми торган гамәл бу. Сабыррак һәм түземлерәк булырга өндәр идем мин милләттәшләрне. Кешенең кайбер кимчелекләрен кичерә белергә дә кирәк бит.

Мине борчыган тагын бер мәсьәлә бар. Шул ук тарлык-татарлык, бер-береңә юл куймау аркасындамы, үз кабыгыңа бикләнү, үсәргә тырышмау нәтиҗәседерме,— безнең югары әзерлекле оештыручы-җитәкчеләребез азаеп киткән. Соңгы елларда яңа татар мәктәпләре, гимназияләр, лицейларны күпләп ачабыз. Директор, завуч эзли башлыйбыз. Юк, табуы җиңел түгел. Башка милләттән кирәк булса, хәзер әллә ничәү табыла. Кичекмәстән укытучылар белемен күтәрү институтында мәктәп җитәкчеләренә резерв әзерләүче курслар оештырырга кирәк. Аларны мәктәп-мәгариф белән идарә итү хикмәтләренә өйрәтергә кирәк. Эзлекле, максатчан эш алып барсак, бәлки, якын елларда бу хәлне дә төзәтеп булыр. Иң мөһиме — җәмгыятьтә укытучының лаеклы ролен билгеләргә, укытучы шәхесенә һәм хезмәтенә хөрмәтне тиешле дәрәҗәгә күтәрергә кирәк.

*— Кадрлар, төзелеш һәм ремонт кебек мөһим мәсьәләләр хакында сөйләшкәндә, игътибар итәсез микән, дәреслек мәсьәләсе гел онытылып кала... Кемгә ничектер, миңа, мәсәлән, чыгышларыгызда да Сез милли дәреслек, аны язу һәм бастыру хәлләренә "канат очы" белән генә кагылып үтәсез кебек тоела. Югыйсә, Сез бит әле соңгы елларда "коеп куйган" министр гына түгел, мәктәп өчен тулы бер цикл дәреслекләр язган автор буларак та танылдыгыз. Бу хезмәтегезне "күреп", аның министр вазифасын башкарырга вакыты кала микән соң, диючеләр булды.*

— Вакыт, чыннан да, бик аз. Әлбәттә, дөньяның кайбер рәхәтлекләреннән баш тартырга туры килә, моның өчен сабырлык һәм ихтыяр көче дә, тәүлегенә 12 — 13 сәгать эшләрлек сәламәтлек тә булуы кирәк. Һәр елны ялга киткәндә мин зур бер төргәк эш алам һәм шул эшне башкарып кайтам. Мин үземә максат куйдым: атнага 20 сәгать буш вакытымны фәнгә, мәкаләләр һәм дәреслекләр язуга бирәм.

Мәгариф эшенең эчтәлеген дәреслекләр һәм программалар, аларның ни дәрәҗәдә сыйфатлы булуы билгели бит. 1964 елга кадәр без 30 нчы елларда ук язылып, камилләшә-шомара барган дәреслекләр белән эшләгән идек. 1964 елдан соң яңа дәреслекләр мәйданга килде. Әмма яңалык алып килү белән бергә, аларның "төерләре" дә байтак булып, шул уңышсыз яклары эчне пошыра иде. Инде милли мәгариф стандартлары мәсьәләсе дә көн тәртибенә баскач, үзебезгә диган дәреслекләрне үзебез язарга тиешбез дигән бурыч туды. Бу очракта без берничә максатны күздә тотабыз: 1) эчтәлектәге хаталарны төзәтәбез; 2) иң уңышлы методиканы сайлап алабыз; 3) җирле материалларга таянабыз. Әйтик, физика законнарын Татарстан хуҗалыгының төрле тармакларында кулланугa бәйләп күрсәтү, һичшиксез, бу фәнне өйрәнүгә омтылыш һәм ихтыяҗны арттыра.

Гомумән, дәреслекләрне Мәскәүдән алып, тәрҗемә аша укыту заманы узып бара. Төрле типтагы мәктәпләребез бар икән, аларда укытуны милли мәгариф үзенчәлекләрен искә алып, заманча нигезгә куярга уйлыйбыз икән, дәреслекләрнең дә яңача эчтәлекле, иҗади яктан төрле формада һәм сан ягыннан җитәрлек булуы таләп ителә. Татарстан китап нәшриятында эшләп килгән бер редакция алдына бу кадәр зур бурычны кую да, аны үтәү дә мөмкин түгел иде. Без мөстәкыйль, махсус нәшрият кирәклегенә ышандык һәм бөтен кыенлыкларны җиңеп, ул нәшриятны булдырырга ирештек. Бергәләшеп, килешеп эшләгәндә, заманча милли дәреслекләр мәсьәләсен уңышлы хәл итеп чыгачакбыз. "Мәгариф" нәшриятының эшчәнлегеннән без бик канәгать. Ләкин бер мәсьәлә бар: финанслаудагы кыенлыклар дәреслек бастыруны тиешле дәрәҗәдә һәм күләмдә башкарып чыгарга комачаулый.

*— Мондый гәпләшүләр вакытында кайбер газит-журналлар хөрмәтле кунактан үзләрен мактатып кала башладылар. Алар үрнәгенә ияреп, Сезнең авызга теге яки бу фикерне салырга җыенмыйм, әмма форсаттан файдаланып, үз гөманымны әйтәм: безнең бу әңгәмәне укытучыларның күпчелеге күрми-укымый калачак. Чөнки алар арасында "Казан утлары"н алдыручылар бик азайды булса кирәк. Үпкәләштән булмасын, мәгәр, минем фикеремчә, "Казан утлары"на күз салып яшәмәгән укытучы — физикмы ул, яисә физкультура укытамы — үзен мөкәммәл шәхес, тәрбияче-остаз дип саный алмый.*

*Аннары, язучылар журналында Сезне сөйләштереп тә, мәктәп китапханәләрендәге татар китабына кытлык хакында дәшми калсак, дөрес аңламаслар. Язучы халкында балалар әдәбиятына министрлык шактый битараф, хәтта салкын карый дигән фикер дә бөреләнеп килә... Чыннан да, балалар китабына дәүләт исеменнән кем заказ бирергә тиеш? Дәрестән тыш уку өчен дигән әсәрләр, китаплар исемлеге генә дә әллә ничә биткә сузыла бит. Ул китаплар мәктәптә, кулда булмагач, коры исемлек, эш белән ныгытылмаган теләк-таләп кенә килеп чыга,— димәк, татар баласына рухи тәрбия бирүдә "ак таплар", күңелләрдә бушлык хасил була?*

— Мәктәп китапханәсе бик бай булырга тиеш. Китапханә өчен дип, балалар санына карап, мәктәп бюджетында махсус акча карала. Ләкин соңгы өч елда, мәгълүм кыенлыклар аркасында, әлеге статья үтәлми. Мәктәпкә бит спорт җиһазлары да, ремонты да кирәк. Акча җитми, әмма аңа карап тормыш туктап калырга тиеш түгел. Класстан тыш уку өчен программа буенча бик күп әсәрләр карала. Димәк, ул китапларны бала мәктәп китапханәсеннән алырга, әлеге китаплар һәр балага җитешле санда булырга тиеш. Соравыгыз урынлы. Мин моны игътибардан, кулдан

ычкынганрак өлкә дип саныйм. Әлбәттә, без районнар, мәктәпләрне тикшергәндә бу мәсьәләләргә кагылабыз. Әдәбият укытуның дәрәҗәсен билгеләгәндә класстан тыш әдәбиятның китапханәдә булу-булмавы, балаларның китапханәдә шөгыльләнүе карточкалар буенча тикшерелә. Ләкин нинди китапларга ихтыяҗ бар, алар күпме санда кирәк, — бу эш белән шөгыльләнү, чыннан да, җитми. Класстан тыш әдәбият белән тәэмин ителешне министрлыкның эш планнарына кертергә, махсус, көн саен кайгыртырга тиешбез.

"Казан утлары" хакындагы фикерегез белән дә килешәм. Ул фикер тулаем көндәлек матбугатка кагыла. Һәр заманда да укытучының абруе ни дәрәҗәдә культуралы, мәгълүматлы икәнлегенә бәйле булды. Бигрәк тә авыл җирендә укытучыны "аяклы энциклопедия"— дөнья һәм әдәбият хәлләреннән хәбәрдар кеше булганы өчен ныграк хөрмәт итәләр, аңа киңәш сорап киләләр. "Казан утлары" журналын без 1951 елдан башлап алдырабыз, төпләнмәләрен саклыйбыз. Укырга яңа кызыклы китап табылмаганда, шул төпләнмәләрне кабат актарган чаклар да була.

*— Васил ага, инде сүзне түгәрәкләргә вакыт... ихтимал, кайсыбер агай-эне, артык "акыллы" сораулар биреп, Сездән "миллирәк" булып күренергә теләмәгәнем өчен, мине тәнкыйть тә итәр. Чөнки алар бүген гомумән андый максатның куелмавын һәм шуның өстенә Сезне "стенага тери" торган сорауның табигатьтә дә юклыгын белмиләр... Безнең сөйләшү, алда әйтелгәнчә,— юбилей мөнәсәбәте белән. Без бүген просто хәтерне бераз яңарттык һәм күптән борчыган мәсьәләләрнең дә кайберләренә кагылып-кагылып кына үттек. Инде Сезне "сөйләштерү" дән туктыйм, әмма үзем өчен ясаган ачыш — Сезнең "кеше-оркестр" булуыгызны белүдән туган тәэсир әле дә суынмый бугай... Тупланган белем-тәҗрибә яисә холык-фигыль нықлыгы гына түгел, адәм баласының күкрәгендә типкән моң чишмәсе — нәкъ менә ул! — зур авырлык килгәндә дә, олы бәхет басканда да сабыр һәм олпат булып калырлык көч бирәдер. Әйдәгез, 60 яшегез үреннән гомерегез бишегенә — Ык буйларына, Мөслим тугайларына әйләнеп кайтыйк та, иң-иң яраткан көегезне искә төшерик әле...*

— Безнең Мөслим ул түбәнлектә, төпкә төшеп урнашкан бит. Һава торышын әйткәндә дә, игътибар итәсездер, кышын анда башка төбәкләргә караганда бераз салкынрак була... Ыкның аргы ярындагы әрәмәләр өстеннән матур биек таулар күтәрелеп китә. Алар инде Урал тауларының башыдыр. Әнә шул Урал таулары итәгенә учак ягып утырган чаклар искә төшә, әлбәттә. Төнге Мөслимнең матурлыгына хозурланып, хисләнеп утырган чаклар...

Менәргә иде Урал тауларына,
Басарга иде кыя ташына ... —

дип сузган җырларыбыз... Мөслим иңкүлеге Урал тауларына тоташып киткәндәй, бер көй икенчесенә ялгана. Сагындыра шул кабатланмас мизгелләр!

Гомер агышлары да әнә шулайрак бара кебек. Анда да башта сизелер-сизелмәс, йомшак кына авазлар, үлән башларын сыйпап узган җил төсле, әлегә түбәннән генә аккан фикер агышы тоела башлый. Аннары инде алар зурая, көчәя, үзәнлекләр тауга үрли-әверелә барган сыман үсә-үсә, әкренләп кеше рухының олы биеклекләре төсмерләнә.

... Басарга иде кыя ташына.
Шул кыядан кушылып җырларга иде
Урал бөркетләре тавышына.

Минем теләгем: бүген тормыш үренә менеп җиткәннәр — үзләрен үстергән, күтәргән үзәнне онытмасыннар, әлегә үзәннәр буйлап килүчеләр исә биеккә, яктыга омтылу тойгысыннан мәхрүм булмасыннар иде.

*14 февраль, 1997 ел*

# ГАСЫРЛАР КАПКАСЫН АЧКАНДА

«Татар халкы талантларга бай», — дигәнне шактый ишетергә туры килә. Моны хәтта безне яратып бетермәүчеләр дә танырга мәҗбүр. Әйе, бер дә юкка гына халкыбыз тарихка «бөек» исеме белән кермәгән инде. Планета халкы 5.500 телдә (зур шивәләре белән) сөйләшә. ЮНЕСКО билгеләве буенча, шуның ундүрте — дөньякүләм тел, алар арасында татар теле дә бар. Тагын бер мисал: революциягә кадәр безнең халык 15 мең исемдә китап чыгарган. Калган төрки халыклар (алар 30) барысы бергә 1000 исемдәге китап кына нәшер итә алган. Тарихчыларның әйтүенә караганда, Болгар дәүләтендә дә, Алтын Урдада да, Казан ханлыгында да «китаплы кеше» абруйлы саналган. Явыз Иван Казанны алгач, хан китапханәсенең байлыгына шаккаткан, көнләшүдән йокыдан калган һәм бихисап китапларны утка ыргытырга кушкан диләр.

Казан ханлыгы дәүләт булудан туктагач исә татарларга иҗат белән шөгыльләнү бик тә кыенлаша. Яңа хакимнәр аларның балаларына дөньяви белем бирүгә нык комачаулаган. Шулай булуга карамастан, Казанда, Уфада, Ырынбурда, Троицкида, Иҗбубыйда урта һәм югары мәдрәсәләребез барлыкка китерелгән. Аларда дини белем бирүдән тыш, дөньяви фәннәр дә укытыла башланган. Яктылыкка, белемгә омтылу татарның матур бер гадәтенә әйләнгән. Ленин да, урыслар белән чагыштырганда, татарларда мәктәпләр саны җан башына 10 мәртәбә артыграк дигән. Бөек галим К. Фукс балаларын белем бирү өчен татарларның җан атуларын әйткән. Монда, мөгаен, диннең роле дә зур булгандыр. Чөнки Коръән белем алуны бөек, изге эш дип атый. Кемнәрдер ничә шешә аракы эчүе белән мактанганда, татарлар балаларына белем, һөнәр бирү өчен көчләрен кызганмаган.

Тарих тәгәрмәчен кире әйләндереп булмый. Шулай да әйтәсе килә: Финляндия, Дания, Норвегия кебек илләр урынында булса, (моны халык санының чыгып әйтүем), безнең халык ничек алга китәр иде! Колонияләр басып алган дәүләтләрне мактап булмый. Чөнки алар нигезендә көчләү, кан түгүләр ята. Тик шунсы факт: инглиз, француз, испан колонизаторлары үзләре басып алган җирләрдә шактый алга киткән экономика, мәгариф һәм мәдәнияткә дә нигез салдылар. Әлбәттә, үзләре файда күрер өчен. Шунлыктан әле дә ел саен, мәсәлән, Лондонда «Бөек Британия дуслык берләшмәсе» әгъзалары — элекке колонияләрнең житәкчеләре җыйнала. Шунда бер-беренә ярдәм итү мәсьәләләре карала һәм уңай хәл ителә. Франция, Италия, Бельгия, Голландиянең дә элекке колонияләре белән мөнәсәбәтләре әйбәт. Ә СССР таркалгач, элекке союздаш республикалар бәйсез дәүләтләргә әйләнгәч, шуларның күбесе тизрәк НАТОга керү ягын кайгырта башлады, чөнки алар урыс империясенең үзләрен яңадан басып алуыннан куркалар. Бабурин, Макашев, Анпилов кебек шовинистлар, Дәүләт думасы мөнбәренә басып, «урыс идеясен» пропагандалыйлар. Ә бу исә — сугыш юлы. Чөнки «урыс патриотлары» Русияне 1917 елдагы чикләре (димәк, Финляндия, Польшаны да басып алып) эчендә аякка бастыру турында хыяллана.


Үзебезгә килсәк, без инде болай да «бөек империянең» аяк астында ятабыз. Шулай шул: тарихыбыз данлы-шанлы да, искиткеч фаҗигале дә. Мәсәлән, 1552 елда Явыз Иван Казанны басып алгач, бөтен ир затын диярлек суеп бетерә. Хатыннарның, балаларның бик күбесен чукындыра, коллыкка озата. Урыс патшасының әмере белән, ханның бай китапханәсе, дәүләт архивы юк ителә, алтын һәм башка байлыкны тулысы белән Мәскәүгә алып китәләр. Урыс империясенә нигез әнә шулай салына. Моннан соң да яңадан-яңа басып алуларга йөз тотыла. Явыз Иван варислары чагыштырмача кыска вакыт эчендә ике кыйтгадагы йөзләрчә халыкны, аларның җирләрен кулга төшерә. Ләкин императорларга бу гына

житми. Беренче Петрның Русияне бөтен дөньяга хуҗа итү һәм дәүләтнең башкаласын Истанбулга күчерү теләге-васыяте тормышка ашырылудан тукталмый. Кайберәүләр: «Нигә Русиягә Кавказ кирәк булды икән, икътисади яктан, ул зыян гына китерә?»,— дигән беркатлы сорау бирәләр. Әйе, бүгенге Дагстан, төньяк Осетия, Адыгея бюджетының күпчелек өлешен үзәктән җибәрелгән акча тәшкил итә. Сәбәп сәяси: Кавказ Һинд океанына чыгу, янадан-яна җирләрне басып алу өчен яулана. Жириновский шул теләкнең бүген дә шовинистлар йөрәгенә сары май булып ягылуын белә һәм урыс күңелен «итекләрен Һинд океаны суларында юарга» әгъвалый.

Сорау туарга мөмкин: ни өчен болар хакында мин язам соң? Җавап: соңгы елларга кадәр урыс тарихын шул кадәр бозып күрсәттеләр ки, без «бәхетле язмышыбыз өчен» басып алучыларга рәхмәт әйтеп китаплар яздык, җырлар чыгардык. Тик менә «демократия җилләре» исә башлагач кына, кайбер галимнәр, үз-үзләрен аямый, халкыбызның чын тарихын ачарга керештеләр. Моның өчен аларга мең рәхмәтебезне әйтергә кирәк иде. Әмма дә ләкин, бер яктан, бу тикшеренүләр шовинист «галимнәрнең» җенен чыгарды, икенче яктан, үзебезнең кайбер укымышлылар чын тарих тудыручыларга тәнкыйть яудырырга тотынды.

Мөхтәрәм милләттәшебез, олы галимебез, халкыбызның чын фәнни тарихын тудыруга зур өлеш керткән Равил Фәхретдинов хезмәтләре белән якыннан танышкач, күңелне югарыдагы уйлар, фикерләр биләп алды.

Мәгълүм ки, элекке союздаш республикаларда милли мәдәният, әдәбият, сәнгать, тарих, этнография һәм башкаларны күпсанлы фәнни-тикшеренү институтлары өйрәнеп килде. Ул республикалар бәйсез дәүләтләргә әйләнгәч, фәнни үзәкләрнең саны тагын да артты. Бездә исә нибары бер институт — Тел, әдәбият, тарих институты гына яшәп килде. Ә ул ни генә эшләп өлгерсен соң? Шулай да алга омтылыш бар кебек. Мәсәлән, 1996 елның көзендә, Президентыбыз фәрманы белән, махсус Тарих институты төзелде. Табигый, аңа иң элек янача уйлый торган, «сыйнфый позициядән чыгып» эш итүне кире каккан галимнәр кирәк. Алар күп түгел, ләкин алар бар!



Шуларның берсе — бу язманың герое Равил Фәхретдинов. Моны махсус әйтүнең мәгънәсе шул: Тел, әдәбият, тарих институтында бу галимгә, бик йомшак итеп әйткәндә дә, эш өчен уңай шартлар тудырылмады. Киресенчә, аяк чалучылар шактый иде.

Галим турында сүз башлагач, аның тәрҗемәи хәлен сөйләмичә мөмкин түгел. Югыйсә, күп нәрсәләр аңлашылмас, күләгәдә калыр иде. Гадәттә, теге яки бу күренекле шәхеснең шәҗәрәсе, нәсел-нәсәбе белән кызыксыналар. Бу да табигый. Равил Фәхретдиновка килгәндә, аның 1937 елның 14 мартында Габдрахман абзый гаиләсендә дөньяга килүе билгеле. Туган җире — Балтач районының Кариле авылы. Малайга ике яшь тулганда, Габдрахман Фәхретдинов үзенең туган авылы Балтачка кайта. Равил шунда белем ала, урта мәктәпне тәмамлый. Мөгаллимнәре аңа зур өметләр баглый, галим булыр, диләр.

Габдрахман абзый, укымышлылар затыннан булса да, заманасына муафикъ эш сайлый: төзүче була. Тирә-юньдә «Габдрахман йорты», «Габдрахман салган сарайлар», дигән сүзләр йөреп кенә калмый, бу төзүче төрле бәйгеләрдә җиңеп чыга, аның хакында гәзит-журналларда, китапларда язалар. Шуларның берсе — «Народы мира» исемле китап. Кыскасы, Габдрахман абзый гади төзүче генә түгел, иҗат кешесе була. Совет властен, ялкауларга юл биргән хакимиятне җаны сөйми. Табигате белән шат күңелле, уен-көлкеле һәм үз фикеренә ия бу ирне туган ягында әле дә хөрмәт белән искә алалар. Равилдәге принципиальлек, мөгаен, әтисеннән киләдер — геннардагы мирасны хәзер инде бездә дә таныйлар! Галимнең әнисе Нәгыймә апа турында да бик күп җылы сүзләр әйтергә мөмкин. Шуны гына искә төшерик: Нәгыймә апа төскә-биткә бик чибәр, аш-суга оста. Авылда чәкчәкне ул гына пешерә, ул шуның

белән дә дан тота. Инде пакълыкка-пөхтәлеккә килгәндә, Нәгыймә апа чын татар хатын-кызы була. Равил әнә шундый кешеләр гаиләсендә үсә, шәхес булып формалаша.

Равил Фәхретдинов 1958 елда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле, әдәбияты һәм тарих бүлегенә укырга керә. Ул заманда безнең халык алдында укытучы бик тә абруйлы зат иде. Мөхәммәт Мәһдиевнең бер әсәрендә мондый вакыйга тасвирлана: укучы класс журналын алырга укытучылар бүлмәсенә кергәч, шунда бер мөгаллимәнең ашап утыруын күреп, нишләргә белми, телсез кала. Мин моңа тулысынча ышанам, чөнки без дә укытучыларны кимендә фәрештә итеп күз алдына китерә идек.

Равил Фәхретдиновның институтта ничек укуын белү өчен, шуларны әйтү дә җитә: башта Тукай, аннан соң Ленин стипендиаты була. Аңлашыла ки, бу дәрәҗәгә ирешү өчен, «инә күзе аркылы» узарга кирәк. Моның өчен бик яхшы өлгерү генә җитми, җәмәгать эшләрен башкаруга да нык әһәмият бирелә. Равилгә гаиләдән килгән (әтисе — үзешчән сәнгать ярышларында күп тапкыр бүләкләнгән оста гармунчы!) музыкаль сәләт ярдәм итә. Ул институтның татар студентлары хорын оештыра һәм бөтен уку дәверендә шул коллективка җитәкчелек итә.

Кыска гына вакыт эчендә бу иҗат төркеме шәһәр күләмендәге студентлар олимпиадасында икенче урынны ала. Яшьләрнең дүрт тавыш белән «Ай былбылым», «Салкын чишмә», «Кара карлыгач микән» кебек җырларны башкаруын тамашачылар да, жюри дә югары бәяли. Мондый уңыш Равилне хәтта консерваториядә укырга да ымсындыра. Әмма тарихчылар аеруча хөрмәт итә торган олы җанлы педагог Е. И. Устюжанин белән сөйләшү бөтенесен хәл итә дә куя. Ул: «Әйе, синең музыкага сәләтең дә, омтылышың да бар, ләкин синдә бер дигән тарихчы таланты абайлана. Мин соңгысын сайларга киңәш итәр идем. Татар һәм Татарстан тарихы әле һаман ак кәгазьне хәтерләтә. Чын тарих юк. Аның булуын бүген кайберәүләр теләми дә. Әмма килер вакыт, халык чын тарихын белергә омтылыр. Андый тарихны барлау, язу исә синең кебек яшь көчләрсез мөмкин булмас».

Әнә шул ачыктан-ачык сөйләшү Равилнең киләчәк язмышын хәл итә дә инде. Ул бөтен гомеренә җитәрлек олы максатын билгели: туган халкының гыйльми тарихын барлыкка китерү. Ләкин егет тормышта очрый торган чоңгылларны уйламый, алар була дип баш ватмый. Тик чынбарлык фаразлардан да катлаулырак шул.

Хәер, Равил институттагы укытучыларын бүген дә җылы итеп искә ала. Чөнки алар булачак галимне археологик тикшеренү осталыгына, шул юлдагы авырлыклар алдында каушап калмаска, түземлелеккә өйрәтәләр. Өстәвенә егетнең дәрт-дәрманы да ташып тора. Ул ел саен берничә мәртәбә археологик экспедицияләрдә катнаша. Якындагы нияте дә ачыклана: Татарстан җиренең урта гасырлардагы археологик картасын төзү. Бу дәвергә кагылышлы документларны XIII гасырда монголлар, аннан соң Аксак Тимер, Явыз Иван яулары нигездә юк иткәнлектән, археологик казынуларның чын тарихны тудыруда әһәмияте аеруча көчәя төшә.

Р. Фәхретдинов студент чагында ук археологик тикшеренүләргә катнашу өстенә, Мәскәүдә, Ленинградта узган фәнни конференцияләрдә үз темасы буенча чыгышлар (докладлар) ясый; матбугат битләрендә беренче фәнни хезмәтләрен бастыра. Яшь галим үзенең беренче ачышларын да ясый. Алга китеп булса да әйтим: Равил студент чагында алдына куйган бурычны чирек гасыр дәвамында үтәүгә ирешә — Идел-Кама Болгарстанының археологик һәйкәлләр картасын төзи. Анда бүгенге Татарстан территориясенә кергән 2000 һәйкәл теркәлә. Шуларның яртысын диярлек ул үзе ача! Бу — таң калырлык хезмәт. Һәйкәлнең урынын ничек төгәл күрсәтергә мөмкин икән? Алар арасында монгол чорына кадәрге истәлекләр, Алтын Урта һәм Казан ханлыгы дәвере истәлекләре, вакыты төгәл билгеле булмаган гомумболгар истәлекләре дә бар. Шул кадәрене җыярга, тупларга адәм баласының акылы да, түземлеге дә җитә икән әй!

Инде картаның үзенә килгәндә, аның Равил язган «Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и ее территория» дигән китапка (Таткитнәшер, 1975) теркәлүен (моннан тыш та ике карта бар) әйтергә кирәк. Бу китапта автор бихисап фактик материаллар китерә. Хезмәтне язганда Равил 616 чыганакка һәм әсәргә таянган.

Равил пединститутны 1963 елда кызыл диплом алып тәмамлый һәм шул ук елда Казан тел, әдәбият, тарих институты аспирантурасына керә. 1968 елда Мәскәү дәүләт университетының археология буенча гыйльми советында

кандидатлык диссертациясе яклый. Әмма докторлык диссертациясен яклау галимебезгә 1992 елда гына тия. Чөнки, тарихчыларыбыз татар дәүләтен һәрвакыт үзара ызгыш, хакимият өчен көрәш һәлак иткәнен башкаларга караганда яхшырак белсәләр дә, үзләре дә шул ук хатаны кабатлыйлар. Бу шомлык Алтын Урда дәүләтенең соңгы чорыннан алып безне бүгенгә кадәр эзәрлекли. Ирексездән уйлыйсың: бер-беренә шул кадәр хөсетлек башка халыкларда бу дәрәҗәдә бармы икән?

Галимнәрнең бер ишесе: «Равил Фәхретдинов татар тарихын Алтын Урдага гына кайтарып калдыру белән шөгыльләнә. Билгеле ки, ул дәүләтне монгол-татарлар төзегән. Ә Европа моголларны да, татарларны да яратмый. Димәк, безгә монголлар Алтын Урдасыннан ераграк тору хәерле»,— диләр. Белмәгән кешегә акыллы сүз тоела болар. Әмма чынлыкта алай түгел. Тәнкыйтьчеләре Равил Фәхретдиновны «болгар» булырга чакыралар. Бу үзе яна күренеш түгел. Вәисевчеләрне искә төшерү дә күпне сөйли кебек. Әмма декрет чыгарып милләт исемен алмаштыру бик тә кыен нәрсә. Әйе, андый очраклар юк түгел. Мәсәлән, сугыштан соң «Таулы Ойрот»ны «Таулы Алтай»га алмаштырдылар. Чөнки ойротларның бөтенләй башка халык булуы, хәзерге Тыва республикасында яшәүләре ачыкланды. Әмма саны 20 мең булган таулы алтайлылар белән бөтен планетага сибелгән 7 миллионлы татарны чагыштыру мөмкин түгел. Мәсәлән,ниндидер могҗиза белән Татарстан Дәүләт Советы татарларны болгарлар дип игълан итте ди. Әмма республикабыздан тышта яшәүче татарлар (милләтнең 75 проценты) бу карар белән килешерме, аларга безнең карар закон була алырмы? Алайга китсә, урысларның да чын исеме «урыс» түгел, норман-варяг кенәзләре таккан бер атама гына... Моны урыс тарихчылары шулай ди. Әмма урыс үз исеменнән хурланмый һәм баш тартырга да җыенмый. Кем әйтмешли, ни чыкса, шул без татарлардан чыга. Ләкин каш ясыйм дип, күз чыгарырга мөмкин. Болай да бердәмлеккә мохтаҗ татар халкын таркатып ташласак, кемгә хезмәт итәбез була инде? Бу кемгәдер ошыймы-юкмы, тарих безгә «татар» дигән исем биргән һәм «бөек халык» дип өстәгән. Безгә кадәр яшәгән мәшһүр бабаларыбыз да юкка гына татар булулары белән горурланмагандыр. Мөгаен, алар «Европа хәлләрен» бүгенге кайбер галимнәрдән ким белмәгәндер. Һәрхәлдә, Тукай, Дәрдемәндләр шундыйлардан. Тукай һич тә шик калдырмаслык итеп болай ди:

Татар бәхте өчен мин җан атармын:
Татар бит мин, үзем дә чын татармын.

Дәрдемәнд тагын да кыюрак һәм конкретрак әйтә:

Татарлыктан татар гарь итәрме,
Кеше үз исемене инкарь итәрме.
Татарлыкта татар углы татармын,
Татар түгел димә — башың ватармын!

Бу хакта Равил Фәхретдиновның да фикерен тыңлап карыйк: «Халкыбызның үзенә бик тә кадерле булган «татар» исеменә пычрак ягып, аны бүтән исемгә, мәсәлән, «болгар»га алыштырырга өндәп... аны эчтән таркату, санын киметү, бүлгәләү эшен бүгенге көндә бик тырышып «Болгар әл-Җәдид» оешмасы, ул чыгара торган «Болгар иле» газетасы алып бара». («Татар углы татармын». Чаллы. 1993).

Укучыда гади генә сорау туарга мөмкин: үз гомеренең 30 елын (нинди еллар бит әле!) «Идел-Кама Болгарстаны» һәйкәлләрен, димәк, туган илебез-җиребезнең тарихын өйрәнүгә биргән галим Равил Фәхретдиновны: «Ул бары тик Алтын Урданы гына татар дәүләте итеп карау ягында», дип гаепләргә урын бар микән? Соңгы берничә ел эчендә татар, Татарстан тарихына багышланган берничә китап һәм дәреслек чыкты. Авторлары — Мифтахов, Мөхәммәдева, Нуретдинов. Әмма алар, элекке «большевистик концепцияләрдән» азат булмаганга, каты тәнкыйтькә очрады. Шуннан соң Р. Фәхретдиновның «История татарского народа и Татарстана» (Казан, «Мәгариф», 1995), «Татар халкы һәм Татарстан тарихы» (Казан, «Мәгариф», 1996) дигән дәреслекләре дөнья күрде. Алар Татарстан мәгариф министрлыгы тарафыннан расланган. Игътибарга лаек: укытучылар, киң җәмәгатьчелек әлеге дәреслекләргә югары бәя бирде.

Аталган дәреслекләрнең эчтәлеге белән танышкач, авторны «Алтын Урданы пропагандалаучы» дип раслаулар үзеннән-үзе юкка чыга. Моны дәреслекнең бүлекләре дә «әйтеп тора»: I. Татарстан җирендә борынгы җәмгыять. II. Евразиядәге борынгы төркиләр һәм төрки кабиләләр. III. Татар халкының урта

гасырдагы беренче дәүләтләре (Төрки каханлыгы. Кимән каханлыгы. Хәзәр каханлыгы. Бөек Болгар иле). IV. Болгар дәүләте. V. Алтын Урда. VI. Казан ханлыгы.

Кайчак Р. Фәхретдиновка мондый үпкә белдерәләр: «Ни өчен 30 ел буе Болгарны тикшердегез дә, аннан соң Алтын Урдага мөкиббән киттегез?». Мәсьәлә кемнедер ярату-яратмауда түгел. Объектив карашлы галим бервакытта да бу юлга басмаска тиеш. Әмма совет чоры объективлыкны «сыйнфый караш» белән алмаштырды. Урыс тарихчыларының озак елларга сузылган һәм яраткан «хакыйкатьләре» бер: «Русиянең арттылыгына татар-монголлар гаепле. Алар урыс халкының үсешен тоткарлап торды». Чынлыкта бу фикерләр бик тә бәхәсле. Мәсәлән, Карамзин, Соловьев кебек күренекле тарихчыларның язуына караганда, Урыс дәүләтен тудыруда татарларның, Алтын Урда ханнарының роле бик зур. Бу чыннан да шулай. Тагын бер фикер: ярый, татарлар урыс жирен 200 ел җәберләп, талап торганнар ди. Әмма аннан соң да 550 ел вакыт узган. Тик Русия һаман да хәерчелектән чыга алганы юк. Ә моннан 40-50 ел элек кенә колония булудан туктаган, икенче төрле әйткәндә, бәйсезлек алган илләр (мәсәлән, Мисыр, Алжир, Һиндстан, Пакыстан, Индонезия, Малайзия, Корея, Марокко, Тунис һ. б.) нык алга киттеләр. Совет тоталитар системасы татарларның тарихи үткәнен кан дошман күрде. Татар тарихын, бигрәк тә Алтын Урда чорын өйрәнү катгый тыелды. Бу хакта Равил Фәхретдинов болай ди: «Рус булмаган, бигрәк тә төрки халыкларның, шулар эченнән татар халкының күп гасырлы тарихының бай сәхифәләре төшереп калдырылды яки тискәре итеп күрсәтелде. Бу хәл аеруча Алтын Урда тарихына кагыла. Ул тарихны өйрәнү һәм халыкка житкерү безнен Татарстанда сталинчыл ВКП(б) Үзәк Комитетының 1944 елгы 9 август карары белән чынында бөтенләй тыелды». («Татар халкы һәм Татарстан тарихы». 1996).

Тарихи үткәннәрне кайтарып булмый. Ә кайтарасы, хаталарны төзәтәсе килә. Мәсәлән, «Идегәй» дастанын белмәгән татар бар микән? (Аның тулы вариантын иң беренче язып алган Нигъмәт Хәкимне 1937 елда Мәскәүнеӊ Любянка төрмәсе базында аталар. «Гаебе» шул: «дастанны язып алып, халыклар дуслыгына зыян китергән»). Әйе, Идегәй сугышларда җиңелү белмәгән-күрмәгән бөек яугир. Әмма ялгышлары да фаҗигале. Аксак Тимер Алтын Урда шәһәрләрен жир белән тигезләп йөргән бер вакытта, Идегәй аңа каршы көрәш ачмый, бәлки, ханнар тәхет өчен үзара ызгышканда, шуларның берсен яклап, утка кера. Бигрәк үкенечле хәл: Аксак Тимер баскынчылары йөз меңнәрчә халыкны кырган, кол итеп алып киткән. Алар арасында оста төзүчеләр, рәссамнар, алтын-көмешчеләр һ. б. да булган. Әлбәттә, без Алтын Урдадагы хәлләрнең күбесен белмибез, әмма шулай килеп чыга: бөектән дә бөек, легендар шәхесебез Идегәй объектив рәвештә Алтын Урданың юкка чыгуын тизләткән...

Тагын бер мисал. Казан ханлыгында да дәүләт житәкчеләре арасында тәхет өчен көрәш туктап тормаган. Явыз Иван Свияжскида гаскәр, корал туплау өчен ныгытма төзи, ханлыкны икегә бүлә, шуның аркасында татарлар бер заман тиешле күләмдә гаскәр дә туплый алмый. Гади генә мантыйк та, әлеге ныгытманы ничек тә юк итү ягын карауны таләп итә. Әмма бу хакта уйлаучы да булмый, ахрысы, «Мәскәү яклы», «Кырым яклы» партияләр бер-беренә пычрак аталар. Дошман боларның һәммәсен белеп-күреп тора. Сатлык жан Шаһгали Казан ханлыгына әйтеп бетермәслек бәлалар китерә. Өстәвенә татар ханлыклары да ярдәмлек күрсәтмиләр. Болар һәммәсе Казан ханлыгының һәлакәтен тизләтә. Их бу бердәмлекнең булмавы... Бердәм чакта «Ибраһим, Мөхәммәтәмин һәм Сафагәрәй ханнар, Казан җиренең барлык гаскәрләрен бергә туплап, урысларның Казанга 1469, 1506, 1524, 1530, 1545 еллардагы һөҗүмнәрен кире кага алганнар бит» («Татар халкы һәм Татарстан тарихы», 195 бит). Чит ил тарихчысы С. Герберштейн татар сугышчыларына бик югары бәя бирә: «Мәскәүле, качып котылудан бүтән бер нәрсә турында уйламыйча, тизрәк качу ягын гына карап тора; дошман килеп чыкса яки эләктереп алса, ул каршы торып маташмый. Ә татар, аттан егылып төшсә дә, авыр яраланып коралыннан язса да, һаман куллары, аяклары, тешләре белән, гомумән, күпме булдыра ала — шул кадәр каршы тора, һаман көрәшә», — ди (Р. Фәхретдинов. Татар халкы һәм Татарстан тарихы. Казан, «Мәгариф», 1996. 195 бит).

Тагын бер мәгълүмат китерик: «Рус, Көнбатыш Европа һәм татар тарихи чыганакларында казанлыларның утлы ату кораллары — туплары һәм авыр мылтыклары (пишаль) булганлыгы әйтелә. Рус һәм совет тарихи әдәбиятында Казан ханлыгында андый кораллар булмаган, булса да, татарлар аннан файдалана белмәгәннәр, дип киленде. Бу һич тә дөрес түгел! Көнчыгыш Европада утлы корал беренче тапкыр нәкъ менә Урта Идел буенда — XIV гасырның 70

елларында Болгар шәһәрендә кулланылган» («Татар халкы һәм Татарстан тарихы», 196 бит)

Бу Америка ачу түгел: татар халкының чын, фәнни тарихын тудыруда Равил Фәхретдинов керткән өлеш сөйләп бетергесез зур һәм кыйммәтле. Югарыда әйтелгән иде инде: урыслар Казанны алганнан соң, Явыз Иван әмере белән, дәүләтебезнең бик бай китапханәсе юк ителә. Урыс матбугатында: «Иван IV нең бик бай китапханәсе булган, әмма ул каядыр яшерелгән бугай. Аны табасы бар»,— дигән сүзләр еш кабатлана. Кем белә, бәлки ул китапханәдә Казан ханы китаплары да сакланадыр. Әмма безнең өчен алар бүген юк. Дөрес, татар тарихына кагылышлы документлар чит илләрдә бераз сакланган, урыс елъязмалары да кайбер мәгълүматлар бирәләр, әмма алар нигездә берьяклырак. Чын тарихыбызны белүнең аеруча бер нәтиҗәлесе — археологик казылмалар. Әйтелгән иде инде, бу өлкәдә язмабыз героеның хезмәтләре күпкырлы һәм һәртөрле мактауга лаек. Аның тарафыннан Болгар, Бүләр шәһәрлекләре, Алтын Урданың башкаласы Бәркә Сарай, Бату Сарай хәрабәләре казыла, бик күп яңа материаллар табыла. Равил табигате белән бик хисле җан иясе. Ата-бабаларыбызның үткәннәре белән «турыдан туры танышканда» ул ниләр кичерә, уйлый икән? Хәрабәләр урынында кайчандыр бик матур шәһәрләр булган, аларда көмеш, алтын акчалар сукканнар, бакчаларында фонтаннар атып торган, кошлар сайраган, шагыйрьләр матурлыкка яки мәхәббәткә мәдхия җырлаганнар. Ә хәзер җир өстендә берни дә юк, әйтерсең лә, бөек дәүләтләребез, югары мәдәниятебез, булмаган да. Кемгә нәрсә дип үпкәләргә, ниләр кылырга? Әй бу үткәннәр, бөек ата-бабаларыбыз... Нинди казанышларыбыз юк ителгән бит! Ул урыннарда хәзер әрем, кылганнар гына үсеп утыра...

Тормышта, бигрәк тә фәндә «сан» һәм «сыйфат» дигән төшенчәләр бар. Аларны Р. Фәхретдиновка карата куллансак, икесе дә әйбәт һәм үз урынында. Мәсәлән, гомуми күләме 240 табакка житкән 200 ләп фәнни хезмәте һәм китаплары шул хакта сөйли ич! Бу очракта аларга анализ ясау мөмкинлеге юк. Тик шунсы хак: галим юкны бушка аудармый, сүз боткасы куертмый, аның һәрбер хезмәте конкрет һәм дәлилле була. «Ташлар моңы» китабы (Казан, Таткитнәшер, 1978) — шуның бер үрнәге. Бер яктан, бу китап фәнни хезмәт булса, икенчедән, монда язучы осталыгы, әдәби тел белән эш итү «манерасы» сизелеп тора. Автор Идел-Чулман Болгарстаны заманасын шулай итеп тасвирлый ки, әйтерсең лә, шул чорларда борынгы ата-бабаларыбыз белән фикер уртаклашып яшәгән (Бу китапның урысча һәм тулырак варианты Казанда 1986 елда басылды).

Академик Обручевның зур галим икәнен шул өлкәдә эшләүчеләр генә белә диярлек. Әмма бу галим бигрәк тә «Санников җире», «Азия чытырманлыгында» исемле китаплары белән бөтен дөньяга танылды. Бу ике роман төрле илләрдә күп телләрдә басылды. Халык аларны әле дә зур кызыксыну белән укый. Димәк, белеп һәм урынлы файдаланылган, әйтелгән сүз бөек көчкә ия. Яхшы китап акылга гына түгел, хисләргә дә тәэсир итә, ә бу исә инану формалашуның иң нәтиҗәле алымы. Хәтерлим: беренче сыйныфта укыган чакта «Монгол баласы Дындып» дигән китапка тап булдым. Укытучыбыз уку елының икенче яртысы башлангач, һәммәбезне дә мәктәп китапханәсенә яздырды. Әлеге китапны шул чакта укып чыккан идем. Алтмыш елдан артык үтеп китсә дә, ул әсәрнең эчтәлеген мин бүген дә исемдә тотам. Дындып — арат, безнеңчә әйтсәк, авыл малае. Аның әтисе — атлар караучы. Ул аларны бүреләрдән саклый, үлән мул үскән урыннарда көтә, тамаклары тук булсын, ди. Дындып әтисен дә, атларны да, гомумән җан ияләрен яратып үсә. Кешеләргә гел генә яхшылык эшли. Ул чакта, табигый, мин Монголия дигән илнең кайда булуын, андагы халыкның тормышын белми идем. Әмма монгол малае Дындып гомерлеккә дустым булып күңелемдә сакланды. Бу һич тә мактану түгел, гомерем буе атларны, башка мал-туарны, этләрне, кош-кортны яраттым. Телләрен белмәсәм дә, әле һаман этләр янында тукталып, сөйләшеп китәм. Мөгаен, монда монгол малае Дындыпның уңай йогынтысы чагыладыр. Равил Фәхретдиновның «Ташлар моңы», «Татар углы татармын» китапларын укыганда да, күңелемне сүз белән аңлатып бетерми торган әллә нинди хисләр биләп алды. Минемчә, бу китапларны укыганнарда милли үзаң үсәчәк, шуның аркасында илебез, халкыбыз сакланып калачак. Тарихи ачышлар ясау бик мөһим эш булса да, үзмаксатка кайтып калмый. Үткәнен белгәннәрнең генә киләчәге бар. Бу — аксиома.

Равил Фәхретдинов очерклары, эсселары белән матбугатта күптәннән чыгышлар ясый, радио-телевидение дә аңа сүз бирә. Инде китапларны искә төшерсәк, 1973 елда галимнең беренче әсәре дөнья күрә, ул «Җырчы» дип исемләнә. Автор

монда күренекле җырчы Илһам Шакировның халык күңелен яулау серләрен ачуга ирешә. Чыннан да, халыкның милли үзаңын үстерүдә җыр сәнгатенең әһәмияте бик зур. Концерт залына сокланып карыйсың да, тамашачыларның йөрәге бердәй тибүен, үзләрен бер милләт затлары итеп сизүен тоясың. «Тарихчы нигә шундый әсәр язган?» — дип кызыксынучыларга, Равил кеше шәхесен формалаштыруда җырның тылсымлы көчкә ия булуын белә диярргә телим. Татар җырында кайбер халыкларда булмаган бер тылсым бар. Бу — моң. Шул сүзне башка телгә күчереп тә булмый, аны тоярга, күңелеңнән кичерергә кирәк. «Татар ни өчен моңлы, сагышлы?» дигән сорауны да ишетергә туры килгәли. Тарихыбыз бик катлаулы, данлы казанышлар һәм фаҗигаләр белән тулы икән, бу халыкның әкиятләрендә, гомумән халык авыз иҗатында, бигрәк тә җырларда чагыла. Җан авазы булып тышка чыга. Моны Равил бик яхшы белә һәм бер китабын «Ташлар моңы» дип атый. Бик тә уңышлы исем! Чал чәчле болгар хәрабәләре арасында йөргәндә йөрәктән кан таммыймыни, күңелдә моң хасил булмыймыни?

Әлбәттә, безнең данлы тарихыбыз, каханлыклар заманы, Болгар дәүләте, Алтын Урдабыз булган. Алар ниде күптән мәңгелек томаннарына кереп югалган. Әмма татар йөрәген һәрвакыт сулкылдатучы чор — Казан ханлыгы дәвере. Чөнки бу ханлык юкка чыгу белән татарның дәүләтчелеге беткән. Ә дәүләт ул бөек хәзинә, яшәү мәгънәсе. Бервакыт В. Г. Белинский: «Малороссиялеләрдә бервакытта да дәүләт тә, дәүләт төзү хакында уй-теләк тә булмаган»,— дип язган. Мәскәүдә укыганда мин украин коллегаларыма: «Белинский хаклымы?» — дип сорау биргән идем. Алар ул чакта, әлбәттә: «Киев Русе — безнең дәүләт»,— дип әйтергә батырчылык итмәделәр. Шулай да В. Г. Белинскийны «шовинист» дип атадылар. Инде безгә килгәндә, «татарларның дәүләте булмаган», дип үтә шовинистлар да әйтә алмас. Күпләрдә милли үзаң түбән булса да, алдынгы зыялыларда дәүләтчелек идеясе, хисе бервакытта да бетмәде. Аз гына мөмкинчелек туу белән, халык үз дәүләтен, нинди формада-кысаларда булса да, торгызырга омтыла. Бу бигрәк тә 1905—1917 елларда, хәтта совет властеның башлангыч чорында ачык чагылды. Милли хәрәкәт тарафдарларында бүген дә, әлбәттә, тыныч юл белән бәйсез дәүләт төзү дәрте дөрли.

Казан ханлыгы очраклы рәвештә генә яшәүдән туктамый. Ул хакта югарыда сүз булган иде инде. Ләкин әле дә шактый агай-эне дәүләтебезнең нинди булуын һәм нигә юкка чыгу сәбәпләрен белми. Бу гаҗәп тә түгел. Чөнки соңгы 5—6 елны исәпкә алмаганда, халык аңына Энгельсның Маркска язган бер хатындагы фикер сеңдерелде. Энгельс Русиянең татарларны, башкортларны, Кавказ халыкларын басып алуын хуплый, моны прогрессив күренеш дип атый. Янәсе, урыс империясе әлеге халыкларга мәдәният алып киләчәк. Бу «фикер» совет заманында күкләргә чөелде: имеш, чынбарлык урыс халкына «вак халыкларны» үз тирәсенә тупларга кушкан. Перспективада бу гамәл аеруча акланган икән: урыс халкы «нацменнарны» коммунизм оҗмахына — бәхетле дөньяга алып бара. Энгельс фикеренең үтә шовинистик карашлар җыелмасы булганлыгын хәзер инде дәлилләп торасы да юк. Иң кызганычы һәм үкенечлесе шул: эчүне, урлашуны, кеше үтерүне белмәгән мөселман татарлар совет демократиясе кояшы астында күршеләренең иң начар гадәтләрен үзләштерделәр. Ә тоталитар система халкыбызның күпме алтын генофондын юк итте! Кем кемгә «цивилизация орлыклары чәчкәнне» Маркс, Энгельс түгел, тарих белә: татар халкының соңгы өч дәүләтендә (Болгарстан, Алтын Урда, Казан ханлыгы) заманасы өчен алдынгы казанышлар булган. Бу яктан, ул күпләргә үрнәк биргән. Р. Фәхретдинов төзегән дәреслектә («Татар халкы һәм Татарстан тарихы») бу хакта материал җитәрлек. Әмма бүгенге өлкән буыннар ул дәреслектән файдаланмый. Моны яхшы белгәнлектән, Равил халыкның милли үзаңын үстерүнең башка кайбер чараларын шактый актив файдалана — газит-журнал битләрендә даими чыгышлар ясарга өлгерә. Менә шуларның бер үрнәге: «Фаҗигале тарихның кайбер серләре» («Ватаным Татарстан», 1994 ел, 15 октябрь саны) мәкаләсендә автор, тарихи фактларга таянып, соңгы дәүләтебезнең һәлакәткә очрау сәбәпләрен һәм моның нәрсәләргә китерүен гади тел белән ача. Мондый мисалларны шактый китерергә мөмкин. Радио-телевидениедән ясаган чыгышларын да өстәргә була.

Равил Фәхретдинов эшчәнлеге хакында сөйләгәндә, тагын бер якны онытмаска кирәк. Бу — аның татар милли хәрәкәтенә актив катнашуы. Бу ничек кенә сәер тоелмасын, кайберәүләр үзләренең милли хәрәкәткә катнашмауларын, митингларга чыкмауларын «Тукай үрнәге» белән акламакчы булалар. Әмма, беренчедән, Тукай заманы — бөтенләй башка, ул чакта бүгенге мөмкинлекләр юк иде. Икенчедән, шагыйрь үзенең иҗаты белән татар халкын саклап калу өчен бик күп көч куйды. Гади генә шигырьләре дә туган якка, халыкка мәхәббәт хисләре белән

сугарылган иде. Дөресрәге, бөтен иҗаты татар халкына багышланган. Шунлыктан Тукайга сылтау — урынсыз!

1989 елда беренче мәртәбә Хәтер көне оештырылды. Аңа нибары 200 ләп кенә кеше катнашты. Чөнки халык бик нык өркетелгән, куркытылган иде. Бу көнне оештыручыларның берсе Равил Фәхретдинов булды. 1990 елда «Мирас» региональ үзәге төзелде. Аның бурычы — халкыбызның тарихи мирасын барлауны көчәйтү, юлга салу иде. Бу үзәк янында берничә комиссия корылды. Мәдәни һәйкәлләрне, истәлекләрне саклау комиссиясенә җитәкчелек итү мөхтәрәм галимебез Равил Фәхретдиновка йөкләнде. Үзенә күрә гади генә факт, әмма шулай да сорау туа: ни өчен бу комиссияне башка тарихчылар түгел, ә Фәхретдинов җитәкләгән? Чөнки ул үз милләтен ярата, аның киләчәгенә ышана. Әлеге комиссия Сөембикә манарасына ай кую, Бакый Урманчега һәйкәл салу, аның музеен ачу, 1552 елның октябрендә Казанны, Ватаныбызны яклап һәлак булучыларга һәйкәл торгызуны тәкъдим итте. Дөрес, мондый идеяләр элек тә кайберәүләр аңында яралгы хәлендә яшиләр иде. Әмма бу мәсьәләләрне рәсми рәвештә, ачыктан ачык әлеге комиссия генә куя алды. Эш шуңа кадәр барып җитә ки, җаен табып, комиссия җитәкчесе президент М. Ш. Шәймиевтә була, президент аның идеяләрен хуплый, болар өлгергән мәсьәләләр ди, ярдәм итәчәген әйтә. Әмма әлегә һәммәсе дә искечә калып килә...

Шәһәр топонимика комиссиясе төзелгәч, аңа әгъза итеп Р. Фәхретдиновны да тәгаенлиләр. Галим шәһәрдәге урамнарның яртысына татар исемнәре бирүне яклап чыга, бу һәрьяклап гадел эш булыр иде ди. Халкыбызга ят, яманаты чыккан исемнәрне татар халкының күренекле затлары исеменә алмаштыру, теләк булганда, әллә нинди кыенлык тудырмас иде. Әмма әлегә бу теләк нигәдер тормышка ашмый. Төрле сәбәпләр «табыла», вакыт үтә тора.

Алтын Урда дәүләте хакында югарыда шактый сүз булды. Р. Фәхретдиновның тарих дәресләкләрендә бу дәүләткә шактый зур урын бирелгән. Әмма гасырлар буена, бигрәк тә совет тоталитар системасы вакытында бу дәүләтнең чын тарихы пычратылып, бозып күрсәтелде. Алтын Урда дәүләтенең төзелү елы — 1243, таркалу вакыты — 1430-1440 еллар. 200 елга сузылган бай тарих. Бөеклеге дә, фаҗигаләре дә җитәрлек. Бер төркем галимнәр, Р. Фәхетдинов тырышлыгы белән, 1993 елның 9—10 августында Алтын Урда төзелүгә 750 ел тулуга багышланган Халыкара фәнни конференция узды. Аны рәсми рәвештә Казанда Татарстан Фәннәр академиясе, академиянең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият тарих институты, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты уздырды. Ике көн буена пленар җыйналышларда, секция утырышларында бик күп илләрнең галимнәре чыгыш ясады. Алар Алтын Урда дәүләтенең тарихына һәм мәдәниятенә багышланган бик күп мәгълүматлар игълан иттеләр. Беркем дә Алтын Урданың татар дәүләт икәнлегенә шик белдермәде. Пленар утырышта Р. Фәхретдинов «Алтын Урда һәм аның Евразия цивилизациясендә тоткан урыны» дигән бик мөһим темага доклад ясады. Аның секция утырышындагы чыгышы «Борынгы төркиләр һәм Алтын Урда»га багышланды. Конференция зур уңыш белән узды. Монда Р. Фәхретдиновның көче куелуын кунаклар да билгеләп үттеләр.

Еллар ага да ага. Гомер дигән серле йомгак сүтелүдән туктамый. Киң карашлы белем иясе, халык яраткан, үз иткән галимебез Равил Габдрахман улы Фәхретдиновка шушы көннәрдә 60 яшь тулды. Гомер бәйрәмен ул эшчәнлегенең бәрәкәтле җимешләре белән каршылый. Равил әфәнде шәхси тормышында да бик бәхетле. Җәмәгате Әлфия белән алар бер уй-теләктә яшиләр. Олы уллары Раил әле генә тарих фәннәре кандидатлыгына диссертация яклады. Кече уллары Камил — табиб.

Без, мөхтәрәм галимне шактый якыннан белүчеләр, аңа сәламәтлек, озын гомер, яңа иҗат уңышлары телибез. Бу теләкләргә бөтен халкыбыз кушылыр, дип уйлыйбыз.

**Мәхмүт ӘХМӘТҖАНОВ**

## Индус Сирматовка 60 яшь



Берәүләр әдәбиятка яшьтән үк бик тиз атылып керә, икенчеләр исә ашыкмыйча, сабыр гына үз сукмагын салырга тырыша. Индус Сирматов — икенчеләр җөмләсеннән. Студент елларында ук шигырьләр һәм хикәяләр яза, аларның байтагы көндәлек матбугат битләрендә дөнья күрә, коллектив җыентыкларда басылып чыга. Әмма әдәбиятта Индус Сирматов исеме үзе ир уртасы булып өлгергәндә генә ешрак күренгәли башлады.

Ул 1937 елның 11 мартында Татарстанның Актаныш районы Чиялек авылында туган. Байсар урта мәктәбеннән соң 1959 елда Алабуга педагогия институтын тәмамлый. 1959—63 елларда Апас район газетасында, аннары район комсомол оешмасының җитәкчесе булып эшли. 1963 елдан бирле Татарстан дәүләт телевидениесендә: яшьләр өчен тапшырулар, әдәби-драматик тапшырулар редакцияләрендә өлкән мөхәррир вазыйфаларын башкара. Бүгенге көндә ул — әдәби-нәфис тапшырулар редакциясенең баш мөхәррире.

Балалар өчен язылган «Ләйсәннең бер җәе» дигән повесте 70 нче еллар башында «Инешләр Иделгә кушыла» җыентыгында дөнья күрә. Дөньяны танып белергә тырышу, тирә-ягындагы кешеләр белән аңлашу эзләү, батырлыкка омтылу,— нәниләргә, яшүсмерләргә хас күркәм сыйфатлар. «Офыкның аръягына» дип исемләнгән повестенда автор балалар психологиясендәге шушы сыйфатларны үзенчәлекле итеп чагылдырды.

1995 елда «Казан утлары» журналында басылган «Керәшен кызы» дигән повестенда И. Сирматов керәшеннәр тормышын тәфсилләп сурәтли белде, аларның гореф-гадәтләрен һәм рухи дөньясын сәнгать чаралары ярдәмендә киң катлам укучыларга җиткерде.

Кешенең күңел халәтен мифик образлар аша сурәтләү әдәбиятта элек-электән яшәп килә. «Ак бишек» исемле повесте белән И. Сирматов та шушы өлкәдә үзеннән күпмедер өлеш кертте. Кыскасы, авторның дистәдән артык башка повесть һәм хикәяләре дә тормышыбыздагы хәлләрне, кеше холкындагы үзенчәлекле сыйфатларны күрсәтеп бирү ягыннан игътибарга лаек.

Бүгенге көнебездә телевидение драматургиясе — чагыштырмача яңарак юнәлеш. И. Сирматов сәнгатебезнең бу тармагын үстерүдә актив эшләүче, аны әйдәп баручыларның берсе. Татарстан телевидениесендә озак еллар эшләү дәвамында ул «Мырау батыр» (Нәкый Исәнбәт әсәре буенча), «Онытылмас еллар» (Ибраһим Гази әсәре), «Язгы аҗаган» (Мәхмүт Хәсәнов әсәре) һ. б. күп кенә спектакль һәм фильмнарны экранга, тамашачылар хөкеменә тәкъдим итте.

Ул — Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

# Тәлгат Нәҗмиев

## Юбилей мөнәсәбәте илә...

Районыбызда СССРның халык артисты Шәүкәт ага Биктимеров иҗатын зурлап билгеләп үткән көннәр иде. Якташыбыз белән бергә театрның баш режиссеры Марсель Сәлимҗанов җитәкчелегендә бер төркем артистлар да килде. Алар арасында Равил Шәрәфи, Ирек Баһманов, Ринат Тажетдинов, Нәҗибә Ихсанова, Рәсим Сәләхов, Әсгать Хисмәтов кебек танылган шәхесләр байтак иде. Менә йомгаклау кичәсе булачак тамаша залына алып кердек кунакларны. «Сәхнәдә — ярты гасыр» дип зур, матур итеп язылган иде затлы пәрдә өстенә. Шуннан Равил Шәрәфи күзен чекерәйтеп карап-карап торды да: «Булып бетмәгән бу», — дип әйтеп куймасынмы.

— Нәрсәсе булмаган? — диеште дуслары.

— «Ярты» дигән сүз өстенә шешә сурәте ясап куярга да кирәк булгандыр, ахрысы...

## Сиңа шулай тоела ул

Бу истәлекле очрашулар ахырына якынлашканда берсеннән-берсе матур тост әйтешүләр китте. Мактап та күрсәтте инде Шәүкәт аганы Равил Шәрәфи. Әллә нинди көчле дәлилләр, чагыштырулар китерде ул. Шуннан Ирек абый Баһмановның түземлеге бетте:

— И күп тә беләсең инде син, Шәрәфи, — дип куйды.

Тегесе бер дә аптырап калмады:

— Алай түгел. Син күп нәрсәләрне белмәгәнгә генә шулай тоела ул, дускаем, — диде.

## Нинди хатын?

Зур дәрәҗәле ике кеше сөйләшәләр икән.

— Казаннан Сабага Фәлән Фәләнеч кайткан булган. «Союзпечать»тән Анна Ахматованы алып киткән... — ди икән берсе.

Үзе зур урында эшләсә дә, икенчесе әдәбият өлкәсендә сай йөзә икән, шундый китапка подписка барын да белмәгән.

— Анысы нинди бозык хатын тагын? — дип сораган ул.

# АВТОРЛАР ИГЪТИБАРЫНА!

## Салым инспекциясе искәртә:

**1996 елда алган керемнәр турында салым органнарына декларация бирер вакыт житте. Әлеге декларацияләрне исәп-хисап елына төп хезмәт урыны булган һәм шул чорда төп хезмәтеннән тыш керем алган, шулай ук төп хезмәт урыны булмыйча, башка чыганаклардан керемнәр алган физик шәхесләр бирә. Декларация салым органнарына, әгәр 1996 елда төрле чыганаклардан алынган (төп хезмәт урынын да исәпкә алып) керем 12 миллион сумнан арткан очракта гына тапшырыла.**

Әгәр физик шәхесләр ел дәвамында керемне (теләсә нинди күләмдә) бары тик хезмәт урыннарыннан гына алган һәм аларга башка керемнәр кермәгән икән, ул вакытта үз керемнәре турындагы декларацияне салым инспекциясенә тапшыру мәжбүри түгел.

Декларацияләрне төгәл тутыру максатында алынган керемнәрне үзлегеңнән ел дәвамында теркәп бару урынлы. Мәсәлән, куен дәфтәреңә керемнең каян, күпме күләмдә алынганын һәм шул керемнән күпме салым тотып калынганлыгын күрсәтәсең.

Керем турындагы декларацияләрне тутыру буенча тулырак мәгълүматларны яшәү урыннарындагы салым инспекцияләреннән алырга мөмкин. Декларация кәгазе (бланк) бушлай бирелә.

Салым түләүче исәп-хисапны түбәндәге таблицадан файдаланып үзе дә башкарырга мөмкин.

| Ел дәвамында алынган барлык керем | Салым күләме |
|---|---|
| **12000000 сумга кадәр** | **12 процент** |
| **12000001 сумнан 24000000 сумга** | **1440000 сум + 12000000 сумнан тыш кергән акчаның 20 проценты.** |
| **24000001 сумнан 36000000 сумга кадәр** | **3840000 сум + 24000000 сумнан тыш кергән акчаның 25 проценты.** |
| **36000001 сумнан 48000000 сумга кадәр** | **6840000 сум + 36000000 сумнан тыш кергән акчаның 30 проценты.** |
| **48000001 сумнан күбрәк** | **10440000 сум + 48000000 сумнан тыш кергән акчаның 35 проценты.** |

Гражданнар 1996 елда алган керемнәре турындагы декларацияләрен 1997 елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча салым инспекциясенә тапшырырга тиешләр. Әлеге сроктан узган физик шәхесләрне салым инспекциясе 2—5 айлык минималь хезмәт күләмендә штрафка тартырга мәжбүр булачак.

**Татарстан Республикасы**
**Дәүләт салым инспекциясе.**

## ПРЕЗИДЕНТКА — АЛТЫН МЕДАЛЬ

Халыкара эшчәнлектә күркәм уңышларга ирешүе һәм Венгрия—Татарстан арасында хезмәттәшлекне үстерүдә зур өлеш керткәне өчен, Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев Венгрия Республикасы Президентының Истәлек алтын медале белән бүләкләнде.

## ТАТАРСТАН ДЕЛЕГАЦИЯСЕ — ЧЕЧНЯДА

12 февральдә Грозный каласында Ичкерия-Чечен Республикасы Президенты итеп Аслан Масхадовны тәкъдим итү тантанасында Татарстан Республикасы делегациясе дә катнашты. Делегация житәкчесе — ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, шагыйрь Ренат Харисовны һәм аның юлдашы — Бөтентатар конгрессы башкарма комитеты рәисе, академик Индус Таһировны бирedә бик җылы каршылаганнар. Безнекеләр Чечен Республикасы Президенты А. Масхадовка Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиевнең махсус хатын тапшырганнар (Җөмһүриятебез Илбашы аны үзенә җайлы вакытта Казанга килергә чакыра). Чакыруны А. Масхадов зур рәхмәт әйтеп кабул иткән.

## ТАРИХ ИНСТИТУТЫН ТӘГЪДИРЛӘҮ

17 февральдә Татарстан Фәннәр академиясенең Тарих институтын тәгъдир итү тантанасы булды. Аны ТР Фәннәр академиясе президенты М. Хәсәнов ачты. Тантанада Җөмһүриятебез Илбашы М. Шәймиев катнашты һәм чыгыш ясады. Ул әлеге институтның дәүләтебез елъязмасын язуда зур роль уйнаячагына, татар халкының тарихын яңа сәхифәләр белән баетачагына ышаныч белдерде.

Президент М. Шәймиев институт директоры Р. Хәкимовны 50 яшьлек юбилее белән котлады, аңа һәм институт хезмәткәрләренә нык сәламәтлек, яңа уңышлар теләде.

Тантанада шулай ук Татарстан Премьер-министры урынбасары И. Хәйруллин, ТР Мәгариф министры В. Гайфуллин катнашты.

*ТАТАРСТАН*
*ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНДӘ*

## ИДАРӘ УТЫРЫШЫ

ТР Язучылары берлеге идарәсенең гыйнвар азагында булган чираттагы утырышында Чаллы төбәгендәге әдәби мохитнең бүгенге хәле, проблемалары турында бүлек житәкчесе Рахмай Хисмәтуллинның чыгышы тыңланды. Идарә әгъзалары бүлек эшчәнлегенә нигездә, уңай бәя биреп, киләчәктә бу өлкәдә эшне тагын да яхшырту буенча файдалы фикерләр әйттеләр.

Идарә утырышында, шулай ук, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге бүләгенә кандидатлар күрсәтү булды. Быел бу бүләккә шагыйрь Ренат Харисның «Хисемнең исеме» дигән яңа китабы күрсәтелде.

«Казан утлары» журналының баш мөхәррире, шагыйрь Равил Фәйзуллинның «Лунные тополя» исемле китабын идарә әгъзалары бертавыштан Россиянең А. Пушкин исемендәге Дәүләт бүләгенә тәкъдим иттеләр.

Утырышта катнашучылар яшь иҗатчыларның 5—6 март көннәрендә Казанда узачак конференциясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча да фикер алыштылар.

## ӘДӘБИ ЕЛ ЙОМГАКЛАРЫ

14 февральдә Татарстан Язучыларының Г. Тукай исемендәге клубында әдәби ел йомгакларына багышланган җыен булды. ТР Язучылары берлеге идарәсе житәкчесе Р. Мөхәммәдиев, Әдәбият фонды директоры Д. Салихов 1996 елда башкарылган эшләр турында сөйләделәр, хәл ителәсе мөһим мәсьәләләргә тукталдылар. Аннары балалар әдәбияты, поэзия, проза буенча Г. Гыйльманов, Л. Шагыйрьҗан, Ф. Галимуллин чыгышлары тыңланды. Рус телендә язучыларның үткән елгы иҗади эшләре белән В. Корчагин таныштырды. Жанрлар буенча фикер алышуларда Татарстан китап нәшрияты директоры Х. Әшрәфҗанов, язучылардан Г. Ахунов, Р. Мингалим, Р. Рахман, М. Әгъләмов һ. б. катнаштылар.

## М. ХУҖИН — БҮЛӘК ИЯСЕ

Татарстан Язучылары берлеге идарәсе үткән ел әдипләр арасында, «Елның иң оста хикәячесе» дигән исемен яулау өчен, Татарстанның халык язучысы Фатих Хөсни премиясен булдырган иде. Утызга якын кандидат арасыннан әлеге бүләккә беренче булып олуг әдипнең якташы, язучы Мәгъсүм Хуҗин лаек булды. Аңа бу бүләк авторның «Идел» журналында басылган «Пшыяцулька» («Дус кыз») исемле хикәясе өчен бирелде.

## КАЛӘМДӘШЛӘРЕБЕЗ САФЫНА

Җөмһүриятебез язучылары сафына талантлы яшьләр даими килеп тора. Яшь авторларны Татарстан берлегенә кабул итү коллегиясе (рәисе — Татарстанның халык шагыйре Шәүкәт Галиев) соңгы вакытта та-

гын берничә иҗатчының әсәрләрен тикшереп, берлекнең идарә утырышына тәгъдим итте. Нәтиҗәдә, Рәшит Ягъфәров, Дания Гайнетдинова, Ольга Левадная, күпчелек тавыш белән, ТР Язучылары берлегенә әгъза итеп кабул ителделәр.

### ИҖАТ ОСТАХАНӘЛӘРЕНДӘ

27 февральдә «Казан утлары» журналы редакциясендә «Поэзия», «Проза» һәм «Публицистика» остаханәләренең берләштерелгән күчмә утырышы үткәрелде. Анда «Казан утлары» журналының даими авторы — шагыйрь-прозаик, әдәби тәнкыйтьче, публицист-эссеист Рафаэль Сибатның (Хуҗинның) күпкырлы иҗади эшчәнлеге турында эшлекле-җитди сөйләшү булды. Фикер алышуларда Татарстанның халык язучы Гариф Ахунов, Аяз Гыйләҗев, Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеев, ТР Язучыларының Әдәбият фонды идарәсе рәисе, шагыйрь һәм прозаик Әхсән Баянов, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире, шагыйрь һәм публицист Равил Фәйзуллин, ТР Язучылары берлеге идарәсе рәисе урынбасары — шагыйрь, прозаик, драматург Әхмәт Гадел, Фатих Хөсни исемендәге премиянең беренче лауреаты, прозаик Мәгъсүм Хуҗин, остаз вә сабакташларыннан — шагыйрьләр Рәдиф Гаташ, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләм, Нәҗибә Сафина, Наис Гамбәр, Шаһинур Мостафин, әдәби тәнкыйтьче Мансур Вәли, Рифә Рахман h. б. чыгыш ясадылар.

Р. Сибатның күпкырлы иҗатына, нигездә, уңай бәя бирелде һәм ул бертавыштан Татарстан Язучылары берлегенә әгъза итеп тәгъдим ителде.

### Г. ӘПСӘЛӘМОВНЫ ИСКӘ АЛУ

13 февральдә Татарстан Язучыларының Г. Тукай исемендәге клубында танылган әдип — күп кенә роман-повестьлар авторы Габдрахман Әпсәләмовны искә алу кичәсе булды. Аны, кыскача кереш сүз белән, ТР Язучылары берлеге идарәсе рәисе Ринат Мөхәммәдиев ачып җибәрде. Кичәдә катнашучылардан Татарстанның халык язучысы Гариф Ахунов, Әхсән Баянов, Ләбибә Ихсанова, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллин, Лерон Хәмидуллин, мәрхүм әдипнең хәләл җефете Маһинур ханым h. б. үзләренең истәлекләре белән уртаклаштылар. Габдрахман аганың оныгы — яшь шагыйрә Альбина Әпсәләмова исә аңа багышланган шигырьләрен укыды. Кичәдә халкыбызның танылган җырчыларыннан Габдулла Рәхимкулов, Флера Сөләйманова, Лидия Әхмәтова, нәфис сүз остасы Зөһрә Шакирҗан да чыгышлар ясап, кичәнең эчтәлеген тагын да баеттылар.

### КИТАПЛАРЫБЫЗГА — ЮГАРЫ БӘЯ

Россия мәдәният фонды, Россия дәүләт балалар китапханәсе һәм Россия балалар китабы советы ел саен уздыра торган «Отчий дом» дип исемләнгән Бөтенроссия китап конкурсында безнең «Мәгариф» нәшрияты дипломант булды. Әлеге олуг бәя аңа «Минем беренче татар сүзлегем» дип аталган күркәм басма (авторлары — Фираз һәм Чулпан Харисовлар), «Татарстан һәм татар халкының тарихы» дигән мәктәп дәреслеге өчен бирелде.

### ЯЗУЧЫЛАР — КУКМАРАДА

20—22 февраль көннәрендә язучылардан — Казан дәүләт педагогия университетының әдәбият кафедрасы мөдире Фоат Галимуллин, «Казан утлары» журналының бүлек мөхәррире Шаһинур Мостафин һәм күрше Киров өлкәсендә татар телендә чыгып килүче «Дуслык» газетасының үз хәбәрчесе Рафаэль Сибат, Кукмара районында булып, «Мелита» акционерлык җәмгыятенең 9 нчы мех фабрикасында һәм сөт-май комбинатында эшләүчеләр, шулай ук «Игенче» һәм «Дуслык» күмәк хуҗалыкларының хезмәт алдынгылары беләночраштылар. Район күләмендә үткәрелгән «Безнең маяклар» слетында Кукмара районының якташлар җәмгыяте рәисе Ф. Галимуллин да чыгыш ясап, Татарстан язучыларының кукмаралыларга кайнар сәламен җиткерде, тормышларының һәр өлкәсендә дә янадан-яңа уңышлар, нык сәламәтлек теләде.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасы Президенты Указы белән, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Тарих институты директоры, Татарстан Президентының дәүләт киңәшчесе **Рафаэль Сибгат улы Хәкимовка** «Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** рәссам Бакый Урманченың «Уралтау эргәсендә» картинасыннан фотокүчермә.

Д. Йосыпов фотосурәте.

# ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАРЫБЫЗ!

Тиздән журналыбызның чыга башлавына (инкыйлаб чорыннан башланган дәвере күздә тотыла) 75 ел тула. Без — «Казан утлары» хезмәткәрләре бу истәлекле вакыйганы милли матбугатыбызның олы бәйрәме дип саныйбыз һәм татар җәмәгатьчелеге дә аны шулай кабул итәр дип өметләнәбез. Юбилей бәйрәме булгач, әлбәттә, күңелле мәшәкатьләр дә, истәлекле очрашулар, тантаналы кичәләр дә, котлаулар да булыр. Һичшиксез, бу редакция коллективына өстәмә мәшәкатьләр белән бергә, яңа җаваплылыклар өсти һәм, әлбәттә, горурлык хисләре дә уята. Бу юбилейны артык шауламыйча гына, әмма мәгънәле итеп уздырырга җыенабыз. Һәм аны оешкан төстә үткәрү планы тормышка да ашып килә.

Менә шушы уңайдан Сезнең белән, хөрмәтле укучыларыбыз, киңәшләшәсе һәм Сезгә үтенеч белән мөрәҗәгать итәсебез килә. Без үз редакциябездә шушы 75 ел эчендә чыккан журналның барлык нөсхәләрен туплап, махсус күргәзмә оештырырга җыенабыз. Кызганыч ки, төрле сәбәпләр аркасында элеккерәк елларда (гарәп имлясы, яңалиф белән чыккан, шулай ук, 40—50—60 елларда кириллица шрифтында басылган данәләр) чыккан бик күп саннар редакциядә сакланмаган. Моны без үзебезнең (бу очракта төрле елларда эшләгән хезмәткәрләрнең дә) зур кимчелеге дип саныйбыз. Ә, теләгәндә, һәр ялгышны төзәтергә була. Милли үзаңыбыз үскән, вакытлыча югалган Дәүләтчелегебезне торгызу чорында халкыбызның баш журналы булган «Казан утлары»ның гасыр буе диярлек сузылган рухи антологиясен җисми рәвештә тергезергә кирәк!

Сез бу мәсьәләдә олуг ярдәм күрсәтә аласыз! Ихтимал, Сездә, бигрәк тә өлкән буын милләттәшләребездә безгә кирәк журнал нөсхәләре исән-имин сакланганнардыр. Ә аларның күбесе, бәлки, шәхси тупланмаларда тузан җыеп, файдаланылмыйча ятадыр. Әгәр әлеге мирасны редакция архивында бергә туплый алсак, мәдәниятыбыз хәзинәсенә керткән уртак зур өлешебез булыр иде һәм ул байлыктан киләчәктә авторларыбыз да даими файдалана алырлар иде. Шуңа күрә, хөрмәтле укучыларыбыз, Сезгә мөрәҗәгать итәбез: мөмкин булса, безгә бик тә кирәк булган ул иске (истәлекле) журнал данәләрен редакциябезгә юлласагыз икән! Кемнәрнеңдер һәдия итәргә нияте йә мөмкинлеге булмаса, без бу изге гамәлне бәхилләтер өчен, журналыбызны бушка яздыру йәки бүтән формада хак түләү юларын үз өстебезгә алыр идек. Журналыбызның адресы басмабызның 2 нче битендә.

Хәерле язлар, изге теләкләр, саулык-иминлекләр телибез Сезгә.

*Журнал хезмәткәрләре исеменнән*

*баш мөхәррир* — Равил ФӘЙЗУЛЛИН.

Индекс 73210



Танылган язучы Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARЬ
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)